# казан утлары

7

ИЮЛЬ · 1974



ПУШКИН КАЗАН КРЕМЛЕНДӘ.

Л. Фәттах картинасыннан

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИЖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

7
ИЮЛЬ
1974

## Бу санда

М. ЮНЫС. Тозлы җил. Повесть . . . . . . . . 3
Х. ТУФАН. Багышлаулар дәфтәреннән. Шигырьләр . . . . . . . . . . 54
Ф. ШӘФИГУЛЛИН. Җидегән. Шигырьләр . . . . 63
С. ШӘРИПОВ. Сөлек. Хикәя . . . . . . . . 66
Р. ӘХМӘТҖАНОВ. Тормыш арбасы. Шигырьләр . . . . . . . . . . 84
Р. МИҢНУЛЛИН. Таулар. Шигырьләр . . . . . . 88
Ф. САФИН. Ташчы. Шигырьләр . . . . . . . . 92

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . . 94
Ә. МАЛИКОВ. Язмышлар . . . . . . . . . . 96
Ф. ХӘБИБУЛЛИН. Ышанып атлыйбыз . . . . . . 107

ДӨНЬЯ КЛАССИКЛАРЫННАН ТӘРҖЕМӘЛӘР

ПАБЛО НЕРУДА. Мин сиңа эндәшәм. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 114

СӘНГАТЬ

М. ГЛУХОВ. Эзләнүләр җимеше . . . . . . . . 116

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Ф. КАДЫЙРОВА. Сәнгатькә багышланган гомер . . 121
Г. КАЗАНСКИЙ. Тәрҗемән хәлем . . . . . . . 122

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Х. МИННЕГУЛОВ. Әхмәд Үргәнҗи һәм аның ике чордашы . . . . . . . . . . . . . . 130

ИСТӘЛЕКЛӘР, ОЧРАШУЛАР

Г. КАЙБИЦКАЯ. Ильяс Әүхәдиев — музыкант . . . 135
Ф. КАМАЛОВА. Халыкчан моңнар . . . . . . . 142

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ТӨРЛЕСЕННӘН

Е. ГОРТИНСКИЙ. Арктикага сәяхәт . . . . . . 151

ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Х. КУРБАТОВ. Ирекле шигырь. . . . . . . . 164

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

И. АХУНҖАНОВ. Шигърият юллары чатында. . . 175

КИТАП КҮЗӘТҮ

А. ЛИТВИН. Кызыллар һәм аклар. . . . . . . 186
Н. ГАМБӘРОВ. Гөрләвекләр яз алып килә. . . . 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. . . . . . . 190



*Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 12.*

Баш редактор: **Гариф Ахунов.**



Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәукәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова (җаваплы секретарь), Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**



Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 4/IV-1974 ел. Басарга кул куелды 27/V-1974 ел. ПФ 09126. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 87 000 экз. Заказ Ю-87. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 12.



© «Казан утлары». 1974 ел.

## Миргазиян Юныс

# ТОЗЛЫ ҖИЛ

повесть

### I



Лекциягә керер алдыннан гына профессорның университетка килмәгәнлеген әйттеләр. Бу — соңгы лекция иде. Без йөгерешеп аудиториягә кердек, конспектларыбызны тиз генә җыеп, ишеккә ташландык. Алдан чыгып барган студент, ачылып киткән ишектән сакланып, артка чигенде.

Аудиториягә безгә таныш булмаган өлкән яшьтәге бер кеше килеп керде:

— Унөченче аудитория шушымы?

— Әйе, шушы. Ләкин безгә профессор Федотов керергә тиеш иде бит.— Алдан чыгучы студент ят кешене әйләнеп узып, ишек тоткасына үрелде.

— Коллега Федотовны больницага салдылар. Көнбатыш Европа әдәбияты курсын ул терелгәнче мин укыячакмын,— дип, ишектән керүче әлеге кеше кафедрага таба юнәлде.

Без, моның ялгыш керүенә өметләнеп, тагын бер тын көтеп тордык та теләр-теләмәс кенә урыннарыбызга таралдык.

Ни өчендер яңа укытучының берәр гаебен табасы килә иде. Шунлыктанмы, беренче күрүдә үк аның әллә ничә кимчелеген күреп алдык. Бу профессорның костюмы алама ук булмаса да, студентларга лекция укыганда кия торган кием түгел иде. Аның башы чамасыз зур, муены нечкә. Тузгыган ак чәчләре дә парикмахерны сагынып саргая башлаган шикелле күренә иде.

Бөек генералиссимусның алтын рамга куелган зур, мәһабәт портреты астындагы кафедрага менеп баскач, карт галимнең ябык гәүдәсе тагын да кечерәеп калган шикелле булды.

Яңа профессор күзлеген сөрткән булып, бераз аудиториянең тынычланганын көтеп торды да үсмер егетләрчә ачык тавыш белән дулкынланып сөйләп китте:

— Галимнәрне, мөстәкыйль фикер йөртүчеләрне, хәтта дөньяга реаль караштагы барлык шәхесләрне инквизиторлар яккан учакта яндыру эле һаман дәвам итә. Комсыз, ач рыцарьлар Европаны талап-бөлдереп бетергәч, тәре походлары оештырып, шәрык җирен таптый башлыйлар.

Елдан-ел ачлык, үләт халыкны кырып тора. Хокуксызлык, изелү өстенә Европада инквизиция идарә итә. Чорның иң алдынгы, иң хәким вәкилләре аяусыз эзәрлекләнәләр. Куркып яшәү, әйтәсе сүзне әйтә алмыйча, икейөзле булып йөрү күпләрне, бик күпләрне акылдан шашуга дучар итә. Шуңа карамастан, киләчәк Ренессанс чорының идеясе, аның гуманистик карашы астыртын гына шытып чыга башлый. Бу фикерне чиркәү чаңнарын басарлык булып яңгыраган Франсуа Вийон шигырьләре аша исбат итеп була:

Ты жив, прохожий. Погляди на нас.
Тебя мы ждем не первую неделю.
Гляди — мы выставлены напоказ.
Нас было пятеро. Мы жить хотели.
И нас повесили. Мы почернели.
Мы жили как и ты. Нас больше нет...

Сулгарак борылып карадым. Валерия Трифонова көзгегә карап, гамьсез генә бер кыяфәттә, иреннең буявын яңартып утыра иде. Минем исә бугазыма кайнар бер төер килеп тыгылган иде. Тора-бара лекция сөйләүче профессор үзе дә дарга асылган кешеләр арасында кебек тоела башлады, мин үзем дә, дусларым да элмәкле бауга асылганбыз... Дарга асылынып торуы нинди газаплы... Күз күрми, тән тоймый. Бары тик бушлыктан килгән сүзләр генә йөрәккә үтеп, тәнне чымырдатып торалар.

— Кошмар! Ничек бирелеп тыңлый!.. Шушы профессор турында анекдот сөйлимме? — диде Валерия.

— Лекциядән соң сөйләрсең. Тыңлыйк әле, яме...

Карт галим сөйләвендә дәвам итте:

Дожди нас били, ветер тряс и тряс,
Нас солнце жгло, белели нас метели.
Летали вороны — у нас нет глаз.
Мы не посмотрим. Мы бы посмотрели...
Ты посмотри — от глаз остались щели...

Адәм балаларын дарга асучы палачларга булган нәфрәтем эчемә сыймыйча ташып чыга. Йодрыкларымны йомарладым, каты кысылудан тешләрем авырта башлады. Азатлыкны, хакыйкатьне буучы түрәләргә, халыкның аңын томалаучы руханиларга каршы көрәшкә ташланасым килде. Уң ягымда утырган үзбәк малае, дустым Өметгали, терсәге белән кабыргама төртте:

— Әллә берәр җирең авыртамы, Габдрахман?

— Юк, авыртмый.— Мин, йокыдан уянган кеше шикелле бер тын миңгерәүләнеп утырганнан соң, кире чынбарлыкка кайттым. Нәфрәт тудырган усал һәм ләззәтле бер әрнү тойгысы әкренләп сүрелде. Бераздан тәмам айныдым, бары тик йөрәк авыртуы гына басылып җитмәгән иде.

— Габдрахман, син мине ташлап китмә, яме,— Өметгали миңа һаман шикләнеп карый иде әле.

— Нигә?

— Икәүләп Казан вокзалына барасыбыз бар.

— Анда минем нәрсәм калган?

— Кечке поезд белән минем авылдашым килә. Шуны күңелле итеп бергәләп каршылыйсы иде.

— Лекция беткәч күз күрер. Комачаулама, яме.

Профессор, Франсуа Вийон турында сөйләп бетереп, яңадан Урта гасырдан Ренессанска күчкән чорны бәяләргә керешге. Ул чорда язылган әсәрләр искә алынды, шул әсәрләрне язган әдипләрнең тормыш юллары бәян ителде. Никадәр бирелеп тыңласам да, күңелемдә Вийон шигырьләре кузгаткан дулкынлану башкача кабатланмады.

Лекция бетү белән ашыгып коридорга чыктык. Кеше җыелганчы ашханәгә кереп, тизрәк чиратка басарга кирәк иде. Ләкин без соңга калган булып чыктык. Өченче каттан төшеп университетның ишегалдын үткән арада касса янына озын чират тезелеп өлгергән дә иде инде.

Стромынка ашханәсенә кайтып ашау нияте белән, Моховой урамына чыктык. Тышкы якта, капка баганасына сөялеп, дустым Баграт Мехтербашев университет карарга килгән туристлар белән сөйләшеп тора иде. Баграт алар белән ашык-пошык кына саубуллашты да безгә килеп кушылды:

— Мин сезне сәгатьтән артык эзләп йөрдем, кая олактыгыз?

— Белмим, кем олаккандыр бит. Без лекция тыңладык,— дидем мин.

— Федотовны больницага кергән диделәр бит. Лекцияне кем укыды?

— Ят профессор укыды,— диде Өметгали.

— Тыңларлык булдымы соң?

— Булу гынамы? — Мин Багратка лекция тыңлагандагы кичерешләремне сөйләп бирдем.

— Бу вакытка кадәр үзең кайларда йөрдең? — диде Өметгали Багратка.

— Якташларымны озаттым. Беләсез инде озатышуны. Аерылышыр алдыннан кыстап буфетка алып керделәр. Шунлыктан соңга калынды. Соңгы мәртәбә дәрестән китүем. Киләчәктә, теге дөньядан кайтып, бабам килсә дә, лекция калдырасым юк.

— Ашыкма әле, Баграт,— дидем мин.— Бүген кич Өметгалинең кунагын каршылыйсыбыз бар. Аңа да Мәскәүне күрсәтергә кирәк булыр. Шуны озатып җибәргәннән соң ант итәрсең.

— Каршы алып урнаштыра алсак, мин сезне шәһәр күрсәтергә чакырып мәшәкатьләмәс идем,— диде Өметгали.

Моңа кадәр Баграт безне шаярып сөйләшә дип уйлый иде, ахры. Чынлап сөйләшүебезгә төшенгәч, ул кызып ук китте:

— Мин монда укырга килгән кеше. Җитәр, гид булып йөрергә яллланмаган мин. Башка беркая барасы юк!

— Бүгенге кунакны гына каршылыйк инде. Син кеше хөрмәтләүнең рәтен беләсең,— диде Өметгали, ялынып.

— Авылдашың министр түгелдер әле. Аны делегация белән каршылау кирәкмени? Бүген ял итәм. Бер атна Мәскәү магазиннарын таптадым. Болай буласын белсәм, укырга Сахалинга киткән булыр идем.

— Юк, анда да котыла алмас идең. Синең якташларың Сахалинга да барып җитәләр. Укырга керер алдыннан мин анда өч ел яшәдем.

— Каршыларга үзем генә барсам, авылга кайткач, «Өметгалинең дусларын күрмәдем, әллә ул кеше белән аралашмый микән?» — дип сөйләп йөрүе бар. Безнең якта төмсә кешене яратмыйлар.

Дус-ишсез тора алмаучы Багратка шул җитте. Ул, бүтән кыстатып тормыйча, риза булды:

— Соңгы мәртәбә. Иртәгәдән мин башкалага килгән кешеләргә хезмәтче түгел. Синең кунагың хакына гына барам. Бетте, гид булып йөрүгә нокта куела.

Без Горький урамы аркылы чыгып, «Охотный ряд» станциясенә кердек.

— Туры вокзалга барабызмы? — диде Баграт.

— Торакка кереп, киенеп чыгасы иде. Безнең якта эш киеме белән кунак каршылау әдәпсезлек санала,— диде Өметгали.

— Син, валлаһи, чит илдән килгән делегация каршылаган шикелле кыланасың. Өйләнәсе кызыңның әтисе түгелдер бит? — дидем мин.

— Ул район күләмендә атаклы кеше. Аның өлкән малае мин укыган мәктәпнең директоры. Үзе мамык үстереп орден алды.

— Андый кешене фраксыз каршылап булмас шул,— диде Баграт.— Яхшылап хәзерләнеп килик. Бәлки оркестр да ялларбыз? Нинди машина ярата ул? Ролс-Ройс аңа ошармы? Кайткач, чәчәкләр дә әзерләп куярга кирәк булыр...

Данлыклы университет студентлары буларак, без купшы киенергә ярата идек. Чалбарым химчистартуга еш бирелүдән төсен тәмам югалткан булса да, офицерлар кия торган киң балаклы постау чалбар иде ул. Аягымдагы кед стипендиягә генә яшәүче студентлар арасында искиткеч модалы санала. Өстемдә Көнбатыш романнарының геройлары гына киеп йөри торган хаки күлмәк. Дөресен әйткәндә, ул күлмәк сару кайнатырлык арзанлы яшел ситсыдан тегелгән иде. Алмашка икенче күлмәгем булмагач, мин аны көн аралаш юам. Шунлыктан ул, уңып, Көнбатышта яшәүчеләргә гаҗәп күркәм күренә торган хакига охшый башлады. Кер сабыны гына күлмәкнең сыйфатын ул кадәр үзгәртә алмас иде. Бу үзгәрешкә, әлбәттә, минем әйбәт кием киеп йөрисе килүнең дә тәэсире тиде инде...

Киемнең иң арзаны да студент өстендә әллә нинди кыйммәтле булып күренә. Студент күңелендәге «без җәмгыятьнең акылы, без киләчәк кешеләре» дигән әчке горурлык тышка чыгып, аны күркәмләп тора, күрәсең. Шуңадырмы, студентның тузып беткән күлмәге дә ыспайланып йөрүченекеннән матуррак булып тоела.

Ул елларда тар балаклы чалбар модага керә генә башлаган иде әле. «Тар балакларны» дружина штабына алып кереп «эшкәртәләр» дә, чәчләрен алып, «стиляга» дигән хурлыклы мөһер сугып чыгаралар. Безнең Өметгалиебез стилягалыкның капма-каршы ягында иде. Башында матур түбәтәй булса, ул киемнең башкасына әллә ни әһәмият бирми иде.

Әфлисун үсә торган якта яшәүче халыкларның затлы кием яратулары турында сөйләп торасы юк. Багратның өстендә прилавкага чыкмыйча гына акчалы кеше кулына килеп керә торган затлы кием була. Егетнең йөз, буй-сын чибәрлеге артык киенеп йөрмәгәндә дә укуына шактый зыян китерә иде.

## 3

Стромынкага кайтып җиткәч, Баграт дустыбыздан сорады:

— Кунагыңны урнаштыру мәсьәләсен хәл иттеңме соң? Гостиница ягын алдан җайлап кую зыян итмәс иде.

— Үз бүлмәбезгә урнаштырып булмасмы әле,— диде Өметгали.

Бүлмәбездә буш урын юк иде.

— Маштаковның да өйдә чагы бит. Башка вакытта атна саен каядыр китеп олага иде. Сынаулар бетсә, өйдә утырмас иде инде,— дидем мин.

— Әсәрләнсә сынау дип тормый ул. Тур Хейердал Кавказга ял итәргә киләчәк дип әйтсәм, кунакка урын табылачак,— диде Баграт.

Безнең белән бер бүлмәдә яшәүче дүртенче студентның бер мәзәк гадәте бар иде. Ул бөлеп-җөтеп коллекция җыя. Башка коллекционерлар шикелле иске акча, марка, этикетка җыю белән вакланып тормыйча, Маштаков мәшһүр кешеләр кулланган әйберләр белән генә эш йөртә иде.

Кышкы сессия алдыннан Маштаков, сынауларын ташлап, Америка миллионеры Сайрус Итонны күрү өчен Ялтага барып кайтты. Әле күптән түгел генә Перу җырчысы, данлыклы Инна Сумак артыннан йөреп ике атна дәрес калдырган иде.

Гомумән мавыга торган кеше генә коллекционер була ала — анысы күптән билгеле. Маштаков кебек мавыгучан кешене моңарчы беркемнең дә очратканы юктыр әле.

Университетка кергәнче ул армиядә хезмәт иткән. Аның коллекционерлыгы да шул чакта башланып киткән булса кирәк. Сугыш бетәр алдыннан аны Ялта конференциясенә килгән хөкүмәт башлыкларын сакларга куйганнар. Шул чакта Маштаков Сталинны, Рузвельтны һәм Черчильне күргән. Аларны күрү белән генә канәгатьләнмичә, соңыннан кешегә күрсәтермен дип Черчильнең сигара төпчеген, Рузвельттан калган салфетканы кулга төшерә алган.

Кем белгән, әгәр Ялтага кинәшергә килгән әлеге өч шәхесне күрмәгән булса, бәлки Маштаковта коллекционерлык хиреслеге уянмаган да булыр иде. Пенсиягә чыкканчы армиядә хезмәт итәр иде, мавыгу дигән михнәтле юлда очрый торган күп газапларны кичермәс иде.

Газап татымаган кеше ләззәтнең дә тәмен белми диләр бит. Бәлки коллекционерлык хиреслеге белән авырып китмәсә, ул да чын ләззәтне татый алмаган булыр иде.

Ялта конференциясендә Маштаков Сталин кулланган әйберне эләктереп кала алмаган. Тарихи вакыйгага катнашкан кеше булуына башкаларны ансыз ышандыра алмам дип уйлаган, күрәсең. Сталин үлгәч, Маштаков ял сорап ала да, самолетка утырып, юлбашчыны соңгы юлга озатышу өчен Мәскәүгә оча. Шул көнге кысылышта аның җиде кабыргасын сындырганнар, үпкәсенә, бавырына зыян килгән. Шушы вакыйгадан соң ул Ерак Көнчыгыштагы частена ярты ел вакыт үткәч кенә кайта алган.

Маштаковны госпитальгә салып алты ай дәвалаганнар да, инвалидлык биреп, пенсиягә чыгарганнар.

Эзләнүчән кеше пенсиядә дә тынычланып ята алмый бит ул. Маштаков университетка укырга кергән. Ләкин аның бу мавыгуын уку авырлыгы да баса алмады.

Атаклы кешеләр артыннан йөри торгач, Маштаков үзе дә әкренләп мәшһүр кешегә әйләнеп бара иде инде. Безнең бүлмәгә аның коллекциясен карарга галимнәр, генераллар, коллекция җыючы язучылар килгәлиләр. Андый көннәрдә без дуртәүләп чыгып, саклау камерасыннан авыр тимер сейфны күтәреп алып керәбез. Дустыбыз як-ягына каранып ала да ашыкмыйча гына авыр тимер капкачны ача. Дулкынланудан мескеннең кулындагы пинцеты сизелер-сизелмәс кенә калтырана башлый. Экспонатлар сейфтан чыгып, бер-бер артлы өстәлгә җәйгән ак кәгазь өстенә тезелә. Маштаков куанып елмая: «Бу Хәбәш императоры Хайле Селассие Беренчедән калган ипи сыныгы. Бусы Җәвахарлал Неруның олтанынннан купкан балчык кисәге. Монысы маршал Жуковның күлмәк сәдәбе. Бу — кырык тугыз тәүлек Тын океанда йөзеп йөргән атаклы Җиһаншинның теш щеткасы. Бусы патриарх Сергийның астына җәеп яткан җәймә кисәге. Менә монысы...»

Коллекциясен кешеләр килеп караган көнне мескен Маштаков дулкынланудан таң атканчы йоклый алмый. Андый төннәрдә дустыбыз торып утыра да тынычлану өчен кишер кимерә башлый иде.

Маштаковның тагын бер мәзәк мавыгуы бар. Ул кайсы ашамлыкта күпме калорий, күпме витамин һәм никадәр файдалы матдә булуы белән дә кызыксына. Бервакыт «Здоровье» журналыннан дөньяда иң файдалы азык — кишер икәнлеген белгән. Шуннан соң ул гел кишер белән генә туклана башлады. Дустыбыз көне буе кишер чәйни. Лекция тыңлаганда да шытырдаган тавышка борылып карасаң, Маштаков мыштым гына кишер кимереп утырган була. Мескеннең ашказаны кишердәге каротинны үзләштереп бетерә алмас булды, күрәсең. Бер мәлне Маштаковның тәне кызгылт-сары төскә керә башлады. Шуннан соң врачлар аны кишер ашаудан тыйдылар.

Файдалы яшелчәсеннән мәхрүм калгач, дустыбыз «Работница» журналыннан карабодай ярмасының калорий ягыннан балык уылды-

гыннан да өстенрәк торганлыгын белгән. Соңгы вакытта ул карабодай боткасы ашый башлады.

Тулай торакка кайтып кергәч, Баграт, Маштаковның тумбочкасын ачып, аның ярма җебетә торган савытын карады:

— Егетләр, пыяла банка урынында юк. Безнең Маштаков каядыр киткән,— диде ул.

Маштаковның караваты минеке белән янәшә. Ул мендәре өстенә язу куеп калдырган иде.

«Габдрахман дус!

Син ышанычлы кеше. Бик үтенәм, деканны кисәтеп куй. Мин бик мөһим эш белән Кисловодскига киттем. Кайткач, белешмә тапшырырмын. Коллекция җыеп йөри дип гайбәт тарата күрмәсеннәр. Декан мине бик каты кисәткән иде. Кайткач сөйләрмен.

Дустың Маштаков».

— Мин аның китәчәген белдем,— диде Баграт.— Кичә бик мавыгып Тур Хейердал турында мәгълүмат җыеп йөргән иде. Атаклы сәяхәтче Фәннәр академиясе чакыруы буенча Советлар Союзына килгән. Маштаков һичшиксез шуны аулый.

— Маштаковыбыз яшәсен! Хәзер мин кунагымны туры монда алып кайтам,— диде Өметгали.

## 4

Бүген иртән университетка ашамыйча гына киткән идем. Дусларым өс алышырга керешкәч, мин тизрәк ашханәгә йөгердем. Монда да чират бик зур иде. Чиратның койрыгына басып бераз көтеп карагач, тамак ялгау фикереннән ваз кичеп, дусларым белән вокзалга юнәлдем.

«Сокольники»да трамвайдан төшеп, метро станциясенә кердек. Без Өметгали белән билет тикшерүче кыз янынннан узып эскалаторга бастык. Баграт та билетын тикшерүче кызга сузды. Кыз кинәт аның кулыннан эләктереп алды да, эскалаторга кертмичә, тотып калды:

— Эләктеңме, егеткәем?

Мин кызны шаярадыр дип уйлап:

— Эләктер, эләктер, чибәр кызлардан качып йөри торган гадәте бар аның,— дидем.

— Ни эшлисез? Мин бит... Мин билет белән керәм,— диде Баграт, кызарып.

Билет тикшерүче кыз ишек төбендә торган милиционерга дәште:

— Иптәш милиционер, килегез әле, хыянәтче тоттым!

Милиционер әче итеп сыбызгысын кычкыртты.

Өметгали билет тикшерүче кызны үгетләргә кереште. Мин Баграт янына чыгып, милиционердан тизрәк үткәреп җибәрүен үтендем.

— Ышанмагыз, иптәш милиционер. Алар беренче мәртәбә билетның контрольсез ягын ерттырып, бер билет белән ике тапкыр кереп йөриләр,— диде контролер кыз.

Стипендияне беркадәр янга калдыра торган байтак хәйләләр белсәк тә, адым саен башкаланың мәшһүр кибетләре күңелеңне вәсвәсәләп, атаклы театрлары сине әллә нинди тамашалары белән кызыктырып торганда ике стипендия арасындагы утыз тәүлек... ай-һай, ай-һай, бик озын күренә шул. Шунлыктан, акча алган көн ераклаша барган саен чыгым-тотымсыз яшәү серен табу хәйләсе дә арта бара иде. Кесә тәмам коргаксыган чакларда, яшермим, бер билет белән ике тапкыр метрога керү хәйләсен дә ара-тирә кулланганый идек. Гөнаһ эш эшләгәнбездер инде.

Яшьлек синең суфилыгың белән исәпләшеп тормый шул. Бу эш әхлак нормасына сыеп бетмәсә дә, шулай да законны яртылаш булса да боза иде. Бәлки безнең шул чактагы практикадан чыгып хәзерге студентларга самолет билетын ярты бәясенә сата башлаганнардыр?

Баграт исә, безнең шикелле, һәр тиенен җидегә бүлми, җитмеш төрле ихтыяҗның берсенә генә тотмый, шунлыктан бу эшкә аның катнашканы да булмады. Ул акчасын Кавказ халыкларына гына хас зур юмартлык белән туздыра белә иде. Ашханәгә кергәч, барыбыз өчен дә акчаны ул түли. Әҗәткә сорап торсаң, кайтарып биргәндә акчаны алмый. Соңгы өч тиенен юл чатында утырган инвалидка биреп, үзе трамвайга утырмыйча җәяү китә торган бер кеше иде Баграт.

Милиционер бик сүзчән кеше булып чыкты. Ул безне читкәрәк алып китте дә ашыкмыйча гына үгет-нәсихәт сөйләргә тотынды. Бу хәлгә мин бераз тынычлана төштем. Гадәттә күп сөйләшергә яратучылар кочләрен ләчтит сатуга тотып бетерәләр. Шунлыктан берәр чара күрергә аларның энергияләре калмый.

Милиционер алдашуның каян килеп чыкканлыгын, аның зарары, шул зарардан туа торган начарлыклар турында сөйләде. Вакытыбыз булмаса да, ни эшлисең, тыңларга мәҗбүр булдык.

— Коммунизмда алдашу бетәчәк,— диде милиционер.— Ул чакта кешенең аңы шул кадәр югары булачак ки, һәркем үз билетын үзе тикшерәчәк.

Ул безгә әнә шулай үгет биргән арада яныбызга хәтсез генә кеше җыелып өлгергән иде. Бер пенсионер милиционерның сүзеннән хата тапты:

— Коммунизмда транспортка утыру бушлай булачак. Димәк, билет тикшерүнең кирәге калмаячак,— диде ул.

— Ишеттегезме, гражданнар? Коммунизмга типичный потребительский караш. Без мондый настроениеләргә отпор бирергә тиешбез.

Бәхәс кызып киткәч, мин Багратка күз кыстым. Ул Өметгалинең кабыргасына төртте. Без ашыкмыйча гына контролерның яныннан үтеп, эскалаторга бастык та метрога төшеп киттек.

Аркаларына капчык аскан, чемодан тоткан кешеләр кыяр-кыймас кына метро каршысына килеп туктыйлар да мондагы ыгы-зыгыга бер тын карап торгач, ни булса — шул дигәндәй, тәвәккәлләп эчкә таба атлыйлар. Башкала темпы, мондагы кызулык-ашыгычлык тыныч, аулак шәһәрләрдә яшәргә өйрәнгән кешеләрне башта бераз өркетә. Көчле ташкын аларны эләктереп ала да җилтерәтеп аска алып төшеп китә. Беренче мәртәбә башкалага килүчеләр үзләре яшәгән җирдәге темпны сакларга тырышалар. Ташкынга каршы торып булмаслыкны аңлагач, барыбер язмыштан узмыш юк дигәндәй, кул селтәп, ургылып аккан тере ташкынга кушылалар.

Метро поезды халыкларны шәһәргә тарата. Метро ишеге көне-төне халык ташкынын йотып тора. Янәшәдәге икенче ишек эскалатордан күтәрелүчеләрне ургылдырып урамга бушата.

Үгет тыңлаган арада без каршылыйсы поезд Мәскәүгә килеп өлгергән иде инде. Мамык мәмләкәтеннән килгән таза, матур кешеләр шәһәргә тарала башлаганнар иде.

5

Перронда калган пассажирларны тикшереп бетергәч, вагон эчләрен дә караштырып чыктык. Газизхуҗа агайга охшаган кеше бер җирдә дә юк иде.

— Син аны таныйсыңмы соң? — диде Баграт Өметгалигә.

— Дөресен әйткәндә, бездә Газизхуҗа исемле кеше дистәдән артык. Шуларның кайсы килгәнлеген телеграммага әйтеп язмаганнар. Шулай да, күрсәм, таныр идем.

— Үзең, «район күләмендә танылган кеше ул» дип, башыбызны катырасың, үзең Мәскәүгә кайсы Газизхуҗа килгәнлеген дә белмисең икән,— диде Баграт, күңелсезләнеп.

Перронны карап үткәч, вокзал эчен дә тикшереп чыктык. Өметгалинең кунагы монда да күренмәде.

— Ул сине эзләп Стромынкага китмәгәндер бит? — дидем мин.

— Юк, китәргә тиеш түгел. Ул бит шәһәрдә йөри белми,— диде Өметгали.

Багратның Өметгалине юатасы килде:

— Кунагың телсез түгелдер әле, сораса, Стромынка юлын гына күрсәтерләр.

— Әгәр Газизхуҗаның өлкәне булса, ул бер авыз русча белми бит,— диде Өметгали чын-чыннан борчыла башлап.

— Тагын бер мәртәбә вокзал тирәсен карап чыгыйк та милициягә хәбәр итәрбез,— дидем мин.

Без тагын вокзал бинасын тикшереп чыктык һәм кайту нияте белән ундүртенче троллейбус тукталышына таба юнәлдек. Итек чистартучының будкасы янында аякларын бөкләп утырган бер карт үзбәк, безне күргәч, колачын җәеп, Өметгалигә ташланды:

— И-и-и, күз нурым! Син Сәфәргали малае бит. Ничек матурлангансың. Танырлык та түгел. Бик вакытлы килдең, йөрәк маем. Мин инде кире Бохарага кайтып китәргә җыенып утыра идем.

Газизхуҗа агай кире Бохарага кайтып киткән очракта, без күп нәрсәдән мәхрүм каласы идек. Өметгалинең әнисе газиз улына бер төенчек каклаган ит, бер капчык кипкән җимеш, бер тубал ләвәчә җибәргән иде. Газизхуҗа агай күчтәнәч итеп авиабомба зурлыгы бер бохар кавыны да алып килгән.

Капчыкларны, кәрзиннәрне, чемоданнарны өчкә бүлеп күтәрдек тә трамвайга киттек. Кавынны Газизхуҗа ага безгә бирмәде. Кавынның тәмле исенә чыдый алмыйча, тотып кимерә башламагайлары бу комсызлар дип курыкты булса кирәк. Ул аны үзе күтәрде.

Әкренләп трамвай эче кавын исе белән тулды. Пассажирлар тынгысызлана башладылар. Кайберләре борыннарын кыймылдатып иснәнәләр иде. Бер карчык, шулай иснәнә торгач, Газизхуҗа агайның кулындагы кавынны күреп алды:

— Моны кайда саталар?

Карчык соравы җавапсыз калды. Газизхуҗа агай, кавынны кысып кочаклаган килеш, шәрык ягында гына сакланып калган борынгы заман гамьсезлеге белән бер ноктага караган хәлдә, оеп утыра бирде.

— Бохарада саталар аны,— диде Өметгали.

— Кайда ул Бохара? Шәһәр читендәмени?

— Бохара Урта Азиядә, гражданка,— диде карчык янында басып торган бер хәрби кеше.

— Гафу итегез, мин аны Мәскәүнең яңа урамыдыр дип уйлаган идем. Хәзер бит урамнарга әллә нинди сәер исемнәр кушалар,— диде карчык, акланырга теләп.

Мәскәүдәге «пик» сәгате вакытындагы кысынкылыкка өйрәнгән кеше югалып калмый. Стромынкага якынлаша башлагач, без, терсәкләребез белән юл аралап, ничек кирәк алай ишек янына килдек.

Трамвай безнең тулай торак янына туктады. Без сикереп тротуарга төштек. Газизхуҗа ага кавын кочаклаган килеш, ишектән чыга алмыйча, трамвай белән китеп барды.

Өчәүләп дөбер-шатыр килеп Яуза күпере аша чыгып барган трамвай артыннан йөгерәбез.

— Ә-әй, туктатыгыз! Газизхуҗа агай, киләсе тукталышта төш, ишетәсеңме? — дип кычкырды Өметгали, Преображенский мәйданы янындагы үрдән күтәрелеп барган трамвайга карап. Аннары:

— Бетте баш. Кунакны харап иттек. Ул безне башкача таба алмаячак. Ни эшлибез? — диде ул хафага төшеп.

Армиядә хезмәт иткән кеше беркайчан югалып калмый. Мин командa биргәндәй бер тавыш белән боерык бирергә керештем:

— Баграт, такси алып, артыннан куа кит. Син, Өметгали, трамвайга утырып, тукталышларны тикшереп бар. Мин милицияне аякка бастырам. Тизрәк кыймылдагыз, ишетәсезме? Мин сезне телефон янында көтәрмен — ярты сәгать саен шалтыратып, хәлне миңа белдереп торыгыз.

Капчыкларны тулай торакка илтеп куйдым. Милиция бүлегенә кереп, кеше югалтуыбызны сөйләп бирдем. Тулай торакның ишеге янына, телефонга якынрак килеп вахтага бастым.

Минут саен телефон шалтырап тора. Мин кабаланып трубканы алам. Ләкин дусларымның тавышлары һаман ишетелми. Ярты сәгать үтте. Ике, өч сәгать көтеп утырдым. Һаман хәбәр-хәтер юк. Ни булды боларга? Әллә үзләре дә адаштылармы?

Мин борчыла башладым. Армиядә хезмәт итмәгән кешеләр белән эш йөртеп кара әле. Ябалак миләр, мондый операцияне башкарганда даими элемтә кирәклеген ничек инде аңламаска!

Телефон янынннан китмичә, тагын бер сәгать чамасы көттем дә дежур торучы хатынга әйтеп, урынымнан кузгалдым.

## 6

Ашханә ябылыр вакыт җитеп килә иде инде. Иртән бер валчык ризык капмыйча лекциягә киткән кеше, мин һаман ач йөрим. Хәлнең җитдилеген аңламаган кеше белән уртак эшкә тотынмавың артык. Югыйсә, дусларым шул кадәр гамьсез булгач, шушы вакытка кадәр хәбәр бирми торгач, минем постны ташлап китәргә дә хакым бар иде. Шуңа да карамастан, мин караңгы төшкәнче көтеп утырдым. Ашханә ябылырга унбиш минут кала дежурныйга әйттем дә тамак ялгарга киттем.

Касса алдында минем шикелле соңга калып килгән бер студент аш сайлап азаплана иде. Аның җилкәсе аша карап меню кәгазеннән арзанрак аш эзләргә керештем.

Студент ашыкмыйча гына менюга язылган ашамлыкларны тикшереп чыкты. Бераз уйлап торгач, ул, кылана төшеп, әйтте:

— Бер порция сөләйман балыгы, шашлык, пудинг, зәйтүн җимеше, бер шешә сыра.

— Уналты сум да утыз тиен,— диде кассир кыз, ашамлыкларның хакын исәпләп чыгаргач.

Студент кесәсеннән акча янчыгын алып актарына башлады. Кассир кыз бераз көтеп торды да миңа таба борылды:

— Әйтегез.

— Бер стакан катык, солы боткасы, чәй, дүрт телем ипи.

— Ике сум җитмеш тиен,— диде кассир кыз һәм теге студент ягына борылды.— Сез түләргә уйлыйсызмы?

— Акчамны таба алмыйм әле. Утыз сум тирәсе калган акчам булырга тиеш иде, кая куйганмындыр, белмим.— Студент акча янчыгын ачып касса алдына селекте. Кара пластмасса тәлинкәгә чылбыры өзелгән көмеш брелок, якуттан ясалган йөзек кашы, берничә метро билеты килеп төште, тәмәке валчыклары коелды. Студент үзе уңайсызланып

елмая иде.— Әллә төшереп калдырганмын инде, әллә берәр шпана кесәмә кереп чыккан.
— Чек суктырганчы карарга кирәк иде аны,— диде кассир кыз, ачулана башлап.— Хәзер нишләтим инде синең чегыңны? Кичә дә кассаны тапшырганда үз кесәмнән егерме сум өстәп салдым.
Студент елмаюдан туктады. Хәзер ул уңайсызланганлыгын яшерергә тырышмый иде инде.
— Мин беркая китәргә җыенмыйм. Уналты сум акча өчен вөҗданымны сатасым юк. Иртәгә иртән ашханә ачылу белән кертеп бирермен.
— Өстәп түләргә минем акчам юк,— диде кассир.— Ашханә мөдире кул куйсын да чекны «сүндерәм».
Бер тын икеләнеп торганнан соң мин соңгы егерме биш сумлыгымны кассир кызга суздым:
— Икебез өчен дә түлим.
— Рәхмәт,— дип, студент миңа таба борылды.— Джентельменлыгыгызны онытмам.
Студентның өстендә люкс ательеда гына тегелгән кыйммәтле костюм иде. Аягында затлы мокасин. Мондый киемне Мәскәү чиркәүләрен рәсемгә төшереп йөрүче туристларда гына күргәнем бар. Бу студент ашның да акчалы кешеләр ашый торганын гына сайлап алды. Гадәттә, уналты сум миңа ким дигәндә өч көн яшәргә җитә иде. Студентның үзен тәкәллефсез тотуына, мин алган ашларга кашын җимереп каравына хәтерем калды:
— Джентельмен булганлыктан түгел, стипендия алгач кайтарып бирү шарты белән түләдем,— дидем мин. Аерым утыру нияте белән алган ашамлыкларны иң ерак өстәлгә илтеп куйдым. Ул да алган ашларын подноска куйгач, беравык як-якка карап икеләнеп торды да минем янга килде:
— Бергә утыруга каршы килмисезме?
— Рәхим итегез.
Студент шешәнең бөкесен ачып, сыраны ике стаканга бүлеп салды.
— Аппетитны бик яхшы ача.
— Рәхмәт, минем аппетитымның ябылганы юк. Шул ачыклыкны тутыру өчен алган стипендия көчкә җитә,— дидем мин.
— Сез сыра яратмыйсызмыни? Сыра — плебейлар эчемлеге шул. Сез виноград шәрабе, коньяк эчә торгансыздыр? — Студент мин алган солы боткасына карап, көлемсерәп куйды.— Сез әллә джин, кальвадос, виски гына эчәсезме?
Миңа бурычлы булып китүенә аның ачуы килә иде булса кирәк. Студентның үз-үзен тотышында: «Алган ашамлыкларым өчен син түләдең. Мин сиңа бурычлы, шуңа карамастан, син минем белән ярыша алмыйсың. Ышанмасаң, чагыштырып кара: синең киемең нинди дә, минеке нинди, син нәрсә ашыйсың да, мин нәрсә ашыйм»,— дигән эчке бер масаю сизелә иде.
Бурычлы булып калмас өчен мин дә төрттереп җавап бирдем:
— Укырга кергәннән бирле мин андый эчемлекләрне өнәми башладым. Сыра — плебейлар эчемлеге. Әмма плебейлар сыраны сөләйман балыгы ашап эчмиләр. Плебей халкы юрганына карап аягын суза.
Студент мин әйткән сүзләрнең мәгънәсен аңлады, ләкин сер бирмәскә тырышты. Уңайсызлануын шаян сүз белән каплый алды.
— Фән кыясын кимерү өчен калорияле ризык ашау кирәк. Калория җитәрлек булмаган очракта дипломга өстәп дистрофия, гастрит ише нәрсәләрне дә алуың бар.
— Сез медик түгелсездер бит?
— Кызганычка каршы, түгел. Без сезнең белән бер фән йомыркасы өстендә утырабыз. Сез филфакта бит, әйеме? Мин сезне профессор Благовның спецсеминарында күргән идем.

— Безнең очрашканыбыз да бар икән. Мона кадәр филфакта уналты сумлык аш ашаучылар барлыгын белми идем әле.
Студентның ясалма тоны югалды. Ул кинәт җитдиләнеп китте.
— Безнең курста, дускаем, утыз сумлык аш ашаучылар да бар. Эш ашның бәясендә түгел. Авылдан килгән кайбер студентлар солы боткасын да атнасына бер мәртәбә генә алалар. Үзләре саклык кенәгәсенә акча җыялар.
— Юрганыңа карап аягыңны сузмасаң, гастриттан да куркынычрак авыру эләктерүең бар,— дидем мин, солы боткасы өчен студенттан үч алып.
Ул сөйләшүне башка темага борып җибәрде:
— Нинди хыял сине филфакка китереп кертте соң? — диде студент «син»гә күчеп.
— Кем белгән? Филфакка керү бәлки үзе хыял булгандыр?
— Юк инде, дус кеше, филфакта укучы егетләрнең күбесен каләм тибрәтү теләге кыбырсытып китергән.
— Сезнең үзегезне дә шул теләк кертмәгәндер бит?
Дөресен әйткәндә, андый хыял күңелемнең бер почмагында күптән пыскый иде. Ләкин бу турыда әлегә үземә дә ачыктан-ачык әйтергә курка идем.
— Типсәм тимер өзәрлек чагымда ирекле көннән синекдоха, амфибрахий шикелле сафсатаны ятлап йөрер идеммени? Дөресен әйткәндә, Герцен, Лермонтовлар укыган йортның исеме дә бераз кызыктырды инде. Хәзер аңладым, моннан тизрәк таюдан да яхшы юл юк.— Студентның бу фикерен инкарь итү өчен авызымны ачкан идем, ул миңа әйтергә ирек бирмичә сүзендә дәвам итте:— Без ятлаган кагыйдәләр күптән муртаеп беткән. Монда алган белем бары тик дәфтәр тикшерергә генә җитәчәк.
Шушы тармакта сүз куерту бу студентның яраткан эше иде булса кирәк. Ул тагын да җанланып китеп, сөйләвендә дәвам итте:
— Лев Толстой, әдиплек теләге уяна башлаганын сизгәч, Казан университетын ташлап киткән.
— Толстой дөрес эшләгән,— дидем мин.— Шулай да укуны ташлап китәр алдыннан мөмкинлегеңне тикшереп карау да зыян итмәс иде, бәлки синең талантың Толстойныкыннан кечерәктер?
Студент җавап бирмәде. Хәзер ул башка нәрсә турында уйлый иде.
— Син, дус кеше, тиз генә акча табу юлын белмисеңме?
— Беләм. Якшәмбе көн иртәнге алтыда безгә килсәң, кичен кесәңдә кырык-илле сум акчаң булачак. Якшәмбе көнне без Москва-товарныйга вагон бушатырга барабыз.
— Дус кеше, бу — үтелгән этап инде. Мин язма сүз сатып акча төшергәлим. Берәр калын журналда синең танышлыгың юктыр бит?
— Бар. «Атлантик мансли»да. Син инглизчә яза беләсеңме?
— Син юморист икәнсең. Оттың — бер дә нуль.
Студент тәлинкәсендәге соңгы ит кисәген чәнечкесенә эләктереп авызына капты да сыра йотты:
— Университет тормышына нокта куярга вакыт җитте. Поты бер тиенлек абстракт кагыйдәләрне тәти кызлар ятласын. Мин моннан китәм. Белемне тормышның үзеннән аласым килә минем.
— Ашаганың өчен түләргә тормыштан белем эзләү генә җитәме соң? Ашың хәләл булсын өчен бераз бил бөгү дә кирәк түгелме икән? — Студентның кәпрәюенә ачуым килә иде минем.
— Эштән курыкмыйм мин. Университетны ташлагач, мин диңгезгә чыгып китәм. Белсәң иде диңгез һавасын сулап яшәүнең рәхәтлеген! Эх, ул үзе бер бәхет бит! Битеңне иркәләп бриз җиле сыйпап киткәндә, сөйгәнеңнең суырып үбүе бер якта торсын. Ә тирә-яктагы күренешләрнең минут саен үзгәреп торуы? Покыдан уянган саен күз алдыңда —

яңа ил, яңа дөнья.— Студент калган сырасын эчеп бетереп, пудингын актаргалап карады да чәнечкесен өстәлгә ташлады.

Бу егеткә карата туган нәфрәтнең кинәт югала башлаганын сиздем. Моннан бер генә минут элек ул миңа калай әтәч, этисе җилкәсен кимерүче бер әрәмтамак булып күренә иде. Диңгез турында сөйли башлагач, ничектер кинәт үсеп, егетләнеп киткәндәй булды. Ләкин мин аның сүзләренә тулысынча ышанып бетә алмадым. Күңелдә ниндидер шик калды.

Җыештыручы хатын, борчырга теләмичә, безнең яныбыздан берничә мәртәбә ураштырып үткән иде инде. Күршем чәнечкесен ташлаганын күргәч, ул якынрак килде:

— Ашханә ябылды, егетләр. Хәзер идән юа башлыйм.

Без урыныбыздан кузгалып, коридорга чыктык.

— Син кайсы бүлмәдә торасың? — диде студент.

— Утыз икенчедә. Ә син?

— Мин квартирда торам. Минем исемем Феликс. Латинча — бәхетле дигән сүз. Дзержинскийга охшасын дип кушканнар.

— Габдрахман. Безнең авыл мулласының исеме шулай булган.

— Гафу итәсең, аңлап бетермәдем. Рахманин шикеллерәк яңгырый: Габ-рахман... Мин ашыгам. Борчылма, әҗәтемне акча керү белән түләрмен. Пока! — Шулай дигәч, Феликс ашыгып аскы катка төшеп китте.

## 7

Мин кергәндә, Газизхуҗа агай чәй эчәргә керешкән иде инде. Өстәлне минем ятак янына китереп куйганнар. Газизхуҗа ага аякларын Будда шикелле итеп бөкләп караватт өстенә менеп утырган. Ак парчалы кара түбәтәен арткарак шуыштырып кигән. Чапанын ачкан, күлмәк изүен ычкындырып җибәргән. Маңгаена тир бөртекләре бәреп чыккан. Шыбырдап ага башлагач сөртер өчен Өметгалинең сөлгесен кунакның җилкәсенә салып, хәзерләп куйганнар.

Кунакның йөзендә искиткеч күркәм канәгатьлек билгесе. Бу кешедәге табигый хозурлыкны бүлеп өләшсәң, бөтен Мәскәүне бәхетле итеп булыр иде. Аңа берни кирәкми. Аның җитмәс җире, мохтаҗлыгы юк. Яшәү рәхәтлеге белән ләззәтләнү Газизхуҗа аганың эченә сыймыйча ташып тышка чыккан. Аның канәгатьлеген күрү генә дә тормышның җитмәс җирләрен, кайгы-хәсрәтләреңне юып төшерерлек иде.

Чәй эчү ритуалын карарга күрше бүлмәләрдә яшәүче студентлар да җыелганнар. Алар, бу эксперимент ничек тәмамланыр икән дип көткәндәй, картның авызына карап, тынып калганнар.

Газизхуҗа агай касә төбендәге соңгы тамчы чәйне йотып җибәрүгә, Өметгали кабаланып яңаны агызды.

— Җитәр, Өметгали. Ясама, рәхмәт, хушландым.

— Эч инде тагын берне, Газизхуҗа әкә. Чәебез ошаса, эч.

— Монысын эчеп бетерәм дә башканы ясама. Сусавым басылды, хушландым. Бик әйбәт булды. Аллага шөкер, әйбәтләп каршыладыгыз. Туранбай алып китеп олактыргач, хөрмәтләп, артымнан эзләп йөгергәнсез.

— Унөченче чынаягын эчертә. Кунагын үтерә бит бу,— дип пышылдады күрше бүлмәдә яшәүче студент минем колагыма.

Чыннан да тамашачылар бераз тынычсызлана башлаганнар иде. Гадәт буенча ясаган чәйне эчми калдырырга ярамый иде. Газизхуҗа ага ярдәм сорагандай як-ягына каранып алды да, тагын да матуррак елмаеп, касәдән чәй чөмерергә кереште.

— Нигә аны интектерәсең? Ярылса нишләрсең? — дидем мин Өмет-

галинен колагына.— Кыстаган кешенең күңелен күреп, көчләп ашау җәзадан да авыр бит ул.

— Кыстамасаң, хөрмәт күрсәтмәде дип уйлавы бар. Бездә кунакны шулай кыстап сыйлыйлар,— диде Өметгали.

Бездә дә кунакны шулай кыстап сыйлау гадәте бар иде. Исемдә, кытлык елда, ашарга бер умачлык он юк чакта, Кандыз исемле авылда яшәүче ерак кардәшләребез каяндыр кайтышлый безгә чәй эчәргә керделәр. Әни күршеләргә кереп әҗәткә он алып чыкты. Кемнәндер үзенең кашимир яулыгына алмаштырып ит алып кайтты.

Казанда быкырдап ит кайный башлады. Өйдә бәйрәм алдыннан гына була торган тантана урнашты. Моңа кадәр сүнәр-сүнмәс кенә барган әңгәмә кинәт җанланып китте. Аш пешкәч, әни кунакларны табын янына чакырды. Аларның соңгы чиккә җитеп ашыйсы килүен әлкәннәр түгел, без дә сизеп алган идек инде. Ләкин ашъяулык янына утыру белән кунак апалар, «рәхмәт, ашар җиребез юк, әле яңа гына ашап чыккан идек» дип, кулларын алъяпкыч астына яшереп утыра башладылар. Әни аларны кыстарга тотынды. Аның кыставында борынгы заманнардан килгән бер гадәт — ашны зурлау, кешеләр арасындагы әйбәт мөнәсәбәтне ихтирамлау, кешелеклелекне олылау бар иде. Шул чакта мин кыстауны табын янында кулланыла торган, борынгыдан калган юмартлык билгесе, кешеләрнең бер-берсен ихтирамлау юласы икәнлегенә төшендем.

Ашап туйгач, дога кылдылар. Кунаклар китте. Алар киткәч, әҗәтебезне ничек түләрбез инде дип әнинең борчыла башлавын көткән идем. Ә ул, киресенчә, сөенеп бетә алмады:

— Иншалла, хур булмадык. Кунакларның күңелен күрә алдык. Сезне сыйларга да бер җай табылды. Күптән итле аш ашаганыгыз юк иде, бәбкәйләрем...

Төрки халыкларның кунакчыллык гадәтләренә ияреп борынгылардан коллективлык законы килгән. Хәтеремдә, картлар бергә утырып ашауны күмәк туклануга гына санамыйча, бер-береңне ихтирамлау, дуслашу ритуалы итебрәк карыйлар иде.

Газизхуҗа агай, чәен эчеп бетергәч, зур, мөһим эш башкарган кеше кыяфәтендә сөлге белән маңгай тирен сөртеп алды.

— И-и, туганкайларым. Бик сусаган идем. Юл буе чәйгә интегеп килдем. Вагонда кара чәй бирәләр. Без бит яшел чәй яратабыз. Монда да бик эчәсем килгән иде. Рәхмәт яусын, бәхетле булыгыз! — Шушы минутта дөньяда аннан да бәхетле, аннан да канәгать кеше бар идеме икән?

— Кавынны кайчан кисәбез соң? — дидем мин Өметгалигә.

— Кавынны без күптән кистек инде,— диде ул, аптырап.— Син ашамадыңмыни? Без бит синең өлешеңне калдырган идек. Егетләр, Габдрахманга калдырган кавынны кем ашады?

Бүлмәдә кавынның исе генә калган иде инде. Түзмәдем: «Крокодиллар, минем өлешне кем ашады?» — дип кычкырып җибәрдем.

Үзбәк картының чәй эчкәнен карап утыручы студентлар бохар кавынының исен сизеп кергәннәр икән. Кергәне берсе минем өлештән бармак башы кадәр генә кисеп алып кавын тәмен татый торгач, күчтәнәч юкка чыккан.

— Варварлар, вөҗданыгыз кайда сезнең?

— Әйттем бит мин сиңа яшереп куй дип. Шушы чүл бүреләре көтүенә нәрсә җитсен соң! — диде Баграт, мине кызганып.

Чит бүлмәләрдән җыелган студентлар әкренләп таралдылар. Тулай торак тынып калды. Без йокларга әзерләнә башладык.

Газизхуҗа агайның ятарга исәбе юк иде әле. Ул, Өметгалине каршысына утыртып, аңа Өчарык яңалыкларын сөйләргә тотынды.

Өметгали укып яткан арада авылда уннан артык бала туган икән. Өч карт, бер карчык бу дөньядан киткәннәр. Без фән кыясын кимереп яткан арада ярәшү-өйләнешү вазифасы Өметгалидән яшьрәк егетләргә күчкән.

Газизхуҗа аганың сүз тәртибе тирән мәгънәле табигый композициягә буйсына иде. Ул башта туу-үлү шикелле яшәү дәверендәге иң мөһим вакыйгаларга кагылды. Аннан соң өйләнешү, һөнәрле булу ише, кеше гомерендә тирән эз калдыра торган, онытылмас хатирәләрне санап чыкты. Шушындый әһәмиятле хәлләрне сөйләп тәмам иткәннән соң гына ул көн саен була торган гади вакыйгаларга күчеп китте.

Җиләк-җимеш, мамык уңышлары турындагы сүз дә артта калды. Әңгәмә Мәскәү тормышы һәм безнең укуыбызга күчте. Инде сөйләшүнең темасы һаман тарая, конкретлаша бара иде. Ниһаять, гәпләшү гел Өметгали тирәсендә генә әйләнә башлады. Газизхуҗа аганың гамьсез генә ләчтит сатып утыручыдан рәсми кешегә әйләнеп китүен без сизми дә калдык. Ниһаять, ул сөаль алучы булып ук китте:

— Син инде, Өметгали, башкаланың ниверситет намлы иң зур, иң данлыклы мәдрәсәсендә укыйсың, әйеме?

— Әйе, шунда укыйм, Газизхуҗа ага.

— Укуыңның кадерен белеп, ата-анаң, кардәш-ыруыңның үтенечләрен үтәп киләсеңме соң?

— Үтәп киләм.

Өметгалинең җавабы сөаль алучыны тулысынча канәгатьләндермәде булса кирәк, ул авылдашының өлгереше турында бездән дә сорашты.

— Мәскәүгә китәр алдыннан синең әткәң белән бик озак сөйләшеп утырдык. Әткәң әйтте: «Өметгалине тагын бер мәртәбә кисәт, хәлфәләренең сүзен тыңласын. Кешегә сүз ирештермәсен, ялган сөйләмәсен, итагатьле булсын»,— диде. Син, Өметгали, шушы бурычларыңны да гадел итеп үтәп киләсеңме?

— Бу җинаять ачарга килгән суд тикшерүчесе түгелдер бит? — диде Баграт минем колагыма.

Мондый рәсмилек безгә көлкерәк тоелса да, Өметгали тикшерүгә ихлас күңел белән карый иде. Ул кунакның соңгы соравына бик җитди итеп җавап бирде:

— Үтәп киләм, Газизхуҗа ага.

— Сине мәдрәсәгә озатканда Өчарык кешеләре әйткән әманәтне онытмагансыңдыр бит? Шул сүзләрне кабатлап чык әле, Өметгали энем.— Газизхуҗа, миндәренә ята төшеп, авылдашының җавабын көтеп тора башлады. Өметгали безгә карап бер тын тартынып торды да барыбер бу миңа бәйләнәчәк, тизрәк җавап биреп котылырга кирәк дигәндәй, санап китте:

— Һәр эшкә изге ният белән генә керешергә, харамга ягылмаска, хәмер эчмәскә, гөнаһ эш кыйлмаска...

Өметгалинең җавабы кунакны канәгатьләндерде булса кирәк. Газизхуҗа аганың йөзе яктырып китте. Ул яңадан үтә гамьсез мөлаем бер кешегә әйләнде:

— Өметгали, сиңа вә синең иптәшләреңә Өчарык җәмгыятенең фатихаларын тапшырам.— Газизхуҗа ага бик зур эш башкарган кеше кыяфәтендә караватына сузылып ятты да ике-өч минуттан борынын сызгыртып йоклап та китте.

Без йокы алдыннан һава суларга дип ишегалдына чыктык.

— Сез аны ничек таба алдыгыз? Аның тикшеренер өчен килгәнен белгән булсак, эзләп йөрмәгән булыр идек,— дидем мин, сирень куагы астындагы эскәмиягә барып утыргач.

— Ул икенче тукталышта ук төшкән дә каршы килүче трамвайга утырып кире вокзалга кайткан. Анда үзбәкчә белә торган татар милиционерын очратып, хәлен сөйләп биргән. Милиционер аны тулай торакка

ук китереп куйган. Без кайтканда ул кавынын кочаклап ишегалдында утыра иде,— диде Баграт.

— Мин бит кичкә кадәр дежурный янында аны саклап утырдым, ничек күрми калганмын икән? — дидем мин.

— Милиционер аны тулай торакка директор кабинеты аша алып кергән,— диде Өметгали.

Икенче көнне иртән Үзбәкстан посредствосыннан Өметгалинең кунагын алырга машина килгәч кенә Газизхуҗа аганы орден тапшыру өчен Верховный Совет Президиумы чакырганлыгын белдек.

## 8

Баграт шәһәр тормышын тәнкыйтьләп, авылда яшәүне мактый:

— Шәһәрдә бусаганы атлап чыгу белән кесәгә керергә кирәк. Кесәңә акча салып чыкмасаң, шәһәр сине кабул итми. Акча түләп трамвайга утырасың, трамвайдан төшкәч, метрога түлисең. Шәһәрнең магазиннары, кино-театрлары, музейлары — барысы да синең кесәңә карап торалар. Авылда айлар буе акчасыз яшәп була. Җимеш — бакчаңда, сөт — базда, икмәгең — келәтеңдә. Юк, егетләр, авылда яшәүгә бер ни җитми!

— Алай булгач, ник авылда яшәмисең? — дип сорый Өметгали. Баграт дәшми. Бу фәлсәфә Багратның акчасы беткәнлеген күрсәтә. Кесәсенә акча кергәч, бу фәлсәфәне онытачак ул.

Стипендия алган көнне Баграт, гадәттә, Горький урамын урап кайтырга ярата. Шушы кечкенә сәяхәткә Өметгалине дә, мине дә чакыра. Өметгали бармый, ул эшсез селкенеп йөрергә яратмый. Мин дә баш тартам, чөнки шәһәргә чыгу белән Багратның кеше сыйлыйсы, сыйланасы килә башлый. Үгетләп тә, тәнкыйтьләп тә безне күндерә алмагач, Баграт сүзен сүз итәр өчен бер үзе шәһәргә чыгып китә.

Багратның стипендияне ашаудан башкага тотмам дигән нәзере бар. Шуңа күрә ул беренче очраган универмагка карамыйча да уза. Икенчесе янынннан үткәндә дустыбыз күз кырые белән генә витринага карап китә. Дүртенче, бишенче магазиннар да Багратны туры юлдан яздыра алмый. Кызганычка каршы, адәм баласының ихтыяр көче корычтан коелмаган шул. Әгәр каһәр суккан уникенче кибет очрамаган булса! Шул уникенче вәсвәсә мескеннең акчасын харап итә дә куя.

Безнең заман кешесе әйберне кирәклектән генә алмый бит. Хатын-кызның күбесе, ирләрнең кайберләре эч пошуын басар өчен магазинга бара. Шул баруда үзенә җәфа булудан башка бер нәрсәгә ярамаган әйбер сатып алса, безнең заман кешесенең җаны тынычлана. Әгәр акылы бу әйберне алуга каршы килсә, аны нәфес котырта башлый: син башкалар кебек үк тырышасың, башкалар кебек акча табасың, үзеңнең башкалардан ким түгел икәнлегеңне күрсәтәсең килсә, акчаңны кызганма, ал бу әйберне, ал...— ди.

Баграт атна саен я хрусталь пульверизатор, яисә маймыл сурәте төшерелгән галстук, я булмаса алтын йөгертелгән җиз кием щеткасы күтәреп кайта. Бу әйбернең әллә ни кирәк түгеллеген, аяк астында гына аунап ятачагын Баграт белә. Шуңа карамастан, сатып алу чиренә каршы торырга аның көче җитми. Алган әйбернең зыяны бер-ике атнадан мәгълүм була. Хрусталь пульверизаторга түләнгән акча бүген ашалырга тиешле котлетныкы булган икән. Ни эшлисең, ач яшәп тә булмый. Каян булса да әҗәткә акча табарга туры килә.

Стипендиядән тыш Баграт ай саен әтисеннән акча ала иде. Әтисе җибәргән акчага өстәп аңа армиядә хезмәт итүче абыйсы да ике йөз сум салып тора. Мәскәүдә яшәгән апасы «театрга билет алырсың» дигән булып энесенә сиксән-туксан сумны барган саен тоттырып җи-

бәрә. Узган атнаны башкалага йомыш белән килгән кардәше «студент халкына калория кирәк», «Арагви»га барып цацеви, чахохбили аша дип, Багратның кесәсенә берничә кыштырдык кәгазь тыгып киткән иде. Шуңа карамастан, Баграт — студентлар арасында иң мохтаҗ, иң акчасыз кеше. Аның җыйган бурычларын түләр өчен киләсе ярты еллык стипендия дә җитмәячәк.

Кризис иң югары баскычына җиткәч, Баграт киносценарий язарга утыра. Бары тик шушы юл белән генә бурычлардан котылып булыр дип уйлый ул. Безнең Баграт төн йокламыйча Чарли Чаплин, Федерико Феллини, Юрий Нагибин, Довженко, Теннеси Уильямслар язган сценарийларны өйрәнеп чыга. Айлар буе башын күтәрмичә эшли. Ашаганы — студент ашханәсендә бушлай бирелә торган ипи һәм шикәрсез чәй. Сценарий язганда үзенең кыйммәтле киемнәрен шкафка бикләп, минем яшел күлмәгемне сорап алып кия. Хәзер безнең Баграт курстагы иң ярлы, иң тырыш студент.

Сценарий язылып бетә. Баграт бик озак кинорежиссер Калаташвили белән очрашырга тырышып йөри. Ниһаять, режиссер аны кабул итә. Сценариен режиссерга тапшырган көнне Баграт атаклы кешеләр арасында йомшак замша куртка киеп йөрү модага кергәнлеген белеп кайта. Берничә көннән аның өстендә поши тиресеннән тегелгән көрән куртка һәм җилкәсендә — тагын ярты еллык стипендиясен йотарлык бурыч. Бурычны үзенең киләчәген биреп алуы турында Баграт уйлый белми әле. Сценарий язылып бетү шатлыгыннан дусларын сыйлый.

Атаклы режиссер аның кулъязмасын кире кайтарганда әйткән: «Иптәш Мехтербашев, синең сценариең ярарлык түгел, әмма өметеңне өзмә, тырыш, эшлә, өйрән, син перспективалы егет»,— дигән. Перспективалы язмыш шулай авыр, шундый газаплы була шул...

Киләчәктә сине шундый зур перспектива һәм бөтен дөньяны сокландырырлык дан көтеп торсын, ә син һәр тиенеңне санап, кысылып яшә, имеш! Алай яшәргә Баграт обыватель түгел. Ул иҗат кешесе, артист...

Баграт киләчәкнең дан, бәхет, уңыш алып киләчәгенә чын күңелдән ышанучы оптимист иде.

## 9

Без укып яткан арада дөньяда күп нәрсә үзгәрде. Сугыш еллары бераз ераклашты. Тормышлар сизелерлек дәрәҗәдә әйбәтләнде. Без үзебез дә үзгәрми калмадык. Бары тик Өметгали генә һаман Өчарыктан килгәндәге килеш кала бирде. Ул башкаланың зур, катлаулы тормышы ургылып акканлыгын күрми дә, күрсә дә, аңа әһәмият бирми иде.

Өметгали йокысыннан елмаеп уяна. Күзен ачмыйча гына бер тын хозурланып яткач, әкрен генә тора да юынып керә. Шул арада инде аның хуш исле чәе кайнап чыккан була. Ул Өчарык җимешләре белән, озаклап, кәефен күреп чәй эчә. Конспектларын җыеп, портфеленә тутыра да һаман шулай елмаеп, салмак кына атлап университетка юнәлә.

Өметгали ашыга белми. Кая ашыгырга? Кабаланып яшәүнең ни кирәге бар? Киләчәк ул, ашыкмасаң да, үз вакытында килеп җитәчәк. Шушындый әйбәт, күңелле бүгенгене ташлап киләчәккә ашыгу арзанлы дуамаллык кына бит ул. Билгеле, киләчәктә Өметгалине дәрәҗәле урын, ихтирамлы эш көтә. Университетны бетергәч, ул туган Өчарыгына кайтып, балалар укыта башлар. Моңа кадәр аларның кышлагында Мәскәү хәтле Мәскәүдә укып кайткан мөгаллим юк иде әле. Өчарыкта гына түгел, аларның районында да андый укытучы бар микән? Сәфәргали малае районнан беренче булып башкаланың иң зур, иң атаклы

уку йортына барып керде һәм аны тәмамлагач, дәүләт гербы төшкән зәңгәр тышлы зур диплом алып, үзенең кышлагына кайтачак. Өметгалинең бу эше эти-әнисенә генә түгел, кардәш-ыруларына, кышлакка, хәтта бөтен районга дан өстәячәк. Университетны бетергәч, үз-үзенне илтифатлы тотып, күрсәткән ихтирамга лаеклы булырга тырышасы гына кала. Бусы киләчәктә. Уйлап карасаң, бүгенге көн дә киләчәктән ким түгел бит. Мәшһүр университетның студенты булу үзе генә дә ни тора. Өметгали — әйбәт студент. Иптәшләре аны ихтирам итә. Дөньялар имин, яшәү гаҗәп рәхәт. Ник Баграт шикелле киләчәк куаныч белән генә юанып яшәргә? Я булмаса Габдрахман шикелле туктаусыз үткән көннәрне сагынып офтанырга?

Имтиханда бишле алу Өметгалигә зур бәйрәм. Аның өчлесе башкаларның дүртлесеннән әйбәтрәк була. Ул өчлегә дә чын күңелдән шатлана белә. Ник шатланмаска: тырышып, көч түгеп укып алган хәләл өчле бит ул. Икеле билгесен безнең дустыбыз алмый һәм алачак та түгел. Чөнки ул һәр лекцияне күңел биреп тыңлый, һәр сынауга әйбәтләп хәзерләнә.

Сәләте алай зур булмаса да, Өметгали ышанычлы студент иде. Ул үз вазифасын тырышып, җиренә җиткереп үти торган әйбәт укытучы булачак. Берничә елдан аны директор итәчәкләр. Әкренләп ул районның мәгариф бүлеге мөдире булып күтәреләчәк. Республиканың халык агарту министрлыгына кадәр күтәрелсә дә, Өметгали үз эшен башкара алыр. Аның бар көче, бар сәләте көндәлек эшкә, бүгенге көн өчен яшәүгә тотылып бара иде. Бүгенге көндә безнең төп бурычыбыз уку булганлыктан, Өметгали дөньяда укудан башка нәрсә барлыгын белми дә, белергә дә теләми.

Тәти киенеп йөрү Өметгалине кызыктырмый. Атаклы университет студенты булу үзе генә дә аны бизи. Күңел ачу да кирәк түгел. Өметгалинең күңеле һәр вакыт ачык, шат. Чөнки һәр көнне, һәр сәгатьне аның теләге тормышка ашып бара.

Алган стипендиясе Өметгалигә җитеп бара. Гел уку турында уйлап, укудагы уңышлары белән ләззәтләнеп яшәгән кешегә акчаның кирәклеге дә шактый кими. Барына риза булып яшәгән андый кеше төшенкелеккә бирелми, бәхетсезлекләр дә сирәк очрый. Өметгалинең хыялы үзеннән аерылмыйча, һәр вакыт үзе белән бергә йөри иде.

## 10

Баграт белән Өметгали, уныңчыны бетергәч, туп-туры университетка килеп кергәннәр. Ә мин җиденчедән соң ике ел колхозда эшләдем, армиядә хезмәт иттем. Шул чакта бераз дөнья күрергә дә өлгергән идем.

Университетка керү минем төп максатым түгел иде. Авариядән соң планнарым җимерелеп, теләгемә ирешүдән өмет өзелгәч, озын-озак уйлап тормыйча филология факультетына укырга кердем.

Мәктәптә укыганда безне матур әдәбиятның уңай образларын кире образлардан аерырга гына өйрәттеләр. Әллә бу фәнне ярата торган укытучы туры килмәде, әллә әдәбиятны яратырга өйрәтү программага кертелмәгән иде. Бездән елдан-ел «әдәбиятта художестволы уйлануның төп чарасы булып торган» образларны таләп иттеләр. Матур әдәбиятның яшәү хакыйкате икәнлеген мин госпитальдә ятканда гына аңлый башладым. Очар кошлар белән бер биеклектә йөрү бәхетен югалту сынган сөякләр сызлавыннан да көчлерәк булып йөрәкне әрнеткән чакта китап миңа ярдәмгә килде. Китап белән кинәшеп тә, серләшеп тә була иде. Ул мине төшенкелеккә бирелмәскә, көрәшергә өйрәтте. Китап дөньядагы күп нәрсәнең серен ачты.

Армиядән киткәч, сәламәтлеген җитми дип, мине үзем теләгән җиргә эшкә алмадылар. Филфак миннән баш тартмады. Аналар юмартлыгы белән ул мине күкрәгенә алып җылытты, юаныч бирде. Ләкин минем өчен филфакка керү — акыллы, матур, кайгыртучан кызга яратмый өйләнү белән бер иде... Бу хакыйкатьне мин бик соң аңладым.

Уку авыр иде. Тырышырга, төн йокламыйча сынауларга хәзерләнергә туры килде. Икенче курсны тәмамлаганда мин әйбәт укучы студентлар арасында идем инде. Өченче курска күчкәч, укуны тагын да яхшыртып була иде, ләкин шушы елны үземнән укытучы да, филолог та чыкмаячагын аңлый башладым. Укуның азагы якынлашкан саен ялгышуым ныграк сизелә барды.

Укырга кергәндә мин матур әдәбият яратуымны шушы фән белән шөгыльләнәсе килү дип аңлаганмын. Бу ялгышу киләчәктә мине бәхетсезлеккә дучар итәчәк иде.

Дөньяда күңеленә ошамаган эш белән шөгыльләнүдән дә авыр җәза бармы икән? Укырга керер алдыннан мин университетны бетергәч нәрсә эшләрмен дип уйлап карамаганмын. Башкалардан ким булып күренмәс өчен уку йортының атаклырагына керергә тырышканмын. Аласы һөнәрем ихтыяҗыма туры киләме-юкмы — бу турыда уйламаганмын. Мин үземнең дилетантларча мавыгуны эчке таләпкә, хаҗәткә санап ялгышканмын.

Җир йөзендә ничәмә миллион музыка яратучы яши. Ләкин аларның меңнән бере дә музыкант була алмый. Чөнки музыкантка музыка уйнау — җаваплы эш, ә мавыгучыга — күңел ачу. Әдәбият өлкәсендә дә нәкъ шулай. Университетка кергәнче мин бу хакыйкатьне аңламаганмын.

Беренче курсларда укыганда данлы университет студенты булу горурлыгы киләчәк турында баш ватарга урын калдырмаган.

Әти-әниләребезнең белемле кеше алдында баш иеп, гыйлемгә чиксез ихтирам белән караулары да һөнәр сайлауга зыян китергән, күрәсең. Белемле булуны алар һәр вакыт беренче урынга куя килделәр. Алган белемне тормышта куллану турында кайгырту ул чакта юк иде әле. Укып чыккач нәрсә эшләрмен икән дип мин өченче курска җиткәч кенә борчыла башладым. Педагогка тиешле сыйфатлар миндә юк. Филолог булып, язучылар иҗатын тикшерү мине кызыксындырмый. Мине һаман очу, ил гизү, давыллы тормыш үзенә тарта иде.

Соңгы елларда аякларым ныгып, култык таягыннан котылгач, авиация тормышын тагы да катырак сагына башладым. Авиациягә кадәр мин кая куйсалар шунда эшли ала идем. Сабан сөрү дә ошады миңа, олауда йөрү дә. Авылда яшәгәндә печән чабу, урман кисү шикелле авыр эшләр дә канәнатьләндерә иде. Әгәр очучылыкның ни икәнен белмәгән булсам, бәлки укытучылыктан да бәхет табып яши алган булыр идем.

Өметгалинең кунагын каршылаган көнне ашханәдә очраган теге мактанчык студент диңгездә йөзү турында сөйләде дә минем күңел тынычлыгымны җимереп, йөрәк җәрәхәтемә тоз сибеп китте.

Ерак диңгезләр кичеп, ярларында пальма агачлары үскән атауларны күрәсе килү теләге малай чактан бирле минем күңелемне тынгысызлый иде. Шул студентның сөйләгәнен тыңлагач, үсмер чактагы хыялым тагын яңарып китте, йөрәгем бала чактагыдай ярсып тибә башлады.

Дөресен әйткәндә, укуымны ташлыйсым килми иде. Көн саен яңа фикер, яңа белем өстәлеп торган омтылышлы студентлар тормышы ошый иде миңа. Ләкин диплом алганчы китеп калмасаң, эшкә билгеләнер вакыт җиткәч, беркая китеп булмаячак. Университеттан китү мәсьәләсен ничек тә киләсе сентябрьгә кадәр хәл итәргә кирәк иде. Башкача тәвәккәллек җитмәгәндә гомер буе үкенергә туры киләчәк.

Тукта әле. Бу урында мин Валерия белән сөйләшмәгән бит. Минем китүем турында ул нәрсә уйлый икән? Аның белән киңәшмичә, аның сүзен ишетми торып, бу эшкә тотынырга ярамас.

## 11

Валерия мине консерваториягә орган музыкасын тыңларга чакырган иде. Скрипка, фортепиано, симфоник оркестр концертларын тыңлаганым булса да, монда кадәр орган музыкасын ишеткәнем юк иде әле.

Кешенең зәвыгы бала чакта ук формалашып өлгерә булса кирәк. Бала чакта ишеткән таныш көй яңгырады исә тәнгә ток йөгергәндәй була, бугазга кайнар төер килеп тыгыла.

Мәскәүдә кулларына гармун тотып, урамда уйнап йөрүчеләр юк. Музыка тыңлыйсың килсә, концертка барырга кирәк. Башта мин Казаннан килгән артистларны карарга гына йөрдем. Әкренләп Көнбатыш Европа композиторлары язган көйләр дә аңлашыла башладылар. Аңлау белән ярату бер-берсеннән ерак тормый. Концерт тыңларга йөри башлагач, Григ, Бизе, Брамс, Равель, Сарасате кебек бөек композиторлар язган көйләр дә дулкынландыра, күңелдә әллә нинди ләззәтле сызлану уята башлады.

Рус композиторларын мин ни өчендер соңрак, Европа музыкасын үзләштергәннән соң гына, аңлый алдым. Мусоргский, Римский-Корсаков язган көйләрне аңлау өчен хәзерлек күбрәк кирәк иде. Шунлыктан Мәскәү университеты үз студентларының культурасын күтәрү өчен бик күп көч түкте. Атнасына ике мәртәбә безне атаклы артистлар, музыкантлар, рәссамнар белән очраштырып тордылар. Менә бүген дә Валерия белән лекциядән соң консерваториягә китмәгән булсак, зур театр артистлары белән очрашырга бара идек.

Лекциядән соң китапханәдә киләсе семинарга әзерләнеп алдык та, Герцен урамына чыгып, консерваториягә таба юл тоттык. Концерт башланырга сәгатьтән артык вакыт бар иде әле. Без Чайковский һәйкәле төбенә утырып концерт тыңларга килүчеләрне күзәтә башладык.

— Монда шәһәрнең иң алдынгы интеллигентлары җыела,— диде Валерия.

— Без дә шул төргә керәбезмени?

— Нигә кермәскә? Син мәшһүр профессор булачак кеше.

— Ә син?

— Мин Элам Харниш [1] шикелле бер шәхескә кияүгә чыгып, шуңа аш пешереп, керен юып яшәү турында хыялланам.

Ялтыравыклы күлмәк кигән бер хатын сәхнәгә чыгып Бах музыкасы турында сөйләде.

Музыка турындагы сүз әллә ничек тәэсирсез кебек тоела. Мелодия кешенең сүз белән аңлатып булмаган катлаулы хисләрен кузгата. Шунлыктан музыкага тиң сүз шигърияттә дә сирәк очрый.

Ялтыравыклы күлмәк сәхнә артына кереп киткәч, тамашачылар алдына чал чәчле ябык бер карт килеп чыкты.

Карт музыкант, урынына утырыр алдыннан, фрак итәкләрен күтәреп куйды да, иелә төшеп, органның клавишларына басты. Стенага беркетелгән калай торбалардан шомлы салмак авазлар агылып чыктылар да түшәмгә бәрелеп залга коелдылар. Тавыш җиденче кат күктән төшкәндәй тантаналы иде. Музыка минем көндәлек тормышымдагы тынгысызлыкны, фани дөнья борчуларын каплап китте. Тылсымлы тавышлар дөньясында мал, файда, өстенлек шикелле теләкләргә урын юк иде. Безнең көндәлек тормышыбызга әрсезләнеп кергән зур гауга-

[1] Элам Харниш — Джек Лондон әсәренең герое.

лар, төрле гайбәтләр, акча табу борчулары каядыр китеп югалды. Органнан чыккан тантаналы илаһи аваз ниндидер камиллек, рухи пакьлек, хыял дөньясына алып китте. Бу тавышлар гүяки әйтә кебек: «Син, адәм баласы, бу дөньяга бик азга килгәнсең, онытма, җир йөзендә Мәҗбүрият, Файда дигән төшенчәләрдән тыш Хакыйкать һәм Матурлык дигән бөек тойгылар да бар. Син адәм затыннанмы? Адәм затыннан булсаң, шул бөек исемгә лаек булырлык итеп яшәргә тырыш! Иманың бармы синең? Синнән соң яшәячәк кешеләргә нәрсә калдыра аласың? Үзеңнең адәм затыннан икәнлегеңне исбатлау өчен, тормышны матурлауда җиң сызганып эшлисеңме? Синең яшәвең яхшылыкка таба юнәлгәнме, әллә син үз иминлегең, үз хаҗәтеңне генә кайгыртасыңмы?» Концерт беткәнче шушы сораулар тойгыларымны тетрәтеп тордылар.

Орган тавышы тынды. Концерт тыңлаучылар урыннарыннан кузгалдылар. Без дә, бер-беребезгә күтәрелеп карарга куркып, әкрен генә урамга чыктык.

Күн пальто кигән бер кеше, каршыбызга килеп, Валериянең кулыннан тоткач, сискәнеп киттем.

— Валерия, әниең сине өйгә алып кайтырга кушты.

— Ярый, кайтырбыз. Башта Аликны Стромынкага илтеп куйыйк әле, Тимофей.

Шофер Валериянең колагына нәрсәдер әйтте. Сабакташым теләр-теләмәс кенә миңа кулын сузды:

— Тыныч йокы, Алик. Концерт турында иртәгә сөйләшербез инде.

— Тыныч йокы, Валерия. Иртәгә мин биргән китапны алып кил, яме?

Валерия машинага кереп утырды. Зур, көчле автомобиль урыныннан кузгалды.

Машина койрыгындагы кызыл ут кабынып киткәч кенә әйтәсе сүземнең әйтелми калганлыгы исемә төште. Антракт вакытында ничә мәртәбә сөйләргә дип авызымны ачсам да, кайтканда иркенләп аңлатырмын дип, ниятемне озату вакытына калдырган идем. Шушы каһәр суккан машина Валерияне миннән аерып алып китеп, әйтәсе сүзләремне әйтергә ирек бирмәде.

Урам ягындагы тәрәзәләрдән саргылт яктылык сирпелә. Юридик факультет бинасы янындагы йортның икенче каттагы тәрәзәсеннән өстәл янында ашап утырган гаилә шәүләсе күренеп китте. Мин иртән чәй эчкән генә килеш көн буе бер валчык ризык капмаган идем.

Урам почмагындагы азык магазинының ишеген ачып, башымны тыктым. Бушаган шешәләрне әрҗәгә тутырып яткан бер кыз минем якка карамыйча гына:

— Магазин ябылды,— диде.

— Тамак ялгарлык бирәр нәрсә калмадымы соң?

Сатучы кыз көн буе эшләп алҗыган булса да ачуланмады:

— Менә бер шешә кымыз бар.

Минем колагымда һаман Бах, Гендель музыкасы яңгырый иде әле. «Кымыз» сүзен ишеткәч, башкорт далаларында йөргән елкы көтүләре, тау кабыргасына кырын ятып курай тартучы түгәрәк йөзле башкорт егете күз алдыма килде.

— Рәхим итеп, шул шешәне бирегез әле,— дип, эчкә кермичә генә, сатучы кызга акча суздым.

Сатучыларга без җылы сүзне бик, бик сирәк әйтәбез. Башкала магазиннарында эшләүчеләрнең хезмәтләре бик авыр. Алар тырышалар, көненә берничә мең кешенең күңелен күрәләр, кичкә таба тәмам арып-алҗыйлар.

Сатучы кыз кулыма авыр шешәне китереп тоттырды. Кызның хәлемә керүе күңелемне йомшартып җибәрде. Әллә шушы кызның урамга чыкканын көтеп торып, Валериягә сөйлисе сүзләремне аңа гына сөйлимме икән? Юк, дөньяда әйбәт кешеләр күп булыр. Валерия бер... бер генә... Түзәргә кирәк...

Халыкның тамаша йортларыннан таралган вакыты. Метро вагоны тәти киенгән кешеләр белән тулган. Кымыз шешәсен куеныма кыстырган килеш, вагон почмагындагы буш урында музыка кузгаткан катлаулы тойгыларга бирелеп, тулай торакка кайтып барам. «Сокольники» станциясенә җиткәч метродан чыктым да кымызымны тотып, Стромынка урамына таба киттем. Бүген мин бәхетле — минем кымызым бар... «Ә Валериян кайда?» — Бусы иблис коткысы.

Урамда минем шикелле соңга калып кайтучылардан ара-тирә яшь-җилбәзәкләр генә күренгәли.

Тулай торак каршысында үскән сиреньнәр арасында аулак эскәмия бар иде. Шул эскәмиягә утырып, саф һавада ашыкмыйча гына «батырлар эчемлеге» белән хозурланыйм әле, дидем. Шешә авызындагы калай бөкене эскәмия тактасының читенә эләктереп, аска таба тарттым. Төнге тынлыкта гөрселдәп атылган тавыш ишетелде. Куак артында үбешеп торган бер кыз белән бер егет читкә ташландылар. Икенче мизгелдә кемдер калтыраган кулы белән якамнан эләктереп алды:

— Син аттыңмы, хулиган?

— Баграт, ни эшлисең монда?

Икебез берьюлы көлеп җибәрдек.

— Харап булды, шешәдә бер йотым кымыз калмаган. Әллә нинди каһәрле эчемлек икән лә бу! — дип, шешәне куак эченә ыргыттым.

Ашыйсы килүне су белән бастырып, одеял астына кереп яткач кына күңелемә акыллы фикер килде: «Магазиннан чыгу белән берәр аулаграк җир табып кымызымны шунда эчәсем калган. Поездда чайпалып килә-килә шул дәрәҗәгә җитеп куперганнәр инде ул».

Минем әле һаман кымыз эчеп караганым юк.

## 12

Без Валерия белән күптән дуслашкан идек. Бу кыз икенче курста укыганда ук минем күңелемне яулап алды. Хәзер инде минем шатлыгым да, кайгы-хәсрәтем дә Валериянең мөнәсәбәтенә бәйләнешле иде.

Ул көнне дә лекция беткәч, җәяүләп «Ударник» кинотеатры янына килеп туктадык. Валерия квартирларына кереп тиз генә ашап чыкты. Әнисе, бу дәрес хәзерләргә бара икән, дип уйласын өчен ул конспектларын да алган иде. Дәфтәрләрне подъезд саклаучы милиционерга калдырып шәһәргә киттек.

Эстрада театры каршына, Мәскәү елгасының бетон ярына беркетелгән дебаркадерга су трамвае килеп туктаган иде.

— Алик, әйдә утырабыз,— дип, Валерия кулымны кысып тотты да трамвайга таба йөгерә башлады. Икенче мизгелдә мин аны очыртып дебаркадерга таба алып киттем. Без кергә, су трамвае урыныннан кузгалды.

Рубкага беркетелгән репродуктордан елга өстенә дәртле җыр агыла. Яр буенда күңел ачып йөрүче яшьләр безгә кул болгыйлар.

Трамвай, үзәк парк ярларын узып, әле яңа төзелеп беткән Лужникидагы стадионга якынлашты. Каникул вакытында мин ике ай комсомол путевкасы белән стадион төзүдә таш салучы булып эшләгән идем. Үз көчем кергән корылманы күргәч, түзмәдем:

— Колизей зурлыгы һәйкәл салып куйдык узган каникулда! — дидем.

— Шушы төзелеш белән исемең тарихка кереп кала инде. Минем генә тарих битенә керерлек эш башкарганым юк әле,— диде Валерия.

— Ике ел Берләшкән милләтләр бинасында яшәү тарихи вакыйга түгелмени? — дидем мин. Валерия бераз уйлап торды:

— Юк, тарихи вакыйга түгел. Мин анда әти икмәген генә ашап яттым. Дөресен әйткәндә, әтием кызы булып кына яшәү туйдыра башлады. Әти-әни канаты астыннан чыгып, үз даным өчен эшли башлыйсым килә. Университетны бетергәч, үземнең дә мөстәкыйль кеше икәнлегемне исбатлау өчен Мәскәүдә калмыйча, юри авыл җиренә китәчәкмен.

— Купмегә?

— Гомергә. Егет кеше булсам, мин синең шикелле шәһәрдә тузан эчеп ятмас идем. Мин Джек Лондонның геройларын яратам. Аның китапларындагы сәяхәтчеләр, моряклар акылымнан яздыралар мине. Алик, әгәр син шул Джек Лондон геройлары шикелле дөнья ваемнарына төкереп, сәяхәткә чыгып китсәң, мин бәхетемә чыдый алмыйча үләр идем.

— Валерия! — дидем мин, кабынып китеп,— шушы көннәрдә мин...

Су трамвае Герцен белән Огаревның ант иткән урыны — Воробьев тавы итәгенә килеп туктады.

— «Шушы көннәрдә» мин синең нәрсә эшләргә җыенганыңны беләм.— Валерия, минем терсәгемә ябышып, ярга төшә башлады.— Син шушы көннәрдә очрашуга кул селтәп, сынауга хәзерләнергә утырмакчы буласың.

Мин аңа китәргә җыенып йөрүем турында сөйләмәкче идем,— бу теләгем кинәт юкка чыкты. Күңелемә авыр шом кереп утырды. «Бәлки шушы кызга ошар өчен генә мин укуымны ташлап, диңгезгә чыгып китәргә хыялланып йөри торганмындыр?»

Без яр буеннан читкәрәк китеп, яшел чирәмлеккә барып утырдык.

Елганың теге ягында утлар кабына башлады. Стадионда пневматик чүкеч белән таш ваталар иде. Чүкеч тавышы кинәт туктап калды. Тынлыкны бозып, стадионнан сулдарак, Новодевичье зираты ягыннан, хатын-кыз елаган тавыш ишетелеп китте. Мин сулышымны кысып тыңларга керештем.

Әллә шул зиратка күмелгән берәр кеше җир астында яту газабыннан зарланып елыймы? Тарихчылар безнең каршыдагы монастырь чиркәвенең базына әсир итеп Мәскәүгә китерелгән Сөембикә күмелгән дип сөйлиләр.

Бәлки шул бәхетсез хатын шулай елыйдыр?

Менә мин, кич утырып сынауга хәзерләнәсе урында, үз сүзле чибәр кыз Валериянең капризына буйсынып, елга яры буенда аунап ятам. Без, ир затлары, үзебезне хатын-кыздан акыллырак, сәләтлерәк күрсәтергә тырышабыз. Сугышта армия, фронт белән җитәкчелек итү безнең кулыбыздан килә. Сәяхәттә дә без үзебезне суда йөзгән балык кебек сизәбез. Шуңа карамастан, ирләр бер вакытта да хатын-кызлар шикелле көчле булып, алардагы җаваплылыкны өсләренә ала алмыйлар.

Җир йөзендә яшәүчеләрнең барысы да — ана балалары. Бала чакта синең язмышың ана кулында. Егет булып житкәч тә син сөйгәнең белән очрашканчы гына үзеңне мөстәкыйль сизәсең. Яшәү дәверендә ниндидер илаһи бер көч туктаусыз синең язмышыңны хатын-кызларга бәйләп тота.

Мин сискәнеп киттем. Валерия чәнчә бармагын сагаеп кына минем аяк балтырындагы җәрәхәт эзенә тидереп карады:

— Авыртамы?

— Юк, авыртмый.

— Син сугышка катнашмагансың бит? Ни эшләп яраландың?

— Булды инде. «Батыр» ярасыз булмый диләр бит. Минем йөрәгемдәге яраларым аягымдагыдан да тирәнрәктер әле,— дидем мин, шаяруга күчеп.

Валерия карашын кызыл нурга манчылган каурый болытларга күчерде.

— Эч поша, Алик. Менә син яшәүдән тәм табып, киләчәккә зур планнар корып яшисең. Хәтәр бер эштә яраланып тәнеңне бизәкләргә дә өлгергәнсең. Мин көн саен әбиемнең: «Валерия, нигә ашыңны ашамадың?», әниемнең: «Валерия, әллә акылыңнан шаштыңмы? Яшел күлмәк белән кем кызыл туфли кия?» шикелле үгетләреннән башка бер нәрсә ишетмим.— Сабакташым, терсәгенә таянып, чирәмгә ятты. Аның чәче беләгемә тиюгә йөрәгем дөрселдәп тибә башлады...

— Минем белән очрашканда да эчең пошамы?

— Поша, Алик. Әллә нишләп яшәүнең бер кызыгы да юк. Иртән тору белән аш турында кайгыртасың. Аннан соң төшке ашны ашарга әзерләнәсең. Кичкесен ашагач, йоклар вакыт җитә. Ашаудан бушаган арада, башка кешеләрдән калышмаска тырышып, киенү турында кайгыртасың. Яшәвең чын яшәү булсын өчен эшләргә, хезмәт кешесе булырга кирәк дип тукыйлар. Күрдем мин ул эш өчен үлеп яшәгән кешеләрне. Аларның күбесе хезмәтнең акча ягын гына күрә. Әгәр андый кешеләргә «эшләмичә тик ятсагыз, күбрәк түләрбез» дисәләр, икеләнеп тормыйча, эшләрен ташларлар иде. Минем хезмәт хакы, хезмәт даны шикелле нәрсәләрдән азат булган бер эш табасым килә. Әгәр эшнең андые табылмаса, яшәү я гел бәйрәм булсын, я туктаусыз көрәш. Мин башкача яшәргә риза түгел. Нилектән бәхетле була алмыйм икән мин?

— Яшәү тоташ бәйрәм булмый инде. Озакка сузылса бәйрәм дә туйдыра. Эш хакы да кирәк нәрсә. Эшнең рухи ләззәте өчен генә эшләп буламы икән, белмим.

Валерия башын күтәреп бер тын миңа карап торды да кычкырып көлеп җибәрде:

— Син, Алик, күпне күргәнсең, күп беләсең. Синең күп белүеңнән дә, белгән нәрсәләреңнән фәлсәфә ясавыңнан да минем эчем поша башлый. Син яшәмисең, яшәү турында кагыйдә чыгарып шул кагыйдә белән тукланып торасың.

Валериянең сүзләре минем йөрәгемә килеп кадалды. Мин үзем дә бу турыда бераз сизенә идем. Күңелеңә ошаган кешене үзең теләгән матур сыйфатларга төрәсең дә аның чын сыйфатларын күрми башлыйсың.

Мин Валериягә идеалымдагы кыз сыйфатларын биреп бетергән идем инде. Шуңа күрә, башын минем тезәмә салып чирәм өстендә чалкан яткан бу чибәр кыз белән минем хыялымдагы кыз арасында бернинди аерма юк шикелле тоела иде. Сүзләрнең ачырагын сайларга тырышып, әйттем:

— Билгеле, синең эчең пошарга тиеш. Син әле һаман курчак уйнавыңны дәвам иттерәсең. Аермасы шул: синең хәзерге курчакларың — тере кешеләр. Бар нәрсәне чәйнәп синең авызыңа салалар. Курчак шикелле киендереп, сәдәфләреңә кадәр эләктереп торалар. Икмәкне үзең көч түгеп тапсаң, яшәү рәхәтен бик яхшы тояр идең.— Бер башлагач, эчемә җыелганнарны чыгарып бетерергә ниятләгән идем, соңгы чиктә ничектер тыелып калдым.— Синең минем белән очрашуың да эч пошканнан гына бит.

— Алик, минем сүзгә хәтерең калдымыни? Бер дә хәтереңне калдырасым килмәгән иде.

— Юк, калмады. Синең һише чибәр кызлар әйткән сүзнең мәгънәсенә әһәмият биреп тормыйлар. Матур кызлар сөйләгәндә музыка тыңлаган шикелле аның тавышын гына ишетәләр.— Хәзер инде Валериянең хәтере калды. Кыз читкәрәк шуышып утырды:

— Егетләрнең барысы да бер төсле. Синең дә башкалардан аермаң юк. Хәзерге заман егетләренең лыгырдаудан башка кулларыннан бер эш килми. И алла, нигә бу кадәр эчем поша икән! Нигә күңелсез икән миңа?!

Новодевичье зираты ягындагы кызыллык сүнде. Караңгылык куера башлады. Яр буендагы йортларда утлар кабынды. Ленин тавы ягында кемнәрдер сөйләшәләр. Шуларның берсе кычкырып көлде. Тау итәгенә төшеп килүче кешеләрнең аяк тавышлары ишетелде.

Ниндидер чит телдә сөйләшеп килүче егетләр һаман якынлаша баралар. Менә алар яныбызга ук килеп җиттеләр. Узып киткән чакта бер егет иелебрәк безнең якка карады да тукталып калды:

— Сәлам, Лера! Эшләр барамы?

— Сәлам, Леон! Бара. Үзеңнеке ничек?

— Уртачарак, Лерочка. Яшәү ал да түгел, гөл дә түгел. Күп вакыт соры...

— Син дә сорылыктан зарлангач, белмим, кем генә дөньяны балкытып яшидер...— Сөйләшкән саен Леон безгә таба якыная бирә иде. Хәзер инде ул яныбызга ук килеп җитте. Валериянең кызыксынуын күреп, егет чирәмгә утырды.

Алар миңа аңлашылмый торган бер жаргонда сөйләшәләр иде. Егетнең сөйләшүендә әле күптән түгел рус телен үзләштергән Европа кешесенең акценты сизелә. Киеменә, үз-үзен тотуына карап, аның университетта укучы чит ил студенты икәнлеген аңлап алдым.

Мин урынымнан кузгалдым да метрога бара торган сукмакка чыктым.

— Алик, син мине ташлап китәсеңмени? — Валериянең тавышында ясалма үпкә, хәтере калганлыгын күрсәтергә тырышу сизелә иде.

— Ташлап китмим, калдырып китәм,— дидем мин, ачуымны яшерергә тырышып.

Килеп утырган егетнең якасына ябышасым, аны җиргә егып таптыйсым килә иде. Шушы бәгыремне көйдергән көнләшү хисенә бирешмәс өчен җәяүлеләр сукмагыннан читкәрәк китеп, метро станциясенә таба йөгерә башладым.

Вагонга кергәндә дә Валерия янына кире кайтып, теге егетне куып җибәрәсе, хисләремне ачып саласы килү теләге басылмаган иде әле. Үземне кулга алып, тулай торакка кайтып киттем.

Шул аерылышудан соң мин аны очратсам да, күрмәмешкә салышып, исәнләшмичә узып китә торган булдым. Ул яныма килсә, тизрәк китү ягын карыйм. Соңгы вакытта ул минем исемә сирәгрәк төшә башлады.

## 13

Баграт бүлмәгә килеп керүгә кычкырып җибәрде:

— Сөенечле хәбәр!

— Нинди хәбәр? — дидем мин.

— Болай гына әйтә торган түгел. Сөенчесенә нәрсә бирәсең?

— Кавказ тауларының — карын, Кара диңгезнең — суын. Алар да әз күренсә, Өметгалинең пошынмаслыгын өстәп бирәм,— дидем мин.

— Я, сузма. Минем магазинга барасым бар,— диде Өметгали.

— Әйтим инде алай булгач: декан безгә сынауларны чирәм җиргә китүчеләр белән бергә тапшырырга рөхсәт итте. Без җәйге каникулга ике атнага алдан китә алабыз.

Сөенечле хәбәр бу. Уку никадәр мавыктыргыч булса да, җәйгә таба ял итәсең, авылыңа кайтып, туганнарыңны күрәсең килә башлый.

— Рәхмәт, зур эш эшләгәнсең. Сынауларны биргәч, без чирәм җиргә дә китә алабыз. Анда бармасак, ярты айлык ял бер дә зыян итмәс,— дидем мин, Багратның аркасыннан каккалап.

— Нигә ашыгырга? Вакыт җиткәч тә өлгерербез әле.— Өметгалинең бу сүзе безнең кабынып киткән энтузиазмга салкын су сипкәндәй итте.
— Габдрахман, ишеттеңме?
— Ул бит шаярта гына.
— Юк, шаяртмыйм,— диде Өметгали.— Сынавымны кешеләрдән элда бирәм дип кабаланасым юк.— Борынгы шәрык хәкимнәре шикелле, Өметгали һәр эшнең үз юлы белән эшләнгәнен ярата. Теге яки бу хәлне үзгәртү аның гадәтендә бөтенләй юк иде.
Өч ел эчендә беренче курстагы авыл малайлары хәзер башкала студентлары булып беттеләр инде. Чәчләрен тасма белән үреп йөргән авыл кызлары өч ел эчендә әллә нинди прическалар ясарга өйрәнделәр. Аларның кайберләре, Италия артисткасы Джина Лоллобриджидага охшарга тырышып, күкрәкләрен тырпайтып, юрга ат шикелле атлап йөри башладылар. Егетләр авылдан ияреп килгән беркатлылыкларын салып ташлап, битләренә башкала егетләренең ясалма гамьсезлеген элделәр. Һәр студент әйбәт яки яман якка күпмедер үзгәрде, шомарды, яңа гадәтләр, яңа кыланышлар үзләштерде. Өметгали генә үзенең Өчарык авылыннан алып килгән гадәтләре белән яши бирде. Аның табигый мөлаемлыгы, дөньяга шәрык философларыча каравы беркадәр сәер күренсә дә аңлаган кешене сокландырырлык иде.



## 14

Яуза яры буендагы парктан тулай торакка таба беренче трамвай дөбердәп килә башлау белән мин йокыдан уяндым. Караватымнан сикереп төшеп, Баграт янына бардым. Баграт чалкан яткан килеш авызын киң ачып, тирән-тирән итеп сулу ала. Аның кара бөдрә чәче бөселеп маңгаена төшкән. Бер тын аны уятырга кызганып, икеләнеп торганнан соң беләгеннән тотып җилтерәттем:
— Сәгать биш, Баграт, торасыңмы?
— Бик иртә түгелме соң? — Торасы килмәгәннән шулай дип сорады иде аның.
Баграт киенгән арада, кухняга чыгып, чәй кайнатырга куйдым, китап-дәфтәрләремне җыеп алдым.
— Йоклый бит, ә? Җир тетрәп, түшәм җимерелә башласа да вакыты җитми урыныннан кузгалмас,— диде Баграт Өметгалигә таба ымлап.
Без иркенләп чәй эчтек. Конспектларыбызны күтәреп урамга чыктык. Урам себерүчеләрнең эшләре кызган вакыт иде. Анда-санда гына иртә таңнан ниндидер җитди йомыш белән ашыгучылар күренә. Төнге сменада эшләп, өйләренә кайтучылар очрый. Ара-тирә мәхәббәтләренә онытылып таң атканын сизми калган яшь-җилбәзәк тә күренгәләп китә.
«Сокольники» паркына кадәр җәяү бардык. Парк капкасыннан керү белән яңа салына башлаган Кушма Штатлар күргәзмәсенең гөмбәзе күренде. Ярым сфера рәвешендәге павильонны саргылт пыяладан корганнар иде.
— Капиталистлар эшкә кире яктан башлыйлар икән. Бу павильонны түбәдән башлап төзеделәр,— диде Баграт.
— Нигездән башласалар, төзү материалын кран белән күтәреп торырга кирәк булыр иде. Алар аны җирдә җыеп, домкрат белән генә күтәрттеләр бит,— дидем мин.
— Мәктәптә укыганда мин архитектура институтына керергә хыялланып йөргән идем. Ни өчендер университетка килеп кердем.— Бу минутта Баграт университетка керүенә үкенгән шикелле күренде.

Кеше йөри торган җирдән читкәрәк китеп, аулак бер куаклык арасын сайлап алдык та үләнгә яттык.

— Бергәләп кабатлыйбызмы?

— Аерым кабатлау әйбәтрәк булыр,— диде Баграт.— Кеше укыганда гел башка нәрсә турында уйлап утырам мин.

Баш очыбызда өздереп сандугач сайрый. Сузылып ятып күз талганчы күкнең зәңгәр чиксезлегенә карыйсы килә. Бу сынау мәшәкатьләреннән тизрәк арынасы килә, хыялый бер дөньяга кереп китәсе дә шунда яшисе килә.

Тарихи грамматика конспектын ачтым.

Дәфтәрнең беренче битеннән үк яртылаш кына язылган сүзләр, әллә нинди сәер билгеләр, кыскартулар күренә башлады. Шушы тамгаларга карап, моннан тугыз ай элек тыңлаган лекцияләрне искә төшерергә тотындым.

Шулай рус теленең гасырдан-гасырга ничек үзгәргәнлеген күзәтеп утырганда әтием белән урманга чикләвек җыярга барган чак исемә төште. Әти, бераз бөкрәя төшеп, яшь имәннәр арасыннан куелыкка кереп бара. Аның гражданнар сугышыннан алып кайткан ревматизмы елдан-ел көчәя иде. Көн бозылыр алдыннан әтинең йөрәге авырта, буыннары сызлый. Көзге яңгырларда, ташу вакытларында аяк-куллары таш булып ката да, әти, мескен, урыныннан тора алмыйча интегә. Әле дә, биле авырткандыктан, башын күтәреп өскә карый алмый. Аяк буыннарының шыртлавы миңа ишетелеп тора.

Әти агачлык арасыннан гамьсез генә атлый бирә. Ара-тирә җирдән бер уч үлән йолкып алып, агач ботагына элеп куя.

— Әти, нигә агач ботагына үлән эләсең?

— Билге куймый барсак, кайту юлын ничек табарбыз соң?

Мин ул үләннәрне әти пошига кышкы азык булсын өчен киптерергә элә дип уйлый идем. Кызык та инде бу әтиләр: урманга кергәндә үк чыгу ягын кайгыртталар. Ә мин биш елга сузыласы белем урманына керер алдыннан чыгу ягын карарга онытканмын.

Әтинең тәҗрибәсе миңа да ярап куйды. Тарихи грамматиканың сукмакларына төрле билгеләр куеп бардым. Хәзер шул билгеләргә карап, лекциянең эчтәлеген исемә төшерәм.

Берничә сәгать башыбызны күтәрмичә тарихи грамматиканы кабатладык. Ниһаять, Баграт дәфтәрен чирәм өстенә ташлады:

— Бернәрсә аңламыйм. Рус теле болай да катлаулы, өстәвенә, онытылып беткән иске кагыйдәләрне чокыштырып башыбызны катыралар. Әйдә, бераз тән язып йөреп килик.

Сукмакка чыгып, йөгерешеп киттек. Алан җиргә тезелгән пингпонг өстәлләре янына килеп чыккач, икебез берьюлы туктап калдык.

— Әллә бер генә партия уйнап алабызмы? — Багратның карашыннан ялваруы күренеп тора иде.

— Юк, уйный башласак дөньябызны онытырбыз. Сынаулар беткәнче уенны калдырып торыйк.

Баграт белән без пинг-понг уйнаганда танышкан идек. Ул якшәмбене без сер бирергә теләмичә көне буе көрәштек. Бер кызып китсә, Багратны туктатып булмый. Аның өчен җиңелү — үлем белән бер. Мин дә теннис ракетасы тотып, «дошман» каршысына бассам, үземне кулыма кылыч алып, атакага барган кеше итеп сизә башлыйм. Бәлки минем канымда да киң далаларда кылыч белән юл салып йөрүче борынгы кабиләләр гадәте сакланып калгандыр.

Урыныбызга әйләнеп кайттык, кабатлау эшенә керештек.

— Кара әле, Габдрахман, күңелемә бер кызык фикер килде. Әгәр без күлмәкләребезне алышып кисәк, малыбыз бер бөртек тә артмый. Ә менә фикерләребезне алышсак, фикер байлыгы икеләтә зурая. Гаҗәп нәрсә бит бу, әйеме? — диде Баграт.

— Үзем таптым дип уйлый күрмә тагын. Бу фикерне Спиноза исемле философ синнән алты гасыр алдан әйткән,— дидем мин.

Караңгы төшеп, тирәбездә паркка ял итәргә килгән кешеләр йөри башлагач, без конспектларыбызны җыеп, тулай торакка кайтып киттек.

## 15

Өметгали сынау бирергә керешкәнче, без инде имтиханнарны тапшырып бетереп килә идек. Борынгы рус әдәбиятыннан имтихан биргәч, курсны тәмамлап, каникулга кайтып китә ала идек. Сынауларны бетерү миңа аеруча куанычлы булачак. Көнбатыш Европа әдәбиятын мин деканның үзенә тапшырдым. Билге куяр алдыннан ул зачет кенәгәмне актарып карады да:

— Рахманкулов, сез нинди җәмгыять эшләре алып барасыз? — дип сорады.

— Студком члены, факультетның комсомол оешмасы бюросында.

— Соңгы экзаменыгызны бишлегә бирә алсагыз, фәнни совет утырышында сезне Ленин стипендиясенә күчерү мәсьәләсен карарбыз. Уңыш телим...

Деканның сүзе уйланырга мәҗбүр итте. Мәктәпне бишлегә тәмамлап чыкканнан соң отличник булуның кыенлыкларын аңлый башлаган идем инде. Мәктәптә укыганда отличник булуы әллә ни авыр түгел. Университетта андый җиңеллек бетте. Монда хәтер яхшылыктан гына бишлегә укып булмый башлады. Программаны тулысынча үзләштерү өчен күп чыганаклар карарга, байтак өстәмә материал укып барырга кирәк иде. Хәзер Ломоносов чоры түгел шул. Һәр фән буенча бик күп мәгълүмат, кагыйдәләр тупланган. Барлык фәннәрне тигез үзләштереп барырга көч тә, вакыт та җитми. Көчен төрле якка таратмыйча, бер генә тармакка әһәмият биреп, максатына таба үз сукмагыннан гына барган кеше, билгеле, күп нәрсәгә ирешә ала. Әгәр инде отличник исеме таксалар, шул исемне югалтудан куркып, һәр фәнне тигез куасың. Шунлыктан көчең таркала, яраткан фәнеңне тирәнәйтергә вакыт калмый.

Дүртле белән бишле арасында барган акыллы укучы өчле алса да әллә ни кайгырмый. Ә синең бишлеләрең арасына бер дүртле килеп керсә, төн йокыларың кача, дөньяның яме бетә.

Шушы хакыйкатьне аңлаганнан соң, университетта тарих, әдәбият, философиядән башка фәннәрне көчәнмичә генә үзләштереп барырга исәпләгән идем. Деканның вәгъдәсе мине бишле алу көрәшенә ташланырга мәҗбүр итте. Әгәр стипендиат итсәләр, әлбәттә, вагон бушатырга йөрүдән котылып булыр иде.

Уку шактый арыткан иде инде. Шуңа карамастан, соңгы сынауга ныклап хәзерләнә башладым. Бу сынауны да бишлегә тапшырасым килә иде.

Ни өчен һәр халык үзенең тарихын белергә тырыша икән? Борынгы рус әдәбияты тарихын кабатлаганда мин бер яңа фикергә юлыктым. Үткән заман тарихын аңлау киләчәккә бару өчен кирәк. Узгандагы ялгышларны белү киләчәктә аларны кабатламас өчен кирәк. Үзең яшәгән чорны дөрес бәяләү өчен дә тарихны белү яхшы. Гомумән, адәм баласы үзенең каян килеп чыкканлыгын белмичә тынычланып яши алмый. Ата-баба, бабаларның бабалары эшләгән эш, алар кылган гамәлләр белән дә горурланасы килә.

Борынгы рус әдәбиятын кабатлыйм. Моннан мең ел элек булган вакыйгалар минем күз алдымнан үтеп торалар.

Менә борынгы славяннар урманнарны яндырып, төп казып, иген игәргә урын әзерлиләр. Салам түбәле тәбәнәк өйләрнең ишекләреннән

төтен бәркелеп чыга: хатыннар ирләренең аудан кайтуына аш әзерлиләр.

Ләкин, кызганычка каршы, халыкларның иген игеп, ауга йөреп тынычлыкта яшәүләре тарих битләрендә бик аз очрый. Үткән заман тарихы гел сугыш, яу, кан кою турында сөйли. Туктаусыз сугышып тору аркасында күпме халык кырылган, күпме авыллар, зур калалар көлгә әйләнгән. Халыкларның еллар буе эшләп, көч түгеп тапкан маллары сугыш вакытында юкка чыккан. Күпме аһ-зар, күз яше китергән шул каһәр төшкән сугыш.

Геродот тарихны җиңүчеләр яза дигән. Әгәр тарих язу өчен генә шул кадәр кан коелган булса, бу зур ялгышлык.

## 16

Сынауны арткарак калып тапшыру күп яктан файдалы: сынау алучы, арыгач, бик төпченеп тормый башлый. Билетлар саны да азая. Кайбер үткенрәк студентлар, бөтен билетка да җавап әзерләп тормыйча, шул калган билетлардагы сорауларны гына карап өлгерәләр.

Борынгы рус әдәбияты буенча сынау бирү сәгате килеп җиткәч, җиңел юл белән тапшыру өчен информация җыеп йөрүче кызлар имтихан алучының профессор Гудзенко икәнлеген ишетү белән тиз генә таеп өлгерделәр. Китәр алдыннан бер кыз әйтте:

— Дүшәмбе көн башка экзаменатор булачак. Гудзенко төпченергә ярата. Ул саранның өчлесен алу өчен дә материалны баштанаяк белергә кирәк.

Әлеге кызның бу сүзләре миңа көлке тоелды. Кызлар алар материалны кабатларга иренәләр. Кайсы профессорның ничегрәк сынау алганлыгын төпченеп йөреп вакытларын әрәм итәләр. Ныклап хәзерләнгән кешегә сынауны кем алса да барыбер бит.

Аудиториягә хан заманыннан калган күн портфелен күтәреп профессор Гудзенко килеп керде. Ашыкмыйча гына сынау билетларын өстәлгә таратып ташлады:

— Ну, күгәрченкәйләрем, рәхим итегез.

Бүлмәдә тынлык урнашты. Берәүнең дә башлап чыгасы килми иде.

— Сез сынау бирергә килмәдегезмени? — диде профессор.

Мин өстәл янына килеп, иң өстә яткан билетны кулыма алдым:

— Егерме беренче билет. Беренче сорау:

«Батыйның 1237 елда Рязань каласын җимерүе турындагы повесть»,— дидем дә кинәт тукталып калдым.

«Въ лѣто 6745, во второе на десять лѣто по принесении чюдотворного Николина образа ис Корсуня, приѣде безбожный царь Батый на русскую землю со множеством вой татарскыми и ста на Рѣкь на Воронежь близь Резанскъа земли».

Батыйның Рязань каласын җимерүе турындагы легенданың беренче җөмләсен яттан белсәм дә, мин аны бер генә мәртәбә дә тулысынча укып чыкмадым. Нигә укымадым икән?..

Рязаньлыларга да гаскәр җыеп, ныгытмалар корып, дошманны зур кораллы көч белән каршы алырга кирәк иде. Алар руханиларның әкиятенә ышанып, дөнья белән мавыгып йөриләр. Батый, Рязаньга килгәнче, минем бабаларым җирен, Идел буен канга батырып ташлаган. Повестьны җентекләп укыйсы урында менә шундый уйлар белән чикләнеп калганмын.

— Соравы авырмы әллә?

— Соравы әллә ни түгел, җавабы авыр.

— Алай булгач, башка билет алыгыз.

Башка билет алсам, җавабым никадәр яхшы булса да, бишле куелмаячак иде. Миңа бишледән ким алырга ярамый. Шушы соңгы бишле минем тормыш шартларымны үзгәртеп, укуымны җиңеләйтергә тиеш иде. Бераз икеләнеп торганнан соң әйттем:

— Рөхсәт итсәгез, мин сынауны бүген бирмәс идем.

— Алай булгач, мин сезгә вакытлыча гына «икеле» куеп торыйм. Киләсе очрашуда, хәзерләнеп килсәгез, төзәтермен. Онытмагыз, күгәрченкәем, хәзер инде сез миннән башка экзаменаторга борынгы әдәбиятны тапшыра алмыйсыз. Уңыш телим.

Мин бер сүз дә әйтә алмадым. Елга аша чыкканда күпер җимерелеп упкынга төшкән кеше кебек идем мин. Күңелемнең бер почмагында минем бәхетсезлегемә читтән генә карап торучы ниндидер ят бер бәндә: «Менә эләктеңме? Шул кирәк сиңа! Бишле көткән идең! Дускаем, дөньяда «икеле» дә бар әле. Аны да татып карау зыян итмәс. Борын чөеп йөрмәскә файдалы ул икеле алу...» — дип үртәп торган шикелле иде.

Баграт урыныннан торып, өстәл янына килде:

— Профессор, гафу итегез, Рахманкулов программаны бишлегә белә. Ул моңа кадәр дә гел бишлегә генә укып килде. Сорагыз, ул нинди сорауга да җавап бирәчәк.

— Сез аның адвокатымыни, күгәрченкәем? Икенче килүеңдә мин Рахманкуловтан отличникка куелган таләп белән сораячакмын.— Профессор хәзерләнеп утыручы студентларга таба борылды.— Тагын кем җавап бирергә әзер?

17

Мин ишегалдына чыктым. Анда абитуриентлар кайнашып йөри. Алар үзара әллә нинди ясалма бер күңел күтәренкелеге белән сөйләшәләр. Үзләрен ниндидер даһиларча тоталар. Университетның һәр ташы абитуриентларның күңелендә ихтирам тойгысы уята. Монда йөргән кешеләр аларга ниндидер тарихи кеше булып күренәләр. Озакламый, шушы атаклы биналарда дәрес тыңлый башлагач, алар үзләре дә мәшһүр кешеләр булачаклар... Их, яшьлекнең татлы хыяллары!

Урамга чыктым. Моховой урамыннан Ленин китапханәсенә таба машиналар ташкыны агыла. Кремльнең Урта Арсенал манарасына караган килеш Моховой урамын, аннан соң Манеж мәйданын үттем. Александр бакчасының коймасы буендагы тротуарга меңгәндә сыбызгы тавышы ишетелде. Борылып, тавыш килгән якка карадым. Кызыл чырайлы таза бер милиционер ашыгып миңа таба килә иде:

— Яшәүдән туйдыгызмыни, гражданин? Сезнең аркада чак кына авария булмый калды. Биш сум штраф! — дип, милиционер квитанция кәгазе сузды. Мин кесәләремне актарып, булган акчамны учыма җыйдым. Кесәмдә дүрт-биш бакыр һәм ике-өч көмештән башка акча калмаган иде.

— Мәгез,— дип, акчамны милиционерга суздым.

— Давай паспортыңны,— милиционерның шелтәле тавышы көчәя бара иде,— эшләгән җиреңә язып тәртипкә утыртыйм әле!

Түш кесәмнән алып, зәңгәр тышлы студент билетын милиционерга суздым.

Укып карагач, милиционер билетны кире кайтарып бирде:

— Җыен ачык авызны шушы йортка җыйганнар. Язып та торасы юк, барыбер чара күрмәячәкләр,— диде дә борылып китеп барды.

Учымдагы акчаларны кире кесәмә салдым да бакчага кердем. Бакча уртасындагы аллеядан Кызыл мәйданга — Мавзолейга таба әкрен генә кешеләр агымы шуышып бара. Мин, узып, Кремль стенасы буенда үскән юкә агачлары астындагы аулак эскәмиягә барып утырдым.

Эскәмиянең икенче башында пөхтә генә киенгәнябык гәүдәле бер карчык кояшта әлсерәп утыра иде. Карчык, күзләрен яртылаш йомып, еракта калган яшьлек хатирәләре дөньясына чумган, ахры. Ул мине күрмәде дә. Ул эчкә таба ямьшәеп кергән иреннәрен кыймылдатып үзалдына нәрсәдер сөйләнә, ара-тирә шатлыксыз гына елмаеп куя иде.

«И-их, еллар үтә: еллар үткән саен тәҗрибә өстәлә. Тәҗрибә өстәлгән саен дәрт-дәрман кими. Уйлап карасаң, дөньяда бер нәрсә дә бушка бирелми. Һәр нәрсә өчен тутырып хак түләргә кирәк. Белемне, тормыш тәҗрибәсен яшьлекнең чәчрәп торган кайнар энергиясенә алыштырып алабыз. Хәтта яшәүнең үзе өчен дә түләмичә булмый... Сынауга әзерләнүгә никадәр көч түктем. Уйлап эшләргә түземлегем җитмәде. Психик атака, мактанасы килү харап итте мине...»

Эскәмия каршысындагы чирәмлектә җим чүпләгән күгәрченнәрне куып йөрүче сабый бала, мине күргәч, туктап, бераз карап торды да, кәкре аяклары белән алпан-тилпән атлап, арырак китте.

Зур шәһәрнең шау-шуы агачлык аша бакчаның бу почмагына да килеп җитә иде. Көн яктыра башлау белән таш йортларда яшәүче җан ияләре асфальт урамнарга, киң мәйданнарга чәчеләләр. Алар иртәдән кичкә кадәр туктаусыз атлыйлар, эшлиләр, сөйләшәләр, ашыйлар, ләкин никадәр тырышсалар да, авыл кешеләре шикелле бер-берсе белән якын торып яши алмыйлар. Бәлки мин дә шушы ашыгу, кабалану аркасында хыялыма омтылуны югалтып, адашып калганмындыр? Авыл башындагы яшел чирәмлектә, инеш буе тугайларында аунап үскән малайның яшьлек хыяллары шушындый идеме соң әле?

Эскәмия каршысында тутәлдә үскән кызыл чәчкәгә бал корты килеп кунды. Мондагы биек таш йортлар, завод биналары аша ничек үтеп керә алган ул?! Машиналар төтененә ысланып үскән чәчәкләрдә ширбәт бармы икән соң? Шушы тузанлы чәчәкләрдән ширбәт җыйгач, юл табып кире умарталыгына кайта алырмы ул? Бал корты, бөҗәккәем, таш гигантлар, адаштыргыч урам чатлары арасында адашудан курыкмыйча ширбәт эзләп йөрергә синең ничек йөрәгең җитә?

Мин дә белем ширбәте җыйгач, җиңел генә үз юлыма чыгармын дип, шушы гигант лабиринтка килеп кергән идем...

## 18

Җәйге каникул вакытында без Баграт белән Кара диңгезнең берәр портында йөк ташучы булып ялланырга хәзерләнеп йөри идек. Багратның мускулларын ныгытып аласы, диңгезчеләр тормышы белән якыннанрак танышасы килә. Ул диңгез темасына сценарий язарга хыяллана иде. Минем, мускуллардан тыш, киләсе елга кадәр кесәләремне дә «ныгытып» куясым килә иде. Хәзер инде бу планны җиңел генә эшкә ашырып булмаслыгы ачыкланды. Минем сынау биргәнемне көтеп Багратның Мәскәүдә ятасы килмәс. Көтәргә риза булса да, мин аны көттерергә тиеш түгелмен.

Менә хәзер нинди дә булса бер нияткә килергә дә, урыннан торып, шул ниятне эшкә ашырырга керешә башларга кирәк! Эшкә тотыну һәр вакыт буталчык фикерләрдән котылырга ярдәм итә.

Мин урынымнан кузгалырга өлгерә алмый калдым. Башымны күтәреп аяк тавышы ишетелгән якка борылып карадым. Чуалган җепкә охшаган уйларым бер мизгелгә югалып калдылар: эскәмия каршында Голливуд фильмнарындагы артисткага охшашлы бер кыз басып тора иде.

— Бу урын бушмы? — диде ул, гаҗәп матур елмаеп.

— Буш, рәхим итегез.— Мин читкәрәк шуышып утырдым.

Кыз сул кулы белән күлмәк итәген төзәтеп алды да минем янума килеп утырды.
Бу кызны минем икенче күрүем иде.
Лекциядән чыккач, Стромынкага кайту өчен метрога төшеп килә идек, шул чак Баграт, минем кабыргама төртеп:
— Габдрахман, кара әле,— диде.
Эскалатор баскычындагы кыз кино кадры шикелле минем күз алдымнан шуышып узып китте.
— Бу нәкъ минем идеалым. Бу кызны мин җир астыннан булса да эзләп табачакмын,— дип, Баграт кыз китеп югалган якка карап тора башлады.
— Моннан да чибәррәкне очрату белән аны онытачаксың,— диде Өметгали.
— Юк, егетләр, теләсәм дә, оныта алмаячакмын. Сихерләде бу мине. Инде төшләремә кереп интектерәчәк,— диде Баграт, хискә бирелеп.
Багратның чынлапмы, шаярыпмы сөйләгәнлеген аңлавы кыен иде. Без аның әнә шулай кинәт кенә кабынып китеп, дөрләп яна башлавын белә идек. Шуңа күрә аның бу сүзләрен шаяртуга санап көлдек тә, университет хәлләренә күчеп, сынауга хәзерләнү турында план корырга тотындык.
Гаҗәпкә каршы, кызның тышкы кыяфәте минем хәтеремдә дә сурәтләнеп калган иде. Күз салу белән мин аны танып алдым.
Тагын бер хәл мине гаҗәпкә калдырды: Мәскәүдә еллар буе йөреп тә таныш кешене капыл гына урамда очратып булмый. Күзгә бер генә мәртәбә чагылып киткән кешене болай очрату күңелгә ниндидер шом салып куйды.
Кыз матур иде. Саргылт чәчләре дулкынланып җилкәләренә сузылып төшкән. Беркадәр калынрак күренсә дә, үтә матур итеп уелган алсу иреннәр, озын керфекләр астына яшеренгән серле зәңгәр күзләр. Ялан тәнгә кигән юка йон пуловер кызның калку күкрәгенә, бил нечкәлегеннән аска таба салмак кына киңәеп киткән янбашларына сыланып, гәүдә сылулыгын сиздереп тора.
Чибәр кызларның кайберләре, матурлыкларыннан оялып, кешегә туры карарга кыймыйлар. Бу кызның үз-үзен тотуы, киресенчә: «Мин чибәр, чибәрлегем кимер дип, саранланып торасым юк, мәгез, карагыз, ләззәтләнегез», дип әйтеп тора шикелле иде.
Мин күңелдә матур кызлар кузгата торган катлаулы тойгыларга бирешмәскә тырышам. Ләкин, никадәр тырышсам да, матурлык кузгаткан ләззәтле дулкынлануга каршы торырга көчем җитми.
Кызларның матурлыгына сокланганда мин бераз акылы җиңеләйгән кеше шикеллерәк күренә идем булса кирәк. Йөргән кызларым минем матурлыкка чамасыз соклануымнан файдалы нәтиҗә ясап алалар иде: «Матурның да матуры булмасам, бу йолкыш миңа болай шашынып сокланмас иде. Матурлыгымның кадерен белим әле. Мондый чибәрлегем бар чагында бу хәчтерүш белән очрашып, базарны төшермәскә кирәк. Миңа ким дигәндә өч мәртәбә Советлар Союзы Герое тиңдер...» дигән фикергә килеп, чибәр кызлар тизрәк миннән икенче якка тартәләрен боралар иде.
Саргылт чәчле бу кыз, минем сокланып караганымны сизсә дә, борынын чөймәде. Ул... «әйдә, соклана бир, сокланудан минем матурлыгым арта гына. Ләкин бел: минем өчен егетләрнең поты бер тиен» дигән кыяфәттә тәкәббер генә утыра бирде. Ул башын чайкап чәч дулкыннарын чөебрәк җибәрде дә озын керфекләрен тибрәтеп сәгатенә карап алды.
Мин бу кызның кемне дә булса көтеп утырганлыгын аңладым. Егетен көткән кыз янында сырпаеп утыру әдәпсезлек иде. Шуңа да кара-

мастан, мин, урынымнан кузгалып китә алмыйча, кызга ара-тирә күз сирпеп кенә караштыргалап утыруымда дәвам иттем.

Бераз вакыт үткәч, тарих музее ягыннан бер егет килеп чыкты. Ул ашыгып безгә таба атлый иде. Егет безгә якынлаша төшкәч, мин аны танып алдым. Өметгалинең кунагын каршылаган көнне минем белән ашханәдә утырган студент — Феликс иде бу.

Кызны күрү белән Феликс минем шикелле хискә бирелеп җебеп төшмәде. Аның адымнары салмаклана төште, йөзенә гамьсезлек билгесе чыкты. Минем танышымның кыяфәте: «Син чибәр, анысы бәхәссез, әмма минем синнән чибәррәкләрне дә күргәнем бар...» дигән сыман иде.

Уртак бер тәкәллефсезлек боларны якынайта иде булса кирәк. Кыз да, Феликсны күргәч, урыныннан сикереп тормады. «Килмәсәң дә бик исем китмәс иде әле» дигән сыман, ашыкмыйча гына үрелеп яңагын Феликсның иренәнә тидереп алды.

Шушы ритуал беткәннән соң гына Феликс миңа таба борылып кулын сузды:

— Минем Элеонорам кем белән утыра икән дип уйлап киләм. Таныгач, шатланып киттем. Сине күптән күрәсем килә иде. Нора, син танышмы? Минем дустым Гап... Гап... валлаһи, тагын оныттым исемеңне. Гафу ит.

— Габдрахман,— дидем мин, Феликска ярдәмгә килеп.

— Нора,— диде Феликсның җанашы елмаеп.— Сез гарәп түгелсездер бит?

Елмайганда күренеп киткән сирәк тешләре дә Элеонораның матурлыгына зыян китерерлек түгел иде.

— Гарәп түгел, фарсы, — дидем мин шаярып.

— Феликс, фарсылар борынгы Грециядә яшәгән халыкларны әле? Фарсылар турында минем ишеткәнем бар кебек.

— Фарсылар, Норочка, борынгы греклар белән сугышкан халык. Хәзер алар Иранда яши,— диде Феликс елмаеп.

— Феликс, син бөтен нәрсәне беләсең. Күп белүең просто минем саруымны кайната.

Сөйләшү бу юнәлешкә таба борыла башлагач, мин урынымнан кузгалдым.

— Хушыгыз. Минем барасы җирем бар иде.

— Кая ашыгасың? Сине күрер өчен мин ике мәртәбә Стромынкага бардым.— Феликс теге вакытта әҗәткә алган акчаны оста гына итеп минем кесәмә тыгып куйды.— Киләсе шимбәдә мин Одессага китәм. Читтән торып укырга күчмәкче булам. Диңгезгә кире кайтырга ниятләдем. Саф һава, романтика, маҗаралар, экзотика. Киттекме бергә? — Соңгы сүзләрен Феликс хәтта ничектер тылсымлы итеп әйтте.

— Белмим шул,— дидем мин, Феликсның тәкъдиме үземне кинәт таркаулыктан арындырып җибәргәнне сизеп.

— Ул һәр очраган кешене шулай йөзү эшенә урнашырга кодалап йөри инде,— диде Элеонора.— Диңгезчелек тә булдымы һөнәр!..

— Диңгезчелек — дөньяда иң әйбәт һөнәр,— диде Феликс, кызының фикеренә каршы.— Беренчедән, диңгезчегә зарплатага өстәп син ярата торган валюта түлиләр, икенчедән, бу эштә ир-егетнең иң чыдамы гына эшли ала. Өченчедән, Мөхәммәт пәйгамбәр әйткән: «Җирдәге җәннәт — ат сыртында, гакыл китабы битендә һәм кызлар кочагында», дигән. Әгәр ул заманда сәяхәткә пароход белән йөрү булса, Мөхәммәт беренче урынга пароходны куйган булыр иде. Шулай итеп, Мөхәммәт сәяхәтне беренче, укуны икенче, ә кызлар кочагын бары тик өченче урынга гына куйган.

— Синең Мөхәммәтең кеше алдында кызларны өченче урынга гына

куйса да, житмеш хатын тоткан кара надан булгандыр әле. Ирләр изге булып сөйләшергә генә яраталар алар,— диде Элеонора.

— Бу турыда ныклап сөйләшәсем килә. Син кайчан Стромынкага киләсең? — дидем мин Феликска.

— Дездемона җибәрсә, хәзер үк барыр идем. Рөхсәтсез китә алмыйм: язмыш аның кулында,— дигәч, Феликс кызына таба ымлап күрсәтте.

— Дурт ягың кыйбла. Бөтенләй китсәң дә бер сүзем юк,— Элеонора карага буялган авыр керфекләрен күтәреп миңа таба күз сирпеде. Аның бу карашыннан: «Менә күрәсезме, үземнең алтыннан кыйммәт матурлыгымны шушы юньсез кулына тапшырып, харап кына булдым инде» дигән корбанлык сизелә иде.

«Бу егеткә алла ярдәм бирсен инде»,— дип уйладым да, саубуллашып, метрога таба юл тоттым.

Феликсның коткысы бу юлы күңелем әрнеп, юаныч эзләгән чакка туры килде. Диңгез ягына китү турында мин чынлап уйлый башладым.

## 19

Борынгы рус әдәбиятын Баграт дүртлегә тапшырып кайткан иде. Мине юатыр өченме, ул профессор Гудзенконы яманларга тотынды:

— Бишме-алтымы студентка икеле куйды. Хәзер инде аларга стипендия бирмәячәкләр. Марат Щеголевтан башка беркем бишле ала алмады.

Щеголев рус әдәбияты күгендә калкып чыгачак зур талант йолдызы иде. Беренче курста укыганда ук аның мәкаләләре әдәби журнал битләрендә күренә башлады. Сәләте һәм сәламәтлеге белән Белинскийга охшашлы Щеголев, университетны бетергәч, озак яши алмады. Әдәбиятта эз калдырып, Ваганьков зиратына күчте.

— Бишле артыннан куып гомеребез үтә, егетләр,— дидем мин.— Мин бүген укуын ташлап диңгез эшенә китүче бер студентны озаттым. Әллә безгә дә шуңа ияреп китәргә инде?

— Каникул вакытында ярый торган эш ул, мин риза,— диде Баграт.

— Читтән торып кына укырга да исәбем бар,— дидем мин. Моңа кадәр бу турыда уйланмасам да, иптәшләремә фикеремне әйткәч, бу ният ничектер күңелгә вәсвәсә салды.

Өметгалигә бу фикер ошамады:

— Читтән торып уку стационарга житми инде. Килеп-китеп кенә укучыларның күбесе диплом алу өчен генә йөриләр бит.

— Диплом өчен генә укучылар стационарда да житәрлек ул. Йөзү эшендә укырга вакыт табып була, диләр. Шуңа өстәп, анда саф һава сулыйсың, дөнья күрәсең, экзотика, романтика, кешенең дәрәҗәсен күтәрә торган авыр, җаваплы эш.— Мин иптәшләремә Феликсның сүзләрен кабатлап, йөзү эшенең уңай якларын санап киттем.

— Юләрләнмә. Соңыннан үкенерсең. Университетны бетерү белән сине аспирантурада калдырачаклар. Акыллы кеше шундый перспективаны зимагурлыкка алыштырамыни? — дип, Баграт мине чын күңелдән үгетли башлады.

— Тузан баскан кагыйдәләрне ятлап гомер уздырасым килми,— дидем мин.— Кулларым исән чакта ирләр эше эшләп карыйсым килә. Диңгез давылларын, тропикның караңгы төннәрен үз күзем белән күрергә хыялланам. Мәрҗән атавында үскән пальма яфраклары кыштырдавын ишетү үзе генә дә ни тора!..

Баграт мине тагын үгетләмәкче иде, Өметгали аркылы төште:

— Үгетләмә шуны, безне үртәр өчен генә сөйли бит ул. Китсен. Йөзү эшенең нужасын татып карагач, күрерсең, бик тиз урап кайтыр. Җаны теләгән — елан ите ашаган, диләр, үгетләмә.

Өметгали дөрес әйтә иде. Моңа кадәр мин күңелемне юатыр өчен генә шулай кылана идем. Өметгали ниятемне фаш иткәч, сүземне сүз итү өчен чын күңелдән дингезгә китүне якларга тотындым:

— Бергәләп китик, Баграт. Филфактан тагын бер студент бара. Ул университетка кергәнче берничә ел диңгездә йөзгән. Уйлап кара, китик, Баграт. Башкача ничек син дөнья күрә аласың? Укуны тәмамлап, эшкә билгеләнгәч, беркая да китеп булмас. Теләмәсәгез, кыстамыйм, әмма мин китәргә ниятләдем. Әгәр шушы хыялымны тормышка ашырмыйча калсам, гомергә үкенәчәкмен.

— Мин дә уйлап карармын әле. Дөньяга чыгарлык бер сценарий язасым килә. Шуны язганчы башка бернәрсә турында да уйлыйсым килми...— Университетны тәмамламыйча Багратның беркая да китмәячәге билгеле иде. «Уйлап карармын» дигән сүзне мине юатыр өчен генә әйтте ул.

— Синең бу кылануың — һавадагы торнага карап кулыңдагы чыпчыкны очыру инде,— дип, Өметгали, минем күңелемне калдырудан курыкмыйча, турысын әйтте.— Арымадыңмы син, Габдрахман? Борынгы рус әдәбиятын тапшырып каникулга китсәң ничек булыр? Ял ит, көч җый. Диңгез синнән качмас. Ниятең үзгәрмәсә, китәрсең. Белмим, дәрвиш булып йөрүдән нинди мәгънә табарсың икән?

— Акыллы киңәш бирүегезгә рәхмәт, уйлап карармын әле,— дидем мин.

Мин инде китәргә ниятләгән идем. Бәлки чыннан да ялгыша торганмындыр. Ялгыша торган гадәтем бар минем, беләм. Ләкин, никадәр тырышсам да, башка кешеләр шикелле ялгышмыйча, үз җаема, үз файдама гына яши алмыйм шул.

Баграт киенеп-ясанып кызы янына китте. Өметгали сынаугa хәзерләнергә утырды. Мин аңа комачауламас өчен ишегалдына чыктым. Сирень куагы астындагы эскәмия буш иде. Шунда барып утырдым да уйларыма чумдым.

## 20

Авиациядән киткәндә дә иптәшләрем мине, китмә, ялгышасың, дип үгетләгәннәр иде. Мин аларның сүзен тыңламадым, киттем.

Очу эше дә уку шикелле ошый иде миңа. Очучылык һөнәрен мин дөньядагы бер һөнәргә дә алыштырмас идем. Шулай тормыштан тәм табып, бәхетле генә яшәгәндә безнең экипаж авариягә очрады. Мин өч ай госпитальдә яттым. Госпитальдән чыгар алдыннан сәламәтлегемне җентекләп тикшерделәр дә, очу эшенә ярамыйсың, дигән катгый карарга килделәр.

Ул чакта мин очмыйча яшәүне яшәүгә санамый идем. Госпитальдән чыгу белән, очу эшендә калдыруларын сорап, полк командиры исеменә рапорт яздым.

Берничә көннән соң полк командиры полковник Трошкин мине штабка чакырып алды.

— Сез бала-чага шикелле кыланасыз, лейтенант Рахманкулов. Бу килеш сезгә һавага күтәрелергә кем рөхсәт итсен. Аксыйсыз, нервыларыгызга зыян килгән. Вестибуляр-вегетатив сизгерлегегез зәгыйфьләнгән. Мин сезне штаб эшенә билгелим. Сәләтле кеше штаб эшендә дә тиз күтәрелә ала. Сәламәтлегегез арулангач, кире очу эшенә кайту мөмкинлеге дә калыр. Бу эш сезгә ошарга тиеш, уйлап карагыз.

Мин штаб эшенә күчәргә риза булмадым. Полк командирының кабинетыннан чыгу белән, кире очучылыкка кайтаруларын сорап, кор-

пус командиры исеменә рапорт яздым. Корпус командиры полковник Трошкин әйткән тәкъдимне кабатлады. Шуннан соң мин һава армиясе командующиена мөрәҗәгать иттем. Рапорт кире полкка әйләнеп кайткач, замполит чакырып алып кисәтте: «Әгәр тагын бер мәртәбә рапорт язып гауга куптарсаң, без сине аэродром саклау ротасына билгеләячәкбез»,— диде. Ана каршы сүз әйтмәскә кирәк иде — мин түзмәдем: «Бүген үк Оборона министры исеменә рапорт язам»,— дидем. Әллә бу бераз акылга җиңеләйгәнме дип, замполит бер тын миңа текәлеп карап торды да: «Мересьев үрнәге сугыш вакытында кыйммәтле иде. Синең тавыш куптарып, очу эшенә кире кайтуларын даулап йөрүең минем шикләндерә. Бу гауга очучыларга түләнгән зур зарплата өчен түгелме икән?» — диде.

Мин шул ук көнне демобилизацияләүне сорап рапорт яздым.

Шушы юл белән замполиттан үч алам дип уйлаган идем мин. Исәпләп карагач, бу кыланышымның гади бер дуамаллык икәнлеген соңга калып булса да аңладым.

Хәзер инде мин аксамыйча йөрим. Төннәрен интегеп йокысыз ятудан да котылдым. Бары тик үземнең дуамаллыгымнан, үземә зыян итә торган эш эшләүдән генә һаман арына алмыйм. Бу гадәт минем канымда, күрәсең. Әгәр полк командирының сүзен тыңлап, штаб эшендә калган булсам, хәзер мин очучылар сафында булыр идем инде.

Тулай торак ишегеннән Өметгали килеп чыкты. Кемнедер эзләп ишегалдында бер тын каранып йөргәннән соң, яныма килеп утырды:

— Маштаков бер төркем фанатик иярте алып кайтты. Аның коллекциясендәге Черчилльнең сигара төпчеген тикшерергә килгәннәр Бәхәсләшәләр. Атаклы Британия политигы гомер буе Гавана сигарасы тарткан икән. Ә Маштаковның төпчегендә «Төркиядә эшләнгән» дип язылган.

— Гомер буе гел бер төрле сигара тартмагандыр инде,— дидем мин.

— Ул кеше гомер буе әрмән коньягы эчкән, Гавана сигарасы тарткан, диләр. Йокыдан торгач, физзарядка урынына бакчасына чыга икән дә кирпечтән дивар сала икән. Үзе кереп киткәч, хезмәтчесе стенаны сүтеп, иртәгә эшләргә кирпечләрне яңадан әзерләп куя икән, дип сөйләделәр.

— Кара әле, Өметгали, Черчилль нәкъ сиңа охшаган икән. Син дә бит гадәтеңне бер тамчы үзгәртми яшисең.

Мин шулай дигәч, дустым көлеп җибәрде:

— Гадәт үзгәртми торган кешеләрне синең күргәнең юк әле. Безнең Өчарык кешеләре ата-бабадан калган гадәтләрне бер генә миллиметрга да үзгәртмиләр. Аларның өсләрендә гомер буе гел бер төрле кием булыр. Утыз градуслы кышкы суыкта да, кырык биш градуслы җәйге эсседә дә Өчарык үзбәкләренең өстендә сырган чапан, башларында түбәтәй, аякларында йомшак үкчәле читек булыр.

Кинәт шунда шәрык кешесенең акыллы булуын аңлап алдым. Яңа эшкә күчеп, яңача яши башлау турында план коруы гына җиңел. Яңа урынга күнегергә кирәк. Яңа эшне өйрәнергә, яңа һөнәрнең тәҗрибәсен тупларга кирәк. Яңа кешеләр арасында яңа авторитет, яңа абруй яуларга кирәк. Яңа коллектив куйган шартларны үтәү җиңел эш түгел. Моңа никадәр көч түгәргә туры килә. Әллә чыннан да китмәскәме?

Өметгали миңа якынрак килеп утырды:

— Юләр кеше шикелле тагын сорыйм әле: син бит безне үртәр өчен генә университеттан китәм дип йөрисең, әйеме?

— Юк, чынлап китәргә җыенам.

— Аңлашылды. Башкача төпченмәячәкмен. Синең миңа аңлашылмый торган үз исәбең бардыр инде.

— Үз исәбең дип, шул тынгысызлык хастасыдыр инде. Кош булып һавада очуның ләззәтен очучы гына белә. Самолетка утырганда мен-

ләгән ат көчле мотор гайрәте генә түгел, очкычтагы кыюлык та синең белән яши. Очкан чакта уйларың, тойгыларың үзең белән бергә биеккә күтәрелә. Бу кичереш диңгезчеләргә дә таныштыр дип уйлыйм мин.

Өметгали бер тын уйланып утыргач әйтте:

— Белмим, синең ашкынуыңда ниндидер ясалмалык бар шикелле. Бәлки андый тойгылар миңа таныш түгелдер. Әйдә, кереп ятыйк. Маштаковның кунаклары киткәннәрдер инде.

Бүлмәбезгә кергәч, тәрәзә янына барып утырдым да, ай яктысына чумган төнгә карап, таң атканын көтә башладым.

Яшәү киләчәктә булачак зур вакыйгаларга хәзерләнү шикелле генә тоела. Хыялларның тормышка ашуы, теләкләрнең үтәлүе — барысы да шул киләчәк карамагында.

Июнь аеның кыска төне тәмам сыекланып, таң яктылыгында эри башлагач, Баграт кайтты.

— Танышканда җир йөзендә моннан да чибәр, моннан да акыллы кыз юктыр инде дип уйлыйм. Йөри башлагач, аның мин эзләгән кеше түгел икәнлеген аңлыйм.

— «Пер Гюнт»ны тагын бер мәртәбә укып чыгарга кирәк сиңа.

— Үзең нигә йокламыйсың? Бүген мин барган җирдә Валерия дә бар иде. Борынгы рус әдәбиятыннан «икеле» алганлыгыңны аңа әйтмәдеңмени? Синнән зарлана. «Бишле билгесе булса, аңа дөньяда башка бернәрсә дә кирәкми», ди.

Ул одеалын ябынып йокларга ятты.

Дусларымның өчесе дә тыныч кына йоклыйлар иде. Тулай торак яныннан дөбердәп трамвай узды. Борылып, Яуза яры буендагы тыкрыкка кереп китте.

Иртәнге кояшның кызгылт нуры Баграт ябынган йон одеалга төште. Зур шәһәр әкренләп йокыдан уяна башлады.

Мин караватымнан торып, ашыкмыйча гына киендем. Чыгып, юынып кердем. Хәзер минем ниятем тәмам ныгып өлгергән иде. Мондый хәлне борынгы римлылар «арттагы күперне яндыру» дип атаганнар.

Ашыкмыйча гына дежур торучы өстәлендәге телефон янына килдем, блокнотка язылган цифрларга карап, номер җыйдым:

— Феликс, синме бу? Хәерле иртә. Юк, Габдрахман бу. Гафу ит, мин синең алай соң ятканлыгыңны белмәгән идем. Әйе, риза. Син үзең кайчан китәргә уйлыйсың? Әйе, синең белән.

Хәзер Феликс сөйләргә тотынды. Ул минем китәргә ниятләвемне хуплый, юлдаш табылуга шатлана иде:

— Алай булгач, хәзер үк Киев вокзалына бар да чиратка бас. Алдан алып куймасаң, Одессага барырга билет табып булмый, диләр. Курорт сезонының кызган чагы бит, аңлыйсыңмы?

— Ярый, мин сине касса янында көтәм,— дидем мин.

## 21

Гаризамны укып чыккач, декан папкага теркәгән кәгазьләрне өстәл тартмасыннан алып, алдыма салды:

— Менә болар стационарга күчәргә теләүче заочникларның гаризалары,— диде ул.— Аннары гаризамның почмагыннан тотып, селкеп күрсәтте:— Мондый гариза әле бары берәү генә. Кәефкә бирелеп кенә язмагансыңдыр бит?

— Яхшылап уйладым, Родион Михайлович... Эшләп укырга көчем җитәр шикелле.

— Бу сессияне гел бишлегә генә бирергә дә көчегез җитәр шикелле иде дә бит. Ә нәтиҗә ничек? Әллә нинди дуамал кеше сез, Рахман-

кулов. Киңәшем шул: тагын бер атна уйлап карагыз да ниятегез үзгәрмәсә, гаризагызга кул куярмын.— Мин коридорга чыккач, декан кабинетының ишегеннән башын сузып миңа эндәште.— Рахманкулов, сез факультетның комсомол оешмасы секретаре белән дус бит. Аның белән дә киңәшеп карагыз. Ул нәрсә әйтер?

Урамга чыккач, бер тын кая барырга белмичә аптырап тордым. Күптән инде тулай торакка җәяү кайтканым юк иде. Җиде-сигез чакрым араны адымлап үлчисем килеп китте. Киткәнче Мәскәү урамнары белән саубуллашырга кирәк иде.

Моховой урамы белән бара торгач, Госплан йортын, Зур театр бинасын үттем дә Дзержинский мәйданына килеп чыктым.

Без яшәгән көннәр каядыр китеп югалалар. Алар урынына без көткән киләчәк килә тора. Вакыт һәр нәрсәне үзгәртә. Киләчәк бүгенгегә әйләнгәч, ни өчендер без көткән тылсымлыгын югалта, гадиләнә, тоныклана төшә. Артта калган көннәр инде синеке түгел, алдагы көннәр — исән булсак, безнеке. Көч бар чакта эшлисе эшне эшләп, яулыйсы позицияләрне яулап калырга кирәк. Картая башлагач, хыялыңа ияреп диңгезгә чыгып китә алмассың.

Дзержинский мәйданын үтеп, Киров урамына кергәндә миемдә фикерләр өере кайный иде. Тагын үз хәлемә кайтып, укуны ташлап ялгышкан тәкъдирдә аклана алырлык дәлил эзләп таптым: «Башка студентларның стационарга ябышып ятулары шуннан: алар әзер белемне генә үзләштереп, авызларына чәйнәп салганны яраталар. Мине андый белем генә канәгатьләндерми. Тормыш дигән зур, даһи китаптагы бөек фәнне үзләштерәсем килә...»

Күңелдә кинәт шом туды. Бу масаю түгелме соң? Бишлегә укырга көч җитмәгәч, авырлыктан качу, чигенү түгелме?

Главпочтамтны үтеп, атаклы француз архитекторы Ле Корбюзье проекты буенча салынган Центросоюз бинасы янына туктап карап тора башладым.

Ле Корбюзье егерменче гасырда туачак мөмкинлекләрне башкалардан алдарак аңлаган. Даһи кеше чордан алдарак бара. Шуңа күрә замандашлары аны аңлый алмыйлар. Бөек француз архитекторы коммунист Ле Корбюзье яңалык җиңсен өчен гомер буе искелеккә каршы көрәшкән.

Ә мин көрәштән куркып чигенәм түгелме? Үз-үзеңне тәнкыйтьләсәң дә, авыртмаслык итебрәк тәнкыйтьлисең. Менә мин хәзер дә үземне аклап юатып куйдым: читтән торып уку чигенү түгел. Киресенчә, эш белән укуны бергә алып бару — икеләтә авыр вазифа...

Садовое кольцоны үтеп, Кызыл капка метросы янындагы мәйданга чыкканда, күңел бераз тынычлана башлаган иде инде. Мәйдандагы яңа салынган биек йорт янында туктап бераз ял иттем. Университетның яңа бинасы шикелле шпильләр, башнялар белән бизәлгән берничә биек йорт башкаланың панорамасына кереп өлгергән иде инде.

Өч вокзал арасына урнашкан Комсомол мәйданын үттем. «Онытырга ярамый, комсомол секретаре Вадим Козырев белән саубуллашып чыгарга кирәк. Учеттан төшкәндә аның туры килмәве мөмкин. Ул Котып диңгезендәге метеостанциядә өч сезон эшләгән кеше. Аның белән киңәшү зыян итмәс».

Сокольники метросына якынлашканда ниятем тәмам ачыкланган иде инде. «Дөньяда бары тик бер генә мәртәбә яшәлә. Гомерне күңелемә ошамаган эш белән үткәрергә минем хакым юк».

Экскаватор грейферына охшатып салынган Русаков клубы бинасын үткәч, Яуза күпере күренде. Күпергә җитәрәк уңга борылып, тулай торакның ишегалдына кердем.

Бүлмә ишеге бикле иде. Дежур торучының запас ачкычы белән ишекне ачтым. Өметгали, һичшиксез, китапханәдә сынауга хәзерләнеп утыра инде. Маштаков та лекцияләрен кабатлау эшенә керешкән булса кирәк. Тур Хейердал артыннан йөреп, ул шактый вакытын югалтты. Баграт Мәскәү магазиннарыннан чирәм җирдә киеп йөрерлек эш киеме эзли иде.

Сынауларын биреп бетергәч, элек корган планын үзгәртеп, Баграт комсомол путевкасы белән чирәм җиргә барырга язылып кайтты. Ул эшне сәхнәдәгечә башкарырга ярата. Уйнаячак роленә җентекләп хәзерләнә. Хәзер минем ул дустым — дала яулаучы ролендә. Бу дөньяда рольсез яшәп булмый. Бала чакта ук «Үскәч син кем буласың?» дип тенкәнне корыта башлыйлар. Беркем дә булырга теләмичә, адәм баласы гына булып калу ни өчендер купләргә ошамый.

Тукта инде. Һаман фәлсәфә чытырманлыгына керәсең. Әйберләрне җыеп, китәргә әзерләнергә кирәк. Бүлмәдә беркем юк. Әзерләнү өчен уңайлы чак.

Тумбочкада, өстәлдә, тәрәзә төбендә өелеп яткан китапларымны җыеп, китапханәгә илтеп тапшырдым. Китапханәнең уку залында Өметгали белән Маштаков, дөньяларын онытып, сынауга хәзерләнеп утыралар иде. Мин аларга кызыгып куйдым.

Конспектларымны җыеп, саклау камерасына илтеп тапшыргач, аннан чемоданымны алып чыктым. Бу чемоданны миңа, аерылышкан чакта, дустым Рәдиф Агишев истәлек итеп биргән иде. Без аның белән эскадрильяның бер экипажында хезмәт иттек. Ул — самолетның техникы, мин — штурман. Мин кичләрен чалбарымны үтүкләп, итегемне ялтыратып чистартам да танцыга чабам. Рәдиф көне-төне укый, урта мәктәпне экстерн юлы белән тәмамларга әзерләнә. Мин Рәдифтән көләм: «Кагыйдә ятлап утыру хәрби кеше эшемени? Авиатор элекке гусарлар шикелле фани дөнья мәшәкатенә төкереп, типтереп яшәргә тиеш!» — дим.

Мине госпитальгә салдылар. Бергәләп танцыга йөрүче дусларым әллә оныттылар, әллә яныма килеп йөрергә вакытлары булмады. Рәдиф көн саен диярлек, култык астына китап кыстырып, минем хәлемне белергә килә иде. Терелеп госпитальдән чыккач, мин танцыга йөрүчеләр лагереннан китап укучылар ягына күчтем.

Чемодан капкачының эчке ягында Рәдифнең туган җиреннән кузгалып киткәннән соң үткән юлы сурәтләнгән иде: Акмулла — Волжск — Иркутск — Семферополь — Мелитополь.

Чемодан Мелитополь шәһәрендә миңа күчте. Мелитополь сүзе астына кайчан аерылышканлыгыбызны тамгалап куйганнан соң, яшәгән шәһәрләрнең исемнәрен язуны дәвам иттердем: «Харьков, Запорожье, Курман-Кемильче, Воронеж, Проскурино, Оренбург, Новосибирск, Омск, Иркутск, Хабаровск, Комсомольск, Уэлен, Казан, Поневежец, Кировобад, Владивосток, Көньяк Сахалин, Смирных, Елизово, Зональное, Караяр, Мәскәү.

Иптәшем биргән чемоданны күтәреп, мин Запорожье шәһәрендәге авиагарнизонга килдем. Аннан соң Воронеждагы реактив самолетларда очарга өйрәнү үзәгенә эләгүем, перегон отряды белән Союзның бер почмагыннан икенче почмагына йөрү. Хәрби юридик академиягә кереп берничә ай укыганнан соң кире авиациягә күчеп, Сахалинга җибәрелү, анда тагын Рәдиф белән очрашу, боз өстенә утыруны сынау өчен Котып дингезенә очу, очучылыкка ярамый башлагач, Караярыма кайтып ял итү һәм Мәскәүгә килеп укырга керү — болар бар да чемодан капкачы эченә сызып куелган.

Эти мәрхүмнең тәҗрибәсе миңа да күчкән булса кирәк. Бу бит этинең урман эченә кергәндә куеп калдыра торган билгеләре шикелле. Минем Одессага китәргә җыенганымны белсә, ул нәрсә әйтер иде икән? Хәзер аның билләре авыртмый торгандыр инде. Авыруын яшермәгән булса, аны сугышка алмыйлар иде инде. Ни өчен комиссия торганда чирен яшерде икән ул?

Теле булса, чемодан күп хатирәләр сөйли алыр иде. Ул дәшми.

Юыну бүлмәсенә чыгып, чүпрәк чылатып алып кердем дә чемоданга кунган тузанны сөрттем. Тузан астыннан таушалып беткән иске күн пәйда булды.

— Дустым, тагын юлга кузгалырга туры килә. Безгә бер урында гына тынычлап яшәргә язмагандыр, күрәсең, — дидем мин аңа. Чемодан җавап бирмәде. Картаюдан таралып төшәргә торса да, ул минем белән кузгалып китәргә берсүзсез әзер иде.

— Хыялыбыз тормышка ашса, без синең белән Стамбул шәһәренең мәшһүр манараларын күрербез. Ерак диңгезләрне кичеп, Сингапурга барып җитәрбез. Моңа кадәр син гадел юлдаш булдың. Бергә йөргәндә юлыбыз уңып торды. Киләчәктә дә безнең юл уңарга тиеш. Исеңдәме, Сахалиннан Караярга кайтканда синең эчеңә кием-салым тутырылган иде, кәгазь акчалар да ярыйсы гына иде. Мондагы студент тормышы сиңа нәрсәләр өсти алды икән?

Чемодандагы әйберләрне ятак өстенә бушаттым.

Иң элек билгә тагып йөри торган офицер кортигы күземә ташланды. Кынысыннан чыгарып, кортикның йөзен тикшереп карадым. Сапның җиздән ясаган җире яшелләнеп тутыга башлаган. Кортикның йөзенә дә бераз тутык төшкән.

Уку дәверендә чемоданга бернәрсә дә өстәлмәгән. Элеккедән сакланган әйберләр инде модадан чыгып, искереп баралар. Менә одеколон сиптерә торган пульверизатор. Мондый әйбер хәзер пенсионерларда гына калгандыр инде. Үтмәсләнеп беткән «Золинген» бритвасы, сәдәп чистарткыч щетка, штурман линейкасы һәм өч сынар оекбаш.

— Сез миңа гадел хезмәт иттегез,— дидем мин чемоданнан чыккан әйберләргә,— мин сезне музейга тапшырырга тиеш идем дә, музейга студент кешенең әйберләрен алмыйлар. Сез минем дустым Маштаковны да кызыксындыра алмассыз инде. Ул да газета битләрен бизәрлек исеме булган кешеләрнең әйберләрен генә җыя.

— Сезне дә карыйк әле,— дидем мин чемоданнан чыккан китапларга,— ерак юлга күп әйбер белән чыгып булмый. Сезнең кайсыгыз киләчәктә дә бәясен югалтмаслык акыл бирә алыр икән?

Дәрдмәнднең кызыл тышлы кечкенә генә китабын, Һади Такташның «Сайланма әсәрләр»ен, Тукайның беренче томын, Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар»ын чемоданыма салып куйдым.

Укыганда көненә ике мәртәбә чәй белән генә канәгатьләнеп булса да Толстой, Достоевский, Михаил Булгаков, Шекспир, Байрон, Джек Лондон, Хемингуэй, Стейнбек, Селинджэр һәм башка шуның кебек әдипләрнең китапларын җыя алган идем.

Киләчәктә яраткан китапларымнан библиотека тупларга хыяллана идем. Тутыра башлагач, шушы стипендиягә җыйган китапларым да чемоданыма сыймады. Бу әсәрләр кузгаткан тойгылар күңелемдә әле һаман яшиләр. «Берәр урынга тукталып яши башлагач, мин сезне килеп алырмын»,— дидем китапларга. Аларны җыеп, бергә бәйләдем дә саклау камерасына конспектларым янына илтеп куйдым.

Кием-салымны чемоданга тутырып, әйберләр арасыннан чыккан иске хатларны укырга керешкәндә, Баграт кайтып керде.

— Сәлам бөек сәяхәтчегә!

— Чирәм җирне яулаучы геройга дан!

— Планың үзгәрмәдеме әле?

— Юк, үзгәрмәде.
— Одессагамы?
— Әйе, Одессага.
— Безгә юл акчасы бирделәр! Җәйге каникул стипендиясен дә алдым. Акча кесәгә сыймый. Әллә «Пекин»га кереп карамельдән катырган лотос авыз итеп чыгабызмы? — дип, Баграт яныма килеп, җилкәмә кулын куйды.— Ничектер ямансу, Габдрахман.
— «Бей барабан и не бойся»,— дидем мин, Гейне шигырен исемә төшереп.
— Маштаков Патрис Лумумба хатыныннан Конго юлбашчысының чәч тарагын сорап алган. Җиденче кат күктә. Хәзер Өметгали белән бергәләп сынауга хәзерләнәләр.
— Күрдем. Китапханәнең уку залында кагыйдә ятлыйлар.
— Габдрахман, чит илгә йөзә башласаң, миңа йомшак замшадан теккән куртка алып җибәрерсең әле. Искиткеч уңайлы һәм күркәм нәрсә ул замша куртка.
— Мин сиңа, Баграт, спортивный «Ягуар» машинасы алып җибәрәчәкмен. Бу киемнәрең, буй-сының белән шундый машинага утырып йөрү генә җитми сиңа.
— Минем күңелне күрәсең килсә, беркая да китмә. Әллә ничек, синнән аерыласым килми... Кал, бульдог!
Күңелдәге тойгылар тышка бәреп чыктылар. Юмор җуела төште. Ямансылата, күңел йомшара башлады. Егет кешегә дулкынлануын күрсәтү килешми иде. Шушы минутта дусларымнан аерылмас өчен ниятемнән баш тартырга әзер идем. Бәхетебезгә каршы, бүлмәгә Өметгали белән Маштаков кайтып керделәр.
— Габдрахман, кая җыенасың, әллә син дә чирәм җиргә китәргә ниятлисеңме? — диде Маштаков, үзенә генә хас беркатлылык белән.
— Берләшкән милләтләр ассамблеясына чакыралар. Шимбә көн Нью-Йоркка очам.— Маштаковны күргәч, шаяру сәләтем яңадан уянды.
— Яңалыкны кеше онытып бетергәч кенә ишетәсең. Габдрахман пиратлыкка чыгып китмәкче. Ул синең музееңа әллә нинди кыйммәтле экспонатлар табачак,— диде Баграт, җиңелчә генә шелтәләп.
— Пиратлык хәзер тыела түгелме соң? — диде Маштаков чын күңелдән.
— Тыела иде дә, миңа хәзер яңадан рөхсәт иткәннәр,— дидем мин.
— Алай булгач, син берәр атаклы пиратның әйберен кулыңа төшерергә тырыш әле. Минем коллекциямдә бер пиратның да экспонаты юк.— Үзенең коллекциясеннән башка темага күчсә, Маштаков, сабый балалар шикелле, нәрсә әйтсәләр шуңа ышана башлый иде.
— Габдрахман, синең Бохара белән Сәмәрканд шәһәрләрен күргәнең бармы? — диде Өметгали.
— Юк шул.
— Алай булгач, әйдә Урта Азиягә китәбез. Андагы һәйкәлләрне күргәч, кыбырсып йөрүең басылыр.
— Урта Азиягә Европа тормышы белән танышканнан соң барам. Шәрык культурасын үзләштерергә җитәрлек хәзерлегем юк әле. Башта Европа цивилизациясе белән якыннан танышасым килә, Көнчыгыш Көнбатыштан катлаулырак. Көнбатышның серенә төшенүе җиңелрәк булыр.
— Әллә син дә берәр төрле коллекция җыя башладыңмы? — диде Маштаков кызыксынып.
— Мин күптән коллекционер инде. Минем коллекциямдә җәяүле кеше йөргән озын-озын сукмаклар, тимер юл километрлары, һава юлы чакрымнары бар,— диңгез мильләре генә җитми иде. Хәзер шуны җыеп кайтмакчы булам.

— Исендәме, Габдрахман, мине шәрык гореф-гадәтләрен саклаучы суфи дип уртәвең? Син үзең бабаларыңның күчмәлек гадәтеннән арынып житмәгәнсең әле,— диде Өметгали.

— Минем бабаларым атларына тапталмаган яшел болыннар эзләп күчеп йөргәннәр. Мин саф һава, иркен сулыш эзлим.

— «Пепель Клааса стучит в моем сердце»,— диде Баграт, Тиль Уленшпигель сүзләрен кабатлап.— Бүген бөек сәяхәтчеләр, тынгысыз йөрәкле сукбайлар хөрмәтенә бокал күтәрергә тиешбез. «Надоело ссориться и спорить, и любить усталые глаза...» — дип, Баграт өстәлгә шәраб шешәсе китереп утыртты.

— Тукта, Баграт, Маштаков белән Өметгалинең сынауга хәзерләнәселәре бар бит,— дидем мин.

— Сынау качмас. Тагын кайчан шушылай дүртәү утырырбыз. Өч ел бер ана балалары кебек тату яшәдек.— Өметгали тумбочкасын ачып, бераз актарынды да өстәлгә каклаган ит китереп куйды.

Маштаков бүлмәдән чыгып китте. Берничә минуттан ул бер банка балык консервысы алып керде. Мин дә урам аша чыгып бер шешә алдым, өстәлгә газета җәеп, калган ипиемне турап куйдым.

Әкренләп күрше бүлмәләрдә яшәүче студентлар да җыела башлады. Студентлар шикелле күңелле итеп утыра белүче бу дөньяда бармы икән? Бераздан күңелдә дуслык тойгылары гына калды. Дөнья тигезләнде. Тормыш ал да гөлгә әйләнде.

Без таралганда көн тәмам яктырып беткән иде инде. Мин, дусларым белән саубуллашып, вокзалга юнәлдем.

## 23

Вокзал эчен җентекләп тикшергәч, перронга чыктым. Мәскәү — Одесса поезды белән китәсе кешеләрнең күбесе вагоннарына кереп урнашканнар инде. Проводниклар кара дермантин сумкаларын култык асларына кыстырып, соңга калган пассажирларны көтеп торалар.

Җилкәсенә берничә капчык салган бер кеше абына-сөртенә перронга чыкты. Капчыклар өстенә ул ике бәйләм вак крендель аскан. Крендель бавына балаларны тәпи тоттыра торган тоткалы чүлмәк бәйләп куйган. Йөгергәндә «төнге чүлмәк»нең капкачы савытына бәрелеп чылтыр-чылтыр килә. Перрондагы кешеләр бу бәндәне елмаеп каршы алдылар:

— Вот дает! Валлаһи, бу бәндә «төнге савыт»ны май салып тотарга алгандыр! — дип, чиертсәң каны чыгарга торган таза, матур проводница яңгыравыклы тавыш белән көлеп җибәрде.

Чүлмәк аскан кеше артыннан перронга Феликс күтәрелде. Поезд кузгалырга җиде минут чамасы вакыт бар иде әле.

— Син Элеонораны күрмәдеңме? — дип сорады ул, мине күрүгә.

— Юк, күрмәдем.

— Урнаша тор. Мин хәзер киләм.

Юлдашым чемоданын җиргә куйды да, борылып, вокзалга таба йөгерде.

Чемоданнарны вагонга алып кереп өске киштәгә урнаштырдым. Тамбурга чыгып Феликсның әйләнеп кайтканын көтә башладым. Озатучыларга вагоннан чыгарга куштылар. Вагон тартылып куйды.

Поезд урыныннан кузгала башлады.

Нәкъ шушы мизгелдә вагон эченә Феликс очып килеп керде:

— Габдрахман, минем чемоданнар кайда?

— Өске киштәдә.

— Табып бир. Мин ашыгам...

— Кая ашыгасың? Поезд кузгалды бит. Барыбер өлгерә алмыйсың.

Коридордагы кешеләр як-якка атылып калдылар. Феликс вагон ишеген тотып торган проводникны этеп җибәрде дә чемоданын кочаклап перронга сикерде.

Саргылт чәчле теге кыз перронда Феликсны көтеп тора иде. Егетенең сикереп төшкәнен күргәч, ул каршы килеп, Феликсны кочаклап алды. Алар үзара дулкынланып сөйләшергә тотындылар.

— Гаҗәп хәл,— диде минем янымда басып торган хатын,— гадәттә, кәткән кешене килгән поездан каршы алалар. Бу нәрсә егетен китәсе поездан каршылады. Аларның һәр эше шулай кире якка эшләнә. Киенүен карагыз әле: күлмәк итәге, ташка үлчим, оят җирен дә капламаган...

Феликс бергә китәргә вәгъдә бирде. Баргач, эшкә урнаштырам дип ышандырды. Үзе тотты да соңгы минутта планын үзгәртте. Аның бу кыланышы мине бик уңайсыз хәлдә калдырды.

Башта перрондагы озатучылар күздән югалдылар. Аннан соң әрҗәәемнәре, юл буена бушатылган яңа тракторлар әкрен генә тәрәзә каршысыннан уздылар. Ташландык вагоннар, запас юлда торган тепловозлар күренеп китте. Ниһаять, салынып бетмәгән йортлар, төзү материаллары өелгән складлар артка таба йөгерергә тотынды.

Нарат агачлары астында посып утырган калай түбәле дачалар күренә башлаганда поезд, башкала чорналышыннан чыгып, зур тизлек белән көньяк-көнбатышка таба чаба иде.

Мәскәү йортлары күздән югалгач та, батып килгән кояш нурларына манчылган университет бинасы ераклаша барган поездга бик озак карап торды.

Менә университет манарасында кызыл утлар кабынып китте. Поезд күе урманлык эченә кереп, юнәлешен үзгәрткәч кенә үзәгемне өзеп торган силуэт күздән югалды.

Башкала һаман ерагая. Ерагайган саен миндә аерылу хисе үсә, көчәя бара. Бервакыт минем поездан сикереп төшеп каласым килә башлады. Их, нигә дусларыңны, күнегелгән җирне, зур, матур шәһәрне ташлап китәргә инде!

## 24

Елга үзәнлекләренә, урман ышыгына утырган йортларның утлары караңгыда җемелдәп кабынып китәләр дә, тәрәзә турысыннан узгач, капыл гына сүнәләр.

Минем туган авылым да хәзер йокларга хәзерләнә торгандыр. Инеш буе талларына оялаган каргалар даулашудан туктап, башларын канат астына яшергәннәрдер. Этләр ояларына кереп посканнардыр. Әтәчтавыклар лапастагы кунакчаларында оеп утыралардыр. Буа камышлыгындагы бакалар гына, көмеш кыңгырау тавышы чыгарып, ара-тирә тынлыкны бозып алалардыр.

Авыл башындагы зиратта әтиемнең кабере өстендәге сәрби куаклары чәчәк ата башлагандыр инде.

Мин мәктәпкә йөри башлаган елларда кызу темп белән илне индустрияләштерү бара иде. Урал, Себер, Донбасс ягындагы төзелешләр авылның яшьрәк ирләрен берәм-берәм суырып алып китә торды. Берничә ел читтә яшәгәннән соң, өсләренә шәһәрдә теккән кара костюм киеп, сагынуга чыдый алмыйча, алар авылга әйләнеп кайталар иде. Коймаларын яңартып, түбәләрен яңа салам белән ябып җибәргәч, шәһәр гадәтләрен онытып, алар яңадан авылча яши башлыйлар.

Безнең күрше Зәкиулла абый да берничә мәртәбә читтә йөреп кайтты. Барган саен озак кына торса да, йорт яңартырлык акча, авылдашларын сокландырырлык кием киеп кайта алмады. Һәр баруында ул

гажәп матур җирләр, ул җирләрдә яшәүче халыкларның кызыклы гореф-гадәтләрен күзәтеп кайта иде. Баеп кайткан кеше безнең иш бала-чагага кырын гына карап уза. Алар читтә йөреп чабатадан арынулары белән масаялар. Зәкиулла абый гына, өлкәннәр алдында мактанырлык акча әмәлләп кайта алмавыннан кыенсыныптырмы, күбрәк бала-чага белән аралаша. Ул безгә чит халыкларның гореф-гадәтләрен сөйли. Аның сөйләгәнен без тын да алмыйча тыңлыйбыз. Өлкәннәр генә аның бер файдасыз нужа күреп йөрүеннән көләләр: «Чит җирдә инде әллә нинди мәзәклекләр бардыр. Аларны гомер буе йөрсәң дә карап бетерә алмассың. Шулай да, Зәкиулла энем, бераз акча әмәлләп, өстеңне бөтәйтеп кайту бер дә зыян итмәс иде»,— диләр.

Өлкән агайларга Зәкиулла абыйның мавыгуы «пүчтәк» эш, өлкәнлекнең абруен төшерерлек ахмаклык кына булып күренә иде.

Бер кичне ул безнең койма янындагы бүрәнәләр өстендә гәпләшеп утыручы ирләр янына килеп аларның сөйләшкәннәрен тыңлап торды да урынсыз гына итеп хыялын ачып салды:

— Юлга акча таба алсам, җир читенә кадәр барам да шунда аягымны асылындырып утырып карыйм. Бу минем соңгы китүем булачак. Шуннан кайткач, менә ипекәй, ындыр артына да чыкмыйча, авылда түшәмгә төкереп ятачакмын...

Юраганга юш килә диләрме әле? Шушы сөйләшүдән соң берничә көн үткәч, юлга җитәрлек акчасы булмаса да, Зәкиулла абыйны поездга утыртып, көнбатышка таба алып киттеләр. Мәрхүм анда кемнәр белән очрашуы турында кайтып сөйли генә алмады. Караяр авылының тынгысыз сәяхәтчесен Украина җиренең бер калкулыгында фашист снарядлары куып җиткән. Ул мәңгегә шунда ятып калды...

Бәлки мин дә Зәкиулла абый кебек «пүчтәк» артыннан гына йөри торганмындыр? Мин үзем күрмәгән җирләрдә әллә нинди матурлыклар, әллә нинди шатлык-сөенечләр күрермен кебек тоела. Үзем күрмәгән җирләрдәге тормышны күз алдыма китерү белән түземлегем югала. Бәлки анда да әллә ни юктыр? Тормышның асылы бар җирдә дә бер бит ул. Тормышның яме, матурлыгы безнең үзебезгә бәйләнгән. «Кая барсаң да, кара сакалың артыңнан калмас», дигәннәр борынгылар.

Узган гомернең хатирәләре һаман, һаман мине тынгысызлыйлар.

...Менә акбур исе килгән класста дәрес тыңлап утырам. Укытучы Африка саванналарында яшәүче җәнлекләр турында сөйли... Менә мин йомшак буразнага басып, сабан артыннан атлыйм. Баш очымда әсәрләнеп тургай сайрый. Кар астыннан чыккан кыр балчыгының исе шундый тәмле!

...Тышта буран. Өй эчендә тыныч, рәхәт. Стена бүрәнәләрендәге һәр ярык, һәр тап әле һаман минем күз алдымда. Түшәм такталарында бала чактан таныш ботак эзләре. Мин аларны һаман оныта алмыйм. Кайвакыт бала чактагы тылсымлы хатирәләр кино кадрлары шикелле күңел тирәнлегеннән калкып чыгалар да атналар буе күз алдымда торалар...

## 25

Тәгәрмәчләр туктаусыз такылдыйлар: «Ял-гы-ша-сың, ял-гы-ша-сың, ялгы-ша-сың...»

Каршымда утырган хатын берничә минутка чыгып, югалып торды. Купега кергәндә аның өстендә кызыл чәчәк төшкән зәңгәр ефәк халат иде. Минем янымда яшь, чибәр сержант түшендәге значокларын җиңе белән ышкып чистартып утыра.

Таушалган ситсы сарафан кигән апа каршымдагы утыргычтан сержант янына күчеп утырды:

— Әниең янына кайтасыңмыни, акыллым?

— Әйе, ялга кайтам. Учениедә отделением беренче урынны алды. Миңа унбиш көнлек ял бирделәр. Солдатларны Мактау грамотасы белән бүләкләделәр.

Сержантның погонындагы ука тасмаларның икесе иске, берсе яңа. Өйрәнүдән соң егетнең дәрәҗәсе дә үскән, күрәсең. Хәзер ул бәхетле кеше. Түше тулы ялтыравыклы значок. Тәненә сыланып торган яшел габардин форма. Күңелендә сөйгән кызы, туганнары белән очрашу бәхете. Мин дә хезмәтемнең беренче елында түш тутырып значок тагып, өр-яңа мундир киеп авылга кайтуны морадыма ирешүгә саный идем.

Ефәк халат кигән хатын битенә пудра сөртте, чәчен тарап кабартты:

— Мәскәү халкын әйтәм, итәкләренә ут капкан кебек кыланалар. Ошамый миңа башкала тормышы. Кырмыска оясындагы тынгысызлык анда. Безнең Одессада яшәүгә ни җиткән.

— Сезнең Одессагызда да шундый кайналудыр инде. Шәһәр тормышы шулай мәшәкатьле инде ул. Калада йөргәндә арыйм мин, эштән чыгам,— диде ситсы сарафан кигән апа.— Авылда рәхәт. Авылда үз көеңә яшәп була.

— Безнең Одессада да яши алмас идегезме? Безнең Одесса андый түгел. Ул шундый матур, ямьле шәһәр. Халкы әдәпле, культуралы. Одессамны мин дөньядагы бер шәһәргә дә алыштырмас идем.

Туган җир турында бәхәсләшүнең нәтиҗәсезлеген мин белә идем. Һәркемгә үз әнисе газиз булган кебек, һәр кешегә үзе яшәгән урын якын. Бу бәхәсләшә торган тема түгел. Мин бу сүзгә кушылмадым. Мондый сүз көрәше бернинди юл белән дә чишелми. Дөньяда начар әниләр булмый. Бу бәхәснең асылы менә шунда.

Ситсы сарафан кигән хатын сөйләп китте:

— Мин Мәскәүдә кап-кара бер кеше күрдем. Учлары ак — әкәмәт инде. Тәне кара кешенең нишләп учы ак була икән?

— Бер лампаслы чалбар кигән кешегә честь биргән идем, карасам — Суворов мәктәбендә укучы селәгәй малай. Лампаслы булгач, мин аны генералдыр дип уйлаган идем. Мәскәүдә, малакаем, бик уяу булырга кирәк,— дип, сержант фикерен кызык кына итеп йомгаклап куйды.

— Минем әниемнең энесе Суворов мәктәбендә полковник булып эшли,— диде ефәк халат кигән хатын. Сержант егет аны төзәтергә кирәк тапты:

— Полковник — хәрби дәрәҗә. Полковник булып эшләү мөмкин түгел. Дәрәҗәсенә күрә аның должносте да бардыр инде.

— Юк, ул полковник булып эшли,— диде ефәк халат, кабатлап.— Кемнең кем булып эшләгәнен генә белерлек. Минем әтием дә офицер, өч энемнең өчесе дә лейтенантлыкта. Ирем дә офицер булып эшли иде. Так что хәрби хезмәт турында мин бар нәрсәне беләм...

Әкренләп әңгәмә безнең үз хәлләребезгә күчте.

Ни турында сөйләшсәләр дә, юл кешеләре бервакыт үз хәлләренә кагылмый калмыйлар. Йөрәк серенне таныш кешегә сөйләве кыен. Андый серне туганыңа да сөйләмисең. Сөйләп зарлансаң, туганыңның бу миннән ярдәм көтә икән дип хафалануы бар. Сереңгайбәткә әйләнүдән куркып, аны үзең белән бергә эшләүче дустыңа да сөйли алмыйсың. Әллә шуңа күрә, бүген очрап, иртәгә аерыласы кешегә тотасың да эчеңә җыелган зарларны рәхәтләнеп бушатып ташлыйсың.

Сержант полкташын эзләп, икенче вагонга киткәч, хатыннар икәүләп миңа серләрен сөйләргә керештеләр.

— Картым сугыштан кулсыз кайтты,— диде сарафанлы хатын.— Бар эш үз өстемдә. Авыл кешесенең мәшәкатен беләсез инде. Ихатала-

рына кадәр үзем ныгытам. Биш бала үстердем. Ирем дә үзе балалар чутында бит әле. Олы малаем Мәскәүдә институтта укый. Институт бетергәч, өйгә кайтып ярдәм итәр дип өметләнә идек. Узган атнаны мәскәвичкәгә өйләнде. Хәзер инде ул Мәскәүдә калачак. Шәһәрдән төшкән килен ирен авылга җибәрми ул. Шәһәрдә үскән кешенең шәһәрдә яшисе килә. Үзләренең фатирлары юк. Өйләнгәч, бәбәйләре булачак бит әле, уйлап карагыз. Кая инде алардан ярдәм көтү! Хәзер үзләренә ярдәм итәргә кирәк,— дигәч, авыл хатыны миңа карады.— Сине дә әниең төн йокысын йокламыйча карап үстергәндер инде. Анаңа ярдәм итәсеңме соң?

— Булмады шул,— дидем мин, гөнаһымны яшермичә.— Стипендия үземә дә тартып-йолкып кына җитте. Инде читтән торып укуга күчтем. Эшкә урнашырга барам. Эшли башлагач, ярдәм итеп булыр дип уйлыйм.

Авыл хатыны бу эшне хупламады:

— Ярдәм итү өчен генә булса, укуыңны ташламаска кирәк иде. Баланың укып чыгып кеше булганын күрү үзе зур куаныч. Ул куаныч ярдәмнән дә артык. Хәзер инде баладан ярдәм көтеп булмый. Сине онытмыйча хат язып торса, шул җиткән. Улым хәзер хат язармы икән, белмим.

Яшь һәм өлкән буыннар арасындагы мөнәсәбәт катлаулылыгын мин бераз аңлый идем. Ата-ана баланы картлык көнендә таянычым булыр дип үстерә. Элекке заманда, бүленмичә, зур патриархаль семья белән яшәгәндә, бәлки ул шулай булгандыр да. Хәзер инде бала аякка басу белән үзе семья корып җибәрә. Семьялы кеше бар көчен, бар тапканын үз гаиләсенә бирергә тырыша. Бу хәлгә кайбер аналарның хәтере кала. «Үзебез шәрә йөреп, балаларыбызны киендердек, үзебез ач йөрсәк тә, аларга соңгы сыныгыбызны ашаттык. Канат астыннан чыгып, ярдәм итәрлек хәлгә җиткү белән безне оныттылар»,— дип рәнҗиләр алар.

Яшәү законы ата-анадан алган тәрбияне балаңа кайтарып бирергә куша. Әгәр яшь этиләр үз балаларын онытып, ата-аналары турында гына кайгырта башласалар, прогресс тукталыр иде.

— Хәзерге заман баласыннан ярдәм көтәргә минем башыма тай типмәгән,— диде ефәк халат кигән хатын.— Мин үземә ышанам. Үзем сәламәт булсам, шул җиткән. Аллага шөкер, балаларым юк. Минем күршемнең малае эчеп килә дә энисеннән акча даулый. Беркөнне энисен тукмап киткән. Аллага шөкер, минем тукмар кешем юк.

— Юк инде, дөньяның бар куанычы шул балалар белән мәшәкатьләнүдә. Үзең зарланасың, үзең шул шайтан токымнарының күңелен күреп интегүдән ләззәт табып яшисең. Шуларны кызганып йөрәгем ачытмаса, яшәүнең бер кызыгы да калмас иде.

Авыл хатыны сәндерәсенә үрмәләп менде, баш астына капчыгын салып, бөгәрләнеп ятты да тирән итеп сулап куйды.

Ефәк халат миңа табарак шуышып утырды:

— Шуның сүзенә ышанасызмы? Авыл хатыннары алар шулай мескен булып күренергә яраталар. Мәскәүгә җиләк-җимеш алып килеп сатkандыр әле. Билләһи, җиргә күмгән бер чүлмәк акчасы бар аның...

Минем үз серләремне сөйләп, эчемне бушатасым килә иде. Авыл хатыны йокларга ятмаган булса, бәлки бераз зарланып та алган булыр идем. Ләкин, ни өчендер, ефәк халат белән сер уртаклашасым килмәде. Мин аңа тыныч йокы теләп, урыныма менеп яттым.

«Ял-гыш-тың, ял-гыш-тың, ял-гыш-тың», дип үрти мине вагон тәгәрмәчләре. «Сер бир-мә, сер бир-мә, сер бир-мә», дип рухландыра вагон түбәсеннән ишетелгән шакылдау тавышы.

Түбә калаеның тәгәрмәчләр белән бәхәсләшеп барганын тыңлап ята торгач, йокыга талганмын.

26

Уянып, тәгәрмәчләрнең рельслар арасындагы җөйне санап барулары ишеткәч кенә кайда икәнлегемне аңлап алдым. Вагон эченә төнге тынычлыкны бозмыйча гына җыр тавышы саркып керә иде. Басынкы контральто белән хискә сугарылган ягымлы тенор чыгарган моңлы көй йөрәкне ләззәтле итеп әрнетә. Сулкылдап торган кайнар тойгыларны күңел генә түгел, тән дә сизеп тора.

Җыр сугыш кырында ятып калган егетен сагынучы бер кыз турында иде. Көй дулкыны җырның сүзләрен көчәйтеп, кыз кичергән сагыну газапларын тыңлаучыга җиткерә. Кызны ялгызлыкка дучар иткән зур, тетрәткеч бәхетсезлек синең да тия, синең йөрәгеңне дә әрнетә. Син дә сугыш кырында үлеп калган егетне кызганып, әфтана башлыйсың. Син дә сөйгәненнән мәхрүм калган ялгыз кызга кушылып сугышны ләгънәтләргә тотынасың. Җыр шушы тойгыларның сүзгә сыймый торган өлешен турыдан-туры синең йөрәгеңә җиткерә...

Тукта әле, мин исән бит. Сугыш миңа тимичә үтте. Ни өчен мин сугышта үлгән ят егет өчен хафаланам, кызның язмышы турында кайгыртам? Минем үз кайгыларым әзмени? Кайгыларым җитәрлек минем. Ләкин чит кеше михнәт күргәндә мин тыныч кына яши алмыйм. Аның кайгысы — минем кайгым, аның хәсрәте — минем хәсрәт. Үзем белән бер планетада яшәгән адәм баласының тойгыларын аңлау, аны кызгану үз кайгыларымнан арынырга ярдәм итә. Кызның кайгыларын уртаклашканда, мин дошман пулясы юк иткән нәселдән нинди даһи кешеләр чыккан булачагы турында уйлыйм. Сугыш егетнең үзен генә үтермәде. Фашист пулясы егеттән туасы балаларны да, алар эшлисе эшләрне, аларның теләкләрен, бәхетләрен дә юк итте...

Кеше зарын уртаклашу, аларның газапларына катнашу синең кешелегеңне үстерә, күңелеңне пакьландырып җибәрә.

Җыр тавышы һаман һавада тирбәнә. Мин урынымнан төшеп, тамбурга чыктым.

Тамбурдагы тонык яктылыкка беркадәр күнеккәч, капчык өстендә утырган озынча йөзле, уйчан коңгырт күзле бер хатынны күрдем. Аның бер күлмәк җиңе буш иде. Хатынына сырышып утырган ирнең күз алмаларын аксыл пәрдә каплаган иде.

Җырчыларның үзләрен күргәч, тагын да моңсурак булып китте. Мин кире вагонга кереп, урыныма менеп яттым да вагон сәндерәсенә җәйгән пиджагыма капланып, эчемне бушаттым.

Җыр тавышы тынды. Вагон көпчәкләренең рельс җөен санавы тоныграк ишетелә башлады.

Икенче уянуымда Украинаның иркен бодай басулары, чия агачлары астында утырган пөхтә ак йортлар, чәчәкләре коела башлаган сары көнбагышлар йөгерәләр иде.

Озын яллы сылу тулпарга атланып кайчандыр шушы киң далалар аша үткәнем бар иде шикелле тоелып китте...

27

Төнлә авыл хатыны вагоннан төшеп калган. Сержант кичә кич полкташы янына киткән җиреннән кире кайтмады. Купеда без тәти халатлы хатын белән икәү генә калганбыз.

— Одесса шушымыни инде? — дидем мин, поезд янынннан шәһәр корылмалары уза башлагач.

— Шушы. Хәзер без Пересыпь белән Молдаванка аша узабыз.— Купедаш хатын парчалы халатын үтә күренеп торган нейлон блузкага алыштырып өлгергән иде.

— Одессаны башкача күз алдына китерә идем,— дидем мин.

— Одессаны башкача? Одессаның башкача булуы? Көләсемне китердегез. «Мәскәү беренче шәһәр, но Одесса да икенче түгел бит»,— диләр бездә.— Юлдашымның минем сүзләргә хәтере калган иде.

Поезд туктады. Каршы алырга килгән ир купедашымның чемоданнарын күтәреп алып чыгып китте. Вагон эче бушап калды.

Мин Одессаның кояшка кызган перронына чыктым.

Ак акацияләр инде чәчәкләрен койганнар. Каштан агачларының чикләвекләре өлгереп килә.

Вокзал каршындагы мәйданда бер көтү күгәрчен жим чүпләп йөри. Трамвай юлы буенда аяксыз бер ир үтеп баручыларны сыбызгы сатып алырга кыстый. Каршыга эт житәкләгән бер хатын килә иде. Этнең танавы йодрык белән дөмбәсләп җәлпәйткән шикелле шөкәтсез, ямьсез. Эт хуҗасының күлмәгенә янар тау рәсеме төшкән. Кара ефәккә ясалган зәңгәр янар тауның кратерыннан кызыл ут көлтәсе күтәрелә. Кратер хатынның нәкъ хисләр кайный торган жиренә — йөрәк турысына туры килгән иде. Бу хәл минем күңелемне күтәреп жибәрде. Чемоданымны жиргә куеп, рәхәтләнеп бер көлдем. Күптән болай көлгәнем юк иде — бик әйбәт булды.

Мондагы хатыннарның барысы да шушындый күлмәк киеп йөрсәләр, мондый күлмәк киюнең үзенә күрә берәр сере дә булса — бик кызыклы шәһәр бу! «Монда әллә нинди серле, гаҗәп нәрсәләр бардыр әле»,— дип уйлап куйдым мин.

Вокзалдан чыккач, уң якта, мәйдан кырыена троллейбус көтүчеләр чиратка тезелгәннәр. Шулар янына барып баскач, хуҗалык сумкасы күтәргән бер агайдан пароходчылыкка бару юлын сорадым.

— Беренче троллейбусның кая барганлыгын беләсезме?

— Юк, белмим.

— Менә белегез инде. Шул троллейбуска утырыгыз да Дерибас урамына житкәнче барыгыз. Уң якта зур сарай күрерсез. Сул якта Дерибас урамы булыр. Шул сарай нәкъ пароходчылык бинасы булыр.

— «Дерибас урамы» дигән сарайдамыни? — Минем сораудан троллейбус көтүчеләр кычкырып көлделәр. Анда ничек барырга кирәклекне бер хатын аңлатырга кереште:

— Сезгә пароходчылыкка барырга кирәкме? Пароходчылыкка барасыгыз килсә, беренче троллейбуска утырмагыз. Дүртенче троллейбус белән Таможня мәйданына кадәр барып, бер бик биек баскычтан өскә күтәрелегез дә пароходчылыкның нәкъ...— Хатын сүзен әйтеп бетерә алмый калды. Аның кулындагы тавык очарга теләп талпынырга тотынды. Хатын тавыкның канатларын артка каерып тотты да троллейбус көтүчеләргә базарда шушындый тавыкларның бүген ни хак икәнлеге турында сөйләргә кереште.

— Одессаны белмәгән кешегә шундый чытырлы юл өйрәтәләрмени? Син, егет кеше, беренчегә дә, дүртенчегә дә утырма. Әнә теге эт житәкләгән хатын басып торган жиргә туктыйсы автобуска утырсаң, ул сине пароходчылыкның капкасы төбенә үк илтеп куячак,— диде яшь кыяфәтле чибәр бер карчык.

Мин карчык күрсәткән якка караган идем, теге күлмәгенә янар тау сурәте төшкән хатынны күреп алдым. Тагын ничектер мәзәк булып китте. Менә кайда ул экзотика...

Киңәш бирүчеләрнең берсенең дә хәтерен калдырмас өчен бернинди транспортка утырмыйча, жәяү генә шәһәр үзәгенә таба юл тоттым.

Туктальштагы сөйләшүдә пароходчылыкның шәһәрдәге иң атаклы предприятие икәнлеге аңлашылды. Шулай булмаганда аны очраган бер

кеше белмәс иде. Өстәвенә, одессалыларның пароходчылык белән кызыксынулары да күренеп тора иде. Димәк, мин әйбәт урынга эшкә керәм.

28

Урамның ике ягына да үскән чинар агачларының ботаклары каракаршы килеп бергә тоташканнар. Шулай итеп, урам өстендә яшел түбә барлыкка килгән. Яфраклар аша урамга яшькелт яктылык үтеп керә.

Монда Мәскәүдәге шикелле ашыгу юк икән. Одессалылар бара торган җирләреннән туктап, витриналарга озаклап карап торалар. Танышларын очратсалар, бер-берсенең төймәләренә ябышып, туйганчы сөйләшәләр. Әңгәмәләрен тәмамлап, урыннарыннан кузгалгач та, әйләнеп килеп, тагын гәпләшәләр. Алар ни өчендер әйтәсе килгән сүзләрен әйтеп бетерә алмыйлар иде.

Пушкин урамындагы йортлар гаҗәп матур икән, Венеция готикасы ысулында салынган бер сарай янына җиткәч, чемоданымны тротуарга утыртып, сокланып карап тора башладым. Йортның фасадындагы бизәкләр гарәп орнаментлары белән ярышырлык иде.

Соклануымны яшерә алмыйча, хәйран калуымны үземә-үзем сөйләп торганымны күргәч, урамның икенче ягындагы эскәмиядә утырган бер карт урыныннан кузгалып, яныма килде. Одессалы сөйләшергә һәвәс кеше иде:

— Атаклы эш биржасы инде бу. Сезнең бу бинаны беренче күрүегезме?

— Әйе, беренче күрүем.

— Патша заманында кешеләрне шушы йортта эшкә яллый торган булганнар. Әлегечә әйткәндә, монда кадрлар бүлеге булган. Бөтен шәһәргә бер отдел кадр.— Карт оста әйтүенә куанып көлеп куйды.— Хәзер монда филармония. Филармониясе бар, артистлары бар, концертлары да булып тора, әмма концерт залының акустикасы юк. Чын акустикалы залның нинди булганлыгын беләсегез килсә, безнең опера театрына барыгыз. Опера бинасы моннан да гүзәлрәк. Аның дөнья күләмендә беренче урында торганлыгын белә торгансыздыр инде? Элек Вена шәһәрендә дә шундый театр булган, сугыш вакытында Вена операсы җимерелгәч, безнеке генә калды.

— Ишеткәнем бар иде шул,— дидем мин, картның күңелен күрү өчен.

— Операның сәхнәсендә пышылдап сөйләшкән тавыш та залның барлык почмакларында ишетелеп тора.

— Акустика ягын алай артык кайгырту кирәк булдымы икән соң? — дидем мин.— Одессалылар сәхнәдә дә урамдагы кебек кычкырып сөйләшсәләр, тамашачыларның колаклары нишләр?

Карт минем шаяртып әйтүемне аңлап җиткермәде булса кирәк. Ул шәһәрнең башка мәшһүр биналары турында сөйләргә кереште. Бу кешенең тиз туктарга исәбе юклыгын сизгәч, мин кузгалып киттем.

Миңа тагын сокланырлык берничә йорт очрады. Ләкин алар янына туктап тормадым. Бары тик «Бу йортта 1821—1823 елларда бөек рус шагыйре А. С. Пушкин яшәгән» дип язылган фасадка гына бераз карап алдым да юлымны дәвам иттем.

Белмим, нилектәндер, минем яраткан язучыларымның күбесе азмы-күпме шушы шәһәрдә яшәп киткәннәр. Максим Горький монда үзенең «Челкаш»ын тапкан, Бунин, Куприн, Паустовский әле мин барган урамның ташларына басып йөргәннәр, Бабель, Юрий Олеша, Илья Ильф, Евгений Петров, Эдуард Багрицкий, Валентин Катаев шушы чинар агачларына сокланып карап йөргәннәр.

Одесса — бәхетле шәһәр. Илнең кайсы шәһәре әле шундый атаклы язучылар иҗатына кергән? Мәшһүр шәһәр турында язу үзенә күрә бер әдәби жанр бит ул. Күп язучылар менә шундый калалар турында яңа фикер табып, яңа тасвирлаулар калдырырга тырышканнар.

Дерибас урамына җитеп, уңга таба борылган идем, каршыма кыңгырау шалтыратучы бер кеше килеп чыкты. Урам уртасына туктаган цистерна янында икенче берәү кыңгырау тавышына чыккан кешеләрнең бидоннарына күбекләндереп керосин агыза иде.

«Монда керосинны да музыка белән саталар икән»,— дип уйладым мин.

Дерибас урамыннан караганда нигытмалы кирмәнгә охшашлы пароходчылык бинасы башка йортлардан аерылып тора иде. Бер квартал чамасы аска төшкәч, шул йортка таба борылдым да капкадан чыгып килүче бер диңгезчедән кадрлар бүлегенең кайда икәнлеген сорадым.

— Ул монда түгел, Диңгез буе бульварында.— Моряк минем белән Пушкин урамына кадәр күтәрелеп, кадрлар бүлеге урнашкан йортны күрсәтте.

Атаклы опера театры бинасы яныннан узып, Пушкин һәйкәле куелган мәйданга килеп чыктым. Шушы мәйданнан башланып киткән аллея биек ак сарай янына җитеп тукталган.

Сулда классик ысулда салынган биек йортлар, уңда, агачлык каплаган текә яр астында, зур диңгез порты яр буйлап сузылып киткән иде. Причалга береккән мәһабәт тимер корабның трюмыннан порт краннары тәлгәш-тәлгәш итеп тагылган мичкәләр күтәрәләр. Кораб белән склад арасында йөк ташучы автокаралар чуалышып йөри. Порт әйләнәсендәге биек таш койма эчендә, тау-тау өелгән товарлар арасында маневр ясаучы паровозлар чабыша. Монда чит кешегә аңлашылмый торган зур мөһим эш бара.

Кояшта кызынып яткан кит балыкларына охшашлы океан пароходлары тышкы рейдта портка керергә чират көтеп торалар.

Кырмыска шикелле тырыш, көчле бер буксир зур корабны пирслар арасыннан порт уртасына сөйрәп чыгарды да борынын ак маяк ягына каратып, борып куйды. Пароходның артында су кайнарга керешTE. Дөбер-шатыр килеп якорь чылбыры шуыша. Пароход теләр-теләмәс кенә урыныннан кузгалды да әкрен генә тышкы рейдка чыга башлады. Ачык диңгезгә чыккач, кораб җитезләнеп китте, дулкын кузгатып алга омтылды.

Кайсы океан аша нинди илләргә юл тота икән бу кораб? Бәлки ул Атлантиканы кичеп, көнбатыш ярымшарга юнәләдер. Я булмаса, Сүәеш каналы аша, җылы җилләр белән сугарылган көньяк диңгезләренең яшел атауларына таба юл тотадыр?..

Һаман кечерәя барган корабтан күземне ала алмыйча, аның офыкка кереп югалганын карап тордым. Бәлки мин утырып китәсе пароход та кузгалырга әзерләнә башлагандыр? Тизрәк барып эшкә урнашырга кирәк. Ашыгыйм, соңга калырга ярамый. Мин, тиз-тиз атлап, кадрлар бүлегенә юнәлдем.

## 29

Кадрлар бүлеге начальнигының кабинетына кергәндә эш вакыты тәмамланып килә иде инде. Кабинетка керү белән, начальник секретарь кызны чакырып, кабул итүне туктатырга кушты:

— Люба, шушы иптәштән соң беркемне дә кертмә. Иртәгә прием юк. Мин башкарма комитет утырышына китәм.— Шулай дигәч, начальник минем кәгазьләремне күз йөртеп кенә укып чыкты.

— Сезне монда кем чакырды?

— Беркем дә чакырмады, үзем килдем.

— Киңәшем шул — акчаң бар чакта тизрәк билет ал. Безгә матрослар кирәкми. Безгә беркем дә кирәкми! — Начальник ялтырап торган пеләш башын учы белән сыпырып алды да кәгазьләремне кире миңа сузды.— Үз кешеләребезне кая куярга белгән юк.

Шәһәрнең күркәмлеге, моңа кадәр очраган кешеләрнең нәзакәтлелек күрсәтүләре, килгән көнне үк начальникның туры үзенә әләгә алуым минем күңелне канатландырып җибәргән иде.

Башта начальник әйткән сүзләрнең мәгънәсенә төшенә алмый тордым.

— Миңа Феликс Каминский сезнең белән сөйләшергә кушкан иде. Сез аны белә торгансыздыр бит? Без Феликс белән бергә укыдык.

— Каминский түгел, министр иптәш Бакаев приказ бирсә дә, урнаштыра алмыйм. Урын юк. Аңладыңмы? — Начальник, сөйләшүнең тәмамланганын белгертеп, өстәл читендәге төймәгә басты.

Мин мондый финалга әзерләнмәгән идем. Хыяллана торгач, үземнең диңгезче булуыма тәмам күнегеп, иләшеп киткән идем инде. Гадәттә, хыял белән яшәүчеләр, планнары җимерелсә, ни эшләргә белмичә аптырап калалар. Мин дә таш стенага бәрелеп миңгерәүләнгәндәй булдым. Кинәт таркауланып киттем, әйләнә-тирәне күрмәс, шәйләмәс булдым. Инстинкт белән генә күзаллап, каядыр атлый башладым.

Башымны күтәреп карауга, алдымда вокзал бинасы күрдем. Вокзал баскычыннан менгән чакта кадрлар бүлегендә онытылып калган чемоданым искә төште. Тукта әле, мин ничек монда әйләнеп килгәнмен соң?

Мәйдан аша чыгып, беренче троллейбуска утырдым да Диңгез буе бульварына кире әйләнеп кайттым.

Кадрлар бүлегенә җыелган диңгезчеләр таралып беткәннәр. Бульвар эскәмияләрендә ниндидер бәхетле кешеләр утыралар. Кемнәрдер агач төпләренә төркем-төркем җыелып сөйләшеп торалар. Мин төркемнән-төркемгә күчеп, кешеләрнең нәрсә турында сөйләшкәннәрен тыңлый башладым.

— Капитан пароходка кире кайтаруларын сорап кадрлар начальнигына радиограмма биргән,— диде күксел куртка кигән бер егет,— инспектор җибәрми, резервта тота. Бүген Куренёнконың үзенә кергән идем. Ул да инспектор сүзен кабатлый. Карга күзен карга чукымый инде. Алар үз кешеләрен урнаштырырга тырышалар.

— Хәзер резерв алты йөздән арткан, диләр. Озакламый шушы санга быел училище бетерүчеләр өстәләчәк.— Диңгезче формасы кигән киң җилкәле, тәбәнәк буйлы бер кеше ачу белән җиргә төкерде.

— Урын җитмәслеген белгәч, яңа кадрлар җыймаска иде аны. Әле күптән түгел янгын сүндерергә хәзерләнгәндәй, ашыгып кеше җыйдылар,— диде күксел куртка кигән егет.

— Лыгырдыйсыз, акыллы башлар,— диде моңа кадәр сүзгә кушылмыйча тыңлап торган чибәр бер грузин.— Гайбәтче хатыннар шикелле кем нәрсә әйтсә, шуңа ышанып, коткы таратып йөрисез! Бүген генә кадрлар бүлегендә кочегарлар җитми дип кеше эзләп йөргәннәрен күрдем.

— Дөрес, аларга һәр вакыт кемдер җитми. Ә сине барган саен урын юк дип борып җибәрәләр. Минем күршем, боцман, отпускадан соң бер көн резервта утырмыйча диңгезгә чыгып китте. Дөресме соң бу, ә? — дип, карт диңгезче тәмәке кабызды.

— Шулай шул. Кирәкле кешене кадрлар бүлегендә озак тотмыйлар. Узган елларны җәйге отпускалар башланган вакытта резервта кеше калмый иде. Хәзер айлар буе кадрлар бүлегенең бусагасын таптап та пароходка әләгеп булмый әле,— диде диңгезче формасы кигән егет.

Мин эскәмиядәге буш урынга барып утырдым. Диңгезчеләр әйткән сүзләр дөрес булса, тиз генә эшкә урнашып булмаячак. Бу инде минем

планнарымның җимерелүе дигән сүз. Өметгали дәрес кисәтте. Һавадагы торнага караганда, кулдагы чыпчык ышанычлырак. Университеттан киткәнче, пароходчылыкта урын барлыгын белешеп карыйсы калган. Хәзер бу шәһәр миңа чит, ямьсез булып күренә иде инде. Хәтта кешеләре дә әллә ничек кыланчык, тәкәббер булып тоела башладылар. Монда минем танышларым юк, урнашыр урыным юк. Ни эшләргә?

Куерып килгән караңгылык ниндидер шомлы, шәфкатьсез иде. Дингездәге утлар ярга мәрхәмәтсез салкынлык тараталар.

...Ерак юлдан кайтканда безнең авыл утлары төн карангысы эченнән җемелдәп сине көтеп торалар иде. Ул утларның җемелдәвендә авылның зарыгып көтүе, сине үз кешесе итүе сизелә. Юл йөреп арыгансың, янгыр киемнәреңне чылаткан, синең ашыйсың, ял итәсең килә. Утлар, караңгыда җемелдәп: «Сер бирмә, егет, ерак калмады. Сине монда җылы өй, йомшак ястык көтә. Җылы су белән юынып җибәрсән, арыган аякларыңа көч кереп китәр» дип, сине рухландырып тора иде.

Дингездәге утлар, киресенчә, үзара күз кысышып, минем шушы хәлгә калуымнан көләләр шикелле иде. Кадрлар бүлеге урнашкан йортның өске катларында ут ала башладылар. Тәрәзәләрдән урамга саргылт якты сирпелде. Тәрәзә каршысыннан ниндидер шәүләләр үткәләп тора иде. Бу йортта яшәүчеләр табын янына җыелырга хәзерләнеп йөриләр булса кирәк. Исемә Валерия белән концертка барган кич килеп төште. Консерваториядән кайтканда мин нәкъ шушындый күренешкә очраган идем...

Яшәү тәҗрибәсе дә юк түгел инде. Һаман акыл керми. Һаман үз җаеңны карый белмисең, үзеңә нәрсә кирәклеген, яшәү кагыйдәсен аңламыйсың. Шул калай әтәчнең сүзенә ышанып, нигә төпләнеп яшәгән җиреңнән кузгалып китәргә иде? Караярыңа кайтып киткән булсаң, хәзер койма буендагы бүрәнәләр өстендә балаларның авыл башына сыер сакларга киткәннәрен карап утырыр идең. Я булмаса, яшьләрне кичке уенга чакырган гармун тавышына турылап, клуб янындагы бакчага таба юл тотар идең...

Йөзү эше турында сөйләшүче кешеләр әкренләп таралып беттеләр. Дингез буе бульвары күңел ачарга чыккан кешеләрне кабул итте.

Мин утырган эскәмия каршысыннан яшь кызлар, җиткән егетләр көлешеп уздылар. Ике кыз, җитәкләшеп, сер сөйләшеп баралар иде. Бәлки бу кызлар да минем шикелле эшкә ашмаслык хыяллар белән әсәрләнеп йөриләрдер?

Монда йөрүчеләрнең көндәлек эшләре эшләнгән, аш ашалган. Алар күңел ачып йөриләр. Өйгә кайтуга аларны җылы урын көтә. Алар гамьсез, шат күңелле, алар аллеяны яңгыратып шатланып көләләр. Бу кешеләр синең ахмаклыгыңнан көлә торганнардыр инде? Дон-Кихот син, Габдрахман. Картайганчы акыл кермәячәк сиңа...

Шушы тәнкыйтьтән соң бераз эчем бушагандай булып китте.

Мин урынымнан торып, Пушкин урамына чыктым. Килгән юлымнан кире вокзалга таба атлый башладым.

*Ахыры бар*

## Хәсән Туфан

# БАГЫШЛАУЛАР ДӘФТӘРЕННӘН

### Уяу кыңгырау

Башкортстанның халык шагыйре
Сәйфи Кудашка

Телефоннар аша
Кәтәсеңдер
Берәр сәлам, хәбәр килгәнне.
Шигырь генә әйтә алыр кебек
Минем хәл дә
Әйбәт икәнне.

Бу елларда
Мин дә шулай инде:
Бер йокыдан җиде уянам.
Урман өстендәге җил астында
Уйланам да һаман уйланам.

Син һаман да
Рухи Алыплардан
Истәлекләр калган төбәктә
Яктырасың:
Алар васыять иткән
Гүзәл гамь бар синең йөрәктә.

Циклоннарны, давылларны кичеп,
Яна-яна яши аласың.
Уяу, сизгер, дәү кыңгырау хәлдә
Сиксәнеңә җитеп барасың.

Гасырларның тәүге чатларында
Язмыш сине азмы тукмаган...
Иммунитет туар моңарда дип,
Уйламаган, ахры, уңмаган.

Дәверләрнең ыгы-зыгылары
Үтмәсә дә сине читләтеп,
Кайсы азау вата алсын инде,
Кайчан ки син — каты чикләвек.

Мең-мең калкан саклый сине уктан
Бу көндә үк, үзең терңдә:
Син мәгънәви, рухи һәйкәл инде
Күңелләрнең кызыл түрендә.

Нурланасың
Рухи Алыплардан
Легендалар туган төбәктә,
Яктырасың: алтын мирас булган
Гүзәл гамь бар синең йөрәктә.

...Алыр өчен түгел тормышка без,
Бирер өчен килдек аңарга:
Алты аршын кәфен җитә безгә
Бу дөньядан китеп барганда.

Телефоның
Көтеп утырадыр
Берәр хәбәр, сәлам килгәнне,
Шигырь генә әйтә алыр бәлки
Минем хәл дә әйбәт икәнне.

1970

●

Җил дә тынган, каеннар да уйчан,
Тирән тынлык төнге Келәштә [1].
Тынлыктанмы, җире шундыйданмы,
Шигъри халәт туа йөрәктә.

Төн.
Келәш тын.
Киңәшәдер кебек
Җир белән күк
Нидер турында.
Йолдызларга гүя Кызлар тавы
Әйтеп куя гәпнең соңында:

— Күктән, читтән килгән нәрсә түгел,
Җирдә туган һәр җан — Җирнеке!
Бәс, күкнеке, алланыкы түгел,
Мостайдагы кодрәт — минеке,
Җирнеке, илнеке!

Келәш, 1967

[1] Келәш — Мостай Кәримнең туган авылы.

## Тик сәлам бу

Н. Н.

Яктырак йолдыз янадыр...
Г. Тукай

Тарихтагы кашка тауларда
Уйчан, сабыр, ялгыз каберләр...
Өсләрендә — гамьсез әремнәр...
Безгәчә дә килеп киткәннәр,
Бездән соң да килер дәверләр.

Ияргәнне түгел, әле дә
Ияртkәнне кадерли Заман.
Арка куеп түгел Давылга,
Күкрәп керү хәерле һаман.

Җан — ялан баш, рухың — ап-ачык! —
Каналсаң да көбә [1] кимисең.
Ораны син — шигырь бәгъренең:
Гамьсезлеккә тынгы бирмисең.

Тик сәлам бу — бездән, замандаш,
Көчле, дәртле, моңлы җаныңа,
Йолдыз кебек янып яшәүнең
Тукайчысы булуларыңа.

Тарихтагы юллар буенда
Ташбилгеләр, ядкарь каберләр.
Безгәчә дә килеп киткәннәр,
Бездән соң да килер дәверләр.

1973

## Юл өзелми

И сез минем Әнгам, Илдар,
Шәүкәт, Марат, Рафаэль!
Монда да мин, и малайлар,
Шаулы шигъри гомер теләп
Сезне искә алам гел.

Нарзанга чумып чыгам да
Китәм Каф тау башына.
Сезнең исемнәрне әйтеп
Басам гарше каршына.

---

[1] Кө б ә — тимер күлмәк.

Шундый изге доганы да
Алла искә алмаса! —
Таудан аңа, аз булса да,
Ара якындыр ласа.

...И башкай, дим, шул яшьләрдән
Бераз үрнәк ала бел:
Ягъни, әгәр салсаң да син,
Шулар сыман сала бел.

Шулар сыман сала бел син
Кулны Пегас ялына!
Әмма салма күзне Кафның
Кашы кыйгачларына!

Яшьләр алмаш булалса да,
Бездәйләргә Парнаста,
Без аларга һич тә, Хәсән,
Ярамыйбыз алмашка.

Безнең тирәләрдән инде
Шигъри Биби-Музалар
Сары сарафан итәген
Җилпеп кенә узалар.

Ә шулай да, ә шулай да
Яшәү ямьле, егетләр:
Канатларым булып тоела
Реальләшкән өметләр.

Нигә шушы алтын чорны
Күкрәп сәламләмәскә,
Нигә шушы яңа елны
Бераз хәйямламаска!

Тыйма, табип! —
Койчы җамга
Туксан градуслыңны,
Канда — ялкын, җанда — дулкын
Тудыра торган тылсымны.

Мөмкин инде, мөмкин миңа
Башны түбән салмаска:
Аусам-китсәм,
Юл өзелми:
Энеләр бар запаста!

Кисловодск, 1967

*Мирсәй Әмиргә*

●

Илнең өлкән Иделенә,
Агыйделнең үзедәй,
Аерата саф агым булып
Килеп кердең син, Мирсәй.

Син дә инде, и энекәш,
Җиттеңмени алтмышка! —
Серле сызык иде бит ул
Безнең байтак язмышта.

Дәү абыйлар — классиклар
Һаман истә бит әле:
Галимҗаннар, Әмирханнар —
Берсе дә бит шул сызыкны,
Берсе дә бит кичмәде.

Шушы серле чикне, энем,
Уза гына ал бары,
Җитмешкә дә, сиксәнгә дә
Җиту җиңел аннары!

Илнең олы Иделендә,
Агыйделнең үзедәй,
Аерата саф агым хәлдә
Яшәсәңче, и Мирсәй.

1967

*Филология фәннәре докторы Х. Ярмига*

●

Килеп чыгып киң яланга
Таудан түгел, түбәннән,
Тура суы буендагы
Туганнардан, Төмәннән,

Эзләдең дә, эзләттең дә,
Җыештың да табыштың
Хәтер катламнарындагы
Алтыннарын халыкның.

Ихтирамлый күңел Сине —
Гади, тыйнак туганны,
Фольклорның батрагы да,
Рыцаре да булганны.

1964

# Лу-и-зааа...

Төшләремдә күреп җанкаемның
Мине анда сагынып ятканын,
Тезләреңә куеп башларымны
Ял итим бер, сеңелем Аккаен.

Сагынадыр ла, Каен, мине анда
Яр булырга вәгъдә биргән кыз:
«Туй ясыйбыз гына дип торганда
Китте ич, дип тагы, имансыз».

Сөю, бәләм, үзенекен итәр,
Үпкәләтер аны, җылатыр.
Дус кызлары янына алып китәр,
Бакчаларда йөртеп юатыр.

Бөтерелер аның тирәсендә
Богемалар — «юеш талантлар».
Күкрәгенә килеп бәрелү белән
«О, Богиням!» дигән карашлар,

Тешләренә кысып «катись» сүзен,
Малайларча кашын киерер
Һәм кызларча итеп, үз егетен,
Үз «җүнсезен» исенә китерер...

Сагына булыр, Каен, мине анда
Иптәшлеккә вәгъдә биргән кыз:
«Исән микән, искә ала микән,
Юк микән, дип, мине, имансыз»...

Баку — Ширван, 1925

●

Мин ышанмыйм әле үлүеңә,
юл юк әле аңа күңелдә:
курешербез күк тагын.

Ах, ничек мин сине юксынырмын
ераклашкан саен бүгеннән,
ераклашкан саен.

Ачса иде миңа үткән гомер
ачылмаска япкан капкасын,
ачса иде.

Син үләсе көнне күрмәс өчен,
китәр идем шунда ташлап барын,
китәр идем.

Шулай итте мине юксыну,
менә шулай итте.

1955

## Ул да яшь кенә иде

Шәшкеләргә китеп вафат булды,
Башкынаем калды яшь көйгә.

*«Ашказар»дан*

Туктат әле, Наҗар, машинаңны,
Төшик әле, төшик арбадан:
Нигә бу су шундый моңсу икән? —
Сорыйк әле шуны таллардан.

...Теге сулар — Обьлар, Енисейләр...
Алар бүтән, алар башкалар...
Көйдә генә таныш идең миңа,
Синмени бу, моңлы Ашказар?..

Мин сунарчы егет түгел идем.
Тимәсәм дә кешкә — шәшкегә,
Минем дә бит аккош кебек кенәм
Калган иде ялгыз, яшь кенә...

Нигә, нигә шундый серле синең,
Моңсу синең яшел ярларың?
Кемнәрнеңдер судан чыгуларын
Көтәмени ятим талларың...

Еллар, еллар!
Минем ялгыз гомер
Югалса ни, әйдә, югалсын:
«Башкынаем калды яшь кенә...» дип,
Юк бит инде, юк бит җылаучым...

1973

## Үзе генә кайткан ат кебек

Аткынае кайтты, үзе юк.

*Башкорт халык җыры «Салават»тан.*

Ни генә юк, башкорт, синең җанда!
Буранбайдан килгән хат та бар,
Каберләргә борылып карый-карый
Үзе генә кайткан ат та бар...

Салашыма килеп әйтеп китә
Ирәмәлнең төнге җилләре:
— «Буранбай за себер китү менән
Басылырмыни илдең ирләре!»

Салаваттан соң да ничәләрнең
Аткынае кайтты, үзе юк,
Иярдәге кәгазь кисәгендә
Иясенең соңгы сүзе юк.

...Таралдыгыз, йөрәк язмаларым,
Юлда төшеп калган хат кебек...
Бер кайтырсыз бәлки сез дә илгә
Үзе генә кайткан ат кебек...

## Талисман

Тынгысыз, ялсыз халәтем,
Сөен син, сөен, сөен:
Тагы йөз елга җитәрлек
Гамең бар әле синең.

Талисман итеп сине, гамь,
Биргәндер әни миңа,
Якласын өчен баласын
Кәрәшчән эстетика.

Мең рәхмәт сиңа, йөрәгем,
Янучы булган өчен,
Гамьнән дә ямьнәр табучы
«Багучы» булган өчен.

Кермәдең, ярашмадың син
Урталык юлларына...
Мең дә бер рәхмәт, йөрәгем,
Битараф булмавыңа.

И минем сәер халәтем!
Сөен син, бәгърем, сөен:
Ахырга кадәр җитәрлек
Гамең бар әле синең.

Талисман итеп бу хәлне,
Әни, син биргән миңа:
Тимәсен өчен улыңа
Имансыз, илсез-ватансыз
Битараф риторика.

1963

## Хуш, сау бул, яр.

Җил тынды. Дулкыннар йокланы.
Ай гына юл суза ярларга...
Үтелгән юлларны күзәтәм,
Җилкәннәр ял иткән арада.

Бер калкып, бер батып дулкында,
Упкында гизгәндә җилкәннәр,
Реалист гакылның киңәшен
Давыллы хисләрем җиңгәннәр...

Нишлим соң, тумыштан шулай мин
Романтик бәндәмен, күрәсең:
Ни малым, ни өем... син фәкать
Бердәнбер мөлкәтем, йөрәгем!

Этәрдем, тибәрдем, җимердем
Гакылның «саваплы» хаятен:
Гөнаһлы, гаепле булсам да,
Бу минем табигый халәтем.

Ә бәлки бәхилләр бу хәлне
Бездән соң шигырьгә килгәннәр?..
Сау бул, яр: уянды дулкыннар! —
Киерелә җилләрдә җилкәннәр!

...Үтелгән юлларны барладым,
Җилкәннәр ял иткән арада:
Буйсынмый гакылга хисләрем,
Син мине гафу ит, Замана.

1972

●

«Яхшы атлар кирәк үтәргә»... дип,
Яңгыратып кара урманны,
Ничә гасыр буе эзләдең син
Татарстан дигән дөньяңны.

Хәерле юл яхшы атларыңа,
Җырыңдагы тулпарларыңа.
Хәерле юл, илем,
Исән-сау җит
Гасырларның аргы ягына.

Барасың бар әле бик еракка,
Үтеп кырны, чорны, даланы.
Җырның-телнең яхшы атларына
Атландырып бала-чагаңны.

Киләчәккә затлы халык хәлдә,
Ышанам мин, җитә алырсың,
Тик Ленинча яши алсаң гына
Татарстан булып калырсың.

1970

## Фаил Шәфигуллин

### Җидегән

Җан дуслар да түгел идек инде алай —
Уйнап үстек бер урамда җиде малай.

Төнге күккә карау белән төшә искә,
Җидегән йолдыз күргән идек без бер кичтә.

Җидебезгә — җиде йолдыз, җиде шатлык,
Кош тоткандай зәңгәр сукмак буйлап чаптык.

Җилләр ефәк, сулар көмеш, офыклар ал,
Һич кайгы юк... баш очында җиде хыял!

...Җиде хыял еракларга дәшкән чакта,
Чыгып киттек җиде егет җиде якка.

Җиде егет җиде җирдә хәзер, бакчы:
Кайсы шахтер, кайсы шофер, кайсы ташчы.

Кемдер кайтты туган йортка, ә кемнәрдер
Тормыш корып, еракларда итә гомер.

Ялгыша да кайсыбыздыр кайчагында,
Адаша да кайсыбыздыр кайчагында;

Беребез дә калмый ләкин җирдә ялгыз —
Баш очында янган чакта җиде йолдыз.

### Әлмәс

Юашланган хәзер, ярсымый
Әлмәс суы язлар җитсә дә.
Моңсу гына чыңлый, чылтырый,
Тыелып кына җырлый; ни сәбәп?

Картайгандыр, ахры, күрәсең,
Узган, ахры, инде яшьлеге.
Әлмәс буендагы таллардан
Тып-тып тамчы тама яшь кебек.

Җәйгә калмый суның эзе дә,
Әллә аккан, әллә юк Әлмәс...
Югалса да, ташкын сулары,
Хәтеремнән ул яз югалмас...

...Юл өзелде, акты күперләр,
Инеш Идел кебек ташыды.
Басулардан Әлмәс туена
Кар сулары чапты ашыгып.

Каерылып купкан бозларда
Елый-елый акты көчекләр.
Ыгы-зыгы килде яр буе:
«Коткарырга иде ничек тә!»

...Әйткән дә юк бала-чаганы,
Куркып калды хәтта ир-атлар —
Котырынып, ярсып, үкереп
Борылып кергәч Әлмәс зиратка.

Зират агачларын ташкын су
Тамырыннан йолкып ташлады.
Чардуганнар ауды чытырдап,
Актарылды кабер ташлары.

Ялтыратып, ялап алды да
Үр астында яткан карларны,
Нишлим соң мин әле, дигәндәй,
Кире чикте Әлмәс аннары.

Ташлар да юк, чардуганнар да,
Кем каберен хәзер кем белгән;
Зираттагы бик күп каберләр
Тигезләнгән иде җир белән...

Булган микән явыз бер бәндә,
Мәрхүмнәрнең монда кайсыдыр...
Әлмәс, әллә шуңа идеме
Ярларыңнан чыгып ярсуың?..

Чәчәкләре нурда коенып,
Янган чакта охшап ахакка,
Табигатьнең садә, саф гөлен
Рәнҗеткәнме берсе нахакка?

Йөргән микән кайсыберләре:
«Мин генә, — дип, — җирдә, фәкать мин».
Әллә инде, Әлмәс, шуңарга
Каберләрне тигез иттең син.

...Изге кеше иде, диләр бит,—
Аксакаллар юкны сөйләмәс, —
Шул ниратта минем әти дә, —
Белмәдеңме әллә син, Әлмәс!?.

...Син тынганга гына карамый,
Яз артыннан яңа яз килә.
Әлмәс, Әлмәс, минем күңелдә
Тик син һаман авыр хатирә.

## Сөю күпере

Үз гомерендә ничә күпер кичә кеше?..
Уйлый торгач кайберләре искә төште.

Инеш аша салынган бер агач күпер...
Идел аша салынган бер корыч күпер...

Һәм салават күпере бар аллы-гөлле,
Бала чакта кичтек аны без бер көнне...

Бар аннары саф хисләләр үткән күпер,
Кылдан нечкә, кылычтан да үткен күпер.

(Әкият түгел) илтер сине ул, әлбәттә,
Җәннәтләрнең җәннәтенә — мәхәббәткә.

Ничек кичим, ничек, димә, һич шаккатма,
Кичәрсең син аны яшьлек дигән атта.

Кире кайтыр булсаң ләкин, килмә ярга,
Кире кайтыр булсаң ләкин, кермә анда, —

Күпер кылдай, күпер — кылыч... аста ялкын,
Мәхәббәттән кайтмас яшьлек дигән атың...

## Этюд

Карт карама көтте сабыр гына,
Яшь ужымнар сөенеп биеште.
Кысыр болыт узды баш очыннан,
Кыр өстеннән коры җил исте.

Шаулады да тынды карт карама,
Бернәрсә дә булмаган сыман...
Яшь ужымнар һаман йөгерәләр
Яумый узган болыт артыннан.

## Бәрәңге алмасы

Беркем дә, беркем дә күрмәсме,
Беркем дә иелеп алмасмы? —
Кап-кара бураэна өстендә
Ямь-яшел бәрәңге алмасы.

Яңгырлы шәрә кыр, юеш җир...
Җил исә кояшсыз яклардан.
Бары тик бәрәңге алмасы
Кояшлы җәй төсен саклаган.

Күзләрнең азагы җиткәнче
Яшьлеген, сафлыгын саклар да —
Күмелер бәрәңге алмасы
Җәй төсен җуймыйча ак карга.

## Сабир Шәрипов

# СӨЛЕК

хикәя

### I



Исхак хаҗи ике улы белән киңәшеп утыра.

— Менә җәйнең уртасы җитеп килә, олан-нар. Явым-төшем һаман юк; язын да су ташы-мады, ичмасам. Үләннәр бик начар үсәләр. Моннан болай яңгырлар явып, үлән бер кадәре үссә дә, ул барыбер печән чабырлык дәрәҗәдә булмас... Быел кыш би-ик авыр киләчәк!..

— Бездә ни чара бар соң, әти? Ходаның язганын күрербез инде.

— Анысы шулай, улым Кадыйр. Ләкин саклыкта хурлык юк дигәннәр, берәр чарасын күрә башларга вакыт... Мал-туарның санын бераз ишәйтеп, әле генә адәм рәтенә кереп киләбез. Әгәр кышын дүрт-биш йөз баш терлегең кырылып калса, тагы да рәттән чыктың дигән сүз түгелме соң?!

— Уеңа ни килде, шуны сөйли бирәсең, бернинди хәвеф-хәтәр күренми әлегә. Көз кайда да, без кайда?.. Аңар хәтле ниләр булып бетәсен кем белгән? Мең ярым елкы, мең ярым куй, йөзләгән сыер, илле-алтмыш дөядән бер өч-дүрт йөз баш үлеп калганга гына карап, кешедән ким булмабыз әле!

— И-и улым, бетмәде шул тинтәкләрчә кыска уйлап кырт кисүең! Хәзердән үк кайгырта башламасаң, җан кысылган чакта акыл табылмый ул. Уйларга вакытың да булмас.

— Әйе, Кәрим, әти дөрес сөйли, уйларга кирәк чыннан да. Тик коры уйлаудан гына ни файда?.. Әйтик, елкыларны — Битпак далага, дөяләрне Чу ягына җибәрербез, ди, ә сыерлар белән куйларны нишләтербез? Менә шуннан башларга кирәк эшне. Минемчә, сыерларның яртысын печәнгә алыштырырга мөмкин. Сөткә туя алмыйча интегеп утыручы ярлы-ябагай әллә ни хәтле, кышның ничек килерен аларның берсе дә уйлап карамый әле. Шуларның һәрберсе, барлыюклы печәннәрен биреп, берәр сыер алырга тырышачак.

— Бәрәкалла! Менә бу чын ата улының сүзе, ичмасам! Өмет бар үзеңнән, өмет бар, улым Кадыйр, бәрәкалла! Шулай да, ы-ым, чак кына җитенкерәмәгән җирләре дә бар әле сүзләреңнең, яшьрәксең шул. Хәер, үсә төшеп, акылың тулган чакта миннән дә уздырып

жибәрүең ихтимал. Хәзер дә бит нәкъ өстенә баса яздың... Яле, тагы да бераз уйлап карагызчы!

— Әллә печәнгә куйларны алыштырыргамы?

— Сатып ук жибәрмик микән барысын да?

— Чү, житәрегез, икәвегез дә туры юлдан яздыгыз. Куйларны алыштырырга дип, син, Кадыйр, туры юлыңнан читкә тайпылдың; ә син, Кәрим, сатып жибәрергә дип, бөтенләй башка якка киттең. Ул ни дигән сүз тагы? Әллә ни зур бәла-казалар ишелеп төшмәгән әле башыбызга... Минем акылны тыңлап карагыз, алайса. Әнә Исел елгасы буйлап баштан түбәнгә кадәр төшсәгез, һәр ике өйнең берсе сөт-катыксыз интегеп утырган булуын күрерсез. Һәрберсенең диярлек печән чабыр болынлыгы бар, мәгәр, терлекләре булмагач, рәтләп печән чапмыйлар. Әгәр менә шуларның кулларына савымга бер-икедән сыер өләшеп чыксаң, хәер-фатиха яудырудан тыш, сыерларыңны да авыр кыштан чыгарып бирмәсләрме соң? Я, ничек уйлыйсыз?

— Менә бу акыл!.. Тик, кызганычка каршы, савып торырга сыер бирсәгезче дип сорап килүче күренми хәзергә. Узган елларда андыйлар булгалаган иде булуын, мәгәр бирмәгәч, алары да юкка чыктылар... Элгәредән килгән гадәт булмагач, «мә, моны ал» диюгә генә күнәрләр микән? Шикләнеп калулары да бар тагы...

— Аның гына әмәле табылыр, тик минем фикерләремнең дөрес булу-булмавын әйтегез. Әгәр дөрес тапсагыз, өләшү хәйләсен дә үзем өйрәтермен.

— Дөрес булмый ни!

— Бик дөрес!

— Алайса, Куандык мулланы чакырыгыз, киңәшербез. Яле, Кәрим, өендә микән ул, барып карачы тиз генә... Ә син, Кадыйр, тыңла: мулла килгәч, мин бер куркыныч хәбәр сөйләрмен, син сүзләремне җөпләп утырырсың. Теге күк кашка атны хәзер үк ишек төбенә бәйләп куй. Минем сүзләрем бетүгә, шуны муллага хәер кылып бирерсең.

Куандык мулла тиз килеп житте. Хаҗи сүзгә башлады:

— Мулла, сине бер киңәшкә чакырдым әле... Мал-мөлкәт исән булса да, тән-бәдәнем әллә ничек авыраеп тора; күңел дә урынында түгел. Бик начар төш күрдем... Әллә кайтмас сәфәр, каты хөкем көтә микән мине... Күпме гомерем калгандыр инде...

— Куегызчы, алла сакласын, юкны сөйләмәгез! Төшкәниләр генә керми соң? Яткан жирегез жайсыз булгандыр. Нәзер әйтеп сәдака бирсәгез, аллаһы боерса, берни дә булмас әле!

— Муллакә, әтинең төшеннән мин дә бик шүрләп утырам. Аның болай каты куркынуын бер дә күрмәгән идем әле. Чырае да әллә ничек үзгәреп уянды... Ярдәмеңнән, хәер-фатихаңнан ташлама инде безне! Теге ишек төбендә торган күк кашка атны сезгә нәзер кылдык. Әтиемнең бик яратып менгән аты иде, хәзер сез менегез,— дип, Кадыйр ишек төбендә торган атка ишарәләп күрсәтте.

Мулла эчтән генә бер-ике кәлимә дога укыды да: «Ходай, Исхак хажины бәла-казадан аулак ит, аның гомерен озын кыл, бала-чагасының игелеген күрсәт!» — дип, кычкырып теләк теләп, фатиха кылды.

— Мулла, син атка атлан, илне гиз, ачыккан-ябыккан ярлы-ябагайлар, гидайлар бар микән, шуларны белеш. Исел суын югарыдан түбәнгә кадәре буйла, кем ач, кем ялангач, шуларның һәммәсен белешеп, кәгазьгә язып кайт. Узган елны, бер кавем ярлы-мескен файдаланып торырга савым сыер сораган чакта, бирмәгән идем, шуларны да төшемдә күрдем, әллә күз яшьләре төште микән...

— Хуп, тәкъсир, хуп, моныгыз бик яхшы, бик изге эш, нәкъ ходай юлы бу! Андый ниятегез бар икән, көне-төне аягүрә хезмәте-

гездә булырмын. Ә, ни, илне гизгәндә карап кына чыгаргамы, әллә берәр сәлам-мазар да тапшырыргамы? Төшегез турында да, бәлкем, бер-ике сүз әйтергәдер?

— Юк, ул кадәре үк кирәкмәс, бары үзең бик ышанган, сыйлаган кешеләргә генә киная кылырсың. Артык шаулап, кеше көлкесенә кала күрмик тагы... Уемның асылын әйтсәм, мин үз кулымда дүртбиш кенә сыер калдырып, калганнарын савып файдаланыр өчен ил арасына өләшергә ниятлим. Ичмасам, ярлы-мескеннәрнең бала-чагасы рәхәтен бер күрсен... Ихтимал, аларның изге теләкләре кабул булып, күңелем дә юаныч табыр.

— Яхшы, тәкъсир, калган эшне миңа гына тапшырыгыз инде. Бүген үк юлга чыгам, бөтен илне гизәм. Әйе, ярлы-мескеннең теләге кабул булыр, тиз савыгырсыз әле, насыйбы булса.

— Ярар, юлың уң булсын.

## II

Исел елгасына Кызылсу кушылган җирдә кырык өй чамасы «ятаклар» тора. Кышлаклары Иселнең буенда гына булып, җәйләүгә күченер чак күптән җитсә дә, алар шул кышлакларыннан әллә ни ерак китмәгәннәр, бәлки сөзәк тау кашлагына таба чак кына елыша төшкәннәр дә, тирмәләре барлары тирмәсен тегеп, тирмәсезләре куыш әмәлләп, анысына да хәле җитмәгәннәре талдан чатырлар ясап, шуларның өсләрен яшел камыш белән каплап, бер чарасын тапканнар. Чөнки җәйләүгә күченер өчен менәр атлары, йөк тартырга үгезләре булмаудан утраклыкка мәҗбүр ителгән ярлы-ябагайлар — «ятаклар» болар. Өстәвенә, Иселнең балыгыннан да аларның аерыласы килми...

Авылның бар халкы — ире-хатыны бергә — иртәнге якта һәм кичкә таба берәр мәртәбә, тәмам чишенеп ташлап, елга буйлап йөгерә-йөгерә, суга чума-чума, балык аулыйлар, барлы-юклы тотканнарын тиң бүлешеп, көндәлек ризыгын аералар. Бүген дә шул, иртәгә дә шул. Узган елларны да шулай иде, киләчәктә дә шулай буласы төсле. Якын-тирәдә шөгыльләнерлек кәсеп юк; ялланып эшләргә байлары да җитәрлек түгел. Чөнки байлары бар җирдә ярлылары да күп була бит. Шуңа күрә бу кырык өйнең кешеләре берәр кәсеп табудан күптәннән инде өмет өзгәннәр. Муллыктан да, туеп ашаудан да... Ә кырык өйдә ике йөзгә якын җан бар. Сыер саны исә ун-унбиш кенә. Тагын биш-алты ат. Тик болар киң болыннардагы үләнне, аннан чабылган печәнне дә майтарып ашарлык мал түгел шул. Артык печәнне чабып сатарга да җае юк. Шуңа күрә болыннарын саклап маташмыйлар алар — кем туры килсә, шул файдалана, күченеп узучылар да рәхәтләнеп, хәтта берничә көнгә куна ятып, терлекләрен утлаталар...

Куандык мулла нәкъ менә шушы авылга килеп төште. Картлар мулла тирәсенә җыелып, ходай сүзләрен ишетергә өмет багладылар. Куандык исә сүзне икенчедән башлады:

— Сатыбай авылыннан иртәнге караңгыда ук чыккан идем. Юлда бер нинди ил юк икән, туктап хәл җыярга, атымны утлатып алырга да булмады. Үлеп-талып, көч-хәлгә генә килеп җиттем. Ягез, берәр нәрсә биреп, авызымны чылатмасагыз, телләрем кибеп бетте, дәрманым калмады.

— Әйдә, кем, чап әле Уразалинең өенә, әйрән-мазары юк микән? Булса, тиз китер, бездә бер йотым әйбер дә калмаган.

— И-и, нәрсә булсын ди анда! Бая гына калдык-постыгын җыеп эчеп, савыт-сабаларын кибәргә куйдылар. Кичкә таба, сыерларны саугач кына булмаса, хәзер бөтен авылдан бер йотым сөт тапмассың.

— Алайса, тизрәк су кайнатыгыз! Бер-икәвегез ау алып Иселгә төшегез, бәлки муллакә тәләгенә эләгер әле.

— Әй, үләр хәлгә җитәм бит, эчем янып бара! Карагыз әле яхшылап, кырык өйдән бер йотым әйрән табылмады дигән ни сүз ул! Адәм ышанмас моңа... Яхшырак эзләгез! — дип, мулла да такылдап зарлануыннан туктамады.

Мәгәр өйдә утыручылар, урыннарыннан кузгалмыйча, башларын игән хәлдә хәрәкәтсез кала бирделәр. Ниһаять, бер карт тезеп китте:

— Анысы дөрес, муллакә, адәм ышанырлык түгел шул. Тик бу авылда ике-өч көн торып карасагыз, үзегез дә ышаныр идегез... Нишләмәк кирәк, булса, кызганыр идекме соң сездән? Ике йөзләп кеше, унбишләп кенә сыер. Сөткә дә су кушмыйча эчкәнебез юк. Савылган саен бетә тора. Аның чын төсен, үз тәмен дә онытабарабыз инде. Бездән соңгылар бөтенләйгә онытырлар.

— Ярдәмләшергә хәллерәк якыннарыгыз юкмы, ичмасам?.. Халык бит, ил бит, яхшылап, инәлеп сорасагыз, савып торыр өчен кайсы казакъ баласы үзенең артык сыерын бирмәс икән?

— Бездә нинди «хәлле якын» булсын, ди, бөтен токымыбыз белән бөлгенлеккә саптык. «Казакъ баласы»ннан да сорамадык түгел, сорадык. Тик, ачның хәлен тук белми, дип дөрес әйткәннәр икән, бирмәделәр шул. Әгәр бирсәләр, алмас идекмени?!

— Алай... Хәлегез бик мөшкел икән сезнең, берәр чарасын күрергә кирәк. Бай кардәшләрегезгә барыгыз, сорагыз тагы. Әле җәй узмаган, болыннарыгыз да мул, мал утлатудан саклап, бераз печән чабып алыгыз. Сезнең хәлегез турында мин дә агай-энегә әйтермен. Исхак хаҗига да әйтергә кирәк, күмәкләшер бәлки.

— Куй аны, муллакә! Исхактан өченче елны гына сораган идек, якын да җибәрмәде. Бүген генә күңеле нечкәреп китмәстер. Юк, әйтмәгез аны, бирмәячәк ул. Аңар әйткән сүз дә әрәм...

— Алай димәгез, барыгыз да мөселман балалары, «мөселманның малы уртак» дигәннәр. Сез үләр хәлгә төшкәндә, ул шулай тыныч кына карап тора алмас. Ярар, мин үзем сөйләшермен аның белән! Өй башына берәрдән сыер алып, кышка кадәр савып торырсыз. Аның сыерлары сөтле, тиз ташламый торган була, кышның уртасына чаклы рәхәтен күрерсез. Аннан ары язга ике-өч кенә ай кала, тагы бозаулар. Шәфкате төшсә, бәлкем...

— И-и, тәкъсир, баш өсте, алайса, баш өсте, коллык сезгә! Алып кына бирегез, моннан артык безгә ни кирәк тагы?!

— Яхшыдан шәрәфәт дигән сүз шушыдыр инде, муллакә!..

— Сезне безгә ходай китердеме, әллә Хозырның үземе сез?

— Ике дөньяда да теләгегез булсын!..

— Урыныгыз — җәннәт түре!

Халык шау-гөр килде, картлар муллага хәер-дога укыдылар. Тыңлап утырган кыз-хатынның күзләренә яшь чыкты. Нидер сизеп, бала-чагалар да тынып калдылар. Моңарчы читтәрәк утырган берәү чак кына калкып, мулладан сорады:

— Савып торыр өчен алган сыер үлеп куйса, нәрсәбезне түләрбез икән? Баштан китмәс бәла булмасмы бу?

Әле генә сөенүләреннән елый башлаган хатын-кызлар сискәнеп куйдылар, ирләр дә сагаеп калдылар; барысы да муллага төбәлеп карады.

— Бәгырьләрем! Ул тәңренең эше инде, аңа бернинди чара юк, мал түгел адәм дә үлә бит! Яхшылап баксагыз, бер көтелмәгән бәлаказасы килеп чыкмаса, ходай үзе саклар әле! Бер генә сыер алмыйсыз бит, егерме яки утыз сыер алырсыз, аның барысы да үлмәстер, берсе-икесе үләр... Нишләрсез, җыйнаулашып түләрсез әле берлеярым сыерны...

...Авыл халкы арасында чыш-пыш, имеш-мимешләр таралып өлгерде:

— Исхак хаҗи тагы да Мәккәгә җыена икән...

— Юк ла, нинди Мәккә, аңар «кылтамак» чире ябышкан, тамагыннан бер бөртек тә үтми, диләр, шуңа күрә иман эзли ул...

— Бик яман төш күргән, имеш...

— Кара, авызыңнан чыгарасы булма!..

## III

Өч-дүрт көннән бирле Исхак хаҗиның авылы ярлы-ябагай белән шыгрым тулы. Аларның беренче төркеме, егермеләп бозаулы сыерны алып, кайтып та китте инде, икенчеләре исә, хаҗи алдында тез чүгеп, авыр тормыштан зарлана-зарлана, инәлеп утыралар:

— Хаҗәкә, башка чарам калмагач кына килдем. Үземнән башка тагы дүрт җан. Барысы да ялангач, бала-чага бөтен җәй буена сөткатыкның йөзен күрмәде; үләр хәлгә җиттек инде... Өметебез сездә генә: көзгә кадәре бер сыерыгызны савымга биреп тормассыз микән...

— И мескеннәрем, миннән башка кеше беткәнме әллә сезгә!.. Савым сыерлары биреп торам дип, бөтенләй бәлагә калдым: ике-өч көндә генә әллә никадәр сыер өләшеп җибәрдем. Бәлки үзегез дә күргәнсездер аларны?

— Әйе, күрдек, тәкъсир! Бик күп гидайларны сөендергән икәнсез, барысы да сезнең исәнлегегезне теләп алкыш әйтеп баралар, Хаҗәкә! Безне дә мәрхәмәтегездән ташламагыз инде...

— Һым, нишләргә инде... Шул хәтле җирдән килеп торгач, буш кул белән җибәреп булмас инде үзегезне, рәнҗеп китүегез бар. Өйдәге балаларыгыз да өмет итеп утыралардыр... Сыерларымның беразын сатып, Мәккәгә юнәлү иде исәп. Мәгәр сезне болай калдырып, ничек тыныч күңел белән китәрсең... Ярар инде, берәр сыердан алырсыз болай булгач. Тик карагыз аны, яхшы багасы булыгыз, үлеп-нитеп калмасын. Печән әзерләдегезме? Ничек кыш чыгасын да уйларга кирәк булыр. Сыерларым сөтле дә, озак та савыла — кышның уртасына хәтле рәхәтен күрерсез. Калын карда мәшәкатьләнеп йөрмәс өчен язын, бозаулагач кына китереп бирерсез.

— И-и, Хаҗәкә, ходаның гына казасы килмәсә, бер сыерны гына асрый алырбыз инде! Печән турында да, кыш турында да уйладык, авылга кайткач ук эшкә тотынырбыз.

— Ярар, алайса, бәрәкәтен күрегез. Бозавын да яхшы карарсыз; көзен, Пукырау базары алдыннан, анасыннан аерып, үземә китереп бирерсез... Яле, оланнар, бу мосафирларга кымыз бирдегезме? Эчкән булсалар, юлларына салыгыз. Чынлап бирсәң, ныклап бир дигәннәр, теләүчеләре булса, икешәр сыер бирергә дә мөмкин, рәхәтен күрсеннәр!

...Алларына берәрдән сыер салып, үз авылларына кайтып баручы гидайларның түбәләре күккә җитәрдәй булган; дәртләнә-дәртләнә сөйләшеп баралар:

— Ходай биргән ризык тешеңне ватып авызыңа керер дигәннәре шушы инде, әнә үләбез, менә бетәбез дип тора идек...

— Әйтмә дә!..

— Яхшының аты да яхшы, заты да яхшы: Хаҗәкәң игелекле кеше шул...

— Әллә... күңеленә кинәт ходай игелек салган булмаса... Күптәннән аның кешегә хәер эшләве ишетелми иде...

— Һи, сөйләмә инде юкны!.. Ни генә әйтмә, Хаҗәкәнең бу эше изгелектән гайре берни дә түгел: күпме гидайларны ачлыктан коткара бит! Исемлеккә язган чакта миңа Кадыйр сиксән дүртенче булдың дип әйтте. Димәк, моңар хәтле сиксән өч сыер бирелгән икән. Моның нәрсәсе начар?

— Ичмаса, балалар бер туячак сөткә!

— Үтереп алмыйча исән-имин генә кире өерләренә кушсак икән...

— Менә, менә, шунысын әйт!

— Быел эшкә яраган хаҗи киләсе елны да хаҗәт булыр әле, егетләр, кышка яхшы әзерләнеп, хайваннарын әйбәт карарга кирәк. Тук-симез тотсаң, корчаңгы да тимәс, чир дә ябышмас. Ходай гына сакласын! Үзеңә дә сак булырга, яхшылыкның кадерен белергә кирәк.

— Сөйләмә дә инде, мондый яхшылыкны бер дә онытасыбыз юк.

— Һай, егетләр, кешеләргә дә исең китәрлек! Хәер, барысына да ошап булмый шул. Әйтик, бу Хаҗәкәнне дә читтән күпме генә чәйнәмәделәр? Әнә, безнең авылдагы йолкыш Бәкерне генә ал. Кайкайдагы юк-барны уйлап чыгарып, гел тузга язмаганны сөйли. Имештер, Исхак берәр этлек белән эшли моны; имештер, ачтан үлсә дә, бай бусагасына барып баш иясе түгел, имештер, сыеры үлсә, хаҗи үзеңне колга әверелдерер... Адәм барыбер бәндә инде шул! Барлык кешегә дә акыл бертигез бирелмәгән. Безнең Бәкергә ул бөтенләй аз эләккән!..

...Кызылсу тамагындагы авыл кешеләре егермеләп сыер әйдәп кайттылар. Шулай итеп, хәзер савым сыерның саны кырыкка җитә язды. Сөт-катык сизелеп мулайды, әлбәттә. Бары Бәкерләр белән тагы берничә өй генә элеккечә сыерсыз-сөтсез кала бирделәр. Бәкернең хатыны, табигый, моңа түзеп тора алмады:

— Өй тулы яшь бала, биш-алты җан... Ни сыеры, ни булмаса кәҗәсе дә юк. Ничек көн күрмәк кирәк? Әллә мин башкаларның хатыннарыннан кимме?! Бер генә сыерны карап, сөтен сава алыр идем, шәт! Ходай үзе биреп торган сыерны да барып ала белмәдең бит, әллә сөттән тәмам ихласың кайткан...

— Җансылу дим, җитәр инде, куй! Сүз аңламасаң, телеңне тыя бел, ичмаса. Ничә кабат әйттем үзеңә: бала-чага белән элеккечә үк үлмәбез әле дип... Тәнем таза, исәнлегем шулай яхшы булса, кыймылдый-кыймылдый бер рәткә керербез әле. Әнә, апкилгән балыкларның кирәк хәтлесен генә ашап, калганын яхшылап тозлавыңны, ыслап киптерүеңне бел. Көзгә хәтле берәр ун пот кадәре кипкән балык җыя алсак, ходай рәткә салыр әле. Кирәк икән, быелга киемкишәкне дә яңартмыйча торырбыз... Берәр башмак тана алып булмасмы дип уйлыйм. Ил белән бергә печәнен дә чабарга кирәк...

— Кутыр бәтиең дә булмагач, ул печән атаңның башына хаҗәтме?!

— Чәче озын, акылы кыска дип, юкка гына әйтмиләр шул сезгә. Абзар-каралтың түбәсенә мул итеп печән өеп алсаң, башыңа ишелеп төшмәс әле! Үзебезгә кирәкмәсә, башкаларга ярап куяр. Әнә, балаларыбыз өй саен йөреп сөт эчәләр, бәлки аларның сыерлары да йорт саен йөреп печән ашарлар. Икенче хаҗәткә дә ярап куюы бар. Тырыша-тырмаша торгач безнең дә кул җитәр әле бер...

— Һи, синең кулың җиткәнче... бүген түзәсе бар бит, бүген! Башкаларның хатын-калачы, бала-чагасы сөт-катыкка гарык булып туйдылар. Ә син ходай үзе биреп торган сыерны да... Балаларыңны уйлар идең, ичмаса!

— Түз бераз, тагы бераз түз! Ул сыер өләшүләрнең ничек бетәсен каян беләсең әле?! Мең елкыга хуҗа була белгән Исхак хаҗи ахмак түгел ул. Ни өчен соң элек тамчы да тамызмый торган кеше кинәт шулай юмартланып китте икән?.. Тагы бераз сабыр итик, бик булмый башласа, киләсе елны алырбыз. Чын изге кеше икән, бу яхшылыкның бер өлешен киләсе елны да эшләр әле. Түз шуңа күрә, үз эшеңне бел, ә минем башымны артык катырма!

Бәкер, балык авын алып, елга буена юнәлде.

Беркадәре вакыт узды. Сөт-катыкка бераз туйгач, Кызылсу тамагындагы авылның кешеләре корт-эремчек хәстәрләүнең дә кайгысын күрә башладылар. Бер яктан балык аулап, икенче яктан печән чапкан халык иртәнге караңгыдан кичке эңгергә чаклы мавыгып эшләде. Хатын-калач ашаудан арткан балыкны тозлап, ыслап, киптерә барды. Бәкер дә башкалар белән бергә печән чапты, балык аулады, балык тозлап киптерде.

Көз җитте. Ярлы-ятакларның кышлактагы өйләре янына печән кибәннәре үсеп чыкты. Бәкерләрнең йорты янына да бер кибән килеп утырды. Өй түбәсендә исә, кечкенә чүмәлә булып, ыслап киптергән балык өеме үсеп чыкты.

Көннәр суыта башлады. Балык җыючы сәүдәгәрләр килеп, йорт саен йөреп балык ала башладылар. Сатучылар исә күлмәк-ыштанлык, бишмәт-чикмәнлек, тагы башка хаҗәт киемнәрен алып, өс-башларын яңарттылар. Бәкернең хатыны өчен иренә бәйләнеп алырга тагы бер сылтау туды:

— Ичмаса, тәннәремне капларлык бер күлмәклек тә алмаска итәсең бит, ни йөзем белән кеше күзенә күренеп йөрим инде? Мескен башым, каян гына синә дучар булдым икән?! Сине баетам дип, болай ач-ялангач интеккәнче, хәер теләп каңгырып китүең яхшырак! Үзең үк үтереп ташла я булмаса!

— Бар, алайса, чәнчелеп кит, эттән туган нәмәстә!.. Карале, я бөтенләйгә югал, яки минем сүземне тыңла! Үзең беләсең, хәзергә балалар яшь, ничек туры килде шулай йөрерләр, түзәрләр. Ә бераз үсә төшкәч, аларга да кием-салым күбрәк кирәк булыр, менә шул чакны белерсең чын авырлыкның нәрсә икәнен. Әгәр хәзергә юрганга карап аяк сузып, кымтанып-кыстанып дигәндәй, иске-москыларыбызны ямап, шуларны киеп торсак, кулыбыз да чак кына озая төшәр иде, ичмасам. Ә син гел баш катырасың... Балык саткан утыз сумны бераз саклап торыйк, Пукырау базарына барып карыйм, бәлки бирәр сыер кисәге алып булыр үзенә. Печәнебез бар, кыштан исән-имин чыгарып, бозаулатып та алсак, үзебезнең хак малыбыз була түгелме соң? Аннары теләгән хәтле ашарсың сөт-катыгыңны. Шулай. Хәзергә иске күлмәгеңне ямап киярсең; минем чикмәнне дә сиплә́п куй. Тәнебез күренмәсә, ямаулы гына булуы берни түгел.

— Утыз сумга да сыер алып буламыни?.. Һи, җаным, әгәр бер сыерга кулым чынлап җитәчәк булса, бөтенләй ялангач йөрергә дә риза бит мин! Сыеры да булмый, киеме дә алынмыйча калып, юклыбарлы акчабыз тузып бетмәгәе дип куркам шул. Рамат [1] түлисе дә бар... Авылнай килеп якаңнан алса, нәрсәңне биреп котылырсың? Җыр җырлап кына юлга салып булмый бит аны...

— Менә-менә! Ичмасам, хәзер акыллы сүзләр сөйли башладың. Әгәр син дә шулай яхшы аңлап, бергә киңәшеп эшләсәк, бер чарасы табылыр әле! Авылнай килсә ни, бер-ике мәртәбә качып калырмын, аннары тагы бер әмәле булыр...

---

[1] Рамат — революциягә кадәр казакълардан алына торган салымның бер төре.

## IV

Халык Пукырау ярминкәсеннән кайта. Бәкер дә, бер бозаулы сыерны алып, җай гына кайтып килә. Түбәсе күккә тиярдәй булган. Мәгәр очраган кешеләр генә күзләрен зур ачып, башын чайкап гаҗәпләнәләр:

— Мескенкәем, нишләп сыерың бу кадәрябык, әллә чирле бер нәмәстәме?.. Өеңә ничек кайтып җитәр икәнсең...

— Җәй буе аусыл [1] белән авырган икән. Хәзер зарарсыз инде. Яхшылап баксам, рәтләнер бит, әйеме? Авылга да әкренләп җитәрбез әле. Шушындыйлары гына булмаса, рәтлерәкләренең янына да барасы түгел. Монысына да әле өч көн сатулашырга туры килде.

Сыерының нилектән гел сөяк белән тиредән генә торуын ул хатынына да яхшылап аңлатты. Икәүләп аңа җылы абзар ясадылар. Авызыннан печән өзмичә, яшь бала тәрбияләгән кебек хәстәрләп бактылар. Һәм ике-өч ай эчендә сыеры да, бозавы да күзгә күренеп тазарды, аруланды.

Авыл халкы сөттән аерылган бозауларын малларның хуҗасы Исхак хаҗига илтеп бирергә җыена башлады. Мәгәр нәкъ шул чакны хаҗидан: «Бозауларны аналарыннан аермыйча язга тиклем бергә тотсыннар, кар беткәч үзем кеше җибәрермен», дигән хәбәр килеп төште. Шулай итеп, сыерлар да, бозаулар да бергә калдылар.

Ә кыш гаҗәп авыр килде. Малларга печән җитми башлады. Аерата терлеге күп байлар мөшкел хәлгә калдылар. Елкыларны Битпак далага җибәртеп, сыерларын ил арасына өләшеп, аларның мәшәкатеннән котылган Исхак хаҗига хәзер кырык-илле дөясе зур бәлагә әверелгән иде. Махсус көтүчеләр белән еракка — кары юка тарафларга җибәрергә вакыты узган: барып җиткәнче ачтан кырылачаклар... Шуңа күрә дөяләр һаман үз авылында яталар. Кышның нәкъ уртасы җитүгә печән бөтенләй бетте. Исхак хаҗиның да җаны борын очында гына калгандай булды. Тәмам аптырагач тагы уллары белән киңәшә башлады.

— Печән хакы алтын бәясенә менде. Бер малыңны сатып алган печән белән икенчесен туендырырлык түгел! Җитмәсә, анысын да табып булмый, гел шулай буранлатып тора бирсә, кая качып котылуың да билгесез...

— Әйе шул, нишләргә дә белмисең. Ялланып мал ашатып бирүчеләр дә юкка чыктылар... Бәлкем, әти, кала урыслары печән сатадыр? Сорашып-эзләштереп карыйк микән әллә?

— Ул икенче мәсьәлә; аннары урыслары да бит печәнне арзанга гына сатмаслар. Теге көнне үк бер олау печәнгә бер ат сорыйлар иде. Хәзер тагы да кыйбатрактыр. Җитмәсә, ул бер олау белән икенче бер атны да кыштан чыгарып булмый. Минемчә, савым сыер алып торучыларның кылларын тартып карарга кирәк. Бәлки бездән алган сыерларны үтереп алучылар бардыр. Андыйлары булса, дөяләрне шундыйлардан бактырырга кирәк.

— Ник булмасын, бар андыйлар! Кызылсу тамагындагы авылда бер сыер, алты бозау үлгән, диләр.

— Алайса, ни карап утырабыз әле? Сыерны үтерүче унны, бер бозау өчен икешәр дөяне язга хәтле ашатып бирсеннәр! Димәк, ул авылда егерме ике дөяне урнаштырып була дигән сүз. Ике-өч дөяне артыграк ала барырга кирәк. Әгәр анда сыйдыра алмасагыз, берәр урысны яллап калдырырга ярый, берсен алып, икесен кыштан исәнимин чыгарып бирсә, анысы да зур эш. Әйдәгез, баргач күрерсез.

---

[1] Аусыл — ящур чире.

— Була бу, була! Кәрим атка атлансын да ил арасына китсен, кулдагы сыерларның исәбен алсын, ә мин егерме биш дөяне әйдәп, Кызылсу тамагына юнәлим. Мин эшләремне бетереп кайтканчы, Кәрим дә кире әйләнер. Аннары тагы күз күрер.

— Дөрес, шулай эшләгез, оланнар. Тик җәһәтрәк кыймылдагыз, вакыт тыгыз, күрәсез бит!

Егерме биш дөяне әйдәгән Кадыйр, юлда бер кунып, Кызылсу тамагына килеп җитте һәм Уразали аксакалның өенә туктады.

— Хаҗи бик күп сәлам әйтте үзеңә. Кыш бик авыр килде, болай булыр дип, бер дә көтмәгән идек, ди. Печән бетте. Дөяләрне вакытында читкә җибәрә алмыйча калдык. Аптырагач, сезнең авылга килдек, ничек булса да, язга хәтле асрап бирерсез.

— Килүең яхшы, улым, тик... ни... бездә дә бит шул үзең әйткән кыш газабы. Барлы-юклы печәннәрен кулларындагы сыерларына ашаталар, артканы булса, сатып көн итәләр. Белмим инде, күз нурым, белмим. Җыйнаулашып сөйләшеп карарга кирәк.

Уразали аксакал авыл кешеләрен чакырта башлады. Бәкер дә килде. Халык җыелып беткәч, аксакал сүзгә башлады:

— Хаҗи зур сәламнәр белән улы Кадыйрны җибәргән икән. Печәннәре бетеп, уңайсызрак хәлдә калган булса кирәк. Язга хәтле дөяләрне асрап бирсен ди икән. Ягез, ни әйтәсез?..

— Атамның тагы бер сәламе бар: бездән алып торган сыерларның, бозауларның берничәсе үлгән икән. Әгәр шул кулларындагы әманәтне үтереп алган кешеләр сыер өчен ун, бозау өчен икешәр дөя асрап бирсәләр, үлгән малларның хакын түләүдән котылачаклар дип әйтте!

— Я, нишлибез соң, егетләр? Сез дип Мәккәгә барыр юлыннан туктады Хаҗәкәгез, савып торыр өчен сыерларын бирде үзегезгә. Анысын бик ошаттык. Җәй буе хатын-балабыз сөт-катыкка туеп яшәде. Хәзер Хаҗәкәнең дә бер ихтыяҗы бар икән, минемчә, аны тыңларга кирәк... Ник дәшмисез?

— Нәрсә әйтик соң, каршы бер сүзебез дә юк... Хаҗи шәригать буенча әйтә булыр; шәригать шулай куша икән, без... ни... Миндәге сыерның үлүе хак, тик ун дөяне ашатып чыга алмам, әгәр җәмәгать кумәкләшмәсә... Белмим инде, нишләрмен икән...

— Чыннан да, нишлисең инде, алырсың болай булгач, без дә... тик карап тормабыз. Димәк, син ун дөяне алдың була. Куҗабәк белән Казый, Рәҗәп белән Илүбай икешәр дөя алырлар; Казыбәк белән Әлкәйгә дә икешәрдән дөя тиеш. Шулай итеп, алты бозау өчен унике, бер сыерга тагы ун — барлыгы егерме ике дөя булды дигән сүз. Я, Кадыйр улым, йомышың йомышланып бетә язды бугай?

— Шулай, аксакал, бетә язды, нибары өч кенә дөям калды. Тик үзем дә сизеп торам, аларны монда сыйдырып булмас шикелле, әгәр печәне мул, терлеге аз бераү булса, хакын сөйләшер идек...

— Бу авылда сездән сыер алмаган өч-дүрт кенә өй бар, шуларның берсе менә бу Бәкер.

— Чыннан да, Бәкер, син ни әйтерсең моңа?

— Асрап утырган бер бозаулы сыерым бар, аннан арткан печәнне бер кешегә сатып куйган идем. Юк, миннән булмастыр, ахры,— дип, Бәкер якын да китермәде.

Ләкин Кадыйр калган дөяләр өчен дә башка авыллардан урынны бик тиз тапты. Шулай итеп, Исхак хаҗиның йөздән артык сыеры, иллегә якын дөясе җылы абзарлы, йомшак печәнле булып, авыр кышта ачтан катып үлү куркынычыннан җиңел генә коткарылды. Урта хәлле хуҗалар исә, печәннәре беткәч, терлекләрен кая куярга белмичә аптырап, ике малының берсен сатып, калганын да үлем тыр-

нагыннан йолкып кала алмыйча, тәмам иза чигеп беттеләр. Тәүбаштан ук бөтен малларыннан аерылып, тәмам бөлгенлеккә төшүчеләр дә аз булмады бу елны...

## V

Яз килеп, көннәр җылынды; җир дә яшәрде.

Исхак хаҗи улларын янына алып, тагы әлеге сыерлары хакында киңәшеп утыра:

— Бу ысулдан, оланнар, киләчәктә дә файдаланырга, хәтта аны кәсеп итәргә кирәк булыр, ахрысы. Бездән әлгәргеләр белмичә эшләмәгәннәр шул. Җандарбәк байныкылар гел шулай итәләр, башкалары да... Күрәсез бит, сыерларыбызны кыштан исән-имин чыгарып бирделәр. Хәзер дә алмаска кирәк ул сыерларны, әйдә, сава бирсеннәр. Бары иркәк бозауларны гына яз саен җыя барырга кирәк, ә башмаклар кала бирсен — үсә торсыннар. Теше таналарны да бергә асрау шарты белән бирергә кирәк савым сыерларны. Шул. Үлгәннәре булса, түләтеп ала торырсыз.

Хаҗиның әмерен җиренә җиткерер өчен Кадыйр Кызылсу тамагына килде, тагы Уразали аксакалның өенә туктап, халыкны чакыртты.

— Бәрәкалла, атаңа бик зур рәхмәт! Сыерларны кире алса, сөткатыксыз нишләрбез дип, котыбыз алынып тора иде. И-и, Хаҗәкәм, тәбәррек, гел безне кайгырта икән ләбаса!

— Анысы шулай шулаен, тик таналарын да бергә калдыруы мөшкелрәк икән. Миндәге бозау теше иде, үлә-нитә калса, нишләрмен?

— Анысы мәгълүм инде, үлгәне өчен түләргә туры киләчәк. Әгәр таналарын да бергә асрарга риза булмасалар, сыерларын да кире алырсың дип боерды хаҗи.

— Куй, алай димә, риза булмаган кеше юк моңа. Сөт-катык барыбызга да кирәк ич, ансыз торуның нәрсә икәнен беләбез инде. Тәвәккәл булгач, тәвәккәл, без риза!

Бәкернең дә сыеры бозаулады, былтыргы бозавы да исән-имин — менә дигән тана. Артык печәне өчен юнәткән акчага хатын баласына кием-салым рәтләде. Хатыны белән куанышып бетә алмыйлар.

— Әйткән идем бит үзеңә! Сабыр төбе сары алтын дигәннәре менә шушы инде: сыерлы да булдык, киенеп тә алдык. Ә тегеләрнең ничек соң хәлләре? Тамаклары өчен бай ялчысына әверелделәр бит!

— Әйе шул, сары алтыным минем! — дип, күзләрен яшь каплаган хатын иренең муенына сарыла...

## VI

Ун ел үтте. Исхак хаҗи әле дә исән. Шул ук кәсеп белән шөгыльләнә. Гадәттәгечә, уллары белән сөйләшеп утыра.

— Я, Кадыйр, кеше кулындагы савым сыерларның хәле ничегрәк икән? Никадәре булган? Санадыңмы? Яле, күрсәтче исәбен!

— Була ул, әти, менә укып ук бирәм: җилмә ыруындагы илле биш йортта утыз биш, дөрмәләрнең йөз өендә тагы алтмыш сыерыбыз бар. Җарыкларда — егерме биш, казанкапларда — сигез, куканнарда — унбиш, Байназар нәселендә — ун, бодана белән җабай, балталы белән күкҗарыл һәм каравылларда барлыгы йөз дә алтмыш сыерыбыз бар. Җәмгысе өч йөз дә унөч сыер була!

— Бәрәкалла, һәр ыру да коры түгел икән, бары кусайлар гына алмаган. Ә ни өчен? Карагыз әле, теге тинәйләр дә читтә калган түгелме соң? Алар нигә сыер алмыйлар бездән?

— Тинәй белән кусайлар, әти, үзләре күп кешеле ырулар бит, аларның үзләрендә дә сыерлы байлар җитәрлек... Әти, дим, әллә әкренләп шушы эштән туарыла башлыйк микән? Бик зурга китеп бара. Кайсыбер өйләрдә дүрт-биш эре сыерыбыз бар. Үзләрендә безнекеннән башка бер тояк та мал юк. Бер көнне, шуларның барысын да җыеп ала башлаган чакта, җәнҗал-мазар чыгуы да ихтимал бит: үзләре ничә елдан бирле багып үстергән малны кем генә тиз биреп җибәрер икән? Ач калу куркынычы да көчле булса... Бәлки хәзердән үк шуларны азлап-азлап җыештыра барыргадыр?

— Куй, улым, куй, хәзергә ашыкма. Шулай, элеккечә үк үрчи торсыннар. Болай үскән мал безнең өчен ике яклап файдалы. Беренчедән, без һәр көзне ике йөздән артык тана-турпак җыеп алабыз, аларны ярминкәдә сатып, мең ярым сумнан артык акчаны янчыкка салабыз. Үлгән бозауларны акчалата түләтәбез, моннан биш-алты йөз сум җыела. Шулай итеп, ел саен кулдагы сыерлардан ике меңнән артык акча кереп тора дигән сүз. Бу аз акча түгел. Ә өч йөз сыерны бергә җыеп бага башласаң, көтүчесе белән каравылчысы да, абзары белән печәне дә кирәк. Әнә теге Бикбайның сыеры үлсә, аңар берәү дә бер тиен түләми, ә безнеке үлми дә, бетми дә. Шуларның барысын исәпләсәң, ярты файдаң җилгә очуын белерсең. Аннары ул кадәре мал бер кулда булса, рәмат-салымын да төгәл түләп торырга туры киләчәк. Ә кеше кулындагысын кем исәпләр? Менә болары файданың бер ягы. Икенчедән, төгәл ике булыс илнең[1] барысы да безгә рәхмәт укып, алкыш әйтеп тора, әрвахларыбызга дога кылалар. Шул ике булыстагы ике мең чамасы өйнең өч йөзгә якыны безнең сыерларны сава, туклана. Шуларның барысы да безгә бурычлы. Үз чиратында, аларның туган-тумачалары, дус-ишләре бар, алары да безнең теләкне тели. «Теләк» дигәч тә, моны коры «алла бирсен» генә дип аңламагыз, юк, мин йодрык белән теләк теләүне күздә тотам. Узган булыс сайлау исегездәдер бит? Әлеге залим Бикморза никадәр мал туздырып, булыслыкка ирешә язган иде, безнең мәлҗегән җүнсез Мөхәммәтҗаныбыз исә җиңелә язды. Нәкъ менә шул мәлне безнең сыерларны савучылар, үзләренең туган-тумачалары белән бергә җиде йөз кадәре өй, «Исхак хаҗи үзе белсен, ул кемне атаса, без шуны яклыйбыз» дип, безнең сүзне сөйләде түгелме соң? «Ачлыкта ашаган кысыр ашның тәме һаман авызда», дигәннәре менә шул була инде. Һәм без үзебез теләгән кешене булыс итеп сайлаттык. Теләк дип, менә шушы күз белән күреп, кул белән тотып була торган «теләкне» әйтәм... Ә сез җыеп алыйк дисез, куегыз, сөйләмәгез юк сүзне. Моңарчы ничек килгән, шулай бара бирсен, файдасын гына ала белегез. Әгәр дә мәгәр чын-чынлап азына башласалар, анда башка мәсьәлә...

— Азынучылары да юк түгел, әнә, теге Кызылсу тамагындагылар шундыйлардан. Былтыр көзен үлгән бозаулар өчен түләмәскә итенеп карадылар. Гауга чыгаручылары да булмады түгел. Быел да аяк терәп даулашырга ниятлиләр дигән хәбәр бар. Алары белән нишләмәк кирәк?

— Элек муллакәң белән икегез барып, җайлап кына, йомшаклап кына сөйләшегез. Моңар күнмәсә, Мөхәммәтҗан булысны алып барырсыз. Аңар да бирешмәсәләр, көч белән тартып алырга кирәк. Ач калу түгел, миңа димәгәе, кырылып бетсеннәр шунда! Яман

[1] Булыс — волость һәм волость башлыгы (волостной).

гадәтләнә күрмәсеннәр. Боларын азындырсагыз, икенчеләре дә тузына башлар, бәлане тамырыннан ук йолкыгыз. Нык торыгыз мондый чакта!

...Яңгырлы-карлы салкын көз. Күз ачмаслык буран. Тышка чыгарлык түгел. Кызылсу тамагындагы авылда төркем-төркем җайдаклар. Барысы да Уразали аксакалның ишегалдына җыела. Агай-эне эше булгач Бәкер белән Чардарбәк тә килгәннәр. Өйнең эче шыгрым тулы. Булыс белән янәшә Куандык мулла, аннан түбәнрәк Кадыйр утыра. Типсә тимер өзәрлек булыс яраннары да шунда. Куандык мулла җай гына сүзгә башлый:

— Уразали кордаш, хәтерлисеңдер, бер заманны сезнең авылга үзем килеп, хаҗи өенә дә үзем ияртеп барып, савым сыерлары алып бирдем үзегезгә. Ачтан интегеп, үләр хәлгә җиткән идегез. Без булмасак, күптән хәер теләп каңгырып киткән булыр идегез. Яле, карт, узган юлыңа бер әйләнеп карачы: элек ничек идегез дә, хәзер ничек булдыгыз?.. Ун ел узды, бала-чагаларыгыз үсеп җитте, каралты-кураларыгыз мал белән тулды. Боларның барысына да Хаҗәкәң сәбәп түгелме соң?!

— Муллакә, син безнең хәлне әле дә җүнләп белмисең икән. Әллә тегеләрне безнең үз малыбыз дип уйлыйсыңмы? Барысы да Исхак хаҗиныкылар бит! Менә мин үзем дә хаҗидан бер сыер алып торган идем. Ул теше бозау тапты, хаҗи алмагач, анысын да асрадым. Киләсе елны тагы теше бозау туды. Бары өченче елны гына иркәкне тапты, шунысын гына хаҗи апкитте. Моннан соңгы елны карт сыер белән әлеге беренче бозау үзе дә бергә бозаулады. Шулай үрчи торгач терлек саны унга җитте. Ә быел исә төгәл алты сыердан өч иркәк, өч теше бозау туды. Ягъни уналты баш булды дигән сүз. Димәк, тугыз-ун ел эчендә Хаҗәкәң бер миннән генә уналты баш үсем алып утыра. Ике бозавы үлеп, бурычка да кердек. Җитмәсә, ел саен шул сыерларның һәммәсенә печән дә әзерләргә кирәк...

— Бик дөрес! Бездә дә нәкъ шул хәл!.. Ун ел эчендә бер безнең авылдан йөз иллегә якын иркәк бозау алып китте бит!

— Ә үлгәннәре өчен ел саен күпмешәр акча түләргә туры килде!..

— Шушы көнне авылда егерме сыердан үрчегән ике йөз иллегә якын баш бар. Яле, муллакә, егермене биреп, ике йөз иллене алу шәригатьнең кай җиренә сыеп бетәр икән?!

— Үзегез гаепле, яхшылыкның кадерен белмәдегез бит! Барысын алып китәргә бер кеше дә җыенмый иде, һәр елгы үрчемен тыныч кына бирә барган булсагыз, бер сүз дә юк иде бит сезгә! Теге көнне, Кадыйр белән икебез генә килгән чакта, тыңлап та карамадыгыз яхшы сүзне, җәнҗал куптардыгыз. Менә булыс белән авылнайлар үзләре килделәр хәзер. Ходайдан куркыгыз әзрәк, берәүнең хәләл малын бирмәскә итәсез бит тагы! Шәригать дигән буласыз, шәригать ул кеше малын хуҗасына бирергә куша. Вәгъдә — иман дигәнәр. Савып торыр өчен алган сыерларыгыз да, аларның үсеме дә — барысы да хаҗига тиешле. Үзегез барып инәлеп сорадыгыз, җитмәсә, хаҗга китәргә ниятләгән сәфәреннән калдырдыгыз. Ә хәзер вәгъдә дә юк, иман да юк! Карагыз аны, бу дөньяның бер көнлек туклыгыннан исәрләнеп, имансыз китеп, теге дөньяның мәңгелек тәмугына барып төшмәгез!

— Ә без нәрсә, кырылып калыйкмы әллә?

— Бер сыерны ун итеп, шуның барысын да ун ел буе багып, асрап килсәк тә, бурычтан котыла алмыйбызмыни?!

— Моның кай җире шәригатькә сыя?

— Әллә шәригатьне үзең генә язасыңмы?

— Закон ни әйтер икән, урысның законын да тыңлап карарга кирәк!

Өй эче шау-шулы кычкыру, сүгенүләр белән тулды. Түрдә утырган волостной бугазы ярылганчы акырып, халыкны көчкә генә тынычландыра алды.

— Туктагыз, тукта! Кычкырышып булдыгызмы соң? Алайса, мине тыңлагыз: шәригать белән закон бергә йөри. Менә шул! Сөтен савып торыр өчен генә хаҗидан сыер алуыгыз хак булса, үләнен түлим, тересен сораган көнне кире бирәм дигән вәгъдәгез дә хак сезнең! Ул малларның үрчеме дә, һичшиксез, хаҗига тиешле. Ә сез вәгъдәгездә тормадыгыз, законны да, шәригатьне дә боздыгыз, димәк, барысын да кире бирергә тиешсез. Кыскасы, менә шул!

— Булыс агай дим, бер сыерын алган булсак, аны ун итеп бирдек, үләненә акчалата түләдек, безнең хезмәт хакыбыз да бардыр, шәт?!

— Үзе ни өчен бердән ун сыер ясамый?

— Үз кулында үлсә, кемнән түләтер иде?

— Көтүчегә хак түләмәс идеме соң?

— Малларының нәкъ яртысын печәнгә саткан булыр иде!

— Әйе, әйе!

— Дөрес әйттең!

— Шулай шул!..

Тагы шау-шу купты, тагы сүгенүләр, каргышлар ява башлады. Волостной баягыдан да зәһәррәк итеп кычкырды:

— Акылдан шаштыгызмы әллә?! Туктагыз!!! Сезнең алда кемнәр утыруын беләсезме соң?!. Ун елдан бирле баккан булсагыз ул сыерларны, аларның файдасын да аз күрмәдегез: җәен-көзен сөт-катыгын ашадыгыз, кыш буе корт-эремчеген кимереп яттыгыз, карын-карын маен[1] базарга илтеп саттыгыз, акчасына кием-салым алдыгыз — моннан артык аталарыгызның башы кирәкме сезгә?!!

— Бер сыер өчен унбиш баш бирүче дә котылмыймы?

— Котылмый! Ул әманәт, әманәт үлми дә, югалмый да, бары үрчеп кенә тора. Әгәр хаҗи шул сыерларны сатып, аларның акчасын казнаның банкасына салып куйган булса иде, ул акча мең елдан соң да югалмас, бетмәс иде. Дау да юк, җәнҗал да юк, кирәк көнне барып иде дә, тыныч кына алыр иде. Менә мин баядан бирле исәпләп утырдым. Әгәр хаҗи бер сыерны илле сумга сатып, елына алты сумнан үсем алу исәбенә банкка салып куйган булса, шул акча банкта илле ел ятса, беләсезме, ул илле сум күпмегә үскән булыр иде? Нәкъ сигез йөз туксан өч сумга! Аннары тагы егерме ел ятса, әлеге ялгыз сыерның бәясе ике мең дә сигез йөз алтмыш алты сумга менгән булыр иде! Әманәт хәзинә менә шулай үсә. Закон шулай боера!

— Ярар, законыңны да белдек, шәригатеңне дә күрдек, хәзер безгә нишләргә кушасың инде?

— Кадыйр мирза үзе белә аны. Кадыйр, син нишләмәк буласың?

— Нишләремне әйттем инде. Ике елдан бирле сугыш-җәнҗалсыз үсем ала алмадым. Акылга утырырмы дип көттем, утырмадылар; теге көнне бөтенләй хурлап җибәрделәр; инде җитәр, туйдым, багланышны өзәм болар белән — хәләл малымны алам да китеп барам. Болардан башка халык бетмәгән бит, тагы йөз өйдә сыерларыбыз бар. Алар, ичмасам, артык сүзнең ни икәнен белмиләр, үсемен үзләре китереп бирәләр. Ә боларның үз убаллары үзләренә!..

— Үтереп ташла безне, алайса!

— Хәер теләтеп җибәр!

— Кулыңнан килсә, кырып ук ташла!

— Кутыр тәкә дә бирәсебез юк!

---

[1] Казакълар элгәре ак майны иләнгән бөтәү карындыкка җыйганнар.

— Малымны биргәнче җанымны бирәм!
— Төкердем синең законыңа!
Тагы өйнең эше шау-шу, сүгенүләр белән тулды. Кайберәүләр акыра-бакыра тышка йөгерделәр; икенчеләре өйдә ыгы-зыгы килә башлады. Тагы волостной тамагын ертып җикеренергә, халыкны тәртипкә чакырырга тотынды, тик аны беркем дә тыңламады. Өзек-өзек сүзләр, әшәке сүгенүләр, хәтәр янаулар гына ишетелде:
— Үтер Куандык мулланы!
— Шул этнең бәласе бу! Сук, тип эттән туган нәмәстәне!
— Барыбер безгә тыныч көн юк!
— Шул кара йөз тәкъвәләнеп аздырмаган булса, Исхак этнең янына да бармас идек!
— Әнә Бәкер Исхаксыз да сыерлы булды!..
— Ә бездә?!
— Үтер! Бетер!
— Атаңа нәгъләт, Исхак!..
— Әнә Кадыйрны үтер, Кадыйрны!!.
Шарт та шорт сугыш башланды. Бөтен авыл сугышка күмелде. Куандык мулла, авызы-башы кып-кызыл булып, аңын җуйды. Чигәсе ярылган Кадыйр да кая качасын белмичә тыз-быз чабып, йодрыктан, таяктан качып йөри. Атларына менеп өлгергән би-булыслар тырагайлатып авылдан чыгып качалар. Хатын-калач чиный, бала-чага елый. Берәүләре аралаган булалар, икенчеләре исә өченчеләрен дөмбәсли. Берәвесе сүгенә, икенчесе ярсып үкерә. Беркемне танып, бер сүзне аңлап булмый. Гарасат, мәхшәр...
Бәкер белән Чардарбәк һәм тагы ике-өч кеше көчкә генә Кадыйрны аралап алалар, үз өйләренә илтеп ябалар. Аннары аңсыз селәеп яткан Куандык мулланы күтәреп китәләр...

## VII

Буран көчәйгәннән-көчәя бара. Кызылсу тамагы авылында төркем-төркем җайдаклар. Җиде-сигез атлы кеше дөбер-шатыр китереп, йорттан йортка чабып йөри. Һәр йорт-курадан ялан баш, ялан аяк, башы-күзе канга баткан кешеләрне өстерәтеп чыгаралар, кыйный-кыйный кулларын артларына каерып бәйләп, җилтерәтә-җилтерәтә бер җирдә укмашып торган җайдаклар янына илтеп ташлыйлар. Аннары тагы эзләнергә тотыналар.

Авыл халкы җиргә сеңгән кебек. Хатын-калач, бала-чагаларның өрәкләре очып, котлары алынган, кычкырып еларга да, ялварып ялынырга да белмичә миңгерәп торалар. Ишекләре каерылган абзарлардан чыгарылган сыерлар, тана-бозаулар тар сукмак буйлап әллә кая китеп баралар. Бик күп сыер китеп бара, каралты-куралардан тагы да сыерлар чыга тора...

— Теге дуңгыз Канаш кая икән? Болары арасында күренми, яшеренеп ята бугай, яхшырак эзләгез! Табыгыз ул этнең баласын!..
— Берәр яры китте микәнни, Канаштан башкалары тәгәл тотылды.
— Илтегез теге кибән янына! Аяк-кулларын бәйләгез дә ташлагыз кибән өстенә үзләрен! Ут төртегез, янып бетсен! Я, ни карап торасыз?! Илтегез шунда!!!
Атын биетә-биетә ажгырган булысның әмере иде бу.
— Тәкъсир дим, булыс агай! Бер юлга ачуыгызны сорыйм, җаннарын саугa кылыгыз, җаннарын! Тәкъсир, җитәрлек кыйналдылар инде, үлеп калулары бар... Әнә Уразали аксакал да үлгән бугай...

Зинһар, дим, тәкъсир, туктатыгыз инде... Болар да мөселман балалары бит, куйдырыгыз инде!..

Шулай инәлеп-ялварып Бәкер зар елап йөри. Чардарбәк исә Кадыйр янында иңрәп ята. Мәгәр волостной да, Кадыйр да биз кебек кансызланып катканнар.

— Теге хатынны тотыгыз! Үтерегез әнчекне! Сакалыма ябышты бит үзе, күзләремне тырнап чыгара язды, эттән туган!

Шулай җикеренеп, җилкенеп Кадыйр йөри.

— Әй, монда икән! Тотыгыз! Канаш табылды, Канаш!

Дөбер-шатыр килеп дүрт-биш кеше тавыш чыккан якка ташлана. Курадан сакалына чал керә башлаган бер ир кешене өстерәп чыгаралар. Дөп-дөп иттереп, ыңкылдата-ыңкылдата ябырылып кыйныйлар. Канаш бер тавыш та чыгармый. Ике кулы белән башын каплап, исерек кешедәй бер яннан икенче якка авыша. Менә берәү җилкәсенә үк китереп суга. Канашның ике кулы да салынып төшә, күзләре акаеп җиргә ава.

— Оланнар! Җитәр инде, сугуны туктатыгыз! Барлап чыгыгыз әле, үлеп-җитеп калучылары юк микән? — дип, ат өстендә торган бер аксакал әмер бирә...

Сугу, кыйнау туктый. Һәр йорт алдында диярлек бердән, икедән аңын җуйган хатын-кыз, бала-чага, яисә тәмам канга баткан һушсыз ирләр ята. Берәүләренең башы ачык, икенчеләре ялан аяк; барысының да диярлек өсте-башы ертылып беткән. Котырынып искән җил аларның ачык өсләренә кар сибә, яннарына көрт өя. Чардарбәк белән Бәкер шуларны күтәреп-өстерәп өйләренә кертеп йөри. Кайберәүләре, үзләре аңнарына килеп, дүрт аяклап үрмәләгән хәлдә, куышларына таба елышалар.

Җайдаклар төркемендә киңәш бара:

— Пыратакул язарга кирәк, законны сүкте, шәригатькә тел тидерде дип.

— Булыска кул күтәреп, бинең ызнагын йолкып алдылар!..

— Мулланы кыйнадылар, Кадыйрның башын ярдылар...

— Барысын да язарга кирәк, барысын да!

— Судка бирергә үзләрен!

— Үрәтникне, үрәтникне чакырырга кирәк!

— Хурлыгы ни тора!..

— Болай калдырырга һич тә ярамый! Өеңне яндырып, малыңны талап алырлар, бетерергә кирәк үзләрен!

— Бик дөрес!

— Сөрергә кирәк, сөрергә! Башкача ярамый!..

Шулай бик озак, бик дәртләнеп шаулашалар...

Волостной белән авылнай, Куандык мулланы да бергә кыстырып, Бәкернең өенә керәләр. Бер тананы чалып ташлаган Бәкер аның тиресен тунап маташа. Ишегалдына ике казанны янәшә аскан хатыны су кайнатып йөри. Чардарбәк исә казан астына утын салып мәш килә. Бөтен ишегалдын ыс, кара төтен каплаган. Өйдә түгел, курада да тар бүген.

Протоколны озак язалар. Аны язып бетерүгә казаннан сосып алган иттән зур бер табакны волостнойның алдына китереп куялар. Ашарга теләүчеләр өйгә сыярлык түгел. Шуңа күрә кайберәүләр тышта гына аягүрә килеш берәрдән калҗа тотып, сөяк кимереп йөри. Түрдә утыручыларны сыйлый-сыйлый Бәкер аларга ялвара, авылдашлары өчен кичерем сорый:

— И-и яхшылар, белгән акылымны алардан бер дә кызганмадым, гел әйтә килдем үзләренә. Тик күбесенең яше миннән олы, шуңа күрә сүземне тыңламадылар. Үз башларына үзләре бәла эзләп таптылар бит! Инде сездән үтенеп сорыйм: хаҗига тиешле маллар алын-

ды, кылган тинтәклекләре өчен җәзаларын да таптылар, теге пыратакул дигән нәрсәгезне куегыз, зинһар. Урыс кулына бирә күрмәгез үзләрен, аларны сөрдерүдән сезгә ни файда? Һәрберсенең бала-чагасы бар, үз балаларын үзләре карасыннар. Моннан ары кулларыннан бернәрсә дә килми бит, акылларына утырырлар, шәт. Куегыз пыратакулыгызны, үтенәм сездән...

Волостной кырыс кына җавап бирә:

— Куюын бөтенләйгә куймыйм әле!.. Дөрес, башта бераз кәгазьне җибәрмичә сынап карармын, әгәр явыз ниятләреннән кайтмасалар, миңа үпкәләмәсеннәр!..



## VIII

Ала кар чагы. Ачык җирләр бөтенләй арчылып калган, бары күләгәрәк төшләрдә, уй-чокыр җирләрдә генә ак «ямаулыклар» ята. Исел өстендәге боз да, аннан-моннан уелып, кузгалып китәргә әзер тора.

Кызылсу тамагындагы кышлак. Җиргә сеңеп утырган егерме-утыз караллты-кура. Күпчелегендә кар эреп беткән. Бары чүп-чар сибелгән берничә курада гына эреп өлгермәгән кар өемнәре ята. Ә калганнарында печән дә, чүп-чар да юк, чип-чиста...

Бәкер сыер абзары өстендәге ике колгага кибәр өчен эленгән тана тиресен, учлары белән капшый-капшый, карап тора. Үзе нидер уйлый. Икенче абзар өстендә Чардарбәк белән хатыны киез тузаны кагып матәшәләр. Бер ара Чардарбәк, төшке кояштан чагылган күзләрен кыса төшеп, як-ягына каранып ала. Бөтен тирә тып-тын. Шылт иткән җил дә юк. Авыл йокыга талган сыман.

— Хуҗасыз калган йорт-куралар зираттан да шомлырак икән,— ди ул Бәкергә таба борылып.

Сүзгә Чардарбәкнең хатыны да кушыла:

— Әйтмә дә инде! Карачы үзләренә, төнлә түгел, көндезләрен дә яннарыннан узарлык түгел... Алардан гел дөп-дөп сугулар, шыңшып елаулар ишетелеп торган шикелле. Йорт-җир түгел, ташландык гүр төсле! Иртә-кичен Иселгә суга баруы да бер җәфага әверелде...

— Әйе шул... Бу өйләрне иясез-хуҗасыз каран калырлар дип кем уйлаган... Исеңдәдер, былтыр нәкъ шушы мизгелдә Уразали аксакал оныгына сөннәт туе ясаган иде. Гөр килеп торды бит бөтен кышлак өсте! Көрәше белән ярышы, үлән-җыры белән шаян сүзләре дисеңме... Теге түбә өстенә көнчуакка җыелган картлар: «Көн җылына бит, тиздән ау алып, елга буена төшәбез инде»,— дип, сөенеп утырганнар иде... Һай, хәйран гомерләр! Киләсе елның нәкъ шушы мизгелендә бөтен авыл тузып бетәр дип кем уйлаган ул чакны?!

— Шулай шул, Бәкер, яшем кырыктан узып китсә дә, мондый хәлләр булыр дип башыма да китерми идем. Ә хәзер үзем күрдем андый шомлыкны: күз ачып йомганчы ике йөзгә якын адәме бар бер авыл тузды да бетте ди... Кем ышаныр моңа?.. Мин дә бит бәлагә чак кына эләкми калдым. Әгәр синең теге бер авыз сүзең булмаса, Бәкер, хаҗидан алган сыерны үзем үк илтеп бирер идемме соң? Тыңлап яхшы иткәнмен сүзеңне, юкса, мин дә шулар белән бергә...

— Шоңкарым, чәй кайнады, киләсеңме инде? — дип, өйдән чыккан Бәкер хатыны кычкыра.

Бәкер, түбәнгә төшеп, өсте-башын кага-кага, ишеккә таба юнәлә. Зур җиз самавар янында искерәк кенә, ләкин ямаусыз камзул кигән, башына әле керләнеп өлгермәгән кимәчәк [1] салган бер яшь

---

[1] Кимәчәк — казакъ хатын-кызларының махсус баш киеме.

киленчәк, тезләнеп кенә утырып, чәй ясарга әзерләнә. Аның каршында утыручы сыек кына кара мыеклы егет, нидер әйтергә җыенгандай, ирен кырыйларын кыймылдатып, елмаеп куя. Киленчәк белән яшь ирнең икесенең дә әле бер-берсеннән туеп өлгермәгән, кызыкның да төбенә кадәр җитмәгән булулары сизелеп тора. Егет тә ямаусызертыксыз киемнән.

Бәкер белән хатыны керүгә киленчәк сикереп тора, олылар утырганчы, тезләрен бөкми. Табын янына тагы ике малай килеп утыра. Барысының да өсте-башы, яңа булмаса да, таза. Түшәк-урын, савытсаба да төгәл. Идәндә киезләре дә бар. Күзгә чалынырлык таза да, чыгарып ташларлык алама да түгел. Кәстән сугылган балчык өйнең эче икегә бүленгән. Алдынгы бүлмәдә дүрт бозау бәйләнгән урын тора, үзләрен күптән түгел генә тышка чыгарган булсалар кирәк, чөнки юеш урыннары кипмәүдән бәвел исе аңкып тора. Табын янына утыргач, Бәкернең хатыны әкрен әйтә:

— Шоңкарым, икегез ике түбә өстендә торып нигә ул хәтле кычкырыштыгыз? Әллә бер-берегезне бүген генә күрдегезме?

— Анысы да дөрес, хатын, язның көне дә бит бары бүген генә якты чырай күрсәтте... Узган-киткәнне, бер ел эчендә баштанниләр кичкәнне искә төшердек. Шушындый якты көндә теге каран калган иясез өйләргә карап күңелләребез бозылды...

— Әйтмә дә инде... И-и дөнья, дөнья! Бичаралар, нишләп йөриләр икән хәзер...

Бәкернең улы Сәрсәмбәк, аның хатыны әлеге яшь киленчәк тә, үзара бер карашып алып, көрсенешеп куялар. Әле генә тәрткәләшеп уйнап утырган ике малай да тынып кала.

— Нишләп йөри дип...

— Берәр хәбәре ишетелмиме, ичмасам?

— Аз-маз. Уразали аксакал өй эчен туздырып-таратмыйча гына калага җитеп алган күренә; үзе шунда Минау байның тиреләрен күзәтергә ялланган бугай. Ул яхшы урнашкан. Канашның өй эче исә Чобарга барабыз дип, җәяүли-җәяүли хәер теләнеп йөри торгач, төрлесе төрле җирдә авырып-сырхап, бер-берсеннән аерылышып беткәннәр дип ишетелде. Күкрәк баласын күтәргән чирле хатыны теләнеп йөргән чакта ике авыл уртасындагы япан далада үлеп калган икән. Гәүдәсен, мәет өстендә елап утырган яшь баласын караңгы төндә кайдандыр кайтып килүче Сәтебәй булыс табып алган. Үле гәүдә өстендә елап утырган нарасыйны күреп, үзләренең дә котлары алынган бугай... Икенче авылга җиткәнче ул бала да үлгән. Канашның калган ике баласы да ике якка каңгырып киткән диләр, берсе әлегә тере дигән хәбәр бар. Икенчесен белмим...

Бәкер башын түбән ия төшеп, түзәлмыйча, мышкылдап елап җибәрә. Бераз сулгуы басылгач, яшьле күзләрен югары күтәреп, түшәмгә карап тора:

— Аяк-кулларын бәйләп булса да, ник авылда тотып калмадык икән үзләрен!

— Синең сүзеңне тыңладылармы соң алар?!. Бергә тораек, барлы-юклыбызны бүлә-яра ашап, бергә-бергә кышны уздыраек, үлсәк тә бергә-бергә үләек дип, мин дә күпме генә ялвармадым соң? Чардарбәк тә аз үгетләмәде. Тыңладылармы соң?! Тыңламадылар шул... Ачуга, хурлыкка түзә алмадылар. Ачу белән генә ни майтарырга булганнардыр, белмим, тузындылар-тузындылар да китеп тә бардылар...

— Улым Сәрсәмбәк, килен, хатын, син дә тыңла. Көннәр җылынып, җир кибә башлагач, авылга кайткалаучылар булыр. Шуларның берсен дә бусагадан буш кул белән җибәрмәгез, әйрәнен дә, катыгын да кызганмагыз алардан. Күпме килсә дә, бүлеп ашарбыз. Печән өсте

җиткәнче өч сыерның сөтеннән корт-эремчеген, маен аерым җыегыз. Үзебезгә ике сыерның сөте дә бик җиткән. Чардарбәк өенең хатын-калачына да әйтергә кирәк — шулай аерым җыйсыннар... Ә без әйләнә-тирәдәге авылларны гизеп, исән калучыларны җыеп карарбыз. Кайчан печән чабып алганчы бергә-бергә көн күрербез, аннары, чапкан печәннәрен сатып, тамакларын үзләре аера башлар. Шулай эшләмәсәк, бу ил бөтенләй юкка чыгар төсле...

Баядан бирле боегып утырган ике малайга кинәт җан кергәндәй була, бер-берсенә карашып, үзара сөйләшә башлыйлар:

— Ишетәсеңме? Балалар да кайта алай булгач, уйныйбыз, әйеме?

— Бабай дим, алар кайчан кайтырлар сон?

— Кайтырлар, бәгырьләрем, кайтырлар, тагы да ишәерсез, тагы да бергә-бергә уйнарсыз... Тик сугышмассыз микән?

— Ю-ук, сугышмыйбыз!

— Мин берсенә бишмәтемне бирәм!

— Мин — итегемне!

— Мин бүрегемне, күлмәгемне дә бирәм!

— Ә мин барысын да бирәм, килсеннәр генә!

Малайларның шулай үзара ярышып гөрләшүләре зурларның боек күңелләрен күтәреп җибәрә. Шулай да Сәрсәмбәк атасыннан сорамыйча булдыра алмый:

— Әти дим, Исхак хаҗиның эшләгән этлеге шулай гына кала бирер микән? Әллә моның тикшерелү көне дә булырмы бер?

— Кала бирмичә нишләсен соң, улым? Исхак хаҗи кем дә, без кем? Ул — хаҗи, аны шунысы өчен генә дә бер сыйлыйлар. Исхак — бай, монысы өчен тагы бер сыйлыйлар. Булысын да, авылнай белән биләрен дә Исхак хаҗи үз кулы белән куя. Барысы да аннан курка, барысы да аның сүзен сөйли. Каладагы түрәләр белән дә ул яхшы таныш. Үрәтниге дә, стражнигы да килгән саен Исхактан бирәр ат менеп китәләр. Алары да аның сүзен сөйләячәк. Болары җитмәгән төсле безнекеләр дә бит яткан еланның койрыгына үзләре бастылар, беренче булып кул күтәреп, булысын, авылнаен, мулласы белән биен кыйнап ташладылар, ил эчендә тинтәк дигән яман ат алдылар, закон бозучы, шәригать хурлаучы булып танылдылар... Кем тикшерсә дә, бер безне генә гаепле итәчәк. Алай тагы бер мәртәбә гаепләнгәнче, тешләрне кысып, шулай кала бирербез инде. Бу — үзебез эзләп тапкан бәла, үзебез сайлап алган сөлек. Әйе, Исхак хаҗи тәнебезгә ябышып каннарыбызны эчә торган сөлек ул...

Өйдә авыр тынлык урнаша...

1929 ел.

Казакъчадан М. ГОСМАНОВ тәрҗемә итте.

## Роберт Әхмәтҗанов

### Тормыш арбасы

Айларда, әллә кайларда
йөри заман арбасы!
Бу — чик түгел, яңа ярга
яңа юллар ярасы...

Яңгырап барсын чор түренә
кешенең хөр авазы.
Аңа бит җирне үзгәртеп,
барасы да барасы!

Әле ярый, кешегә җирдә
кеше булып каласы!
...Шыгырдап, сайрап, дыңгырдап
бара тормыш арбасы!

### Гимн

Борчылмагыз — яшел киңлекләрдә,
яшел калкулыклар төбендә,
җир шавыннан киткән дус-ишләр!
Зәңгәр коштай җәеп канатларын,
барчабызның хәтер күгеннән
тыныч җиргә иңә бу кичләр!

Һәр иртәдә календарьдан бер бит
өзеп алу — һаман шул бер гадәт.
Көн әйләнә, кояш шул һаман!..
Кояш асларында йөргән чакта
исемегезгә сөю һәм сәгадәт
без булырбыз сезгә юллаган!

Борчылмагыз, калды диеп өстә
ярты эшләр, иҗат, бирәчәкләр,
алгы көнгә дигән хыяллар...

Шул ук эшләр җирдә — сез кабызган
чор ялкыны бара киләчәккә:
Вөҗдан уты, Хәтер — уяулар!

## Фатиха

Күзгә җилдә күшеккән күбәләктәй,
яңгырлы чатлардан
килеп кердең, улым, кичке утка,
килеп кердең —
минем бала чаклардан!

И җил куа сине, яфрак катыш
яңгыр ява башыңа!
Ничек шулай җиңел чыгып чаптың
олы дөнья каршына?

Давыл асларына озатам сине, улым,
йолдыз асларында кем ышыклар?
Яшәп туялмаслык шушы җирдә
шундый зәңгәр, чакырып туймас офыклар...

Шундый — дөнья! Адым белән түгел,
гомерең белән кара үлчәп!
Юл алдыннан тик бер генә теләк, улым, —
давылларда кешеләргә
кешелегең күрсәт!

## Таштагы сурәтләр

**1**

Күбәләкнең сыны калган ташта —
болын гербы, яшәү сулышы!
Ничек калган чор төбендә, аста —
гөлгә түгел, ташка елышып?

Чәчәк төсле бизәп тордың микән
бер сылуның назлы толымын?
Кайсы язның күбәләге идең,
якты җаны кайсы болынның?

Абагалар кала ташка иңеп —
мәгънәседер яшәү юлының...
Күбәләгем! Ничек таш куенына
биргән икән сине болының!?

**2**

Казыдык та төштек үткән чорга —
тау астыннан алдык ак ташны.
Кемдер аңа чокып нидер язган,
җил ярдәмгә килде: «Хат башы...»

Җил укыды, телен аңлады җил
бөек сәфәр чыккан кешенең.
«Яз каршы!» дип язган чокып ташка
тик куймаган үзенең исемен.

●

Әй, сайрый сары сандугач,
сызгыра талларымда...
Иманнәрне сыга торган
моң бардыр җаннарында!

Белсәңче, калтырый икән
тамагында нинди кыл?!
Телсез итте! Нәни кошка
инде мин дә, син дә — кол!

Мөмкин ул шулай сызгырып
урманны яндырырга!
Әллә тели безне, улым,
саңгырау калдырырга?

Тап әле шул сандугачны,
талларга күмелгәнме?
Көен яфрактан аламы,
я сайрый күңелдәнме?

Бу сайрауга каеннарда
тузлар кызмас ди микән?
Җирдә — мәңге яшел бәйрәм,
җәйләр узмас ди микән?!

Я сизәдер кыска җәен,
бирәдер безгә үрнәк:
урманнарны калтыратып
җырлап калырга кирәк!

●

Бу кырлардан
тургай җыры
ераклашып бара инде,
әллә кояш янынамы
менде ерак?

Күк читендә — чормада
көмеш урак.

Җәй авышты.
Камыллардан зеңләп ага
көз тавышы...

●

Утыз яфрак, утыз яфрак —
гомерем яфраклары.
Шул яфраклар — елларымның
яшь һәм сафраклары.
Кагылып үткән — болытларның
сөттән агараклары,
Тамса тамган — күз яшемнең
судан паграклары...
Чыксын давыл, тузсын, әйдә, —
гомерем яфраклары, —
Калса калыр — сынау үткән
сабыры, саграклары!

## Соңгы рейс

Узды вагон карлы урамнардан —
салкын корыч чыңы.
Йолдызлы тәрәзәләрдә
киек казлар юлы...

Карлар аша томанланып
соңгы йолдыз янды.
Тукталмадык. Борылышта
зәңгәр апрель калды!
Һәм май калды. Байраклары белән
тәрәзәгә кагылып.
Очты вагон. Яшьлек төсле,
метеор төсле кабынып.

Һәм син калдың анда!
Күзләреңдә
туар язлар моңы...
Тукталыш юк. Бар яшьлекнең
сиңа язган юлы...

Як-ягыңда кала бар да атылып —
ераклаша ара.
...Яшьлегемнән
синең вокзалыңа
соңгы рейс бара.

## Роберт Миңнуллин

### Таулар

Менә нинди була икән таулар!
Колач җитсә, шашып кочмалы.
Таш гасырдан калган сөңге булып,
Болытларга баткан очлары.

Таулар гүя ташка әверелеп,
Катып калган титан дулкыннар...
Эндәшмиләр кырыс ирләр кебек,
Аларда да ирләр холкы бар.

Түбәсенә менеп ояларга
Хыяллана гына киекләр.
Биеклеге белән горур таулар,
Биеклеге белән бөекләр.

Мин тауларсыз ничек яшәгәнмен?
Биеклексез ничек яшәлгән?
Тик кешегә
Мин бервакытта да
Биеклектән торып дәшәлмәм...

### Таш һәйкәлләр

Галиҗәнаб ташлар!
Мәдхияләр
Язылса да сезгә урынлы,
Уникенче гасыр... сигезенче...
Бар да таштан,
Бар да борынгы.
Ничә буын карап соклангандыр,
Ә сез менә һаман үлмисез.
Сезнең аша күпме яулар үткән —
Ярый әле, үлә белмисез.

Төзелгәндә сез бит гап-гади бер
Кәрвансарай,
Пулат булгансыз.
Хәзер исә сокланырлык һәйкәл!
Бу язмыштан ничек уңгансыз.
Гади таш дип,
Гади корылма дип,
Әйтә икән сезгә кем дә кем,
Ышанмагыз аңа.
Кадерегез,
Кыйммәтегез арта көннән-көн.
Сезнең язмыш кешеләргә охшаш.
Тик яшисез җирдә күптәннән.
Безнең дә бит шулай — торган саен
Кадерлерәк һаман үткәннәр.

## Севан

Севан диңгез тигезлегеннән 2 километр биеклектә ята.

Күлләре дә күктә
Таулар кебек.
Шулайдыр дип кем соң уйласын.
Сылу Севан!
Таулар касәсендә
Әйтерсең лә әрмән виносы.

Йолдызларның якын күршесе ул,
Гашыйк булыр әллә кемнәрең!
Су кызлары
Тып-тын гына чыгып,
Су коена монда төннәрен...

Үзәндә дә хәтта
Кибә сулар.
Эзләре дә калмый аларның.
Ә син, Севан,
Сынатмыйсың һаман,
Мөлдерәмә тулы ярларың.

Соклануым —
Сиңа әллә күпме
Гүзәллек һәм куәт сыйганга.
...Биеклектә үзен саклап тоту
Бик кыендыр инде Севанга.

## Мартирос Сарьян

Бүлмәсендә аның таулар җыры,
Таулар төсе,
Таулар һавасы.
Җәннәт монда.

Шушы матурлыкның
Кочагына гына авасы...
Төгәллисе сурәтенә карап,
Уйга талган үзе карт Сарьян.
Мәгънә тулы җыерчыклар аңа
Еллар булып
Ничә кат сарган!
Һаман уйлый,
Һаман төсләр эзли
Йөгерек һәм сизгер куллары.
Яңа төсләр табу сәнгате бу!
Ачышның юк җиңел булганы...
Таулар иле бәйрәм көтә бугай.
Ничек матурланган, ясанган.
Әллә инде Әрмәнстан үзе
Сарьян кулы белән ясалган?!

Ереван — Казан, 1971—72

## Элекке «Англетер» гостиницасында

Есенинның монда соңгы җыры,
Сүнеп өлгермәгән өмете.
Хисләренең ярсып талпынуы,
Акылының соңгы үгете...

Уйланырга куркып басып торам,
Шашып торам искә килалмый.
Ничек аңлатырга бу үлемне,
Шагыйрьләрнең җанын кем аңлый?!

Ә фаҗига булган.
Таш диварлар
Җимерелми ничек түзгәндер.
Шагыйрь бәлки килер таңнарыннан,
Язларыннан өмет өзгәндер?

Бу — үзеңә хыянәттер бәлки,
Коткарудыр бәлки үзеңне.
Ә шулай да нигә кирәк әле
Китеп бару көтми көзеңне!..

Шагыйрь турысында бүгенгәчә
Риваятьләр йөри,
Бәетләр...
Тик ялгышын аның
Булмый яклап,
Булмый аклап,
Булмый гаепләп.

Ленинград, 1972

## Кайткан саен

Тездән генә калган Сөннең суы,
Кечерәеп калган таныш яр...
Кайткан саен бер яңалык көтә,
Сирәгәя иске танышлар.

Сабакташлар күптән өйләнгәннәр,
Яшьтәш кызлар күптән кияүдә.
Һәрберсенең инде, ким дигәндә,
Бер баласы елый биләүдә...

Киткәнгә дә шактый булган икән.
Килеп күрешәләр — танымыйм.
Сыйлашырга шәраб табылса да,
Сөйләшергә сүзләр табылмый.

Фәлсәфәләр,
Уй-шөгыльләр башка,
Башларда да башка мәшәкать.
Бар әңгәмә — бала чакка кайту.
Кабатлана шулай ничә кат...

Хәтта өйләр гел яңарып тора,
Тик әнкәйнең һаман шул өе.
Туган җирне яратулар гына,
Сагынулар гына шул көе.

Кайткан саен бер яңалык көтә,
Югалтулар көтә, табышлар.
Тездән генә калган Сөннең суы,
Кечерәеп калган таныш яр.

1973

## Фәннур Сафин

### Ташчы

Әйтерсең лә ул бал корты,
ару-талуны белми.
Ул төзегән йортлар һаман
кояшка таба үрли.

Ә йортларын күр син аның:
охшап тора кәрәзгә!
Болытларны кулы белән
этә-этә таш тезә!..

●

Хаклык өчен янган шигырьләр бар,
бар тик ялган өчен макталган.
Ялганнары аның сакланмаган,
янганнары ләкин сакланган!..

Шигырьләрдә кеше язмышы бар,
кешеләрдә — шигырь язмышы...
...Кызу каным уйнар оланнарда
Уйларымның калыр кайсысы?..

●

Утка каршы бардылар —
офыкларда калдылар...
Күтәп күзләр талдылар, —
бу аерылу — мәңгегә!..

Ана дәшеп исемен,
сыйпый бала бишеген,
ачып карый ишеген, —
исә бары җил генә...

Көтәрмен... дип калган яр,
хатлар язып салган яр,
беләм, матур ялган бар —
тик бу сагыш гомергә...

Офыкларда балалар
таңнар булып яналар...
Утлы нурлар тамалар,
тамалар, ай, бәгырьгә...

## Саклау кирәк

Урман дусы әйтте шулай
(хуплады аны тирәк):
— Янгыннан һәм кешеләрдән
урманны саклау кирәк!

Урманнарны гынамыни,
кешене саклау кирәк.
Көлсен кояш, килсен гел яз,
изге теләкләр теләп.

Сакламак кирәк илләрне,
туган-үскән җирләрне,
йолдызларны, диңгезләрне,
кызларны һәм ирләрне...

Газиз шәһәр-авыллардан
калмасын тик көл генә!
Пәһлеван, затлы угланнар
әйләнмәсен күмергә!..

Гүя безнең дә оланнар
китеп бара йортлардан...
Аларны сакларга кирәк
утлардан һәм туплардан!

Һәммәбез бер корыч йодрык
һәм хисле, кайнар йөрәк
булып Җирне, халыкларны,
яшәүне саклау кирәк!

## Яшь тай

Давыл булып чаба, тибенә...
Теш кычытканга түгел һич
болдырларны кимерә...

Юашларга карый ятсынып...
Төн пәрдәсен умыра ул,
таң тизрәк атсын дип...

Гамьсезләрдән ерак кача ул...
Упкыннарга очраганда
аягүрә баса ул...

Бары ирек аның иманы...
Йөгән тотып килсәң, — әзер
маңгаеңа тоягы...

Ат йөрәге нидер сизенә...
Теш кычытканга түгел һич
болытларга үрелә!..

# ОЧЕРКЛАР

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**ИЮЛЬ, 1973 ЕЛ**

«Нью-Йорк шәһәре үзәгендә Кама автомобиль заводы өчен җиһазлар сатып алу комиссиясе урнашкан бина бар. Америка компанияләре һәм Совет тышкы сәүдә оешмалары чираттагы контрактларга кул куйдылар. Американың «Кливленд Крейн энд энджиниринг» компаниясе Кама буенда төзелә торган автомобиль гиганты өчен эретелгән металлны сыекландыра торган монрельс системасын, ә «Блаунокс» һәм «Кардинал» компанияләре корыч кою корпус җиһазларын әзерли.

«Кливленд Крейн энд энджиниринг» компаниясе президенты К. Пэймер үз фирмасының Совет автомобиль гиганты төзелешенә катнашуы белән горурлануын белдерде».

**«Правда», Мәскәү.**

«А. А. Фадеев исемендәге Үзәк әдипләр йорты делегациясе Кама автомобиль заводын төзүчеләргә кыйммәтле бүләк — күренекле совет язучыларының автографлары язылган китаплар алып килде. Язучылар төзүчеләр белән очраштылар. Төзүчеләр шагыйрьләрдән: Людмила Щипахина, Петр Вегин, Дмитрий Ковалев, Яков Белинский, прозаиклардан: Майя Ганина, Иван Рахилло, Василий Чечков, драматург Михаил Рощиннарның чыгышын зур кызыксыну белән тыңладылар».

**«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».**

«Мәскәүдәге Беренче май бәйрәме демонстрациясен миллионлаган совет кешеләре күрде. Үзәк телевидение Кызыл мәйдандагы бәйрәм манифестациясен илебезнең барлык почмакларына җиткерде, тамашачыларны Ватаныбызның күп кенә күренекле кешеләре белән таныштырды. В. И. Ленин мавзолее янындагы кунаклар трибунасында барлык союздаш республикалардан килгән вәкилләр бар иде. Шунда без КамАЗ вәкиле — монтажчыларның комсомол-яшьләр бригадасы җитәкчесе Илфат Сибгатуллин белән дә таныштык.

Кызыл мәйданда ул болай диде:

— Мин иптәшләрем исеменнән сезне Беренче май бәйрәме белән котлыйм. Безнең әшебез шәп бара, күңелләребез күтәренке. Быелгы елны без «монтажчылар елы» дип атадык. Ә бу — төзелешнең хәлиткеч чоры җитте дигән сүз.

Май бәйрәменнән ике ай үткәннән соң «Черноморская здравница» хәбәрчесе Чаллыга барды, анда Илфат һәм аның иптәшләре белән очрашты.

— Шәһәрдәге бер урам чатына,— дип яза ул,— Сибгатуллин бригадасы алган йөкләмәләр язылган транспарант куелган. Үзенә тапшырылган барлык объектларны бригада вакытыннан элек монтажларга йөкләмә алган.

Ерак та түгел лозунг эленгән: «Иң мөһиме, иптәшләр,— йөрәкләр картаймасын!»

Чыннан да, Илфат Сибгатуллин кебекләрнең йөрәкләре һичвакыт картаймас. Алар әле безнең совет җирендә әллә нинди могҗизалар тудырырлар».

**«Черноморская здравница», Сочи.**

«КамАЗга әледән-әле язучылар һәм рәссамнар, кинематографистлар һәм композиторлар, журнал редакторлары һәм газета хәбәрчеләре килә. Алар заман сулышын тыңларга, бөек Ватаныбыз куәте тупланган гигант төзелешне күрергә киләләр.

Чаллыда «Ульяновская правда» газетасы журналистлары да булып кайттылар.

Матбугатта чыккан материалларны укып КамАЗ турында шактый белә идек инде. Алдан ук аның масштабын: меңнәрчә кубометр тимер-бетон конструкцияне, уннарча километрга сузылган инженерлык челтәрен һәм коммуникацияләрне күз алдына китерергә тырыштык. КамАЗга килгәч, алар турында пресс-үзәк җитәкчесе Юрий Васильевич Решетов тагы да тулырак итеп сөйләде.

Әйе, әйе, КамАЗ төзелешенең үз пресс-үзәге бар. Читтән килгән журналистлар иң элек шунда керәләр. Чөнки бу моңа кадәр күрелмәгән төзелеш дөньясында үзеңә кирәкле объектны да, кешене дә табу мөмкин түгел, шунсыз КамАЗның чын асылын белеп булмый.

Экскурсантлар белән эшләү пресс-үзәк җитәкчесе вазифасына керми. Әмма Юрий Васильевич безгә аеруча игътибарлы булды. Моның сәбәбе бар. Решетов журналистлык эшен безнең өлкәнең Барыш район газетасына хәбәрләр язудан башлаган... Казан университетының журналистика бүлеген тәмамлаган һәм менә хәзер якташларына бик теләп КамАЗны күрсәтеп йөри...»

Аннары газета төзелештәге яңалыклар турында сөйли.

«Ульяновская правда», Ульяновск.

«Автоскрепер машинасын йөртүче беренче класслы шофер У. К. Наурбиев илебезнең төрле якларында эшләгән: Көнбатыш Украинада шахталар казыган, Казагыстан чирәм җирләрен үзләштергән, Кызыл-Ком чүлендә алтын чыгаручылар шәһәре — Зеравшан каласын салышкан, Ерак Көнчыгышта автомобиль юллары төзегән.

Менә өч ел инде Наурбиев Чаллыда, Кама автомобиль заводы төзелешендә эшли, автоскреперчылар бригадасына җитәкчелек итә. Бригадага коммунистик хезмәт коллективы исеме бирелгән.

— Быел без В. Васин җитәкчелегендәге автоскреперчылар бригадасы белән ярышабыз,— дип яза ул «Труд» газетасында басылган мәкаләсендә.— Башта безгә алар белән ярышу кызык тоелмый иде, чөнки без алардан әйбәтрәк эшли идек. Әмма, ярыш договоры төзегәннән соң, без аларга үзебез ирешкән дәрәҗәгә күтәрелергә булыша башладык.

Ярыш договорында без, һәр ике бригада, яңа һөнәрләргә өйрәнергә дип йөкләмә алдык. Безнең механизаторлар, мәсәлән, читтән торып автомеханиклар курсларында укый, практикадан аерылмыйча теорияне өйрәнә. Бу безгә бишьеллык заданиене срогыннан элек үтәргә ярдәм итә».

«Труд», Мәскәү.

«Аленушка» — бала гына әле. Аңа («Аленушка» — кызлар клубы исеме) — бер яшь тә тулмаган. Ул эшчеләр поселогының 8/29 йортында туды. Ә бу йорт — Чаллыда сәүдә хезмәтендә эшләүче кызларның тулай торагы.

Иң өстә — бишенче катта — ашханә һәм ресторannарның шәһәр трестында эшләүче яшь пешекчеләр яши. Аннан бер кат астарак — азык-төлек сәүдәсе сатучылары, өченче һәм икенче катта — промышленность товарлары сатучылар тора. Ә беренче кат барысы өчен дә уртак: кызыл почмак (анда телевизор да бар), кызлар клубы — зур, якты, матур итеп бизәлгән зал.

Бу клубны тулай торакта тәрбияче булып эшләүче апалы-сеңелле Н. Толченкова белән Л. Синицына оештырдылар. Клубның җитәкчеләре дә шулар. Алар кызларны өй эшләренә, биергә өйрәтәләр, хор белән җитәкчелек итәләр, төрле конкурслар оештыралар. Конкурсларның максаты — профессиональ осталыкны үстерү. «Әйдәгез әле, кызлар» дигән конкурста, мәсәлән, яшь сатучылар галстукны тизрәк бәйләү, әйберләрне тизрәк төрү буенча ярыштылар, ә «Телеңне йотарсың» дигән конкурста кулинария училищесын тәмамлаган кызлар коймак пешерделәр, төрле салатлар әзерләделәр.

«Аленушка»ның девизы — «Ял иткәндә дә өйрән!»

«Советская торговля», Мәскәү.

«Чаллыда Автомобиль промышленносте министрлыгына караган төзелеш предприятиеләре хезмәткәрләренең бөтенсоюз семинары булды. Аңа Горький, Минск, Идел, Кама автомобиль заводлары, Ярославль моторлар төзү заводы вәкилләре, министрлык хезмәткәрләре катнашты».

«Социалистическая индустрия»
на строительстве Камского автозавода».

«Берлинда яшьләрнең һәм студентларның Бөтендөнья фестивалендә КамАЗдан ике яшь төзүче: «Жилстрой» төзелеш идарәсенең ташчылар комсомол-яшьләр бригадасы җитәкчесе Вазих Мавликов һәм «Спецстрой» төзелеш идарәсенең монтажчы комсомол-яшьләр бригадасы җитәкчесе Владимир Шатунов катнашты».

ТАСС.

«Ерак Көнчыгыш эстрада ансамбле — «Амур дулкыннары» Чаллыда берничә көн кунак булды.

КамАЗ төзүчеләргә бигрәк тә ансамбль солисты Виталий Моньков һәм конферансье Яков Уральский ошады».

«Социалистическая индустрия»
на строительстве Камского автозавода».

## Әдип Маликов

# ЯЗМЫШЛАР



Партия активы җыелышы башланырга әле бер сәгатьләп вакыт бар иде. Шәһәрне карый-карый, Муса Җәлил проспекты буйлап атлыйм. Уникешәр катлы йортлар, мәскәүчә гастрономнар... Проспект агымсу шикелле дулкынланып тора. Кешеләр, машиналар агымы. Бер якта — яшь нарат урманы. Тәрәзәләренең күплеге белән бал кәрәзен хәтерләткән, болытларга ашкан ак йортлар күләгәсендә, кондыз шикелле, җиргә сеңеп, бер агач өй «яшеренеп» калган. Ишегалдында мал-туары да күренә. Апрель кояшына борынын сузып, кызыл сыер «сагыз» чәйни. Баскыч төбендә соры песи йокымсырап утыра. Яныма гына бер малай килеп басты. Җиңелчә язгы киемнән, башында кара козыреклы фуражка.

Бу өйнең хуҗалары, мөгаен, шушы биек йортлардан яңа квартира алырлар. Соры песи лифткә утырып кына җиргә төшеп йөрер, кызыл сыерны берәр совхоз фермасына озатырлар...

Күченү чоры. Кешеләр ераклардан, илнең әллә кайсы почмакларыннан кубып киләләр. Зур коллективка оешканчы, яңа урынга иялэшкәнче, алар да төрле зигзаглар аша үтәрләр...

Шулар турында уйландым мин. Ә янәшәмдә торган сары чәчле, сипкелле малайның уйлары кайсы тирәдә йөри икән?

— Нихәл, энем, буламы? — диюгә, ул сискәнеп куйды, картузын басыбрак киде. Мөгаен, Чаллы малае түгелдер.

— Каян килдең, энем?

Шул чак яныбызга өлкәнрәк яшьтәге бер хатын килеп туктады. Өстендә юка плащ, кулында портфель. Ул минем үземә сорау бирде:

— Кемегез була бу егет?

Авыз ачып җавап бирергә өлгермәдем, портфельле ханым, елмаеп, миңа кулын сузды:

— И, кемне күрәм! Каян болай?

— Әлмәттән инде,— дидем, күз күргән кешемне очратуга сөенеп.— Сез соң?

Рафика ханым иде бу. Ул «тормыштан артта каласыз» дигән сыман җиңелчә генә башын чайкады, күтәренке, дәртле тавыш белән тезеп китте:

— Чаллыга күчеп килүемә сигезенче ай. Ә Мәсәбих бөтенләй үз кеше монда. Безне алдырганчы, бер ел тулай торакта яшәде. Рәхим итегез, бүген кич безгә килеп утырыгыз. Әнә генә безнең йорт...

Рафика ханым Фәрхетдинова минем белән сөйләшкән арада картузлы малайдан күзен алмады. Алар икесе бергә китеп бардылар.

Әлмәт урамнарында без еш күрешә торган идек. Ял костюмыннан, ялт итеп киенеп, алар парлап чыгарлар иде. Мәсәбих, үзенең озын гәүдәсеннән уңайсызланган сыман, бераз иелеп йөри. Сөйләшкәндә күршесен ихлас күңелдән тыңлый, тавышсыз гына көлеп куя.

Бервакыт, Әлмәт сабан туеннан кайтышлый, Мәсәбих мине үзләренә алып китте. «Рафиканы каядыр югалттым, барыйк әле безгә»,— диде. Өйләренә кергәч, шкаф башыннан гармун алып, уйнарга тотынды бу. Идәнгә җәелгән йомшак келәмгә аягын бөкләп утырган да өздереп-өздереп уйный. Йөзендә җиңелчә сагыш та, моңсулык та бар. Мәсәбих ул чагында Казандагы финанс-экономия институтында читтән торып укый, төзелеш трестында җитәкче урында эшли иде.

Ул гармунын куйды да радиоалгыч астыннан калын гына бер папка тартып чыгарды һәм, елмаеп, аны миңа сузды:

— Җуләр хатынын мактар, ди, күз йөртеп чыгыгыз әле, зинһар... Мактау грамоталары, медаль таныклыклары, рәхмәт кәгазьләре. Бөтенесе бергә бер папка җыелган. Мәскәүдән, Казаннан министрлар кул куеп җибәргәннәре дә, партия һәм комсомол оешмалары тарафыннан бирелгәннәре дә бар. Мәсәбих ул чагында артык берни сөйләмәде, тик болай дигәне хәтердә калган:

— Рафиканың эше дә, тормышы да бик гыйбрәтле. Җае чыккан да үзеннән бер сөйләтерсез әле.

Менә шушы бүгенге очрашудан соң күңелемне кызыксыну тойгысы бөтереп алды. Ул хәзер дә милициядә, балалар бүлмәсендә эшли микән?..

* * *

Актив җыелышында мин Рафика ханымны һәм аның белән бергә киткән картузлы малайны искә төшереп утырдым.

Киңәшмәдә сүз узган елның йомгаклары һәм алдагы бурычлар турында барды. Саннар, фактлар... Дөньяда тиңе булмаган автогигант аякка басып килә бит. Тамырларын ул тирәнгә җибәргән. Аңа бөтен ил кул сузган.

Элекке килүемдә «вездеход» мине ачык кыр буйлап йөртте. Әрем арасында бетоннан коелган озын плита сузылып ята иде. «Монда завод булачак». Плитадагы шул гади язу мине кинәт тетрәндереп җибәргән иде. Болар бит партия съезды трибунасыннан күчкән тарихи сүзләр. Совет халкының кайнар теләге, вәгъдәсе, анты.

Төзүчеләр, монтажчылар, белгечләр бүген инде тирән субайлардан күтәрелгән, йөзәрләгән гектар мәйданны биләгән яңа завод корпусларының түбәләрен ябу турында сүз алып баралар. Аларга су, җылылык бирергә, цехларга җан өрергә кирәк.

Чәчләренә чал кергән укытучы хатын трибунага менгәч, зал сагаеп калды. Мәктәпләр, спорт заллары җитми дип зарланыр микән? Юк, зарланмады. Ул милиция идарәсе каршындагы балалар бүлмәсенең эшенә, тәрбия темасына тукталды. Һәм шунда ук өлкән инспектор Рафика Фәрхетдинованың исемен телгә алды. Уңай яктан. Аларга җәмәгатьчелек ярдәме кирәклеген әйтте. Кара син аны, Рафика ханым КамАЗ тикле КамАЗ төзелешендә дә югалып калмаган бит...

Партия өлкә комитетының беренче секретаре Фикрәт Табеев укытучы апа әйткән сүзләрне образлы итеп гомумиләштерә төште:

— Төзелеш барганда яраксыз табылган металл конструкцияне бүтәнгә алмаштырырга мөмкин. Ә кеше җанын алай гына алмаштырып куя алмыйсың. Һәр яңалыкның нигезендә кешегә карата игътибарлылык дигән нәрсә ятарга тиеш.

Беренче секретарь сүзен дәвам итте:

— Без монда, Кама буйларында, автогигант салып кына калмыйбыз, ә кеше язмышларын да төзибез. Биредә яңа буын формалаша, беркайда булмаган КамАЗ балалары үсә...

Бөек төзелешнең каймагы җыелган шәһәр активы киңәшмәсендә коммунистик мораль, тәрбия мәсьәләсе алгы планга килеп басты. Чөнки партиябезнең кыйбласы шул якка караган.

«КамАЗда балалар үсә»... Бу сүзләр, теге плитадагы язу шикелле, күңелемдә уелып калды.

Кичен Фәрхетдиновларга киттем. Ишекне унөч-ундүрт яшьләр тирәсендәге бер кыз — буйга тартылган чандыр гына яшүсмер ачты.

— Әйдәгез, узыгыз, абый,— диде ул, күптәнге танышына дәшкән сыман.— Сез Әлмәттән бит, абый?

Кухнядан ягымлы гына калын тавыш ишетелде:

— Фәридә, кызым, котлетлар көя...

Фәридә аз гына югалып торганнан соң, яңадан әйләнеп килде, әтисенең «гайбәтен» сөйләргә тотынды:

— И, бу әтине. Кичке ашны бергә әзерлик дигән була, ә үзенең... Көя башлаган котлетларны әйләндерергә дә йөрәге җитми.

Менә Мәсәбих тә күренде. Элеккечә ягымлы, һаман мөлаем... Шул арада тәбәнәк тумбочка өстендә телефон шалтырады. Мәсәбих, аягын бөкләп, идәнгә утырды, аннары гына телефон трубкасын колагына китерде.

— Әйе, Чаллы тыңлый, Чаллы-ы,— диде ул, авызын зур ачып,— Әлмәтме бу? Шулаймыни? Давай, малай, кил, кил, ике куллап каршы алырлар...

Ә Фәридә әтисен «тәнкыйтьли»: ярты Әлмәтне Чаллыга тартып бетерә инде, ә нефтьне кем чыгарыр анда?!

Рафика ханым кайтканчы хәл-әхвәлләр сорашып алдык. Мәсәбих — экономист, экономик анализлар лабораториясе начальнигы икән. КамАЗның бөтен финанс хәлен, миллионнарча сум тәшкил иткән бөтен керем-чыгымнарын алар көзгедәге шикелле күреп, әйтеп торырга тиешләр. Вакыты тыгыз Мәсәбихнең, һәр минуты пружина сыман. Әтисенең дә, әнисенең дә эшләре муеннан, Фәридәгә мәктәптән соң көндезләрен күбрәк ялгыз торырга туры килә икән. Ә кичен бергә оешалар. Танышларыннан берәрсе дә килсә, тагын да күңелләрәк була ди.

Менә Рафика ханым да кайтып җитте. Ул ялгызы гына түгел, баягы картузлы малайны да ияртқән. Фәридә аларны йөгереп барып каршы алды. Үзеннән сорамыйча гына, малайның баш киемен салдырып, чөйгә элде.

— Исемең ничек?

Малай теләр-теләмәс кенә җавап бирде:

— Валерик...

Фәридә әнисенә дә чишенергә ярдәм итте. Ә әни кешенең арыганлыгы йөзенә чыккан, әмма сиздермәскә тырыша. Плащ астыннан көмеш погоннар ялтырап күренде.

— Рәхим итегез портфелегезне дә, иптәш милиция өлкән лейтенанты,— диде кызы, бераз ирония сиздереп.— Әбәү, авырлыгы, нәрсәләр тутырып кайттың моңа, әни?

Күне шомарып беткән сары портфель эченнән кесә фонаре, таушалган уен карталары, бер пачка папирос, шырпы, зажигалка, тагын әллә нәрсәләр килеп чыкты. Фәридә дәшмәде, башын гына чайкап куйды. Димәк, бүген дә рейд ясаганнар. Бу «трофейлар», әлбәттә, шуның нәтиҗәсе.

Милиция халкы читтән килгән ят «кошларны» әллә каян танып ала. Бигрәк тә малай-шалайларны. Алар, гадәттә, компаниягә ку-

шылмыйча, алан-ялан каранып, бер ялгызлары йөриләр. Рафика ханым Валерикны башта төзелеш тресты каршындагы зур портретлар галереясы янында очрата. Малай һәр портрет астындагы язуны игътибар белән укып чыга, рәсемнәрнең йөзләренә текәлеп карый. Аннары ул булачак ГЭС дамбасы яныннан урап, Кама өстендәге бозваткычларга карый-карый, Иске Чаллы ягына юл тота...

— Сезнең белән очрашудан соң, аны туп-туры балалар бүлмәсенә алып киттем,— диде Рафика ханым, миңа аңлатма биреп.— Бөгелмәдән килгән.

Фәридә түзмәде, кинәт кенә сорау бирде:

— Качыпмыни?

— Чаллыга Алексей Стахановны күрергә дип килгән ул, кызым. Безгә кызык булып китте.

— Стахановларның КамАЗ төзүчеләргә язган хатлары турында ишеткәндер ул,— диде Фәридә, әнисенең янына ук елышып.

Рафика кызын аркасыннан сөеп, иркәләп алды:

— Төзүчеләр бригадиры Рәис Сәләхов белән Стахановны аз гына бутаган ул, кызым. Мәскәү радиосыннан ишеттем дип, минем белән бәхәсләшеп бара.

Фәридә үзенчә хөкем чыгарды:

— Нигә, дөрес әйткән Валерик. Рәис Сәләхов турында «Комсомольская правда»га яздылар. Аның бригадасы планны гел арттырып үти. Димәк, ул да стахановчы!..

Малай мин барында йокысыннан уянмады, үзен сөйләтеп булмады. Аның караву, бу кичне мин күп кенә башка нәрсәләрне белдем.

Фәрхетдиновлар өенә көн саен булмаса да, сирәк-мирәк берәр малай ияреп кайту — гадәти хәл икән. Азмыни КамАЗ күрергә килүчеләр. Даны бөтен дөньяга яңгырый бит. Күпмедер акча юнәтеп, тоталар да юлга чыгалар. Ә Чаллыга килгәч, кайтырга дигән акчаларын мороженыйга, тәм-томга тоталар. Теләсә ничек озат аннары чакырылмаган кунакны. Җәй көннәрендә эшләр тагы да хәтәррәк икән. Кампанияләре белән явалар. Узган ел җәйге каникул вакытында Кострома өлкәсеннән бер төркем малай килеп төшә. «Кыргыйлар» командасы. КамАЗны күргәннәр күрүен, әмма кире кайтырлык рәтләре калмаган. Ахыр чиктә икмәк заводына он бушатырга ялланганнар...

— Аларның бит төрлесе була,— диде Рафика ханым, сәгатькә күз төшереп, Фәридәгә йокларга вакыт икәнен сиздерде,— кайберләре кесәгә керә, автобуста пассажирлар билет алырга дип сузган биш тиеннәрне җыеп үзләштерә башлый...

Бөтен Чаллы төзелешенә бердәнбер балалар бүлмәсе. Штатларында ни бары өч кеше. Фәрхетдинова Рафика яше белән дә, эше буенча да арада иң өлкәне. Бөтен җаваплылык аңа төшә.

Романтика эзләп яки тормыш юлында адашып йөргән сәяхәтчене ата-анасы кулына, я булмаса тәрбия йортына тапшырганчы, аны кундырып чыгару өчен кунак өе күздә тотылмаган. Әгәр милиция бүлмәсендә ябып тота башласаң, бала күңелендә гомерлек рәнҗү калачак. Рафика ханым һәм аның кул астында эшләүчеләр өйләреннән ычкынган сәяхәтчеләрне чиратлап үзләренә алып кайталар, семья табынына чакыралар, түрләрендә йоклатып, икенче көнне юлга озаталар. Бу хәлгә киң күңелле Мәсәбих та, кунакчыл кызлары Фәридә дә инде күнегеп, гадәтләнеп беткәннәр.

Без Рафика ханым белән икенче көнне балалар бүлмәсендә очрашырга сүз куештык. Ул:

— Эш башланганчы, берәр сәгать алдан килсәгез икән,— дип калды.

*
* *

Яшь урамнарны нурга коендырып, апрель кояшы күтәрелә. Шәһәр инде күптән аякка баскан. Юлларда берөзлексез автобуслар, вахта машиналары чаба. Кулларына сумка тоткан, муеннарына кызыл галстук таккан малайлар, кызлар мәктәпкә ашыга. Алар күккә ашкан биек краннар астыннан, зур чүмечле экскаваторлар, тау-тау балчык өемнәре яныннан узалар. Яңа шәһәрнең киләчәге, булачак хуҗалары...

Балалар бүлмәсе күп квартиралы зур торак йортның беренче катында урнашкан. Өлкән инспектор Рафика Фәрхетдинова эш урынында иде инде. Өстендә милиция формасы: гәүдәсенә сыланган зәңгәр китель, елкылдап торган погоннар... Аз гына чал керә башлаган кара чәчләрен шома, тигез итеп, артка тарап җибәргән. Ул мине ягымлы йөз белән каршы алды, алгы бүлмәгә чакырды. Бүлмә бик җыйнак, чиста. Артык бер нәрсә дә күренми. Тәрәзә төбендә яран гөлләре, стена буенда китап шкафы. Идәндә балалар уенчыклары.

— Валерик турында әле сез белмисез,— диде Рафика ханым, сүзне үзе башлап.— Кичә аны автовокзалдан Бөгелмәгә озатып куйдым дисәм, шәһәр очында машинадан төшеп калган егетебез. Кичкә кадәр завод төзелешләрендә, кою, тимерчелек цехларында йөргән, Мәскәү монтажчылары яшәгән «Бытовка»да да булган. Төнге рейдтан кайтып килгәндә, берәү «апа!» дип дәште миңа. Сискәнеп артыма борылсам, күземә күренәме дип торам. Арыган, мескенләнгән. Күзләрендә яшь. Үзем дә чак елап җибәрмәдем...

Рафика дулкынланып сөйли, аның тавышы калтыранып чыга:

— Валерик әнисе белән Мурманск өлкәсеннән Бөгелмәдәге туганнарына кайткан булган икән. Әнисе эчәргә ярата, ди. Малай бу хурлыктан качып, КамАЗга сыену урыны эзләп килгән. Менә бит ничек тормышлар. Әни янына кайтмыйм, диде башта. Җитмәсә, укуын да ташлаган икән.

Рафика ханым беразга тынып, бармак очларын угалады. Аның уйчан соргылт күзләрендә моңсулык билгесе, йөзендә кайгы. Ул кинәт җанланып, кичәге хәлләрне, мин алардан киткәч булган сөйләшүне исенә төшерергә тотынды:

— Беләсеңме, төнге унберләрдә торып утырды Валерик. Фәридә үзенә ипигә варенье ягып, чәй эчерде, шунда ук уртак тел таптылар. Чаллыны мактарга тотынды малай. Шәһәрегездә бер исерек кешене дә күрмәдем, ди балакай. Юл уңаеннан әнисе белән Мәскәүгә кергәннәр. Валерик Ленин мавзолеенда булган, Кремльне карап йөргән. Шундый дәртләнеп сөйли.

Сизелеп тора, Рафика ханым моңа кадәр күз күрмәгән ят малайны үз баласы шикелле итеп яратып өлгергән. Семьялары белән яратканнар. Фәридә аңа укуын дәвам иттерергә, әнисе яныннан бер кая китмәскә киңәш биргән. Әниеңә синнән башка кыен булачак, дигән. Валерик әтисен хәтерләми, ул әтисез үскән икән.

Аннары Мәсәбих сөйләшә малай белән. Ун классны тәмамла да Чаллы институтына укырга кил, аңарчы бездә институтлар ачылган булыр, ди. Егет бәхәскә керә. КамАЗ төзелеп беткәч, янәсе, ни кызыгы кала. Менә хәзер булса...

Бүген иртән Мәсәбих яшь кунакны автобуска утыртып, Бөгелмәгә озатып куярга тиеш икән. Фәридә Валерикка портфель бүләк иткән, портфель эченә дәфтәр, карандашлар салган.

— Болай булса, сездән кунаклар өзелмәс,— дидем мин Рафика ханыма,— үзегезне күрер өчен килә башларлар.

Өлкән инспектор уйга калды, аннары әйтте:

— Нишләргә соң? Күземне йомсам, төнлә төшләремә керә шулар. Һәркайсын бәхетле итәсе килә, юлга чыгарасы...

Иртәнге сигез тулуга, балалар бүлмәсендә эш сәгате башлана. Телефон шалтырый. Ир кеше тавышы. Фәрхетдинова сабыр гына тыңлый, салмак кына сөйләшә.

— Ярый, хәл итәрбез...

Аның йөзе кинәт алсуланып куйды:

— Ничек инде теләмиләр? Без илтеп куярга тиешмени?

Ул урыныннан торып, ишекле-түрле йөренде. Аннары бераз тынычлана төшкәч, миңа хәлне аңлатып бирде.

Игорь исемле унөч яшьлек малай һәм аның ата-аналары турында сүз бара икән. Алар бирегә узган ел Казаннан күчеп килгәннәр. Игорь Казанда чакта ук милициядә учетта торган, өенә кайтмыйча йөргәләп, берничә мәртәбә велосипед урлап тотылган булган. Бу гадәтләрен ул Чаллыга килгәч тә ташламаган. Әти-әниләре Игорьны Азнакай интернат-мәктәбенә җибәртү чарасын күрергә тотынганнар, ә үзләре аны хәтта илтеп кайтырга да риза түгелләр икән. Бу эшне, янәсе, милиция башкарсын.

— Хәзер Игорь Садовский укыган мәктәпнең класс җитәкчесе киләчәк,— диде Рафика ханым. Ул сөйләвендә дәвам итте:

— Карап торуга бер дә бозык малайга охшамаган. Шундый чибәр, сөйкемле. Күңелендәге яшермичә әйтеп бирә. Бер көнне шушы бүлмәдә икәүдән-икәү генә утырабыз. Икебез дә уйга калдык. «Хәзер нишлибез инде, Игорь?» — дип, башыннан сыйпауга, бу миңа зурлар сыман итеп җавап бирә: «Мин төзәлә алмам, ахры, Рафика Сәлимҗановна, ди, мине, мөгаен, утыртырлар»...

Ишектә яшь кенә ханым күренде. Өлкән инспектор аны елмаеп, якты йөз белән каршы алды:

— Әйдәгез, Галина Федоровна, узыгыз!

Алар тиз-тиз генә фикер алыштылар да Садовскийларның квартирасына барырга булдылар. Мин дә иярдем. Юлда ул семья турында сорашып, шактый мәгълүматлар алдым.

Игорьның әтисе үги икән. Өченче класста укучы сеңелесе бар, ди. Әмма яңа әтидән. Туган тиешле бер әби яши икән тагын. Казандагы квартиралары шул әбинеке булган. Биредә аны да исәпкә кертеп, зур квартира алганнар. Хәзер иркендә яшиләр.

Садовская (ягъни Игорьның әнисе) ашханәдә буфетчы булып эшли. Ә Леонид Федорович Шпак — төзелештә бетончы. Димәк, акчаны җитәрлек алалар...

Без ишек шакып керүгә, хуҗа хатын бераз каушап калгандай итте, аннары, тиз генә үзен кулга алып, сайрарга тотынды:

— Әле генә үзем барам дип тора идем сезгә,— диде ул, алтын тешләрен елтыратып,— гафу итегез инде. Килүегезгә бик зур рәхмәт. Менә диванга, йомшак урындыкларга утырыгыз...

Мин Рафика ханымның йөзенә карап куйдым. Ул мондый төчелеккә бик эреп китми һәм күңелендәге ачуын тышка да чыгармый. Шундый сабыр, тыйнак тота үзен.

Бүлмәләре җиһазга бай. Елкылдап торган гарнитур, түрдә пианино, сервант, кыйммәтле вазалар. Идәндә затлы келәм. Бөтен нәрсә җиткелекле.

Шул арада Игорь кайтып керде. Чыннан да сөйкемле бала. Аскы ирене кабарып, аз гына бүлтәеп чыккан. Шомырт кара күзләре янып тора. Ул безне күрүгә, баш иемен салып, исәнләште дә ишек яңагына сөялде. Озын керфекләре түбән иелде. Игорь бу өйдә үзен чит кеше сыман тота. Өстендә аның пычрак иске куртка. Чалбарында ямаулар...

Милиция өлкән лейтенанты Фәрхетдинова, үзендә власть көче барлыгын сиздермәскә тырышып, иптәшләрчә генә сорый:

— Хәзер нишләргә уйлыйсыз инде?

— Үзем илтеп тапшырам,— диде Игорьның әнисе, берсүзсез риза булып,— эштән сорап китәрмен.

— Ә бәлки Игорьга монда гына калыргадыр? Чаллыда да мәктәп-интернат бар бит.

Садовская икеләнеп калды. Күренеп тора, баласын үзләре белән бер шәһәрдә тотасы килми. Ә Игорь исә безнең яннан ук чыгып китте. Димәк, бер-берсеннән тәмам бизгәннәр. Ана белән бала арасында тирән упкын барлыкка килгән. Нинди зур фаҗига.

Өлкәннәр генә калгач, Садовская әбиләрен яманларга тотынды. Ул гына бозды баланы, аны үз бүлмәсенә алды, арага керә, янәсе. Бу сүзләрне ишетүгә:

— Үз гаебегезне әбигә сылтамагыз, Галина Николаевна,— диде Рафика ханым, кырыс кына тонга күчеп.— Игорь сезнең балагыз...

Сүзгә класс җитәкчесе дә кушылды. Хатын-кызлар җитди сөйләшү алып барган арада, мин әби белән Игорь яшәгән бүлмәгә күз салдым. Ике якта ике койка. Зур койкада бер өем кәгазь чәчәкләр ята. Өстәл һәм тәрәзә төпләре сары, яшел, кызыл кәгазьләр белән тулган. Бер генә савыт булса да, тере гөл күрәсе килә шушы бүлмәдә.

— Чакырып-чакырып та мәктәпкә аяк басмадыгыз,— дигән сүзләре ишетелә класс җитәкчесенең. Садовская акланырга тырыша:

— Буфетны ничек ябып китәсең.

Фәрхетдинова сабырлыгын җуймаска тырышып кына сорый:

— Кыш көне, Игорь югалып торган чакта, ни өчен Мәскәүгә китеп бардыгыз?

...Бу квартирадан авыр уйлар белән чыктым мин. Һәммәсе ачыклана бара: кызлары Эмма тугач, бөтен игътибар аңа күчкән. Әтисе дә, әнисе дә аны нык иркәләгәннәр. Ә Игорь күләгәдә калган. Үз әтисе түгел икәнлеген дә сизгәч, аңа бигрәк тә кыенга килгән, күрәсең. Өлкәннәрдән күрмәкче, Эмма да аны читкә тибәрә башлый, абыйсына җикеренә, йодрык белән ташлана. Игорьга карата әнисе хәзер дә игътибарсыз икән. Менә бит, малай атна буена өйгә кайтмыйча подвалларда, җылы үткәргеч коеларда кунып йөргән чагында, Садовская тота да, кием-салым алырга дип, Мәскәүгә китеп бара. Баласын ул затлы киемнәргә алыштыра.

Әби чәчәкләр ясап, шуларны сатып көн итә икән. Аңа Игорь да булыша. Пенсия акчасына ялгау өчен ишкә — куш.

Семьяда үзләрен «артык кашык» итеп сизгән балалар гадәттә үпкә-рәнҗүләрен эчкә йоталар, кемгәдер үчле булалар. Бу үчне алар иптәшләре арасында көчсезрәк саналган малайлардан, кызлардан кайтара башлыйлар. Өлкәннәр теле белән әйтсәк, «сугыш чукмары»на әйләнәләр. Шулай итеп, семьядагы конфликт урамга, мәктәпкә күчә. Бу конфликтны үзләренчә җиңел генә хәл итү өчен кайбер яшүсмерләр өйләреннән качып китәләр. Игорьны да берничә мәртәбә тотып алып кайтканнар. Караңгы подвалларда, төзүчеләр яшәгән «бытовка»ларда аз кунмаган ул.

Ялтыравыклы мебельләр, затлы киемнәр, бармакларда алтын балдаклар... Ләкин ата тиешле, ана тиешле кешеләрнең күңел бушлыгын зиннәтле җиһазлар гына ничек тутыра алсын.

Без Рафика ханым белән яңадан аның эш урынына кайттык. Ярдәмчеләре, өстәлдә язу калдырып, үзләренә беркетелгән участокларга китеп барганнар. Фәрхетдинованың йөзе борчулы. Бу аңлашыла да. Игорь семья тәрбиясеннән, «әни!» дип дәшү бәхетеннән мәхрүм булачак. Семьяда ул хәзер артык кешегә әйләнгән. Аны күрәләтә интернат җилкәсенә ташлыйлар. Ә үзләре һаман баеп яшәмәкче...

— Иң мөһиме — бала күңеленә салынган кешелек хисләрен саклап кала алу,— ди Рафика ханым, үзенең тырышлыкларына йомгак ясагандай.— Игорьны җинаятьчелек юлыннан йолып алдык шикелле. Хәзер инде балалар бүлмәсенә якыная башлады. Үз семьясында яшәргә риза түгел ул, күндерә алмадык. И аның белән җәфаланганнар...

Рафика ханым кечкенә йодрыгын төйнәп, үзалдына сөйләнгән сыман гына итеп, кискен бер фикергә килә:

— Әле соң түгел. Садовская шикеллеләрне җавапсыз калдырырга ярамый. Ана хисен югалту — кешелек сыйфатларын югалту дигән сүз. Кошлар да балаларын оядан чыгарып ташламый. Балаларын очырганчы, авызлары белән җим ташыйлар.

Әледән-әле телефон шалтырый, бүлмәгә берөзлексез кешеләр кереп тора. Менә җитез хәрәкәтле, кыю гына бер яшь егет пәйда булды.

— Рафика Сәлимҗановна, җәй якынлаша бит, нишлибез инде? — ди ул, сүзне конкрет эштән башлап.— Ишегалларында спорт мәйданнарын тәртипкә китерә башлыйсы иде...

— Дөрес сүз, Юра,— ди өлкән инспектор да, ягымлы елмаеп,— әйдәгез бу мәсьәлә буенча иртәгә Гоголева янына барыйк. Планнарын бергә төзербез. Бу эшкә мәктәпләрне дә тартырга кирәк.

Егет чыгып киткәч, Рафика ханым аның турында кыскача белешмә бирә. Комсомолец Юрий Забелин 8 номерлы автотранспорт хуҗалыгында шофер булып эшли икән. Сугышчан комсомол дружинасының иң актив члены. Төнге рейдларда да катнаша. Дружина составында кызлар да бар.

— Менә комсомолка Нина Романова,— дип, миңа фоторәсем сузды өлкән инспектор.— Карагыз әле, чибәрме? «Промсвязьмонтаж» оешмасыннан. Монтажчы.

Чәчләре маңгаена төшкән. Йөзендә горурлык та, аз гына ирония дә бар сыман. Үзе бик ягымлы күренә. Рафика ханым Нинаның бөтен биографиясен белә, аның турында яратып сөйли:

— Көн дә бер кермичә, я шалтыратмыйча калмый. Псков өлкәсеннән. Элек конденсатор заводында намотчица булып эшләгән. Яшүсмерләр белән эшләргә бик ярата. Бәхетле генә булсын инде...

Фәрхетдинованың һәр омтылышында кешегә карата кайгыртучанлык барлыгын тоясың. Ул башкарган эшләрнең асылы да шуңа кайтып кала бит. Тормыш юлында адашкан сабыйларны бәладән йолып калу, кулларыннан җитәкләп, аларны якты сукмакка чыгару. Өлкән инспекторның таянычы зур. Нина шикелле комсомолкалар эштән соң танцыга, күңел ачуга бирәсе вакытларын комсомол рейдларына, балалар бүлмәсенә багышлыйлар. Бөек төзелешләр каласында җинаятьчеләр үсмәскә тиеш. Аңа юл куймаска кирәк. Комсомол рейдлары аена ике мәртәбә үткәрелә икән.

— Ә бая телгә алган Гоголева кем була инде? — дип сорадым мин.

— ВЛКСМның Чаллы шәһәр комитеты секретаре,— диде Фәрхетдинова, бу сүзләргә басым ясап.— Өченче секретаребыз Нина Петровна. Бик уңган кыз. Бергә фронт тотабыз. Балалар бүлмәсе эшенә пенсионерларны да тартабыз.

Рафика ханым күбрәк башкаларның ярдәме, шәһәр оешмалары, мәктәпләр белән элемтә турында сөйли. Партия активы трибунасыннан әйтелгән сүзләргә — балалар бүлмәсенә җәмәгатьчелек ярдәме кирәк, дигән фикергә бу гүя аның җавабы. Игътибарны кәтеп ятарга гына ярамый, аны эш белән яуларга кирәк икән.

Яшь кенә бер кыз килеп керде, исәнләшеп, Рафика ханым каршысына утырды. Алар сөйләшкән арада мин, рөхсәт сорап, шкафтагы китапларны барлыйм. Макаренконың «Педагогик поэма»сы, «Корыч

ничек чыныкты», Аркадий Гайдар әсәрләре, Дзержинский турында китап... Тәрбия темасына күп кенә брошюралар күренә. Кулым калын папкага үрелә. Өлкән инспектор яшь кыз белән сөйләшүеннән бүленеп, уңайсызланып кына:

— Серләремне ачасыз бит! — диде.

Каушавымны сизгәч, ул көлеп җибәрде. Аннары, әйдә, карагыз инде, дип рөхсәт бирде.

*

* *

Чаллыда чагымда Рафика ханым белән күп очраштым: эш урынында да, квартираларында да. Кичләрен кунак өенә кайткач, әлеге «серле» папкадагы язмаларны актарып утырдым. Төрле журналлардан, газеталардан кисеп алынган мәкаләләр, очерклар. Һәммәсе мораль тәрбия темасына. Рафика ханым үзе дә бик актив журналист икән. Аның язмаларын укыгач, катлаулы тормыш картиналары бер-бер артлы күз алдыннан үтәләр. Берсенә берсе охшамаган язмышлар.

Сабый үзен ташландык итеп сизсә, бу коточкыч нәрсә. Балаларыннан ваз кичкән, аларның киләчәкләрен, бүгенге шатлыкларын урлаган ата-аналар очрап куя бит әле.

Әлмәт елларын хәтерли Рафика ханым, өзелеп-өзелеп, куанып әйтә торган «әти», «әни» сүзләреннән мәхрүм ителгән Ринат белән Әминәне исенә төшерә. Берсенә ун яшь, икенчесенә — биш. Ул аларны үзенә якынайта. Әминәне тәүлек әйләнәсенә балалар бакчасына илтә. Еш кына янына барып йөри. Әллә тәрбиячеләр өйрәтеп куйган, бер көнне Әминә аңа «әни» дип дәшә. Шуны ишетүгә, Рафика ханым каушап кала, коелып төшә. «Әни!» Нинди зур җаваплылыкны үз өстенә ала ул. Бала өчен иң кадерле, изге бу сүздән баш тартып кара син аннары...

Төзелеш трестында управляющий ярдәмчесе булып эшләгән Мәсәбих исә Ринатны Урсал тау буендагы пионер лагерена урнаштыра. Алар, ирле-хатынлы, атна саен малайның янына баралар, күчтәнәчләр илтәләр. Соңыннан ул балалар белән аерылышу зур бер кайгыга әйләнә. Мәсәбих тә, Рафика ханым да сабыйларны үзләренеке итәргә бик теләр иделәр дә... Аларның кайдадыр югалып йөргән әти-әниләре бар шул. Алдагысын уйларга кирәк. Алда яңа язмышлар көтә...

— Сезне балалар йорты директоры итеп кенә куясы иде,— диләр милициядә эшләүче җитәкчеләр Рафика Фәхретдиновага.— Ул чагында берсен дә үзегездән арттырмас идегез.

— Әйе, арттырмас идем,— ди өлкән тәрбияче җитди генә,— гел үз канатым астына җыеп барыр идем. Дөнья балалар елмаюы белән матур.

Бер-бер артлы еллар уза, Зәйдә күп сулар ага. Әлмәт матур калага әйләнә. Бер көнне милиция каршындагы балалар бүлмәсе ишеген шакып, буйга җиткән чибәр генә яшүсмер керә.

— Әни! Гафу итегез, Рафика Сәлимҗановна, бу — мин, Ринат,— ди ул дулкынланып, Фәрхетдиновага баш иеп.— Хәтерлисезме? Хәзер Казанда ГПТУда укыйм. Әминә тәрбия йортында. Отличница. Яңадан сезне очратырмын дип ышана идем...

Ринат чалбар кесәсеннән шоколад алып, аны кыюсыз гына өлкән тәрбияченең эш өстәленә китереп куя. Рафика ханым күз яшьләрен күрсәтмәскә, ничек тә яшерергә тырышып, үсмер егетне кочагына ала. Барысын да хәтерли Рафика апасы, ничек хәтерләмәсен.

...Бөгелмә аэропортыннан самолетта бергәләп Казанга очтылар. Кечкенә Әминә аның алдына утырып, йоклап барды. Ринат юл буена берөзлексез конфет суырды. Һавага күтәрелгәч, балаларның күңел-

ләре болганмасын дип, стюардессадан монпасины күбрәк итеп алган иде өлкән инспектор. Ярап куйды.

Ә тәрбия йортында аларны тиз генә кабул итәргә теләмәделәр. Документлары җитәрлек түгел, диделәр. Милиция лейтенанты Фәрхетдинова, сабыйларны җитәкләп, министрлыкка китте, чиратсызнисез министр янына барып керде. Урта яшьләр тирәсендәге, әмма чигә чәчләренә инде ак бәс кунган, пөхтә киемле кеше аның сөйләгәнен сабыр гына тыңлап утырды. Әминә кинәт: «Әни, калмыйм!» дип, кычкырып елап җибәрде. Рафика ни әйтергә дә белмәде. Аның тәне шыбыр тиргә батты, йөрәге кызурак тибә башлады. Сабыйларны үзенә артык якынайтып, бераз хата эшләмәде микән ул? Мәхәббәт белән шаярмыйлар, бигрәк тә бала мәхәббәте белән. Министр алдында, «әни» диде бит Әминә. Җан өзгеч сүз, бердәнбер сүз...

Бик авыр булды аерылышулар, бу ике сабый озак еллар буе Рафиканың йөрәк түреннән төшмәде. Менә бит, дөрес юлга бастыргач, югалмаска, адәм рәтле кеше булырга тырышалар. Тәрбияче өчен монысы иң зур бүләк. Онытмаган бит, яңадан сезне очратырмын дип ышана идем, дигән була.

Үз гомерендә балаларның төрлесе очраган аңа. Берәүләр кыңгыраулы мәктәбен тын, кысан подваллар «романтика»сына алыштыра. Икенчеләре, киресенчә, канат чыкмас борын каядыр еракка, күз күрмәгән якларга очарга омтыла. Өченчеләрен ятимлек кысрыклый...

Әкият сыман хыялга бай балалык елларын кемнәр генә кичермәгән. Һәммә нәрсәне үз кулың белән тотып, капшап карыйсы килә. Кеше кеше булырга әзерләнә. Нинди агымга эләгәсең бит. Кыйблаң дөрес булмаса, соңыннан кире борылуы чиксез кыен.

— Бала ялганламасын, гаебен яшермәсен,— диде Рафика ханым, без үзара сөйләшеп утырганда.— Чирен яшергәнне дәвалавы кыен. Гомумән, ялганчы балалар җинаять юлына тизрәк басучан булалар.

Аңа һәр вакыт дөресен сөйлиләр. Ничек ирешкән ул моңа? Әллә берәр сихере, тел ачкычы бармы соң? Бу сорауга, мөгаен, Рафика ханым үзе дә ачык кына җавап бирә алмас иде. Еллар буе бөртекләп җыйналган тәҗрибә, табигый сизем ярдәмгә киләдер бәлки. Өлкән тәрбиячenең тагын шул сүзләренә дә игътибар иттем мин:

— Баладан сорау алырга ярамый,— диде ул.— Аның белән үз тиңең шикелле итеп, бер сулыштан сөйләшергә кирәк.

Сөйләшергә, серләшергә, хезмәтеңдә үзеңне дежурный итеп тотмаска. Бала хәсрәтен үз хәсрәтең итеп алырга, бергә борчылырга... Андый кайгыртучан апа алдында сабый ничек ялганлап торсын.

Чит балалар турында уйлаганда, Рафика ханым аларның язмышын үз язмышына үлчәп карый. Аңа, имчәк бәби чагыннан әтисезәнисез калган ятимгә, вакытында җылы кул сузмасалар, аны тәрбия кочагына алмасалар, укытмасалар, кем булыр иде микән ул? Бәлки дөньясына бик каты ачу саклап, таш бәгырьле булып үсәр иде.

Камышлы районы Ярмәк авылында ун яшенә кадәр әбисе-бабасы тәрбиясендә үскән, яшел чирәмдә каз бәбкәләре көтеп йөргән сабыр күңелле, уйчан Рафиканы 1937 елда Зыя абыйсы Урта Азиягә алып китә. Үз кызы кебек итеп күрә ул аны. Ятимлек тойгысы әзәрләкләми кызны, ятимлек күләгәсе эреп артта кала.

Күктә эссе кояш, аяк астында кайнар ком, ят дөнья... Табигате ят булса да, кешеләре ят түгел. Шул ук кыңгыраулы мәктәпләр, кызыл байраклы пионер отрядлары. Укы, теләгәнчә хыяллан... Рафика укый, рус, төркмән телләрен өйрәнә. Зыя абыйсы ул чагында милициядә уголовный розыскта хезмәт итә, гыйбрәтле язмышлар, баш әйләндергеч хәлләр турында кайтып сөйли.

Бөек Ватан сугышы башлана. Аның көйдергеч ялкыны Төркмәнстанга да килеп җитә. Эвакуацияләнгән балалар күренә башлый.

Менә шул көннәрдә буй җитеп килгән Рафика мәктәп-интернат балаларына шефлык ярдәме күрсәтүчеләр сафына баса. Егерме яшендә ул Төркмәнстан педагогия институтын тәмамлый, коммунистлар партиясе сафына керә. Рафика, Зыя абыйсы ярдәме белән, милиция идарәсе каршында балалар бүлмәсе оештыра. Мәрхәмәтсез сугыш канатларын кискән, хыялларын чәлпәрәмә китергән сабыйларны ул үз тирәсенә җыя, алар язмышын үз язмышы белән бәйли.

1948 ел. Рафика белән Мәсәбихның яңа гына тормыш корып җибәргән чагы. Төркмәнстанда җир тетри, шәһәрләр, урамнар балчык өеменә әйләнә. Бу коточкыч фаҗига гомер буе күз алларыннан китмәде аларның. Үзең укыткан, көн саен елмаюлы йөзләрен күреп торган, җаныңа якын иткән терекөмештәй сабыйларны җимерек йортлар астыннан казып чыгар да яңадан җир куенына тыгып куй әле. Рафика шулар кайгысыннан хыялыйга әйләнә яза. Мәсәбих та сыгылып төшә. Әле үзләре дә көчкә исән калалар, аларның үзләрен дә подвал куышыннан ярты тәүлек үткәч кенә табып алалар.

Шул җан тетрәткеч хәлләрдән соң балалары тормый башлады аларның, туган бере үлә... Ике Асияләре, бер Зөһрәләре... Дөньяга тутырып карап, матур итеп елмайгач кына, шәм сыман, сүнәләр дә куялар. Әле ярый, Фәридәләре үсте, кул арасына кирәрлек булды. Әле ярый, Рафика ханым тормышын балалар дөньясы белән бәйләгән. Алар язмышы — гүя аның язмышы. Чыннан да, дөнья бит балалар елмаюы белән матур.

Милиция идарәсе каршындагы балалар бүлмәсе исемлегенә теркәлгән яшүсмерне дөрес юлга бастыру, «тамгалылар» исәбеннән чыгару — өлкән лейтенант Рафика Фәрхетдинова өчен зур бәйрәмгә әйләнә. Ә соңыннан, еллар узгач, рәхмәт хатлары эчендә илнең төрле почмакларыннан «кадерле апа», «әни» сүзләре килә башласа, шатлыклары гел арта бара аның. Ул шатлыклар теге чакта, Әлмәт сабан туеннан кайтышлый, Мәсәбих актарып күрсәткән папкага гына сыеп бетәрлек түгел. Бөек КамАЗ төзелешләре адымы белән киләчәккә бара ул шатлыклар.

Рафика ханым кичләрен эштән соңлап, үзе генә кайтып кергән чакларда, кызы Фәридә әнисенә еш кына шелтә белдерә:

— Без әти белән дүрт кешегә җитәрлек аш әзерләгән булдык тагын. Ә син бүген ялгыз гына...

Мәсәбих исә, авызын җыя алмыйча, сүзсез генә елмая, котлетлар көймәгәнме дия-дия, кызына булышып йөри. Милиция формасындагы хатынының эштән ялгыз кайтуын яхшыга юрый ул.

*
* *

Үз таләпләре, үз мәшәкатьләре белән яңа гигант туа. Төнге Чаллы урамында йөрим мин. Төзелеш өстендәге электр нурлары йолдызларга барып тоташкан. Һавада яз исе аңкый. Урамнарда хәрәкәт кими төшкән. Асфальт тротуарларда аяк тавышлары ишетелә: шакы-шокы, чек-чек... Комсомол патрульләре төнге рейдтан кайтып киләләр. Араларында чәчләренә чал керә башлаган бер апа да бар. Алар бүгенге кичнең тынычлыгы, сафлыгы, туачак таңнарның матурлыгы өчен төнге йокыларын калдырып йөриләр. Милиция формасындагы ханымга караңгылык эченнән талчыккан моңсу тавыш белән кемдер сүз куша:

— Апа! Бу — мин...

Адашкан язмыш дәшә аңа. Әйе, балалар бүлмәсенең өлкән тәрбиячесе Рафика Фәрхетдинова кулыннан күп узды алар.

**Ф. Хәбибуллин,**
балта остасы, бетончы.

# ЫШАНЫП АТЛЫЙБЫЗ

Бригадир Виктор Кузьмин эшен бетереп кайтырга җыенганда гына, аның янына икенче сменаның звено җитәкчесе Ибәтулла Шәяхметов килде. Йөгерүдән ул еш-еш сулый иде.

— Витя, лаборант кыз баягы субай скважинасына бетон измәсен салырга рөхсәт итми. Скважина астан ишелә башлаган. Икенчесе дә ишелү алдында, ди!..

Кузьминнын какча йөзе караңгыланып китте. Ул, тынычланырга теләгәндәй, кесәсеннән таушалып беткән сигаретын чыгарып авызына капты. Кабыза алмый интекте.

— Бүген хатынга вакытында кайтырмын дип вәгъдә биргән идем, тагы булмады, кадалгыры! Әйдә, барып карыйк.

Их, син теләгәнчә бетон измәсе белән җитәрлек тәэмин итсеннәр иде лә!

Монтажлаган скважина янында аларны җил иссә сыгылып китәрдәй нечкә билле яшь кенә лаборант кыз көтеп тора иде.

— Я, нәрсә анда? — диде Кузьмин коры гына.

— Әнә, үзең кара.

Кузьмин электр лампочкасын уналты метр җир астына дөм караңгыга төшереп, ишелгән скважинаны тикшерде. Әйе, эшләр шәптән түгел иде.

— Бораулау машинасы белән чистартырга кирәк булыр,— дип куйды Ибәтулла.

— Шулаен шулай да... беләсеңме, бу — скважинадан каркасны кире чыгарып, бораулау машинасын күчереп утырту дигән сүз бит. Күпме вакыт үтәчәк? Аннан соң, икенче ишелә башлаган скважина белән нәрсә эшләргә соң? Юк, Ибәтулла, синеңчә батмый, — дип, бер мәл уйланып торды бригадир.— Тукта, әгәр скважинага бетон измәсе салганчы борау механизмын калдырып торсак, ә? Бик тиз арада субай скважинасын монтажлыйсың да бетон измәсен саласың. Бетон да әрәм булмый.

Кузьмин лаборант кызга күз кысып куйды.

— Бетон измәсе төягән машиналар күренми шул әле,— дип уфтанып алды кызый.

— Әйдә, Ибәтулла, тәвәккәлләп карыйк! Мин телефонга йөгерәм,— диде Кузьмин.

Ләкин телефоннан шалтыратудан да рәт чыкмады.

— Хәзергә бетон булмаячак,— дип җавап бирделәр.
— Ә сез беләсезме?..
— Барысын да беләм. Бөтенегезгә дә бетон кирәк.
Еракта телефон трубкасын куйдылар.
Виктор Кузьминның йөрәген мәче тырнап алгандай булды. Бетон булмаса, бораулаган скважиналар берәм-берәм ишелеп юкка чыгалар лабаса! Күпме вакыт һәм көч әрәмгә китә. Юк, хәзер үк бетон заводына барырга, аңлатырга, исбатларга, таләп итәргә кирәк!
Ул, бетон ташый торган миксерга утырып, бетон заводына китте. Әмма диспетчер монда да алай җәелеп төшәргә ашыкмады.
— Каян алыйм. Бетонны РИЗга җибәрергә диләр бит.
— Минем үземә кирәкми. Скважиналар ишелә, беләсезме, күпме акча җилгә очачак! Зинһар, дим, апакай!
Диспетчер ханым яшь кенә егеткә каш астыннан текәлеп карап торды да:
— Һай бу тынгысыз яшьләрне! Әйдә, уйлашыйк, алайса, берәр әмәлен табарбыз бәлкем,— диде.
...Көне буе аяусыз кыздырган кояш Кама аръягындагы офыкка авыша башлагач, көн бераз сүрелә төште. Бераз җан рәхәтләнеп, күңел иркенәеп киткәндәй булды. Виктор Кузьмин маңгаендагы борчак-борчак тир бөртекләрен сөртте, күкрәге тулганчы иркен сулыш алды.
Кичке кызгылт кояш үзенең алтындай нурлары белән тагын бер мәртәбә двигатель заводының төзелеш мәйданын сирпеп алды да, саубуллашып, иртәнгә чаклы таулар артына кереп югалды.
Виктор Кузьмин, ачыкканлыгын тоеп, сәгатенә карап алды. Вакыт шактый соң, ашханә күптән ябылган иде инде. Ул салмак кына бригада будкасына таба атлады.

*
* *

Чаллыга килгәнче Виктор Кузьмин Ленинград шәһәренең Киров исемендәге заводында югары разрядлы наладчик булып эшли иде. Кама буендагы гигант төзелеш хакында ишеткәч, гүзәл шәһәрне калдырып, комсомол путевкасы белән Чаллыга килде. «Промстрой»-ның яңа гына оештырылган 13 нче төзү-монтаж идарәсенә балта остасы-бетончы булып эшкә урнашты. Бу вакытта бригадада эшләр шәптән түгел иде. План үтәлми, эш хакы түбән, тәртип хакында әйтәсе дә юк. Гаеп бригадирның үзендә иде: оештыру сәләте барлыюклы, әмма иң ачысы — дөньяга төкереп караучылардан булды. Һәм котмәгәндә генә... Эш хакы алганның икенче көнендә бригадир эшкә чыкмады. Бригада егетләре көне буе ятим балалардай әле тегендә, әле монда сугылып, эшләмичә тик йөрделәр.
— Кичә кич белән мин бригадирны күргән идем, лаякыл исерек иде. Йоклап калгандыр,— диде Берәү, шомлы хәбәр җиткереп.
— Күрәсе көннәр бар икән! — дип уфтанды олы яшьтәге Галимулла Шәфигуллин.
«Нинди матур, яңгырсыз көн әрәмгә китә. Кирәк чагында мастеры да килеп чыкмый бит. Нәрсә эшләргә? — дип, Викторның йөрәге әрнеп алды.— Әллә тәвәккәлләп карарга мы?»
— Валера,— дип эндәште ул япь-яшь кенә егеткә,— монтажга керешегез! Ә син, Галимулла абзый, бетонга ябыш, кешеләр ал!
Виктор, әнә шулай бригадирлыкны вакытлыча үз кулына алып, кешеләрне эшкә билгели башлады.
Әмма арадан берәү:

— Син кем соң болай командовать итәргә? — дип, тамак кыргаларга ябышты.

Виктор Кузьмин тавыш килгән якка күз ташлап, тыныч кына:

— Нәкъ синең кебек гап-гади бетончы! — диде.

— Сиңа барыбыздан да артыграк кирәкме әллә? — дип, икенче тавыш аның болай да әрнегән йөрәгенә тагы тоз салды.

— Ә син юкка чыккан бригадирны көне буе көтеп утырыр идеңме? — дип, ярдәмгә ашыкты Шәфигуллин абзый.— Дөрес эшлисең, Витя. Тезгенне ычкындырма!

Виктор Кузьмин бу сүзләрдән соң батыраеп китте. Каршы килүчеләргә карамастан, егетләрне эшкә җигә алды.

Бу вакыйгадан соң берничә көн үткәч, бригадир тагы эшкә чыкмады.

— Исерек башка карап торырга дигәнмени?! Әйдәгез, идарә җитәкчесенә барабыз. Арабызда бригадир итеп куярлык кешебез бар бит! — диде Ибәтулла Шәяхметов.

— Кемне?

— Сорыйсың тагы... Виктор Кузьминны!

Егетләр бердәм җыелып идарә җитәкчесе янына бардылар.

— Үзегез телисез икән, мин каршы түгел, тик җимертеп эшли белегез! — диде идарә җитәкчесе.

Беренче көннәрдә яшь бригадирга бик авырга туры килде. Таркау бригаданы оештыру, хезмәт дисциплинасын ныгыту өчен бик күп көч түгәргә кирәк иде. Беркөнне, сәбәпсез, ике егет эшкә чыкмады. Икенче көнне үк Виктор эштән соң бригаданы җыеп, аларны тикшермәкче булды.

— Я, сөйләгез, ник эшкә чыкмадыгыз? — дип, бригадир егетләргә текәлде.

— Баш төзәттек,— диде Сергей Цилковский, берни дә булмагандай.

— Яшь башыгыздан эчеп йөрү бер дә килешми,— диде Шәфигуллин.

— Эчсә, без кеше акчасын эчмибез лә, үзебезнекен. Бездә ни эшегез бар? — диде икенчесе усал гына.

— Дөрес. Үз акчаларына эчәләр бит! Безнең ни эшебез бар,— диештеләр.

Җыелыш Виктор уйлаганча барып чыкмады. Тәҗрибә аз иде. Ләкин бер атнадан соң бу вакыйга тагын да кабатланды. Виктор Кузьмин алар белән турыдан-туры сөйләште.

— Сезнең кебекләр бригадага кирәкми,— диде ул, сүзен бетереп.

— Кирәкмәсә, без аптырар дисеңмени?! КамАЗда эш бетмәгән! — диде Сергей Цилковский.

Бригадир бу яшь егетләр үзләрен бригадада калдыруны үтенерләр, тәртип бозуны бүтән кабатламаска сүз бирерләр дип уйлаган иде. Ә аларның исләре дә китмәде. Оятсызларча елмаеп, җанны үртәп басып тордылар.

Виктор Кузьмин Сергейлар алдында үзенең көчсезлеген күрде. «Бригадирлык барып чыкмас. Ризалык биреп ялгыштым, ахрысы»,— дип үкенде. «Гади бетончы булганда, ичмасам, ике кулыңа бер эш иде. Хәзер иректе башыңнан ирексез булып утызлап кеше турында кайгырып йөр инде. Әллә гади бетончы гына булып эшләргәме?»

Ул үзенең зарын участок начальнигына сөйләде.

— Бригадирлыктан алыгыз! — диде.

— Беренче авырлыклардан курыктыңмы? Әллә миңа җиңел дип уйлыйсыңмы? Юк, миңа да авыр. Әйдә, бергәләп киңәшик, уйлашыйк. Башка идарәләрдә хезмәткә катнашу коэффициенты кулланалар икән. Виктор, әйдә беренче булып шул эшне кулланып карыйк,—

дип, участок начальнигы моңа чаклы ишетелмәгән нindидер коэффициент турында сүз чыгарды.
Бу көнне участок начальнигы бик күп файдалы киңәшләр бирде. Аның тәкъдиме буенча бригада советы сайлап куйдылар. Баш бирмәүчеләр, тәртип бозучыларны бригада советында тикшерә башладылар. Менә ай азагы килеп җитте. Ничек кенә тырышсалар да, бүтән бригадаларга караганда наряд бик аз ябылды. Һәм хезмәткә катнашу коэффициентын беренче мәртәбә сынап карарга булдылар.

Башта бу билгесез коэффициентка беркем дә зур әһәмият бирмәде. Әйдә, куя бирсеннәр, алдагысын күз күрер, имеш. Аның нәрсә икәнлеге акча алганда гына билгеле булды. Күбесенең кесә яклары югары ган иде.

Акча алганның икенче көнендә эш башланыр алдыннан бригада будкасында гауга купты. Төзүчеләр бер-берсен бүлеп нидер сөйләргә, нидер исбат итәргә тотындылар.

— Ни өчен миңа аз, ә аңа артык? Коэффициентыгыз да, чуртыгыз да кирәкми. Без алай эшләмибез, иртәгә үк китәбез,— диде типсә тимер өзәрлек Әхмәт.

Виктор Кузьмин шауламагыз дигән сыман кулын күтәрде дә, коры гына:

— Ашыгызга карата кашыгыгыз. Моннан соң ничек эшләсәгез, шулай алачаксыз,— диде.

Икенче көнне коэффициентка ризасызлыкларын белдергән төзүчеләр, үз сүзләрендә торып, яңа гына тупланып килгән бригаданы ташлап киттеләр.

Хезмәткә катнашу коэффициентын кулланганнан соң бригадада калган егетләргә ниндидер бер яшертен көч өстәлгәндәй булды. Эшкә соңга калучылар, ялкаулар, хезмәт дисциплинасын бозучылар юкка чыкты.

Икенче ай азагында Виктор Кузьмин «җылылык» трассасының нигезенә салынган бетонның кубометрлар санын хисаплап, башка бригадалар белән чагыштырып карады. Һәм үз-үзенә ышанмады, тагы бер мәртәбә хисаплап алды. Юк, ул ялгышмаган иде. «Промстрой»да беренчелекне яулап алган Мартьянов бригадасын бетон салу буенча унсигез кубометрга узып киткән бит! Менә сиңа кирәксә, әнә нинди икән ул хезмәткә катнашу коэффициенты! Яшь бригадирның какча йөзе иртәнге кояштай балкып китте. Һәм ул бу шатлык турында тиз генә бригада егетләренә җиткерде.

— Кит аннан, булмас...— диде Галимулла Шәфигуллин.

— Болай булгач, акчага капчык әзерләргә туры килә инде,— диде Әхмәт сөенеп.

— Менә сиңа КТУ, эшләтә бит! Уйлап тапкан кешесенә мең рәхмәт төшкере,— диде Галимулла абзый, телен шартлатып.

Көннәр узган саен бригада үсә, ныгый, көч җыя барды. Виктор Кузьмин җитәкләгән коллектив җылылык трассасын сузуда эшләп, көн саен смена заданиеләрен арттырып үтәде, ноябрьга еллык планны үтәп чыкты.

Беркөнне саескан үз койрыгында яңа бер хәбәр алып килде.

— Тиздән безне двигатель заводына ниндидер субайлар белән нигез салырга күчерәләр икән...

— Анда да шул кирәк тә балтадыр инде. Җилкәң генә нык булсын,— диде Салих Хәйбуллин, әлеге хәбәргә һич шаккатмыйча.

— Яңа ысул уйлап тапканнар, ди. Башта җирне бораулыйлар, соңыннан шуңа бетон салалар икән,— дип, Виктор Кузьмин үзенчә ачыклау кертергә ашыкты.

Ә Ибәтулла исә:

— Завод нигезен салу үзе ни тора, егетләр! — дип тел шартлатып алды.

Шушы сөйләнүдән соң берничә көн үткәч, бригада, үзенең кечкенә будкасын трактор белән өстерәп, двигатель заводына күчеп килде.

Айлар буе бертуктаусыз яуган көзге яңгыр төзелеш мәйданын кеше үтә алмаслык пычракка әйләндергән. Эш бик акрын барды. Егетләр тырышып-тырышып эшләсәләр дә, тәүлеккә җиде субай урынына нибары 3—4 субай бетонладылар. Беркөнне планны үтибез дип кенә торганда, бәласе аяк астыннан килде дә чыкты. Бетон көтеп торган арада, измә агыза торган уналты метрлы торба скважина эчендә катып калды.

Бу хәбәрне ишеткәч, Викторның кәефе китте:

— Нәрсә карадыгыз? — диде ул җыелып торган егетләргә.

— Кем белгән аны болай буласын,— дип акланды звено җитәкчесе Салих Хәйбуллин.

— Нәрсә багана кук торасыз? Күтәрү краны кая? — диде Кузьмин усалланып.

— Витя, күтәрү краны белән чыгарырга тырышып караган идек. Булдыра алмый,— дип аңлатты Салих.

— Краныңны монда ку,— дип кычкырды бригадир кранчы егеткә кул изәп.

25 тонналы күтәрү краны озын муенын чайкалдырып, әкрен генә килде дә скважинадан башын күрсәтеп торган нәзек торбага зур корыч ыргагын эләктерде.

— Вира!!! — дип, Виктор төзелеш мәйданын яңгыратып команда бирде.

Юан трослар кылдай тартылып, кранның зур гәүдәсе чайкалып китте. Егетләр кызыксынып бер кырыйга җыелдылар. Кран кинәт туктап калды.

— Бер мәртәбә суыртып карадык бит иде! Арлы-бирле йөртергә кранны такси дип белдеңме әллә?! — дип кычкырды кранчы егет, кабина ишеген ачып.

— Тфү! — диде бригадир һәм кесәсеннән сигаретын чыгарып авызына капты.— Ычкындыр!

Виктор Кузьмин 25 тонналы кранга, егетләргә үртәлеп, үз-үзен кая куярга урын тапмыйча, әле монда, әле тегендә сугылды.

Кинәт ул үзенә эндәшкән тавышка сискәнеп китте, борылып караса, сумаладай кара чәчле башкорт егете Илдус Бакиров басып тора.

— Виктор! — дип кабатлады теге, хафалы кыяфәт белән.— Беләсеңме, бетон юк чакта измә агыза торган торбаны скважинадан ун минут саен чыгарып, кире төшереп торырга кирәк. Минемчә, алай иткәндә торба скважинада катмаячак.

— Вәт, ичмаса, баш! — дип, бригадир аның аркасыннан каккалап алды.

Ул арада мастер, үтеп барышлый гына:

— Кузьмин, идарә җитәкчесе эштән соң бригаданы җыярга кушты,— диде.

«Башланды» дигән уй бригадирның миен ярып узды.

Двигатель заводы төзелешенең бер читендә урнашкан бригада будкасы эштән соң егетләр белән шыгрым тулды.

Җыелышка идарә башлыгы белән бергә комсорг та килде. Әмма алар әлеге катырылган торбага артык бәйләнмәделәр, скважинада кисеп калдырырга куштылар. Менә рәхмәт!..

— Тәҗрибәсезлек хикмәте инде,— дип акланды Виктор.

— Киләсесендә акыллырак булырсыз,— диде идарә җитәкчесе һәм кинәт сүзне икенчегә борды.— Без «Гидропроект» институты хезмәткәрләре белән килешеп, кичке курс ачып җибәрәбез. Эштән соң сезгә укуы бик авырга туры килсә дә, иртәгә барыгыз да дәфтәр, каләм алып килегез. Булдымы?

— Булмаган кая!

Ә комсорг бөтенләй икенче яктан сүз башлады:

— Сезнең бригадага комсомол-яшьләр исеме бирергә булдык. Я, монысына ничек карыйсыз, егетләр?

— Комсомол-яшьләр бригадасы булгач, мине кая куярсыз соң? — дип сорады Галимулла абзый.

Бер мизгелгә тын калган будка эче кинәт кенә җанланып китте, көлешеп алдылар.

— Галимулла ага, синсез бригада ике кулсыз гына түгел, җансыз да калачак бит! — диде арадан берәү.

— Яшьләр белән эшләве үзе ни тора! — диде идарә җитәкчесе, күңелле ым кагып: — Алайса, килештек?!

Җыелыш күңелләрне үстерде үстерүен, әмма субайлар җитештерү эше алга китмәде. Двигатель заводы монтажчылары һаман да боларның үкчәсенә басып баралар иде. Кайсы көннәрдә фундаментлар җитмәү аркасында аларның эшсез утырган вакытлары да булмады түгел. Әлбәттә, таякның авыр башы Виктор җитәкләгән комсомол-яшьләр бригадасына төшә иде. Ә бригадир еш кына идарә җитәкчесе кабинетыннан, январь аеның чатлама суыкларына карамастан, янып-пешеп чыга иде.

Бик хәйләкәрләр дә соң инде бу җитәкче халык: субай да субай дип теңкәгә тиярләр. Аларга таләп итүе җиңел, ә монда теләсәң ничек субай җитештер. Субайларның кирәклеген бригадир үзе дә белә, тик аларның санын ничек кенә арттырырга соң?

Бу хәл бригадирны өзлексез борчып торды. Эштән арып-талып кайткач, кичләрен ул бик озак утырып төрле-төрле графиклар сызгалады. Ләкин берни дә килеп чыкмый иде. Кәгазьләрне ул йомарлап ата торды.

Беркөнне эштән кайтканда, автобусның бозланган тәрәзәсе аша көпчәкле «Кировец» тракторын күрде. Һәм туган заводын, матур һәм җылы цехын күз алдына китерде, сагындырып җибәрде. Автобусның әкрен генә чайкалып баруына күңеленә төрле-төрле уйлар килде. Кинәт кенә аның башында бер фикер туды. Ленинград заводында эшләгән чакта машина җыю конвейеры янынннан еш кына үтә иде. Тукта, тукта, әгәр дә бу линия методын бригадада кулланса, ничегрәк килеп чыгар икән, ә? Бу фикер югалганчы тизрәк кайтып җитәсе, өстәл артына тизрәк утырасы килде. Автобус бик әкрен барган кебек тоелды.

Кайтып җитү белән үк кирәкле схеманы төзеде. Схема бик тә гади килеп чыкты. Бригаданың ике члены, әйтик, күтәрү краны машинисты белән берлектә, әзер скважинага каркаслар төшереп, анда кондуктор һәм озын торбалы бункерлар урнаштыра. Икенче группа бетон кабул итеп тора. Өченчеләре әзер субайлардан кондукторларны салдыру һәм субай башларын җитештерү белән шөгыльләнә...

Икенче көнне Виктор бу хакта бригада советы белән киңәште.

Нәтиҗә озак көттермәде. Январь аенда двигатель заводы мәйданында субайлар бетонлау эше күзгә күренеп яхшыра барды. Һәм ай ахырында көнлек планны үти башладылар. Менә кояшлы февраль аеның беренче көнендә двигатель заводында бик зур вакыйга булды. Бу суык көнне Виктор Кузьмин гадәттәгечә алдагы эшләр турында уйлап килде. Ул килгәндә беренче смена азагына чаклы ярыйсы

гына вакыт булса да, бригаданың кечкенә будкасы төнге смена егетләре белән шыгрым тулы иде. Аларны күрү белән бригадирның иртәнге суыкта кызарган йөзендә көләгә чагылып, кара кашлары җыерылып, күзләре кысылып китте. Монда кырыкка ярылырдай булып, ут йотып йөрисең, ә алар эшләреннән иртә туктап ләчтит сатып утыралар. Ах, ләгыйньнәр!..

Викторның ачуы купты. Ләкин звено җитәкчесе Ибәтулла Шәяхметовның йончыган күзләрендә ниндидер тылсымлы нурларны күреп, ул ачуын тыеп калды, шулай да сүзне коры тотты:

— Ибәтулла, төнге смена ничегрәк үтте?

— Ярыйсы болай, җиде субай бетонладык. Бетон белән тоткарлык булмаса, күбрәк тә булыр иде,— диде Ибәтулла, мыек астыннан гына елмаеп.

Викторның күзләре шар булды:

— Ничә, ничә?..

— Җиде субай! Җиде!

Шундук Кузьминның авызы колагына җитеп ерылды, түбәсе күккә тигәндәй булды. Кара син аларны, бер сменада бригаданың тәүлек заданиесен үтәгәннәр бит!

— Котлыйм, котлыйм! — дип, Виктор Кузьмин егетләрнең каты кулларын кысып чыкты.— Салих, хәзер сезнең звенога сүз.

— Скважина булса, бетон булса, бездән эш тормас,— диде Салих Хәйбуллин, көндезге сменаның звено җитәкчесе.

— Ә сез ник кайтмыйсыз, ник утырасыз? — диде бригадир төнге смена егетләренә.

— Төнлә бер-беребезне юньләп күрә алмадык бит! Бер сөйләшеп утырасы килә әле,— диде Ибәтулла.

Икенче көнне двигатель заводы төзелеше мәйданының үзәк стендына ябыштырылган «Яшен» янында кеше күп җыелган иде. Ул берничә җөмләдән генә тора иде: «Тәүлеккә 7 субай урынына 12 не бетонлаган В. Кузьмин бригадасын тәбриклибез! Молодцы!»

Ләкин Кузьмин җитәкләгән бригада бу рекордта гына тукталып калмады, әзер субайларның саны һәр көн саен арта барды: 12, 16, 22 һәм менә коллективның зур җиңүе — тәүлеккә 28 субай. Бу — тәүлек заданиесен дүрт мәртәбә арттырып үтәү дигән сүз!

...Виктор Кузьмин бригада будкасына килеп җиткәндә, төзелеш кичке эңгер-меңгер кочагына кереп чумган иде. Кинәт кенә көчле прожекторлар кабынып китте.

Икенче җәйне каршы ала бит инде ул! Үткән елны бу завод урынында такыр басу иде. Ә хәзер тирә-якка карадың исә, таң каласың. Ни арада гына биек завод корпуслары калкып чыкты, ә!

Ул бригада будкасына керде. Бригадага күптән түгел генә «Камгэсэнергострой» берләшмәсе бүләк иткән зур радиоланы кабызып җибәрде. Будка эче күңел кылларын тибрәлдерә торган музыка тавышы белән тулды. Виктор утырган килеш йокымсырап киткәнен сизми дә калды.

Бу хәл күпмегә сузылгандыр, ул ишек ачылуга сискәнеп уянып китте. Вакытлы поселоктан төнге смена килеп җиткән икән.

— Виктор, тиз бул, йөгер автобуска! Соңга калуың бар, егетем! Анда хатының белән малаең юлга чыгып, сине көтә калды,— диде Галимулла ага.

Виктор шушы арада гына теле ачылган малаен күз алдына китереп елмаеп куйды. Һәм капыл урыныннан купты...

# ПАБЛО НЕРУДА

*(Тууына 70 ел)*

*Бу шигырьләр — Пабло Неруданың соңгы китабыннан. Ул 1973 елның 11 сентябрь перевороты алдыннан басылып чыга. Заманыбызның бөек шагыйре фашистлар путчы корбаны булды. Әмма аның иҗаты яшь һәм хәрби хунта тиранлыгына каршы көрәшне дәвам иттерә. Азатлык сөючеләр Пабло Неруда шигырьләрен көрәш коралы иттеләр. Аның ялкынлы сүзләре халыкны Чили революциясе дошманнарына каршы көрәшкә чакыра.*

## Мин сиңа эндәшәм

Чилинең баһадир йөзендә юк коллык,
Бабамның тәвәккәл һәм кырыс холкы бар,
Хәсрәтле чорларда чарланган ул холык.

Һәм бүген мин сиңа эндәшәм, сеңелем,
Һәм сиңа эндәшәм, кардәшем — яшь егет:
Ышанмыйм нәфрәткә, ышанмый күңелем.

Бер-берсен суярмы туганнар? — Ышанмыйм.
Ышанам: тик изге көрәшкә берләшеп
Без җиңә алырбыз мәкерен дошманның,

Мәңгелек азатлык яулагач илемә,
Мул иген өлгерер басулар иңендә.

## Яшен белән

Күрче — яшен чатный күкне телеп,
Яшь Лаутаро кыюлыгы кебек.

Кара — безнең ялкын ничек үрли,
Бит Мануэль Родигес үлә белми.

Кире кайтмас халык үткәннәргә:
Бальмаседа безнең белән бергә.

Без җиңәрбез! Хаклы халык эше:
Кулларында яшен уйната ул
Тыныч яшәсен дип җирдә кеше.

Дусларга ул бөтен җанын ача,
Ә чын дуслар безнең миллионнарча!

## Уртак сүзебез

Анд тавында яшен уйный бүген дә,
Диңгез ярын бизәгәннәр ал гөлләр,
Чили, Чили, синең изге күгеңдә

Нурлар чәчеп кызыл йолдыз балкыды,
Төн карасын куды илем өстеннән,
Куды җирдән Арктика салкынын.

Шомлы кара шәүләләрне таратып,
Илгә ирек игълан итте ул йолдыз.
Намуслылар бакты аңа яратып,

Мәшһүр җырчы җырлады үз җырында
Гомерлеккә балкып туган зур бәхет
Һәм мәңгелек чәчәкле яз турында.

Тик ирлеккә, горурлыкка баш иеп,
Дошманыма баш имәгән халкыбыз,
Бәйсез халык нинди мәгърур һәм бөек!

Аның юлы якты да һәм иркен дә.
Үз халкының улы булган беркем дә

Саклаганда палачлардан Ватанын,
Яклаганда сатлыклардан, тираннан
Һич аямас көчен, канын һәм җанын.

Яралардан кан саркылып торса да,
Кире кайтмас корбаннар күп булса да —
Җиңелмәссең, туган илем Чили!

Исла Негра, январь 1973

ЗИННУР НАСИБУЛЛИН тәрҗемәләре.

Максим Глухов

# ЭЗЛӘНҮЛӘР ҖИМЕШЕ

Егерменче еллар азагында Мәскәү һәм башка зур шәһәрләрнең рәссам-графиклары, нәшрият хезмәткәрләре телендә Казимир Эдшмитның «Баскларр, үгезләр, гарәпләр» диган китабы еш кабатлана. Бу китап кибеткә чыгарга да өлгерми, бик тиз сатылып та бетә. Китаплар дөньясында чын-чын сенсация була ул. Моның сәбәбе китапның эчтәлегендә генә түгел, башлыча текстка художестволы аңлатма бирүдә, китапның моңа кадәр күрелмәгән үзенчәлекле график бизәкләрендә була.

Китапны художестволы бизәүдәге бу яңалык кайнар бәхәсләр аша дөньяга килә. «Комсомольская правда» газетасында «Таһировның принципта камил һәм дөрес эше» турында мәкалә басылып чыга [1]. Китап сәнгате белән шөгыльләнүче атаклы белгечләр: профессорлар — В. А. Фаворский, Н. И. Пискарев, М. И. Щелкунов катнашында махсус полиграфия комиссиясе карарыннан соң гына дөнья күрә ул китап. Укучылар да бик тиз бу яңалыкка үзләренең мөнәсәбәтләрен белдерәләр. Мәскәүгә, китапка бизәкләрне эшләгән рәссам адресына илебезнең төрле почмакларыннан, аеруча Казаннан бик күп хатлар килә. Алар барысы да китапны яклап язалар.

Шундый шау-шу тудырган китап бизәкләрен эшләгән рәссамга ул вакытта егерме яшьтән аз гына артыграк була. 1925 елда, рәссамга унсигез яшь вакытта, аның әсәрләре (аерым алганда Г. Кутуйның «Көннәр йөгергәндә» китабының тышлыгы) Парижда үткәрелгән халыкара күргәзмәдә графика сәнгате белгечләре тарафыннан югары бәя ала.

Бу вакытта Фаик Шакирҗан улы Таһиров Казан халкына рәссам-график буларак кына түгел, комсомол активы, бик күп яшьләр кичәләренә, спектакльләргә ясаган декорация авторы буларак та күптән билгеле була инде.

«Баскларр, үгезләр, гарәпләр» китабы чыгып күп тә үтми, Мәскәүдә киң җәмәгатьчелек катнашында Фаик Таһировның икенче хезмәте — инглиз телендәге «Нью-Йорк» диган китапның художество бизәкләре буенча фикер алышу үткәрелә. Бөтен дөньяда танылган плакат рәссамы Моор (Дмитрий Стахиевич Орлов) бу хезмәтне «китап бизәүдә яңалык» дип бәяли. Фикер алышуда оппонент булып шулай ук бөтен дөньяга атаклы рәссам, графика сәнгатенең зур белгече, профессор Владимир Андреевич Фаворский чыгыш ясый.

1931 елда рәсем сәнгате белгече М. П. Сокольников болай дип яза: «Мәскәүлеләр Тилангатер, Сидельников, Таһиров, Елкин һәм башкаларның эшчәнлеге китап бастыруның һәм китапларны эчтәлекнең төп мәгънәсенә ятышлы рәвештә бизәүнең гомуми культурасы нык үсүе турында сөйли» [2].

Әмма тора-бара китапларны бизәү буенча бөтенсоюз күләмендә танылып өлгергән талантлы рәссам Фаик Таһиров бу өлкәдә эшчәнлеген киметә, матбугат басмаларында кулланыла торган хәрефләрне камиллаштерү эшенә керешә.

Утызынчы еллар башында Фаик Таһиров тудырган «Хәреф теориясе һәм практика-

[1] «Комсомольская правда», 5 январь, 1929 ел.

[2] «Журналист», 1931, 2 сан, 20 бит.

сы» курсы хәреф белеменең фән буларак үсешен башлап җибәрә. Типография хәрефләрен булдыру буенча аның хезмәтләре һәм аларны илебез заводларының үзләштерүе кыйммәтле матрицаларны чит илдән сатып алуга чик куя. В. И. Ленин әсәрләренең дүртенче басмасы өчен хәрефләр Фаик Таһиров җитәкчелегендә эшкәртелә.

Китаплар бизәү сәнгатендә чын новатор, яңа хәрефләр тудыру өлкәсендә илебездә иң беренче диярлек фән белгече Ф. Таһиров Мәскәүдә Ленинград проспектында яши. Аның квартирасында беренче күзгә ташланган нәрсә — китаплар. Бик күп китаплар. Озын-озын әллә ничә катлы киштәләр китап белән тулы. Өстәлдә дә китаплар, диван өстендә дә...

Мин күргәндә, Фаик абый белән аның тормыш иптәше Александра Николаевна — сүз уңаенда әйтеп китик, ул да танылган рәссам — китаплар белән мәшгуль иделәр. Аларның тормышын, мөгаен, китапларга мәхәббәт бергә бәйләгәндер дә әле. Миндә ни өчендер шундый фикер калды.

Алар инде җиденче дистәне тутыралар. Шулай да аларга килә торган газета-журналлар арасында «Татарстан яшьләре» дә, «Комсомолец Татарии» да бар.

Казанда үткәрелгән комсомол еллары әле дә хәтерендә Фаик Таһировның. Рәсем сәнгатендә яңа формалар эзләү... Комсомол диспутлары — Ирек мәйданында театрлаштырылган постановкалар. Такташ, аның «Җир уллары» трагедиясе... Славянованың «Париж коммунасы истәлекләре» пьесасы, андагы күренешләр...

Әйе, Казанда үткән яшьлек елларын һич тә онытасы юк аның... Казанга килү белән мена диган егет Гадел Кутуй белән дуслаша ул. Казанга килү белән архитектура-художество институтына укырга керә һәм академик Николай Иванович Фешин лекцияләрен тыңлау бәхетенә ирешә. Казанга килү белән талантлы рәссам-график, татар совет графика сәнгатен башлап җибәрүчеләрнең берсе — комсомолка Александра Коробкова белән таныша.

Казанда өйрәнер нәрсә дә, өйрәтүче остазлар да күп була. Гражданнар сугышы чорында ук анда талантлы гравер, коммунист Николай Сергеевич Шикалов оештырган рәссам-графикларның «Җайдак» исемле җәмгыяте уңышлы эшләр башкара. Бу коллективның бурычын Н. С. Шикалов болай дип билгеләгән: «Хәзерге заман рәссам-графиклары алдында китап гравюрасын чын сәнгать югарылыгына күтәрү, аның үз кануннарын, үз график стилен булдыру мәсьәләсе тора.

Безнең коллектив нәкъ менә шушы стильне эзләү өчен оешты.

Моннан тыш Россиядәге тормышның хә-



Г. Кутуй һәм Ф. Таһиров. 1926 ел.

зерге шартлары бездән җитештерү өлкәсендә киеренке хезмәт таләп итә, без моның белән халык массаларына культура хезмәте күрсәтүдә төрле дәүләт учреждениеләренә ярдәм итәргә тиешбез» [1].

Мәсьәләнең революцион үзгәрешләр чорына тулысынча җавап бирә алырлык итеп куелышы яшь рәссамнарны да ваемсыз калдырмый. Казан художество мәктәбендә тәрбияләнгән рәссамнар, художество мастерскойларында осталыкларын үстерүче яшь талантлар: М. Г. Андреевская, В. Э. Вильковиская, Д. М. Федоров һәм яңа гына Казанга килгән Н. И. Плещинскийлар «Җайдак» тирәсенә туплана. Соңрак 1917 елда ук «Җәберләүчеләр дөньясын без җимерербез» дигән темага монументаль әсәр иҗат итәргә планлаштырган һәм бу әсәрнең бер өлеше буласы «Марсельеза» картинасы эскизларын язган К. К. Чеботарев, А. Г. Платонова, Н. М. Сокольский һ. б. лар «Җайдак»ның членнары булып керәләр.

Китап бизәү өлкәсендә «Җайдак» үзен тиз таныта. Бу чорда ул, мөгаен, «рәссамның иҗат энергиясен тормышны үзгәртеп коруга юнәлдергән... рәссамда артист һәм эшчене берләштерергә омтылган» бердәнбер графиклар коллективы булгандыр. Ә бит рәссамнар аннан-моннан бик кыенлык белән табылган кәгазь кисәкләренә язарга, тиешле күләмдә техник мөмкинлекләр, материал, китап басу җайланмалары җитешмәгән шартларда эшләргә мәҗбүр булалар» [2].

Егерменче еллар башында художество мастерскойларының I курсында рәсем һәм сынлы сәнгать буенча дәресләрне «Җайдак» членнары К. К. Чеботарев һәм А. Г. Платонова, ә югары курсларда П. П. Бенков белән В. К. Тимофеев алып баралар. Алар җитәкчелегендә Казанның яшь рәссамнары нәтиҗәле эзләнүләр аша социалистик реализм сәнгатенең нигез ташларын әзерлиләр.

Фаик Таһиров әнә шул фидакарь рәссамнарның варисы буларак эшкә керешә. һәм шул революцион традицияләрне дәвам иттерүе нәтиҗәсендә китап дөньясында сенсация тудыруга ирешә.

Китап эчтәлеге белән югары идеяле, күрер күзгә матур, кызыклы булырга тиеш. Тышлык, китапның конструкциясе, версткасы, бүлек исемнәренең язылыш формасы, тексттагы аерым урыннарның үзенчәлекле итеп бирелеше — барысы да әсәрнең эчтә-



**Ф. Таһировның тормыш иптәше.**
**Художник А. Н. Коробкова. 1923 ел.**

легенә тәңгәл килеп торсын! Җәмәгатьчелекнең әнә шундый таләпләрен һәр вакыт истә тоткан яшь татар рәссамы Фаик Таһиров үзен, илсбез графиклары арасында иң беренче булып, «китапны бизәүдә партиялелек өчен, югары сәнгать һәм техник сыйфатлар өчен, китапның бизәкчесе-режиссеры булу өчен» көрәш хәрәкәтен башлап җибәрүче итеп таныта.

Ф. Таһиров башлангычына иярүчеләр күп була. һәм бу башлангыч беренче бишьеллыклар чорында сәнгать һәм культура үсешендә зур роль уйный. Ул чорда танылган китап рәссамы В. Н. Елкин Комакадемиядә ясаган чыгышында болай ди: «Без китапның тышлыгын эстетик бизәкләү белән бергә, төп игътибарны, Таһиров өйрәткәнчә, аның текстына юнәлтергә тиеш идек...

Безнең өчен шунысы мөһим иде: бишьеллык дәверендә чыккан брошюраларны җәмәгатьчелек бик җылы кабул итте. Бишьеллык басмаларын бизәп чыгарудагы безнең тәҗрибә башкалар өчен дә үрнәк булды» [3].

Ф. Таһиров шул рәвешчә үзенең иҗат йөзен таба. Бер уйласаң, рәссам өчен тагын нәрсә кирәк инде! Ләкин Таһиров тынгысыз кеше. Ул сызымнар белән шөгыльләнә башлый, язуның генетик нигезләрен өйрәнә, хәрефләр оештырудагы график формаларның (әрмән, корея, борынгы славян һ.б.) үзенчәлекләрен, закончалыкларын тикшерә,

[1] «Җайдак» коллективының беренче графика күргәзмәсе. Казан. 1920. 4 бит.
[2] «Җайдак» альманахы. Казан. 1920. 1 сан. 3 бит.

[3] Пролетар сәнгатьнең үсеш мәсьәләләре, Комакадемиядәге дискуссия материаллары, Рус телендә. Мәскәү, 1931, 135 бит,

эзләнә. Бу яңа эшкә ул тормыш иптәшен, рәссам-график Александра Николаевнаны да тарта. «Азат хатын» журналының беренче саннары Александра Николаевна оформлениесендә эшләнә.

Ирешелгәннәр белән канәгатьләнмәү, яңалык эзләү, бер урында катып калган, мүкләнгән нәрсәне кузгатырга, сафландырырга тырышу сыйфатлары, мөгаен, Фаик Таһировка әтисе Шакирҗан Таһировтан күчкәндер. Ул да заманында танылган кеше булган. Аның исеме татар культурасы тарихында аерым бер сәхифә булып тора.

Шакирҗан Таһиров — татар язуында гарәп фонетик төзелешен куллануга иң беренче башлап шик белдергән зыялыларның берсе. Ул үзенә туган тиешле Каюм Насыйриның мәгърифәт өлкәсендәге барлык прогрессив эшчәнлеген кайнар яклаучы була.

Иң беренче... Беренче башлап... Бу сүзләрне Шакирҗан Таһиров эшчәнлеге турында сөйләгәндә күп кулланырга мөмкин. Әмма иң элек шуны әйтергә кирәк: Шакирҗан ага XIX гасырның сиксәненче елларында ук татарлардан иң беренче Россия художество комиссиясе каршында рәсем укытучысы хокукы алу өчен имтихан бирә. Ә соңрак татар телендә рәсемле әлифба бастырып чыгара.

Әйе, Фаик Таһиров яңа хәрефләр булдыру проблемасы белән юкка гына шөгыльләнмәгән. Нәселдән килгән традиция ул. Әтисе Шакирҗан ага инде онытыла язган каллиграфия фәненә мөрәҗәгать итә. Гарәп язуының генетик нигезләрен өйрәнеп, гомуми закончалыкларны эзли. Хәзер без һәм безнең балалар да Шакирҗан Таһиров эшкәрткән туры язылышлы хәрефләр белән язабыз. Әйе, әйе, нәкъ менә Шакирҗан Таһиров рус генетик алфавитын каллиграфик яктан эшкәртә һәм бу безнең гасыр башында ук иң уңышлы язу үрнәге булып исәпләнә. Россия Мәгариф министрлыгы аны уку йортларында өйрәнү өчен тәкъдим итә.

Гаять зур сәләткә, белемгә (ул немец, төрек, гарәп, фарсы, рус телләрен яхшы белгән, хәтта фарсы телендә геометрия дәреслеге язган) ия булуына карамастан, Шакирҗан Таһиров учительская школа укытучысы дәрәҗәсеннән югары күтәрелә алмаган. Ишле гаиләне туйдыру (аның үндүрт баласы булган), карагруһ дин әһелләре һәм буржуаз милләтчеләр белән даими ызгышу бу талантлы кешенең сәламәтлеген какшата, һәм ул алтмышка да җитмичә



Художник һәм педагог
Шакирҗан Таһиров.

дөнья куя. Ягъни революциядән соң ике ай гына яшәп кала. Әмма Шакирҗан ага балаларында хезмәткә мәхәббәт, яңалыкка омтылу кебек күркәм сыйфатлар тәрбияләргә өлгерә. Күңеле белән ул интернациональ рухлы кеше була. Бу рухны аннан балалары да мирас итеп кабул итәләр. Менә шуңа күрә Шакирҗан ага кызы Зөһрәнең XX гасыр башында ук 4 нче Казан гимназиясендә рус теле укытуы очраклы түгел [1].

[1] Зөһрә Таһирова-Сәлихова шулай ук татар хатын-кызларыннан беренче журналист булып та исәпләнә.

Фаик гаиләдә төпчек малай була. Уника яшеннән үк үз көнен үзе күрә башлый. Моның уңай ягы да була: бик яшьтән эшләп көн күрү, бер урыннан икенче урынга күчеп йөрү аның характерын ныгыта, аңарда кыюлык, үз-үзенә ышаныч тәрбияли. Ул рәссам булырга хыяллана һәм үз дигәненә ирешә.

Фаик язмышы бик күпләр өчен көнләшерлек: татар социалистик культурасының беренче чыганаклары аның исеме белән бәйле. Госман Арсланов, Дмитрий Красильниковлар белән бергә ул татар графика сәнгатенә нигез сала, Гадел Кутуй, Кави Нәҗми, Муса Җәлил, Шамил Усманов кебек татар совет әдәбиятының күренекле вәкилләре белән кулга-кул тотынып эшли.

Егерменче елларда яшәгән сәнгать кешеләренә таң каласың. Аларның эшчәнлеге гаять күп яклы. Мисал өчен Гадел Кутуйның Фаик Таһировка язган бер хатына мөрәҗәгать итик.

«...Син тагын, «сулф»ны [1] уңгарак этәрүче» Кутуй, дип язгансың.

Эш болай тора.

— «Сулф» биел үзен-үзе күрсәтергә тиеш. Безнең өчен «сулф»ның танылган бөтен шәхси көчләре бер уңайдан мәйданга чыгарга — эш бирергә тиешләр. Бу бер. Ишморат [2] театрга алынды. Ул суллык белән сәхнә эшендә тырмашыр. Ә сиңа, Мәскәүдәге яңалыклардан файдаланып, иҗатыңны (рәсем, проектлар, графикалар, башкалар) «Безнең юл», «Яшь эшче» һәм китап тышлары аша булса да... җанландыра барырга кирәк. Ә мин (шулай ук Туфан [3] да) матур әдәбият эченә кереп кайнарга һәм кайнатырга тырышырбыз.

Менә шулар белән бер рәттән Вил Уразай [4] кебекләрне дә уятып, бер җомгакка тупланып, «сулф»ның йөрәк тибүен масса йөрәк тибүенә тоташтырырга кирәк. Моны туктатырлык каршылыклар очрамас шикелле. Б. Симолин [5] кайтты. Бу уңышлы эш. Мине литработадан укытучы итеп театр техникумына алганнар бугай. Димәк, мин Сибарышында үк бәйләнгән — шуңа күрә сулфчыларның Казан активы бер тирәдә диярлек.

Шул!

Журнал! Бу минем бик күптәннән уйлап йөргән азыгым, билгеле, моны хыялдан тормышка күчерергә кирәк. Ләкин ничек? Татгизның хәле авыр. «Гажур» [6] үлеп бара. Такташны да кыскарттылар [7]. Журнал өчен башка якны карарга кирәк. Монысы турында бераз оешкач сөйләшербез.

Тагы бер хәбәр.

Надан яшәп, тормыштан төшеп китәрлек багаж белән көн итеп булмый. Бик күп уйландым. Һәм литлингвистика бүлегенә (Казан) [8] укырга кердем. Беренче курсы минем өчен бик җиңел булачак.

Син белгән яшь язучы Ф. Әсгать [9] авырып ята. Үләр төсле. Ярый, хәзергә хуш. Үзеңә Мәскәүгә язырмын...»

Бу хат 1926 елның 8 сентябрендә Фаик Таһировка Геләнҗик шәһәренә язылган. Ул вакытта ВХУТЭМас (Югары художество-техника мастерское) студенты Фаик Геләнҗиктә иҗади практикада була. Күргәнебезчә, егерменче елларда әдәбият һәм рәсем сәнгате эшлеклеләре «үз кабыклары эченә яшеренеп», үз дөньяларын гына кайгыртмаганнар, зур колач белән фикер йөрткәннәр. Аларны гомуми кешелек язмышлары, илебезнең катлаулы тормышы дулкынландыра, алар үзләрен культура үсеше өчен җаваплы итеп тоялар, белемнәрен үстерү, дөньяга карашларын киңәйтү турында җитди уйланалар.

Әлбәттә, аларның эшчәнлегендә адашулар да булган. Шул үк Кутуй, «суллык» белән мавыгып, кайбер мәсьәләләрдә чамадан уздырып та җибәргәләгән. Әмма без беләбез: эзләнүләр бушка китми, ул әдәбият тарихына кереп калырлык «Тапшырылмаган хатлар» повестен һәм шигырьләр иҗат итә.

Әйе, һәр нәрсәнең сәбәбе һәм нәтиҗәсе бар. Ирешелгәннәр белән канәгать булмау, яңага омтылыш, эзләнүләр кешене кеше, рәссамны рәссам итә.

Фаик Таһиров күңеле белән дә, эшчәнлеге белән дә һаман яшь әле. Соңгы елларда ул Азия, Якын һәм Ерак Көнчыгыш халыклары өчен хәрефләрнең аерым графика формаларын эшләде. Шулай ук әрмән, грузин, корея, һинди, пәнҗәп һәм башка халыклар алфавитлары өчен хәреф рәсемнәрен ул эшкәртте. Фаик абый Таһировның хәзерге эшчәнлеге — егерменче еллардан килгән кайнар омтылышның, җитди эзләнүләрнең дәвамы һәм җимеше ул.

---

[1] Сулф — әдәбиятта һәм сәнгатьтә сул фронт.

[2] Драматург Риза Ишморат.

[3] Шагыйрь Хәсән Туфан.

[4] Вил Уразай — яшь шагыйрь, соңыннан иҗат эшеннән читләшә.

[5] Барис Симолин — язучыларның Казан «леф» оешмасы члены. «Сулф» белән тыгыз бәйләнештә була.

[6] «Гажур» — газета һәм журналлар нәшрияты, ул чорда шактый экономик кыенлыклар кичерә.

[7] Шагыйрь Һади Такташ ул елларда «Азат хатын» журналында җаваплы секретарь булып эшли.

[8] 1926 елның көзендә Г. Кутуй Көнчыгыш педагогия институтына укырга керә. Хәзерге КДПИ.

[9] Фәхри Әсгать (1901—1926 еллар) — талантлы яшь шагыйрь, «Сулф»ның актив членнарыннан берсе.

# СӘНГАТЬКӘ БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

«...Алар икейөзлелек һәм бозыклык белән тулган бай аристократ салоннарыннан түгел, ә бәлки халык арасыннан күтәрелделәр...»

**Мулланур Вахитов.**

*1905 елгы революцион хәрәкәт татар халкының үз профессиональ театрын мәйданга чыгара.*

*Татар театрын тудыру, аны аякка бастыру, әлбәттә, театрга фанатикларча бирелгән, театрдан башка яшәүне күз алдына да китермәгән, аңа хезмәт итүне намус эше итеп караган табигый талантлар исеме белән бәйле. Шундый талантларның берсе — артист Гыйләҗ Казанский.*

*Ул авыр тормыш мәктәбе үтеп, «Сәйяр» труппасының демократик рухлы спектакльләре йогынтысы белән сәхнәгә килә. Уфа, Оренбург һәм Россиянең татарлар яшәгән башка шәһәрләре сәхнәләрендә килешле йөз-кыяфәте, оста уены белән тиз танылып, «Нур» һәм «Ширкәт» труппаларының төп иҗат көчләренең берсенә әверелә. Һәм озакламый бу труппаларда режиссерлык вазифасын да үти башлый. Режиссер буларак, ул труппалар репертуарын заманга аваздаш спектакльләр белән баету, иҗат көчләрен туплау, сәхнә мөмкинлекләрен арттыру эшенә күп көч куя.*

*Гыйләҗ Казанский — татар театрын Фердинанд, Вурм («Мәкер һәм мәхәббәт»), Закир («Бәхетсез егет»), Әхмәтҗан («Уйнаш»), Хәлил («Галиябану»), Исмәгыйль («Сүнгән йолдызлар»), Надиршаһ («Надиршаһ») шикелле кабатланмас образлар белән баеткан үзенчәлекле талант.*

*Гражданнар сугышы чорында Гыйләҗ Казанский беренчеләрдән булып Кызыл Армиянең татар труппасын оештыруда катнаша. Көнчыгыш фронтның легендар 5 нче армия составындагы бу труппа кызыл сугышчыларның политик аңын үстерү, аларда сыйнфый дошманга нәфрәт тәрбияләүдә зур хезмәт күрсәтә һәм үзенең агитспектакльләре, концертлары белән кызылармеецларны аяусыз көрәшкә дәртләндерә.*

*1920 елда Гыйләҗ Казанский Уфада «Үрнәк» труппасын оештыра. Бу труппаны үстерүдә, аны иҗади коллектив итеп ныгытуда да аның роле зур була.*

*1922 елда Башкортстан хөкүмәте Стәрлетамактан Уфага күчкәч, В. Мортазин-Иманский җитәкләгән Башкортстан дәүләт театры да Уфага килә. «Үрнәк» труппасының күп артистлары аңа кушыла. Вәлиулла Мортазин-Иманский театрның директоры булып кала, ә художество җитәкчесе итеп Гыйләҗ Казанский билгеләнә.*

*Гадел Кутуй, 1929 елда татар укучыларын башкорт сәхнә сәнгате белән таныштыру максатын күздә тотып: «Башкорт театрын үстерү, киңәйтү эшенә татар артистлары да күп көч куйдылар; Мортазин, Бохарский, Казанский һәм Зөбәиров иптәшләр аның составында алдынгы урынны алып килделәр һәм хәзер дә шунда эшлиләр»[1],— дип язган иде.*

*Башкортстанда Г. Казанскийны тамашачылар да, артистлар да яраталар, хөрмәт итәләр. 1928 елның 13 апрелендә Башкорт дәүләт труппасы артистларының чираттан тыш үткәрелгән гомуми җыелышы «Гыйләҗ Казанскийның унбиш еллык юбилеен уздыру»[2] турында карар кабул итә һәм юбилей тантанасын шул елның май аена билгели. Юбилей комиссиясе членнары Бәдәр Юсупова[3] һәм Әмин Зөбәиров[4] нәфис сәнгать хезмәткәрләре (Рабис) союзына язган гаризаларында «...сәхнәгә гомерен багышлаган талантлы артист Гыйләҗ Казанскийның күп санлы сәхнә кадрлары*

---

[1] Г. Кутуй. Башкорт театры. Тамашачы. 1929. 4 сан. 9 бит.

[2] Җыелыш протоколы. БАССР Үзәк дәүләт архивы. Фонд Р-504. Опись 1. Саклау бер. 17. 127 бит (Гарәп шрифтында.)

[3] Бәдәр Юсупова (1902—1969) — РСФСРның атказанган, БАССРның халык артисткасы.

[4] Әмин Зөбәиров (1891—1964) — РСФСРның һәм БАССРның халык артисты.

*тәрбияләгән сәләтле педагог»*[1] *булуын искәртеп үтәләр. Шушы гаризага Гыйләҗ Казанскийның автобиографиясе дә теркәлгән.*

*Гыйләҗ Казанскийның автобиографиясен рәсми документ кына итеп карап булмый. Матур әдәби тел белән рус телендә язылган бу язмалар Г. Казанскийның югары интеллектлы, күп яклы сәхнә художнигы булуын раслыйлар.*

*Бу язмалар, бер яктан, Г. Казанскийның нинди авырлыклар белән сәхнәгә килүен күрсәтсәләр, икенче яктан, революциягә кадәрге татар сәхнә интеллигенциясе үткән типик «университет» юлын күз алдына китереп бастыралар.*

*Гыйләҗ Казанскийның язмалары татар театры тарихында моңарчы аз яктыртылган яңа мәгълүматларга бай.*

*«Галия» мәдрәсәсендә Мохтар Мутин катнашында оештырылган спектакльләр, Е. Сыртланованың сәхнәгә килүе, Мохтар Мутин һәм Гыйләҗ Казанскийларның, «Нур» һәм «Ширкәт» труппаларында уйнаганчы ук, үзләренә труппа төзеп, Бөре, Уфа, Оренбург һ. б. шәһәрләрдә гастрольләрдә йөрүләре, Омск каласында татар театр студиясенең эшләве (1919), «Нур» һәм «Ширкәт» труппаларының мөстәкыйль һәм берләшеп эшләү вакытларындагы гастроль маршрутларын күрсәтүе, С. Гыйззәтуллина-Волжская, Н. Сакаев, Камал I, М. Мутин, Ш. Шамильский, М. Мирвәлиева һ. б. артистларның сәхнә биографияләренә яңа мәгълүматлар өстәве белән бу язмалар аеруча әһәмиятле. Язмаларда шулай ук 5 нче армия составындагы татар театры труппасының гражданнар сугышы чорындагы эшчәнлеге дә шактый тулы гәүдәләндерелә.*

*Г. Казанский язмаларында Башкорт театрының оешу чорын яктырткан моментлар, татар-башкорт театр бәйләнешләре юнәлешендә эшләгән Вәлиулла Мортазин-Иманский, башкорт театрының күренекле режиссеры Мәкәрим Мәһәдиев, талантлы артисты Әмин Зөбәировлар турында да әһәмиятле мәгълүматлар бар.*

*Ниһаять, бу язмалар белән танышкач, татар театры тарихында тормышы һәм иҗаты әлегә тиешенчә яктыртылмаган талантлы артист һәм режиссер, сәләтле педагог һәм оештыручы*[2] *Гыйләҗ Казанскийның сәхнә художнигы буларак күп яклы иҗади йөзе ачыларак төшә.*

ФӘҮЗИЯ КАДЫЙРОВА.

# Гыйләҗ Казанский

## Тәрҗемәи хәлем[3]

1891 елда Казан губернасы (хәзерге Татарстан АССР, Арча кантоны) Казан өязе, Яңа Кишет волосте Өчиле авылында ярлы крестьян гаиләсендә туганмын.

12 яшькә җиткәнче Яңа Кырлай авылы башлангыч мәктәбендә, 1902—1903 елларда Казан мәдрәсәсендә укыдым. Әмма үтә ярлы чыгышым аркасында мәдрәсәне ташлап, Казан сәүдәгәре Салих Медведевка хезмәтче булып керергә мәҗбүр булдым. Медведевта һичнинди түләүсез, тамак ялына өч ел хезмәт иттем.

## Медведевтагы тормышым

Элеккеге татар байларының хезмәтчеләрен ничек эксплуатировать итүләре һәркемгә билгеле. Мине дә Медведев аяусыз эксплуатацияләде. Хезмәтчелеккә алганда, Медведев әтигә, улыңны приказчик итәрмен,

---

[1] БАССР Үзәк дәүләт архивы. Фонд Р-504. Опись I. Саклау бер. 17. 123 бит. (Рус телендә.)

[2] Г. Казанский 1931 елда Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында артист, аннан соң Минзәлә колхоз-совхоз театры (хәзерге Минзәлә дәүләт театры)ның режиссеры булып эшли. 1938 елда вафат була.

[3] БАССР Үзәк дәүләт архивы. Фонд Р-504. Опись I. Саклау бер. 17. 131—136 битләр. (Рус телендә).

прилавка артында гына торыр, дигән булса да, әлбәттә, ул аны эшләмәде. Мине һәртөрле пычрак һәм кара эшләргә җикте: ат белән шәһәрнең бер башыннан икенче башына агач, такта тарттыру дисенме, дүртәр потлы капчыкларны җилкәгә салып амбардан кибеткә ташумы, берәр потлы чиләк белән чакрым арага су ташып хуҗаның атларын эчертү, ашатумы, җигү-туарумы, ишегалды, урам чистартумы — болар барысы да көч җитмәслек авыр эшләр булуга карамастан, минем җилкәдә иде. Көчем җитмәсә дә, мин аларны башкарырга тиеш, чөнки карышырга, үтәмәскә минем һичнинди хокукым юк. Хуҗа мине теләсә кайсы вакытта куып чыгара ала. Шуңа күрә, мин ни кушсалар, шуны үтәргә мәҗбүр идем.

Өстәвенә мин артык яшь (бары 14 яшь) һәм иске татар мәдрәсәсендә алган тәрбия мине тыңлаучан, сүзсез кол иткән иде.

Минем эш алар белән генә чикләнми иде әле. Иртәнге 6 дан торып гадәттәге эшләрне башкарып чыккач, мин прилавка артына басып, төнге сәгать 12 гә кадәр сату итәргә тиеш идем. Шулай итеп, әле буыннарым да ныгып җитмәгән килеш, өч ел буенча Медведевка бил бөктем. Бары өч ел шулай эшләгәч кенә, мин хезмәт хакы ала башладым. Авылдан әти килә. Шатлыгы эченә сыймый: ниһаять, аның улы да хезмәт хакы ала башлаячак! Хуҗа әтигә:

— Син бик вакытлы килдең. Улың өч ел миндә хезмәт итте. Яхшы хезмәт итте, тыңлаучан булды. Шуны искә алып һәм алдан сөйләшенгән буенча, дүртенче елда, гәрчә башка байлар хезмәтчеләренә биш ел буе түләмәсәләр дә, мин аңа хезмәт хакы түли башлыйм. Айга өч сум. Елына 36 сум булачак. Әз акча түгел. Улыңнан сора, без аны кыерсытмадык, — ди.

Хуҗа мине атнага өчәр генә тапкыр яңакламаса да, карт әтине кызганып, аның кәефен кырмас өчен: «Юк, җәберләмәделәр», — дип әйтергә мәҗбүрмен.

Шул рәвешле мин Медведевта 1907 елга кадәр хезмәт иттем.

Ул елларны минем кулыма очраклы гына ике китап — төрек теленнән татарчага тәрҗемәләр килеп эләкте. Мәгънәләрен аңламасам да, бу китаплар минем күңелемне биләделәр. Мин аларның һәркайсын унар гына тапкыр укымаганмындыр.

Берчак хуҗа эш белән каядыр китте. Шул бәхеттән файдаланып, мин татар театрына[1] барам һәм аннан моңача һич күрелмәгән яңа дөньяда булу шатлыгын алып кайтам. Шул вакыттан алып минем театрга мөнәсәбәтем битараф була алмады. Моннан соң да мин театрда берничә мәртәбә булдым. «Кызганыч бала», «Хат болгатты» пьесалары куела иде. Бу юлы хуҗа өйдә вакытта, билгеле, аңа сиздермичә бардым. Әмма гауга купты һәм икенче көнне хуҗа мине урамга куып чыгарды.

Күпмедер вакыт авылга әтиләргә кайтып тордым. Әтиләр минем бу хәлемне хуплау гына түгел, киресенчә, мине гаепле санадылар. Әмма аларның әрләвенә карап минем театрны яратуым суынмады. Көтмәгәндә миндә: «Әгәр дә Уфага китсәм?» — дигән фикер туды һәм аны тормышка ашырырга булдым. Өстемдәге актык җиләнемне сатып, юлга билет алдым һәм 1909 елның маенда пароходның дүртенче классында Уфага юнәлдем.

Уфада үземнең Казанда вакытта танышкан белеш кешеләрне эзләп табам һәм алар ярдәме белән хезмәткә урнашырга уйлыйм. Ә хезмәткә ашыгыч рәвештә урнашырга кирәк иде, чөнки мин тукталган танышларым ярлы кешеләр, тамак ялгарлык икмәкне иске резина галошлар ябыштырып табалар. Аларда ике көннән артык торырга һич тә мөмкин түгел иде.

---

[1] Театр — биредә спектакль мәгънәсендә.

Уфага килеп төшкән көнне үк, шул танышларымның күрсәтүе буенча, эш эзли башлыйм. Эш сорап Шәмгунов, Кәримов, Усмановларга[1] мөрәҗәгать итәм. Хәерчегә җил каршы дигәндәй, беркайда да мине эшкә алмыйлар. Өметсезлеккә бирелеп, танышларыма кайтам. Монда мине уйламаган яңалык көтә. Миннән:

— Эшкә урнаштыңмы, урын таптыңмы? — дип сорыйлар. Мин хәлне аңлатам.

— Борчылма, — ди танышым. — Чәй эчик тә минем таныш бакалейщикка барыйк, бәлки ул сине үзенә алыр. Аның кешесе юк бугай.

Чәй эчкәч тә без Казарменный урамында талчукка каршы яшәүче бакалейщик Хәкимов Җамалига киттек.

Танышабыз. Белешем минем кайдан килүемне, кем булуымны сөйли. Хәкимов күп сөйләшеп тормый:

— Миңа кеше кирәкми, әмма, егет ышанычлы булса, алам,— дип ризалык бирә. Ун сум хезмәт хакы, кием үземнеке. Шул шартларга ризалашып, мин Хәкимовта эшли башлыйм. Тырышып, күңел биреп эшлим, шуңа хуҗа миннән канәгать. Салих Медведев кебек җәберләми. Билгеле сәгатьләрдә эшлим, ял да итәм, буш вакытларда кино, театрга йөрүдән дә тыймый.

Тик ел да үтми (минем урнашуга 9 ай үткәч) хуҗа вафат була. Кибет ябыла һәм мин яңадан эшсез калам.

Шуннан мин талчукта мануфактура-галантерея товарлары белән сәүдә иткән Вәлитов Нуретдингә урнашам. Тик монда консерватив карашлы талчукчы кибетчеләр миңа тынгылык бирмиләр.

— Башында фуражка, аягында урыс ботинкалар, пальтосы арттан ерык итәкле. Әллә Иван, әллә Василий,— дип мыскыл итәләр. Янәсе, бу кыяфәтем белән мин мөэмин-мөселманнарның намусына тиям. Шушы фуражка, ботинкалар мине эш ташлап чыгарга мәҗбүр итәләр. Шул хәлдән соң мин катгый рәвештә мөстәкыйль тормыш башлау карарына киләм. Ул вакытка инде мин әзрәк акча да туплаган идем. Шул тупланган акчаны җыеп, бәләкәй генә ит кибете ачам. Сатудан ашауга җитәрлек керем була иде.

Шул чорда мин театрның мәгънәсен һәм әһәмиятен аңлый башладым. «Сәйяр» труппасы Уфага килгән вакытларда мин һәвәскәр булып катнашам.

Шул елларда мин «Галия» мәдрәсәсенең шәкерте Әмин Зөбәиров (хәзер Башкорт дәүләт театры артисты) белән очрашам, аның аркылы «Галия» мәдрәсәсенең башка тыңлаучылары белән дә танышам. Алар белән аралашып, минем фикерем үсә, дөньяга карашым киңәя бара; сәхнәгә якынайган саен якынаям.

Шул чорда алдынгы фикерле приказчиклардан һәм мәдрәсә шәкертләреннән сәхнә сөючеләр оешмасы төзелә. Мин һәм Зөбәиров шул оешмага әгъза булып керәбез. Оешма мәдрәсәләрен ташлап чыккан шәкертләр файдасына «Көнче ир» пьесасын куя. Мин анда хезмәтче ролендә чыгыш ясадым. Аннан соң Мохтар Мутин[2] катнашы белән «Мөгаллимә» пьесасында җаваплы роль — Мәрзыя кызны башкардым.

«Сәйяр» труппасы яңадан Уфага килә. Бу юлы инде мин постановкаларда турыдан-туры катнашам. Аннан соң да «Сәйяр»ның күп спектакльләрендә катнашып, үземнең тормышымны тулысы белән сәхнәгә багышлыйм.

Мин — сәхнәнең турылыклы хезмәтчесе һәм артист-профессионалы.

1911 елда шәхесемә чит булган бәләкәй сату-алу эшләремне бөтенләйгә ташлап, Мутин чакыруы буенча Бирск[3] шәһәренә артист булып

---

[1] Уфада кибет тоткан байлар.

[2] Мохтар Мутин — (1887—1938).

[3] Башкортстанның Бөре каласы.

китәм. Бирелә «Бәхетсез егет» һәм концерт бүлеге белән тагын бер спектакль куела.

Бөре каласында бәхетле очракка тап булабыз. Рус гаиләсеннән Елизавета Шляхтина [1] фамилияле татарча иркен сөйләшүче бер ханым үзенең татар сәхнәсендә уйнау теләге барлыгын белдерә (Шляхтина Елизавета татар сәхнәсендә 1911 елдан уйный, хәзерге вакытта Уфада.)

«Бәхетсез егет» пьесасында ул Җәмилә һәм Гайни рольләрендә уңышлы чыгыш ясады. Мин һәм Мутин аңа безнең белән башка шәһәрләргә чыгарга тәкъдим итәбез. Ул күп уйламый, туган йортын, якыннарын калдырып безгә кушыла һәм шуннан башлап тормышын тулысынча татар сәхнәсенә багышлый.

Шулай итеп, мин, Мутин һәм Лиза ханым (Сыртланова) труппа төзеп, өчәүләп яңадан Уфага кайтабыз. Уфада берничә спектакль куябыз. Сбор [2] юк.

Сәхнә эшчәнлегемнең тәүге көннәрендә миңа авыр вакытлар кичерергә туры килде. Өчәр көн рәттән төшке ашсыз, яки көнгә бер кадак арыш икмәге белән селедка. Аңа карап мин кәефемне төшермәскә тырышам, чөнки татар театры һәм артистларының нинди авыр чор кичергәннәрен ачык аңлыйм. Татар театрының үсеш юлында очраган киртәләр дә, өчәр көн ашамый йөрүләр дә мине ярты юлда туктатып калдыра алмадылар.

## Уфадан Бәләбәйгә

Уфада күпмедер вакыт эшләгәч, без Бәләбәйгә барырга җыена башладык. Безнең белән бергә бер һәвәскәр дә барырга булды. Һәм менә без дүртәүләп килеп төшәбез. Ике спектакль куябыз. Монда да сбор начар. Бары селедкага гына житә. Бәләбәйдән Оренбургка юл алабыз. Поездга билет алгач, безнең Токымбәтов белән икебезгә барлыгы 18 тиен акчабыз калды. Шул акчага без Оренбургка барып житкәнче тамак туйдырырга тиеш идек. Мутин һәм Лиза ханым бездән берничә көнгә алданрак киткәннәр иде. Алар зур кыенлыклар белән генә номерларда бүлмә ала алганнар. Вокзалдан шәһәргә постельләребезне, әйберләребезне аркабызга асып, җәяү бардык. Мутин һәм Лиза ханымны эзләп табабыз һәм номерга урнашабыз. Шул көнне үк спектакль постановкасына әзерләнә башлыйбыз. Оренбург коммерсантлары белән бергәләп берничә спектакль куябыз. Монда инде сбор чагыштырмача ярыйсы булды һәм без кеше башына унар тиен чамасыннан ашханәдә туклануга күчәбез.

Бу вакытта мин урта яшьтәге ирләр һәм карчыклар рольләрен башкара идем (үземнең төп амплуам — «любовник»ларны башкаруга мин бары 1915 елда гына күчтем).

Без Оренбургта вакытта татар театрының беренче артисткасы Сәхипҗамал Волжская тарафыннан оештырылган труппа Ташкенттан кайтып төште. Труппа «Нур» дип атала иде. Аның составында: Сәхипҗамал ханым, Сәмитова, Дулатова, Сакаев, Шамильский, Хәнҗәров, Байгуриннар иде. Алар Оренбургка килү белән ике мөстәкыйль труппа бергә берләшә һәм спектакльләр куя башлыйбыз. Сборлар ярыйсы гына булды. Унбер кешедән торган бу труппа һәйбәт художество көченә ия иде.

Труппа Себергә гастрольгә барырга ниятләнеп, Оренбургтан Бәләбәйгә, аннан Уфага юнәлде. Уфада ике спектакль уйналды. Аның бер постановкасыннан уенда катнашучыларга 12 шәр тиен, икенчесеннән өчәр тиен тиде.

---

[1] Е. А. Сыртланова-Шляхтина (1883—1961). БАССРның атказанган артисткасы, режиссер, педагог.

[2] Сбор — спектакльдән килгән керем.

Өченче спектакль — «Алдым-бирдем» пьесасы әзерләнә. Уфаның карагруһ байларыннан Хәкимовлар губернаторга һәм мөселман диния назаратына мөрәҗәгать итеп, спектакльне куйдырмый калырга тырышалар. Тик алар бу эшкә соң тотыналар. Спектакль канәгатьләнерлек сбор белән хәвеф-хәтәрсез үтеп китә. Шул акчага труппа Чиләбегә юл ала.

Билетка акчабыз җитмәү сәбәпле, миңа һәм тагын берничә иптәшкә вагон сәкесе астында качып барырга туры килде. Чиләбедә ике спектакль куябыз, әмма монда да эшләр «селедкадан» узмый.

Труппа көч-хәл белән Пермь шәһәренә килеп җитә. Монда да әллә ни сбор бирмәгән берничә спектакль. Аннан-моннан юллык акча җыеп, Сарапулга китәбез. Монда хәл бигрәк тә авырлаша. Акчаны номерга түләсәң, билетка калмый, билетка түләсәң — номерга. Шуннан, номерга түләмичә, пароход китәр вакыт җиткәч, сиздермичә генә әйберләребезне алып пристаньга шыларга карар кылабыз һәм шулай эшлибез дә. Номерлар хуҗасы городовойлар белән безнең арттан пристаньга килеп җиткәндә, безнең пароход пристаньнан аерылырга өлгергән иде инде.

Труппа яңадан Пермьгә кайта, аннан Төмәнгә китәбез. Юллык акчаны зур кыенлыклар белән, Сәхипҗамал ханымның костюмнарын ломбардка салып юнәтәбез. Әмма Төмәндә дә безне уңышсызлык көткән.

Юклык талаштыра дип әйтәләр. Юк-бардан низаг чыга һәм труппа икегә аерыла. Мин, Волжская, Шамильский, Дулатова — дүртәүләп, калган әйберләрне ломбардка салабыз да Надеждинский заводына китәбез. Анда яхшы сбор алып, безнең труппа Томск шәһәренә юнәлә. Тик Томск шәһәренең полицмейстеры спектакль куярга рөхсәт бирми. Бу минутта биредә Наурузов тарафыннан Себер газетасы чыгарыла иде. Труппадан берәү Наурузовка мөрәҗәгать итеп, хәлне сөйли һәм киңәш сорый. Наурузов, әгәр дә труппа бер спектакльне нинди дә булса оешма файдасына, ә берне үзебезнең файдага куярга ризалашса, ул полицмейстерны борчып тормыйча, рөхсәт сорап турыдан-туры губернаторның үзенә мөрәҗәгать итәчәгенә ышандыра. Һәм, чынлап та, аның ярдәме белән рөхсәт алынды. Тик шуны да әйтергә кирәк, соңыннан рөхсәтне, сораучының Вәли Наурузов булганы өчен түгел, ә аның провокатор һәм полиция агенты булганы өчен биргәннәре билгеле булды.

Ике спектакльдән соң труппа Чиләбегә кайтты. Әмма монда артистларның җанына тигән мөселман уразасы вакытына туры килдек. Спектакль куярга мөмкин түгел. Ломбардка салырлык яки сатарлык әйбер дә калмаган. Акча юк. Кыен хәлдә калдык. Байларга акча сорап барып, артист горурлыгын түбәнәйтәсебез килми. Ярый әле, бирсәләр. Ә бирмәсәләр? Алар сүзсез генә кире кайтармаячаклар. «Сез, иптәшләр юкка сөйрәләсез. Әйдәгез миңа хезмәткә керегез, менә сезгә айга 15 сум хезмәт хакы. Артисткаларыгызны кияүгә бирербез. Сездән бит кеше көлә һ. б. һ. б.» дип безне рәхәтләнеп мыскыл итәчәкләр. Шуңа күрә без аларга якын да бармыйбыз. Үзебез кебек үк ярлы кешеләр ярдәменә таянабыз. Шул вакытта без көтмәгәндә танышыбыз Бурнаев Гарифны очратабыз. Ул ураза үткәнче үзендә торырга тәкъдим ясый. Шулай итеп, Бурнаев ярдәмендә без кыен хәлдән чыгабыз. Бәйрәмне көтәбез. Ниһаять, бәйрәм җитә һәм без спектакль куябыз. Элеккечә сбор начар. Шулай да күңелебезне төшермибез, эшебезне дәвам итәбез һәм Троицкига юнәләбез. Монда да нәтиҗә шәп түгел, яңадан Чиләбегә юл алабыз. Анда бездән җәй көне аерылып калган Нури Сакаев кушыла. Хәзер инде бишәүләп (җәйлеген яңадан Себергә барып әйләнү нияте белән) кышкы сезонны үткәрергә Оренбургка юнәләбез.

Омскига барышлый Уфага, Чиләбе, Петропавловск шәһәрләренә керә чыгабыз. Омскиның генерал-губернаторына спектакльгә рөхсәт сорап өченче мәртәбә баргач, ул рөхсәт бирмәү генә түгел, өстебезгә аяк тибеп кычкырды һәм, дала халкына агитация ясап йөргән өчен, 24 сәгать вакыт эчендә шәһәрдән юк булмасак, безгә арест салачагын белдерде. Аның фәрманы буенча безне пристаньга городовойлар белән озаттылар. Пароходка бары хатын-кызларга гына билет алып, үзебез билетсыз, капчыклар арасында качып барырга мәҗбүр булдык. Семипалатинскига кадәрле фәкать арыш икмәге һәм кипяток белән туклаunion бардык.

Семипалатинскига килеп җиткәндә безнең кулыбызда 20 тиен акча калган иде. Ә труппада җиде кеше: Сәхипҗамал Волжская, Богданова Зөләйха, Дулатова Фатыйма, Казанский Г., Шамильский, Әлмәшев, Галимов.

Квартира тапканчы, бер тәүлек пристаньда утырдык. Ике бүлмәле квартира табып, барыбыз да шунда төялдек. Монда инде «дала шәһәре, агитация ясыйсыз», дип сукмаделер. Рөхсәт бирделәр. Өч пьеса уйналды. Сборлар да канәгатьләнерлек булды. Артистларның да, ниһаять, тамаклары туйды. (Бу 1914 елның көзе иде.) Гастрольләрне Себернең тагын берничә шәһәрендә дәвам итеп, кышкы сезонга Оренбургка юнәлдек.

Шул көзне мин өченче тапкыр хәрби хезмәткә каралырга дип, туган авылыма кайтам. Хәзерге Татарстан республикасының Арча кантонында хәрби хезмәттән котылу бәхетенә ирешәм. Котылуын да котылдым, тик хәзер ничек Оренбургка барып җитәргә, чөнки бер тиен акча юк. Әтиләрдән акча сорауны башка да китерергә мөмкин түгел. Барыбер бирмәячәкләр. Чөнки минем артист булып йөрүемне хурлыкка саныйлар. Артистлык эшенне ташламасаң, улыбыз итеп санамаячакбыз, дип әйткән чаклары да булды. Алар белән полемика ачуның файдасыз булуын күреп, сүзләрен җавапсыз калдыра киләм. Ә үземдә бары бер генә уй: ничек итеп Оренбургка барып җитәргә? Сәхипҗамал ханымның саубуллашканда әйткән сүзләре хәтергә килә: «Кире Оренбургка килергә акчаң булмаса, хәбәр итәрсең. Юллык табыштырып салырмын», — дигән иде ул. Аңа акча сорап телеграмма бирәм. Ул шунда ук келәмен сатып, миңа 15 сум акча җибәрә. Аны алу белән мин юлга чыгам һәм без янадан Оренбургта эшли башлыйбыз. (Шул елны Шакир Шамильский хәрби хезмәткә алынды.)

Кышкы сезон үтеп китте. Безнең труппа төрле шәһәрләрдә җәйге гастрольләрдә булып яңадан Оренбургка кайтты.

1915 елның ахыры. Шул вакыт Казанда «Сәйяр» труппасында эшләгән Мортазин[1] килә. Аның белән бергә Сыртланова белән Мутин да киләләр. Бергә берләшеп «Ширкәт» («Товарищество») труппасын төзибез.

Шул 12 кешедән торган труппада мәрхүм Мангушев Абдрахман да бар иде.

Труппа сезон ртысына кадәр бергә эшләгәч (тыныша алмау сәбәпле), яңадан ике труппага: «Нур» һәм «Ширкәт»кә аерыла.

Гыйззәтуллина-Волжская, Казанский, Богданова, Аитов Локман, Сюрмәшев һәм тагын бер артистка — алты кеше берләшеп, яңадан «Нур» труппасын аякка бастырабыз. Урта Азия ягына юл алып, Бохара, Чарджуй, Мерв, Оренбург аша Уфага, аннан Пермьгә һәм, ниһаять, Ижевск заводына киләбез.

Ижевскида безне эшчеләр яхшы каршылыйлар, ике спектакльдән

---

[1] Вәлиулла Мортазин-Иманский. «Сәйяр»ның беренче артистларыннан, режиссер, педагог. Башкорт профессиональ театрын оештыручы. БАССРның атказанган артисты.

соң, безне озатканда тагын килүебезне сорап калалар. «Нур» яңадан Уфага кайта. Бу 1917 ел иде.

1918 ел керә. Бу вакытка артистларның материаль хәле әзрәк яхшырган иде инде. Уфалылар матбугат аша труппаның Уфада төпләнүен сорыйлар. Труппа Уфада калырга карар кыла.

Шул чордан бирле труппада режиссер һәм актер булып эшлим. Труппа Уфада...[1] елга кадәр эшли.

1918 елда Уфада сәхнә сәнгате хезмәткәрләре союзы оеша. Мине союз правлениесенә әгъза һәм союзның казначее итеп сайлыйлар.

Труппа членнары җәйге ялга таралалар. Мин ялга Уфадан ерак түгел башкорт авылында калам. Көзен Уфага кайтып, труппаның калган көчләрен җыям һәм унбер кешедән торган труппа төзеп, яңадан эшкә башлыйбыз. Труппада: Казанский, Латыйпов, С. Латыйпова, Богданова, Мирвәлиева, Әминев Гәрәй, Даутов, Нәзип Әбдерәшитов, Мәһәдиев, Гыймранов һәм Гәйшә Әбдерәшитовалар бар иде. Труппаны жалованиедә атнага өч спектакль бирү шарты белән Сәхиев дигән бирәү тота.

1918 елның декабренда Кызыл гаскәрләр кысрыклавы аркасында, аклар Уфаны калдырырга мәҗбүр булалар. Кызыллар тантаналы төстә шәһәргә керделәр. Шул көнне үк труппа кызылармеецлар өчен Кызыл Армиянең шәһәрне алу тантанасына багышлап кичә оештырды.

Кызыл гаскәр тулысы белән шәһәрдә урнашкач, труппаны үз карамагына алуын үтенеп, Бишенче армиянең политотделына мөрәҗәгать итәбез. (Политотделның татар-башкорт бүлегендә ул чагында Баимбәтов иде.) Политотдел риза була һәм без кызылармеецлар һәм эшче массаларга түләүсез хезмәт күрсәтүче труппа булып эшли башлыйбыз.

Безнең труппа Кызыл Армия составында эшли башлаган иң беренче труппаларның берсе иде. Бездән үрнәк алып, рус труппасы да Кызыл Армия составында эшли башлады.

Кызыл Армия оешуга бер ел тулу тантанасын труппа алгы фронт сызыгында, Алатырь шәһәрендә, кызылармеецлар өчен спектакль һәм концерт куеп билгеләп үтте. Фронт сызыгы ике генә чакрымда булган Тау Төмән станциясендә труппа көненә өчәр спектакль куйды. Тау Төмән авылын Колчак бандалары утка тота башладылар. Якында гына снарядлар шартлый. Сугыш кызганнан-кыза бара. Труппа резервтагы частьлар өчен спектакльләр куя. Кызу сугыш уртасыннан безне көтеп торган вагоннарга утырып, яңадан Уфага китәбез.

Күпмедер вакыттан соң Кызыл Армия частьларына аз гына вакытка булса да, Уфаны яңадан калдырырга туры килде. Кызыл Армиянең Уфадан чыккан көнендә дә кызылармеецлар өчен спектакль бара иде. Политотделдан хәбәр килә. Анда безгә ярты сәгать эчендә багажларыбыз белән политотделга килеп җитәргә кушылган иде. Спектакльне туктатып, гриммнарны да сөртеп тормыйча, билгеләнгән урынга киләбез. Кызыл Армия частьлары белән шәһәрне калдырып чыгабыз. Безнең труппадан аерылып, аклар алган шәһәрдә бары берәү генә калды. Калганнарыбыз барыбыз да Кызыл Армия белән Сызраньга кадәр чигендек.

Сызраньда квартираларга урнашып алгач та, труппа пехота полкы өчен берничә спектакль һәм концерт куйды. Кызыл Армия сугышчылары белән мөнәсәбәт иптәшләрчә иде. Бер казаннан ашап, бер солдат кипятогы эчеп, бер тормыш белән яшәдек.

Кызыл гаскәр Колчак бандитларын куа башлады. Штаб белән бергә труппа да Уралга таба кузгалды. Шулай, Кызыл Армия частьлары һәм эшче массалар өчен атнага ике мәртәбә спектакль уйнап, труппа өч айга якын эшләде. Труппа моның белән генә чикләнми. Чи-

[1] Оригиналда елы күрсәтелмәгән.

ләбе тирәсендәге күмер ятмаларында эшләүче шахтерлар өчен дә спектакльләр куйды.

Кызыл Армия Омск шәһәрен алу белән труппа анда юнәлде. Омскига баруы җиңел булмады. 75 чакрым араны 33 көн бардык. Озак баруның сәбәбе: Колчак бандалары чигенгәндә юлларны, водопроводларны шартлата барганнар. Һәр ике станция саен тукталып, паровоз өчен су һәм утын ташырга туры килде. Ничек кенә булмасын, утыз өченче көн дигәндә, ниһаять, Омск шәһәренә килеп җиттек.

Бишенче армиянең политотделы безне һәм рус труппасын Сибнаро[1] карамагына тапшырды. Мин җитәкләгән труппа ел буенча үзенә йөкләтелгән бурычны йөз процентка үтәп килде.

Шул чорда Омскида кыска сроклы театр студиясе оештырылды. Мин һәм Камал I студиянең преподавательләре булып билгеләндек.

1919 елның маенда труппаны Уфага чакырталар. Наробраз (халык мәгарифе бүлеге) соравы буенча, студиядә укулар тәгәлләнгәнче мин Омскида калып тордым.

Студия эшен тәмамлагач, мин Уфага кайттым һәм яңадан труппада режиссер һәм актер булып эшли башладым. Наробраз карамагындагы бу труппада 1920, 21, 22 еллар дәвамында эшләдем.

1922 елның көзендә, Башкортстан республикасының резиденциясе Уфага күчкәч, үземнең барлык иптәшләрем белән ул чагында иптәш Мортазин җитәкләгән Башкорт дәүләт театрында эшли башладым. Анда бер сезон эшләгәч, 1923 елның көзендә, чакыру буенча, Сакаев, Зөбәиров Әмин, Сәмитова, Таждарова һәм тагын берничә артист бергәләп Петропавловск шәһәренә киттек. Биредә бер кыш эшләдек, ә җәй көне гастрольләр белән Омск, Томск, Красноярск, Иркутск шәһәрләрендә булдык. Себернең иң караңгы почмагы — Минусинск шәһәрендә дә булдык. Анда көч-хәл белән яшәп килгән татар клубына аякка басарга ярдәм иттек, драмтүгәрәк оештырдык. Минусинск шәһәрендә татарча бер спектакль уйналды. Моннан башка рус труппасы белән берлектә дә спектакльләр куйдык.

Монда минем материаль хәлем аеруча кыенлашты. Шулай да ай ярым вакыт эчендә татар-башкорт клубының эшен ныклап җайга сала алдым. Мин оештырган театр түгәрәге соңыннан труппа булып китте.

Шуннан беренче пароход белән мин Красноярскига, аннан Иркутск шәһәренә килдем. Анда прискалардан кайтып килүче Лиза ханымны очратып, аның белән берлектә берничә спектакль куйдык. Сборлар начар булу сәбәпле, безнең материаль хәлебез әз генә дә яхшырмады. Шуннан Е. Сыртланова белән бергәләп Свердловск шәһәренә юнәлдек. Юлда, күмер ятмаларындагы шахтерлар булган җирләргә тукталып, берничә спектакль бирдек.

1925 елның көзендә мине Башкортстан республикасы наркомпросы (халык мәгарифе комиссариаты) Башкорт театрына эшкә чакырды. Шул вакыттан алып бүгенгәчә Баштруппада эшлим.

1912 елдан башлап, һәртөрле кыенлыкларга карамыйча, татар театрын тудыру һәм үстерү юлында хезмәт иттем.

Төп эшем — сәхнәдә иҗат итү белән бергә, хәл кадәренчә, иҗтимагый-профессиональ эш тә алып барырга тырыштым.

1927 елның декабрендә сәхнәдән аерылмыйча өзлексез эшләвемә 15 ел тулды.

---

[1] Себер халык мәгарифе бүлеге.

# ӘХМӘД ҮРГӘНҖИ һӘМ АНЫҢ ИКЕ ЧОРДАШЫ

Укучылар хәтерлидер, «Казан утлары» журналының 1972 елгы 6 санында «Сәйф Сараиның яңа әсәрләре» исемле бер мәкалә басылган иде. Сүз анда XIV йөзләрдә яшәгән дүрт шагыйрьнең шигырьләреннән төзелгән «Ядгярнамә» исемле кульъязма җыентык турында бара. Әлеге дүрт шагыйрьнең берсе — урта гасыр төрки-татар әдәбиятының күренекле вәкиле Сәйф Сараи. Аның кульъязмадагы шигъри парчалары һәм «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастаны журнал укучыларына инде таныш. Бу санда без укучыларны әсәрләре «Ядгярнамә»гә теркәлгән тагын өч шагыйрь белән таныштырабыз.

Текстларны хәзерге татар теленә һәм хәзерге графикага күчергәндә беренче публикациядәге («Казан утлары», 1972 ел, 6 сан.) принциплар сакланды.

### ТУГЛЫЙ ХУҖА ХАРӘЗМИ ӘБЙАТЕ

(Туглый Хуҗа Харәзми шигырьләре)

**Гыйшкында бәнем хәстәлегем, солтанимә әйтең,**
**Болбыл тик идәр наләме, бостанимә әйтең.**
**Аглардә күзүм йаше олуг Җәйхунны ташурды,**
**Туфан ичә ил калмасын, субанимә әйтең.**
**Гомрем багына дулды хәзан, вәһ-вәһ, и йаранләр,**
**Вирмәккә шифа гилсен у [л], багбаныма әйтең.**
**Дал итде [1] каддемне һиҗрани җәфасы,**
**Гамь силене йагдырмасын, асманимә әйтең.**
**Туглыйга ирүр татлы шәраб — гыйшкдә газаблар,**
**Монгин эштәй үлсәм, йатуганимә әйтең.**

### ХӘЗЕРГЕ ТЕЛГӘ ТӘРҖЕМӘСЕ:

**Гыйшкында минем хәстәлегем, солтаныма әйтең,**
**Былбыл [моңы] кебек тәэсир итәр тавышы, бакчама әйтең.**
**Елаганда күзем яше олы Җәйхунны [Аму-Дәрьяны] ташытты,**
**Туфан эчендә ил калмасын, идарәчемә әйтең.**
**Гомрем бакчасына тулды көз, кайгы, и дуслар!**
**Шифа бирергә килсен ул, бакчачыма әйтең.**
**Бөкрәйтте гәүдәмне аерылышу җәфасы,**
**Кайгы яңгырын яудырмасын, күгемә әйтең.**
**Туглыйга булыр татлы шәраб — гыйшыктагы газаплар,**
**Мондый эштән үлсәм, йатуганыма [көйчемә!] әйтең.**

---

[1] Дал итде — бөкрәйтте. Гарәп язуындагы «дал» (>) хәрефе күздә тотыла.

## МӘҮЛАНА ИСХАК ХАРӘЗМИ ӘБЙАТЕ

(Мәүлана Исхак Харәзми шигырьләре)

Севгелем бакмый бәңа гамьләрне тазә килтерүр,
Севмәгай диб дөн-гөне һиҗран агазә килтерүр.
Дуд(е) аһымдин карайды йагдулы гөлләр йөзе,
Дөнләрем фәүт итмәгә һәр ан тәказа килтерүр.
Тухтамай гәр әйләнәдүр аһу зарымдин фәләк,
Шул сәбәбдин күк үзә рәддләрне йаза килтерүр.
Нә йазук, рәхим әйләмәй ул, бирәхем җәллад тик,
Тиге мөжгане билә катилемгә җәза килтерүр.
Әйтең: Исхак хакъ улуб, пайында йатгай аһ орыб,
Гилсә гилсен, гилмәсә, тәкъдир җәназа килтерүр.

### ТӘРҖЕМӘСЕ:

Сөйгәнем бакмыйча миңа хәсрәтләр тагын китерер,
Сөйми дип көне-төне аерылышу башлануга китерер.
Аһымның төтененнән каралды
якты гөлләр йөзе,
Төннәремне юк итәргә (киметергә) һәр мизгел ихтыяҗ китерер.
Туктамый гел әйләнәдер аһ вә зарымнан фәләк,
Шул сәбәпле күк үзгә хилафлыкларны янә китерер,
Ни язык!! Рәхим кылмый ул, рәхимсез җәллад кебек,
Үткен керфекләре белән катыйлемә җәза китерер.
Әйтегез: Исхак туфрак булып, аяк астында ята аһ орып,
Килсә килсен, килмәсә, тәкъдир җеназа китерер.

## МӘҮЛАНА ӘХМӘД ҮРГӘНҖИ ӘБЙАТЕ

(Мәүлана Әхмәд Үргәнҗи шигырьләре)

И җаным, бел: кичәр дөнйаи фани,
Йитәр, бәс кыл бәңа имди җәфаны.
Үзең остад булыб бу киң җәһанда,
Бәри хубләргә ургатгел вәфаны.
Күңелләрне йәшәтсен игү атың,
Хәзансез хөсн теләб айләй доганы.
Гомер багында синсез миңә мөшкел,
Кувай йулыңдә булган һәр бәлане.
Гилсәң булгай сийаһ көллиям мөнәввәр,
Кыйлурсән падишаһ Әхмәд гиданы.

### ТӘРҖЕМӘСЕ:

И җаным, бел: кичәр дөнья (ул) фани,
Җитәр, туктат миңа дигән җәфаны.
Үзең остаз булып бу киң җиһанда,
Иң яхшыларга (гына) өйрәт тугрылыкны.
Күңелләрне яшәтсен изге атың,
Көзсез матурлык теләп әйт (!) доганы.
Гомер бакчасында синсез миңа кыен,
Куала (качыр) юлыңда булган һәр бәлане.
(Син) килсәң, караңгы дөньям булыр нурлы,
Кыйлырсың (син) патша Әхмәд гидайны (фәкыйрьне).

## ОШБУ ӘБЙАТ ЖИҺАНГИР ТИМУРЛӘНГГӘ ЙАЗЫЛМЫШ ИРДЕ

(Бу шигъри юллар җиһангир Тимерләнгкә багышлап язылган иде)

И залим вә канхур, вә тәмуг ут йакары, бибаш,
Таки акади Җәйхун илә Сәйхун түлә күз йаш!!
Үрладе күккә аһу фәган, илгә килде каза,
Белгел ки, килмайин калмәс илдин сиңа һәм җәза.
Куйләрә килгән корт очрар чупан тәйагынә,
Кем кутарсә агир таш, төшер үзене айагынә.
Үргәнҗә иктүрсәң арфә, үсүб солым чыкади,
Һәр башакның данидин сиңа үлем чыкади.
Зәһәр салган ашымызә ахыр үзе эчәди,
Кара туфраг үзә үз[е]гә кара кәфен бичәди.
Әхмәд аһын тыңлаб алла сине тәмуга салур,
Дөнйада безә дустлык, гадаләт шаһы калур.

### ТӘРҖЕМӘСЕ:

И залим һәм кан эчүче вә тәмуг утына
ягасы [нәрсә], башсыз,
Кайчанга кадәр агар Аму-Дәрья белән Сыр-Дәрья тулы күз яше!!
Үрләде күккә аһ-зар, илгә килде каза,
Белгел ки, килми калмас илдән сиңа һәм җәза.
Куйга дип килгән бүре очрар көтүче таягына,
Кем күтәрсә авыр таш, төшәр үзенең аягына.
Үргәнечкә иктерсәң арпа, шытып иген [!] чыгар,
Һәр башакның бөртегеннән сиңа үлем чыгар.
Агу салган [салучы] ашыбызга ахыр үзе эчәр,
Кара туфрак өстендә үзенә кара кәфен кисәр.
Әхмәд аһын тыңлап, алла сине тәмугка салыр,
Дөньяда безгә дуслык, гаделлек шаһы калыр.

*
* *

Хәйатны севгүче күзсез адәм мин,
Вәли гамь утидә һушсыз адәм мин.
Фәкать гушемдә йуксулләр фәгане,
Күренмас золым, вәхшәтнең туганы.
Күренмас булганигә күңел хушдыр,
Хәйат [и]мәс, бу хәйат куркулы төшдүр.
Гадаләт төхмын изгән зураванләр
Талар илне, түкүб биһүдә канләр.
Качан тынычлык гөле йортга сачилгай,
Шу[л]дәм Әхмәднең дә күзе ачилгай.

### ТӘРҖЕМӘСЕ:

Тормышны [тереклекне] сөюче күзсез адәм мин,
Ләкин гамь утында һушсыз адәм мин.
Колагымда фәкать юксыллар аһ-зары,
Күренмәс золым-вәхшәтнең туганы.
Күренмәс булганга күңел хуштыр,
Хәят түгел, бу хәят — куркыныч төштер.

Гаделлек орлыгын изгән залимнәр
Талар илне, түгеп гаепсезгә каннар.
Кайчан тынычлык гөле илгә чәчелер,
Шул чак Әхмәднең дә күзе ачылыр.

*
* *

Бу шагыйрьләрдән Мәүлана Исхак һәм Туглый Хуҗа исемнәре безгә Голландиянең Лейден университеты китапханәсендә саклана торган «Гөлстан бит-төрки» исемле кульязма китап буенча электән таныш иде. Анда аларның һәр икесенең берәр газәле урнаштырылган. Инде менә «Ядгярнамә» исемле кульязмада бу авторларның тагын берәр газәле сакланып калган.

Игътибар иткәнсездер, авторлар, шигъри сүз белән оста эш итеп, классик газәл жанрының матур үрнәкләрен тудырып калдырганнар. һәр ике шигырьдә дә көчле мәхәббәт хисләре, сөю газаплары турында сүз бара. Куе буяулар, оригиналь чагыштырулар ярдәмендә, алар мәхәббәтнең олылыгын һәм бөеклеген сурәтли алганнар.

Мәүлана Исхак та, Туглый Хуҗа Харәзми дә — XIV йөз Алтын Урда әдәбияты вәкилләре. Шигырьләренең тел-стиль үзенчәлекләре, авторларның тәхәллүсләре (псевдонимнары) шул хакта сөйли.

Кульязмадагы өченче шагыйрь — Мәүлана Әхмәд Үргәнҗи — моңа кадәр фәндә мәгълүм кеше түгел иде. «Ядгярнамә»дә аның берьюлы өч шигыре урын алган. Ул шигырьләр Әхмәд Үргәнҗинең алдынгы карашлы фикер иясе һәм көчле шагыйрь булуы турында сөйлиләр. Газәлендә ул олы мәхәббәт хисләренә дан җырлый, тугрылыкны алга сөрә.

Шагыйрьнең Аксак Тимер исән чакта ук аның ерткычлыкларын фаш итеп сатира язуы зур батырлык һәм фидакарьлек дип бәяләнергә тиеш. Үткен троплар, оста кулланылган халык тәгъбирләре, ярсулы интонация ярдәмендә ул тиран политикасының асылын, җәмгыять өчен гайре табигый күренеш булуын күрсәтә алган. «Тимер политикасы хатын-кызларны, бала-чагаларны, ир-атларны, үсмерләрне меңәрләп-меңәрләп җәзалаудан, суюдан һәм кырудан гыйбарәт»[1],— дигән иде К. Маркс. Аксак Тимергә бирелгән бу тарихи бәя белән Әхмәд Үргәнҗи шигыреннән чыга торган идеянең аваздаш булуы күп нәрсә турында сөйли. Шул кадәресен дә билгеләп үтәргә кирәк: Сәйф Сараи, Әхмәд Үргәнҗиләр тарафыннан күтәрелгән бу мотив алардан соңгы Идел буе төрки-татар әдәбиятында да уңышлы дәвам иттерелде. (Мәсәлән, Мөхәммәд Әминнең «Гыйкаб» шигыре.)

Әхмәд Үргәнҗинең «Хәйатны...» дип башланган мәснәвие иҗтимагый-социаль характерда булуы белән аерылып тора. Андагы лирик герой тормыштагы гаделсезлекләрне, залимнәрнең башбаштаклыгын күреп борчыла, «юксылларның аһ-зары» аның күңелен телгәли. Шул чор тормышының «куркулы төш» кебек булуына да карамастан, шагыйрь илдә «тынычлык гөле» үсәчәгенә, гаделлек тантана итәчәгенә ышана.

Шигырьләрендәге аерым детальләр билгеле бер дәрәҗәдә әдипнең шәхесен һәм иҗат биографиясен дә ачыкларга мөмкинлек бирәләр. Соңгы мәснәвиендә ул, мәсәлән, үзенең «күзсез» булуын телгә ала. Дөрес, бу сүзнең шигырьдә күчерелмә мәгънәдә кулланылган булуы да ихтимал. Әмма газәлендәге «сийаһ көллийам» тәгъбире дә шагыйрьнең караңгы дөньясына ишарә ясагач, Әхмәд Үргәнҗи сукыр шагыйрь булган дип әйтергә мөмкинлек туа.

Әдипнең Аксак Тимергә багышлап язылган сатирасында Үргәнечтә арпа иктерү телгә алына. Тарихи чыганакларга караганда (Шәрәфеддин Язди һәм башкаларның хезмәтләре), Аксак Тимер 1388 елгы бишенче походы вакытында Үргәнеч шәһәрен җимертергә, андагы халыкны Сәмәркандка күчерергә һәм кала урынына «арпа чәчәргә» боера. Приказ өлешчә үтәлә, әмма өч елдан соң әмир, төрле сәбәпләр аркасында, бу эшне туктатырга мәҗбүр була. Димәк, шигырьдәге «арпа иктерү» детале-

[1] Архив Маркса и Энгельса. Рус телендә. VI том. Мәскәү. 1939 ел. 185 бит.

нең реаль нигезе бар. Һәм мәснәвинең бөтен рухы аның 80 еллар азагында, 90 еллар башында иҗат ителүенә ишарә ясый.

Әхмәд Үргәнҗинең әдәби псевдонимы[1] аның Үргәнеч шәһәре белән бәйләнешле кеше булуын күрсәтә. Ул, каян да булса килеп, я шунда укыган һәм иҗат иткән, яисә шунда туып, шунда яшәгән.

XIV йөзнең соңгы чирегендә Алтын Урданың төп әдәби-гыйльми көчләре, илдәге ызгыш-сугышлардан туеп, Мисыр-Сүриягә күчеп китә. Сәйф Сараи (1396 елда үлә), Рукн-эд-Дин әл-Кырыми (1382 елда үлә), Мәхмүд Сараи (1374 елда вафат була) һ. б. үз эшчәнлекләренең соңгы дәверен мәмлүкләр илендә уздыралар.

Әхмәд Үргәнҗи, Туглый Хуҗа һәм Мәүлана Исхак Харәзмиләрнең дә 80 елларда Мисыр-Сүриядә яшәгән булулары ихтимал. Бу өч шагыйрь Сәйф Сараи белән бәйләнештә торган булырга тиешләр. Чөнки аларның әсәрләре Мисырда төзелгән бер үк җыентыкларда сакланып калган. Аннан соң, Сәйф Сараи аларның икесенә нәзыйрә яза. «Гөлстан бит-төрки» әсәрендә дә ул Мәүлана Исхак исемен телгә алып китә[2]. Шулай ук бу әдипләрнең әсәрләрендә тел-стиль, идея-тематик яктан да уртаклыклар күчле. Боларның һәммәсе дә әлеге шагыйрьләрнең Мисырда яшәүләренә һәм үзара тыгыз мөнәсәбәттә торуларына яктылык сирпи.

Җыйнап әйткәндә, Мәүлана Әхмәд Үргәнҗи, Мәүлана Исхак, Туглый Хуҗа — Алтын Урда чоры төрки әдәбиятының күренекле әдипләре[3]. Аларның исемнәре һәм хис-кичерешләргә бай нәфис газәлләре, реалистик эчтәлекле, публицистик рухлы мәснәвиләре әдәбиятыбызның тарихына кертелергә һәм анда үзләренә лаеклы урынны алырга тиеш.

**ХАТИП МИННЕГУЛОВ,**
**Казан дәүләт университеты укытучысы.**

---

[1] Алтын Урда чоры әдип-галимнәренең төп өлеше Сараи, Харәзми, Кырыми, Болгари тәхәллүсләрен йөрткән. Ә инде Үргәнҗи кушаматы бик сирәк очрый.

[2] Бер хикәятенең соңында (200—201 битләр) Сәйф Сараи түбәндәге юлларны яза:
«...бер мәсәл Хуҗа Исхак Харәзмидән йад тутармән...
Төшеб бер көн атиндан бу мәсәлне
Бәдиһә (ягъни экспромт белән — Х. М.) назм итте Хуҗа Исхак:
Җиһан севгән кешенең күзләренә
Канәгать тулдырур йа үлсә тупрак».

[3] Аларның «Мәүлана» атамаларына ия булулары да очраклы күренеш түгел. Әүвәл бу титул Җәләледдин Руми (1207—1273) һәм аның иярченнәренә генә бирелгән булса, бераздан инде ул башка күренекле әдип-галимнәрнең атамаларына да әверелә. Дәүләтшаһ тәзкирәсендә (антологиясендә) китерелгән күп кенә шагыйрьләр, мәсәлән, «мәүлана» титулына ия.

**Галия Кайбицкая,**
Татарстанның халык артисткасы

# ИЛЬЯС ӘҮХӘДИЕВ — МУЗЫКАНТ

Егерменче еллар ахырында һәм утызынчы еллар башында атаклы драматургларыбыз Кәрим Тинчурин, Таҗи Гыйззәт, Фәтхи Бурнаш, Мирхәйдәр Фәйзиләрнең музыкаль пьесалары Татар дәүләт академия театры репертуарында даими урын алып килде. Ул әсәрләрнең тамашачылар тарафыннан шулай яратып каралуына Салих Сәйдәшевнең талантлы музыкасы да бик нык ярдәм итте.

Драматург, композитор һәм актерларның үзара иҗади дуслыгы нәтиҗәсе булган бу уңышлар театр һәм музыка сәнгатебез үсешендә бөтен бер дәверне тәшкил итә. «Зәңгәр шәл», «Наемщик», «Ил», «Яшь йөрәкләр», «Сүнгән йолдызлар», «Галиябану», «Кандыр буе» пьесаларының премьералары республика күләмендәге зур иҗтимагый вакыйгага әйләнә торган иде. Чөнки ул спектакльләрнең эчтәлекләре дә, музыкалары да чор һәм тамашачыларның рухи таләпләренә аваздаш иде. Актерлар рольләрне заманча оста башкаралар һәм тамашачылар арасында бик популяр иделәр.

Театр коллективы ул елларда зур күтәренкелек белән, бик тырышып эшләде. Иртән театрда — репетиция, кичен — спектакль; шул арада музыкаль партияләрне үзлегеңнән өйрәнеп өлгерергә дә кирәк. Мин үзем, мәсәлән, театрда эшләү белән беррәттән, театр һәм музыка техникумнарында да укый идем. Ләкин без, эш һәм уку белән мавыгып, ул авырлыкларны бөтенләй сизми дә идек.

Салих Сәйдәшевнең үзе язган әсәрләрне җиренә җиткереп, күңеленә ошаганча башкара алырлык оркестр оештыру өчен тырышып йөрүе һәм шул теләгенә ирешә алмаганга борчылуы әле дә исемдә. Шул теләгеннән ул соңыннан да кире кайтмады. Аның тырышлыгы нәтиҗәсендә, ниһаять, театрның оркестрантлары үндүрт кешегә җиткерелде. Салихның шул хәлгә куанып, канатланып йөрүләрен күрсәгез иде сез!..

Театрның оркестр составы тулылану җырчылар өчен дә куанычлы хәл иде, әлбәттә. Чөнки җырчының уңышы ул җырлый торган көйне музыкантларның ничек башкаруына да бәйләнгән бит.

1931 елгы театр сезоны башында оркестрыбызга Ленинград консерваториясен тәмамлаган яшь скрипкачы кайтуы турындагы хәбәрне без, җырчылар, бик кызыксынып кабул иттек. Ул көннәрдә Кәрим Тинчуринның музыкаль пьесасына репетиция бара иде. Чираттагы бер репетиция башланыр алдыннан, Гөлсем ариясенең характеры һәм аны башкару темпы турында Сәйдәшев белән килешеп кую өчен оркестрантлар чокыры буена килгән идем, Салих мине әле беренче мәртәбә пультка утырган яңа скрипкачы белән таныштырды. Зама-

нына күрә әйбәт кенә киенгән, коңгырт-кара күзле, акыллы караш-лы, яшь кенә булса да, инде чәчләре сирәгәя башлаган текә маңгай-лы ул кеше Ильяс Әүхәдиев иде. Аның кыяфәтеннән культуралы, белемле кешеләргә хас тыйнаклык һәм гадилек сизелә иде. Шул очрашу соңыннан безнең утыз җиде елга сузылган зур шәхси дуслы-гыбызның башы булды. Бу истәлек-язмамда мин Ильяс Әүхәдиевнең тормышы һәм иҗаты хакында сүз алып бармакчы булам.

Ильяс Әүхәдиев Әтнә районының Кече Шәше авылында дөньяга килә. Кечкенәдән үк музыкага гашыйк була. Ильясның әтисе Ваккас агай Яушев дигән байга эшкә ялланып, 1908 елны Ташкентка күчеп китә һәм шунда баргач улы Ильяска гармун алып бирә. Шул көннән алып Ильясның хыялы тормышка аша башлый: ул башта гармун уйнарга өйрәнә, аннары үзе дә көй чыгару белән мавыга. Тагын шунысын да әйтеп үтим, бәләкәй Ильясның гармун белән «җенлә-нүенә» әти-әнисе дә каршы килмиләр. Чөнки алар үзләре дә җырлар-га ярата торган моңлы кешеләр була. Әнисе хәтта гармунда үзе уйнап, үзе җырлый да торган була.

Шулай итеп, Ильяс музыкаль фольклорны ана сөте белән үк үз-ләштереп үсә. Аның музыкага һәвәслеге көннән-көн арта бара һәм ул, скрипкада уйнарга өйрәнү өчен, 1918 елда Чимкент шәһәрендәге музыка училищесына укырга керә. Шунда бераз укыгач, Ташкентка күчә һәм училищены шунда тәмам итә. Аннары Ленинградка бара һәм анда бернинди конкурссыз Римский-Корсаков исемендәге кон-серваториягә кабул ителә һәм, консерваториянең оркестр факульте-тын тәмамлап, инде әйткәнемчә, Казанга эшкә кайта.

Ул елларда Ленинградта Ленинград консерваториясенең ректоры булып эшләгән бөек рус композиторы Александр Константинович Глазунов студент Ильясны аеруча нык ярата. Аның ярдәме белән Ильяс башта консерватория оркестрының репетицияләренә йөрергә рөхсәт ала, ә аннары шул оркестрда үзе дә уйный башлый. Алек-сандр Константинович Әүхәдиевкә музыкант буларак зур өмет баглый. Бер вакыт Ильяс имтихан бирү өчен уйнаганда тыңлап торганнан соң Александр Константинович аңа:

— Син, татар малае, әйбәт уйныйсың, музыкант булырсың! — ди.

Бөек композитор Глазунов җитәкчелегендә уку һәм эшләүнең үзе өчен чиксез зур бәхет икәнлеген Ильяс бик яхшы аңлый һәм заманында Римский-Корсаковның укучысы булган Александр Кон-стантиновичның дәресләрен чын күңеленнән бирелеп үзләштерә, рус композиторларының һәм дирижерларының традицияләрен өйрәнә. Әнә шул вакытта аның күңелендә симфоник музыкага карата сүн-мәс мәхәббәт уяна да инде.

Казанга кайткач Ильяс, музыка техникумында укыту белән бергә, Татар академия театрында оркестрант булып та эшли баш-лады. Александр Константинович җитәкчелегендә алган тәҗрибәсен эштә куллану нияте белән, ул Казанда симфоник оркестр оештыруны максат итеп куйды. Шул максатын гамәлгә ашыру өчен, үзе укыта торган училищеда укучылар көче белән симфоник концертлар бирә башлады һәм шул эшен тормышының соңгы көннәренә кадәр дәвам иттерде.

Халык артисты, сизгер һәм кешелекле педагог, зур җәмәгать эшлеклесе, коммунист Ильяс Ваккас улы Әүхәдиевнең тормышы Совет Татарстанының музыка культурасы үсеше белән бик тыгыз үре-леп барды. Ул музыка культурабызның төрле өлкәләрендә сизелер-лек эз калдырды: дирижер, педагог һәм оста оештыручы буларак, татар опера сәнгатен үстерүгә, симфоник музыканы халык арасында пропагандалауга һәм музыка кадрларын тәрбияләүгә зур өлеш кертте. Ильяс шул кадәр күп һәм фундаменталь эшләр эшләп кал-

дырган ки, без — аның белән озак еллар бергә эшләгән якыннары һәм дуслары — хәзер, инде менә ул безнең арадан киткәч, хәйран калып, үз-үзебезгә сорау бирәбез: ул эшләрне бер кеше ничек башкарып чыга алды икән?

Казанга кайтып эшли башлау белән ул концерт эшчәнлеген җәелдереп җибәрде. Рус һәм Көнбатыш Европа классикларының, татар совет композиторларының симфоник музыкаларын пропагандалап, тиз арада беренче симфонияче татар дирижеры булып танылды.

1964 елда ТАССР Верховный Советы исемендәге Казан музыка училищесы Ильяс Әүхәдиевнең 60 еллыгын үткәрде. Шул алтмыш елның утыз җиде елын ул училище белән җитәкчелек итте һәм күп санлы музыка кадрларын әзерләп чыгаруда турыдан-туры катнашты. Аның җитәкчелегендәге училищеда укып чыккан күп кенә кешеләр соңыннан атаклы композиторлар булып киттеләр. Салих Сәйдәшев, Нәҗип Җиһанов, Мансур Мозаффаров, Александр Ключарев — барысы да заманында шул училищеда укыган иптәшләр. Күренекле композиторларыбыздан Фәрит Яруллин, Заһид Хәбибуллин, Рөстәм Яхин, Әнвәр Бакиров, Хөснул Вәлиуллиннар да утызынчы елларда шул ук Казан музыка училищесында тәрбия алдылар. Җырчыларыбыздан Мөнирә Булатова, Зөләйха Хисмәтуллина, Рәйсә Билялова — шулай ук әлеге училищеда укып чыктылар. Казан музыка училищесын тәмамлаган ике меңнән артык кеше (музыкантлар, җырчылар, баянчылар, пианинода уйнаучылар, музыка укытучылары) хәзерге көндә Татарстанның, Идел буе автономияле республикаларының һәм өлкәләренең музыкаль театрларында, симфоник оркестрларында, музыка мәктәпләрендә уңышлы эшләп киләләр. Шул ук Казан музыка училищесында укыганнан ары катлаулы һәм авыр конкурслардан уңышлы үтеп, Мәскәү, Ленинград, Свердловск, Казан консерваторияләрен тәмамлаган йөзләрчә кеше хәзер Мәскәүдә, Ленинградта, союздаш республикаларның башкалаларында эшли. Алар арасында скрипкачылар конкурсы лауреаты Ирина Бочкова кебек, исемнәре безнең илдә генә түгел, хәтта чит илләрдә билгеле булганнары да бар.

Ильяс училищеда скрипка классы буенча дәресләрне үзе укытты. Ул һәр дәрескә бик яхшылап әзерләнеп килә, чөнки шунсыз укучыларны чын-чынлап сәнгатьне яратырга җәлеп итү мөмкин түгел дип саный һәм дәресләрдә иҗади эш итү буенча укучыларына үрнәк булып тора иде. Оркестрантларны теоретик яктан гына түгел, практик эш белән дә тәрбияләүгә Ильяс Әүхәдиев зур игътибар биреп килде. Нәтиҗәдә аның классын тәмамлаучылар һәр яктан җитлеккән оркестрантлар булып чыгалар һәм аларны илебездәге теләсә кайсы оркестр составына бик теләп кабул итәләр иде.

Талантлы дирижер А. А. Литвинов башлап җибәргән Казан мәктәбе традицияләрен дәвам итеп, Әүхәдиев әле утызынчы елларда ук училищеның оркестр базасы нигезендә Казанда үзенең беренче симфоник оркестрын оештырды. Аның киләчәккә караган зур планнарын тормышка ашыру өчен училище оркестры гына һич тә җитәрлек түгел иде, әлбәттә. Шуңа күрә ул Казанда консерватория ачу турында хыяллана иде. Шул хыялын тормышка ашыру юлында ул инде җиң сызганып тырышып йөри дә башлаган иде. Ләкин 1941 ел башында Татар дәүләт опера һәм балет театры директоры һәм дирижеры итеп билгеләнүе нәтиҗәсендә аның бу планы бүленеп калды. Чөнки театрда аңа эш бик күп иде. Ул беренче көннән үк театр эшенә чумды һәм кырык беренче елның башыннан алып, кырык сигезенче елның ахырына кадәр берөзлексез опера һәм балет театрында эшләде. Ил, халык һәм театр тормышындагы күп санлы зур вакыйгалар белән чагыштырганда бу әллә ни күп вакыт түгел. Ләкин

Әүхәдиев әнә шул нибары сигез ел эчендә дә шактый күп эшләр эшләргә өлгерде.

Ильясның театр директоры һәм дирижеры итеп билгеләнүе 1941 елда Мәскәүдә булачак татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына хәзерлек алып барылган чорга туры килде. Республикабызның җитәкче органнары аны нәкъ менә шул уңай белән театрның җитәкчесе итеп билгеләгәннәр дә иде. Әүхәдиевнең директор булып килүен театр коллективы хуплап каршы алды. Ләкин театр ул чакта әле бик яшь иде һәм, шуның нәтиҗәсендә, уңышлы яклары белән бергә, аның күп кенә кимчелекләре дә бар иде. Моның шулай булуы гаҗәп тә түгел, чөнки опера һәм балет театрыбызның ачылуына нибары икенче ел гына киткән иде әле. Татар опералары репертуарда нибары өчәү: Нәҗип Җиһановның «Качкын»ы белән «Иреге», Мансур Мозаффаровның «Галиябану»ы гына иде. Ә Нәҗип Җиһановның Муса Җәлил либреттосы буенча эшләнгән «Алтынчәч» операсы әле яңа гына тәмамланган һәм сәхнәләштерүне көтеп тора иде.

Театрның декадага алып барылачак репертуарында милли опералардан тыш, рус һәм Көнбатыш Европа әсәрләре дә булырга тиеш. Аларны әзерләп җиткерү дә шул ук Ильяс Әүхәдиев өстенә йөкләнгән иде. Ә бит бер операны сәхнәләштерү дә дирижердан бик зур иҗади сәләт һәм оештыру көче таләп итә. Оркестр уйнавыннан һәм һәр җырчының җырын тиешле югарылыкка җиткерүдән алып, спектакльнең костюмнары, декорациясе һәм бутафория кирәк-яракларына хәтле ул җаваплы иде.

Муса Җәлил белән Нәҗип Җиһановның әлеге «Алтынчәч» операсы да әдәбият һәм сәнгать декадасына алып барылырга тиеш иде. Тарихи милли әсәр буларак, репертуарда төп урын аңа бирелә иде. Шуңа аны сәхнәләштерүгә аеруча зур әһәмият бирелде. Ильяс әнә шул җаваплы бурычны башкарып чыгу өчен дә күп көч куйды. Аның тырышлыгы нәтиҗәсендә «Алтынчәч»не сәхнәгә кую өчен СССРның Зур театрыннан режиссер Л. В. Баратов чакырылды, ә операның дирижеры итеп Җәләл Садриҗиһанов билгеләнде. Шулай итеп, Ильясның чын күңеленнән янып эшләве нәтиҗәсендә, кыска гына вакыт эчендә «Алтынчәч» операсы декадага алып бару өчен әзерләп җиткерелде. Операның премьерасы 1941 елның июнь башында булды. Спектакльне караганнан соң Муса Җәлил бик нык дулкынланып сәхнә артына чыкты һәм Ильяска әле шул көнне генә типографиядә басылып чыккан «Алтынчәч» либреттосын бүләк итте. «Ялкынлы директор, дустым Ильяска истәлек» дип язган иде ул аңа.

Әйе, Әүхәдиев җитәкчелегендә эш иткән театр коллективы Мәскәүдә булачак татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына алып барылачак спектакльләрне тулысынча һәм җиренә җиткереп әзерләп бетергән иде. Ләкин фашистлар безнең илебезгә басып керделәр дә ул декада булмыйча калды.

Дирижер буларак кына түгел, кеше буларак та гаҗәеп әйбәт иде безнең Ильяс. Артист халкының да төрлесе бар. Һәр коллективтагы шикелле үк, алар арасында да аңлашылмаучылык һәм канәгатьсезлекләр булгалап тора. Андый хәлләр кайчакларда бик кечкенә нәрсәләрдән, ә кайчакларда принципиаль мәсьәләләрдән дә килеп чыга. Әнә шундый вакытларда Ильяс һич тә кызып китми, сабырлык белән генә тыңлый, кем хаклы да кем хаксыз икәнен иплән кенә тикшерә һәм гадел хөкемен чыгара. Берәүне дә урынсызга кимсетергә юл куймый. Шуңа күрә коллективта ул барыбыз өчен дә авторитет һәм гаделлек үрнәге булып санала иде.

Театрның дирижеры һәм директоры буларак, Ильяс яшь композиторларга аларның әсәрләрен сәхнәгә куйдыру өчен дә бик нык

ярдәм итте. Мәсәлән, 1942 елда әле ул чакта яшь композитор булган Җәүдәт Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясен сәхнәгә куюда аның тырышлыгы бик зур булды. Шунысын аеруча басым ясап әйтеп үтәргә кирәк, ул булышлык әсәрне тизрәк сәхнәгә чыгару өчен генә түгел, бәлки аны һәр ягыннан җитлектереп, яхшы әйбер итеп чыгару юнәлешендә дә алып барылды. Инде әсәр буенча репетицияләр башлангач та дирижер композиторга кытыршырак урыннарын күрсәтә-әйтә торды, шул җирләрен үзгәртүне, шомартуны таләп итте. Аның дөрес һәм яхшы ният белән әйтелгән фикерләрен Җәүдәт тә кире какмады: армый-талмый әсәрен камилләштерүен дәвам итте. Әнә шул һәр ике якның да тырышлыгы нәтиҗәсендә «Башмагым» музыкаль комедиясе дөньяга килде, зур уңыш казанды.

Беренче татар балеты «Шүрәле»нең сәхнәгә чыгуында да Ильясның катнашы бар. Композитор Фәрит Яруллин тарафыннан иҗат ителгән бу балет 1942 елда дөнья күрде. Балетны сәхнәгә куяр өчен әзерләгәндә аның авторы Казанда юк, ул сугыш кырында фашистларга каршы көрәшеп йөри иде. Балет тикле балетны авторыннан башка беренче тапкыр сәхнәгә чыгару шактый четерекле эш ул. Монда мәсьәләнең ничек хәл ителүе балет спектакленә дирижерлык итүчегә кайтып кала. Үз вазифасына һәм композитор иҗатына тиешенчә җаваплы карамый торган дирижер алынса, мондый эшне бозып куюы да бик мөмкин. Әмма, бәхеткә каршы, Ильяс андый битарафлардан түгел иде. Ул Фәрит Яруллинның «Шүрәле»сен мөмкин кадәр яхшы итеп тамашачыларга ирештерү өчен җаны-тәне белән тырышты. Балетның кайбер кимчелекләрен бетерү өчен, тәҗрибәле композиторлар һәм күренекле балетмейстерлар белән сөйләшеп, аларны ярдәмгә чакырды һәм эш барышында файдалы киңәшләрен биреп торды.

Мин ике-өч кенә мисал китердем. Ләкин Ильяс Әүхәдиевнең яшь композиторларга күрсәткән ярдәме болар белән генә һич тә чикләнми. Ярдәмчел, кешелекле булу аның холкының төп сыйфаты иде. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр шулай булып калды. Опера һәм балет театрының тарихын өйрәнүче театр белгечләре Ильяс Әүхәдиев директор һәм дирижер булып эшләгән чорны тикшергәндә, аның ул сыйфатларына киңрәк тукталырлар, тулырак анализ ясарлар дип ышанам.

Татар композиторлары әсәрләрен сәхнәләштерү өчен бик күп эшләү белән бер үк вакытта, Ильяс Әүхәдиев рус һәм Европа классикларының әсәрләрен популярлаштыруга да зур игътибар бирде. Аның дирижерлыгында алып барылган «Евгений Онегин», «Травиата», «Риголетто» һәм башка байтак спектакльләр ул елларда театр репертуарында даими урын алып килделәр.

Операга дирижерлык итүнең катлаулы үзенчәлекләренә тукталып тормастан, Ильяс Әүхәдиевнең ул өлкәдәге эшенә карата шуны гына әйтеп үтәсе килә: аның җитәкчелегендә эшләү һәм җырлау үзе бер рәхәт һәм җиңел иде. Спектакльләрдә генә түгел, хәтта репетицияләр вакытында да ул җырчыларның күңелен төшерердәй хәлләргә һич юл куймый, киресенчә, аларның рухын күтәрергә тырыша, алар мөмкин кадәр яхшырак җырласын, үзләрен иркен тотсын өчен, кулыннан килгәннең барысын да эшли иде.

Виолетта образын өйрәнгән чакта Ильяс миңа да бик зур ярдәм итте. Ул дирижерлык иткән спектакльләрдә төп рольләрне башкарган бүтән актерлар да аңа карата шушы ук сүзләрне әйтә алырлар иде.

Бөек Ватан сугышы елларында безнең театр коллективы, театрда спектакльләр куюын дәвам итү белән бергә, хәрбиләр гарнизонында

һәм госпитальләрдә дә шефлык итеп, солдатларга да концертлар бирде.

1941—1945 еллар илебез тормышында иң киеренке, иң авыр чор булганлыгы һәркайсыбызга мәгълүм. Ул авырлыклар театр коллективын да читләтеп үтмәде. Авыр сынау елларында театр тагын да ныгып, тормышчанлыгын раслады, халкыбыз алдында дәрәҗәсен күтәрә төште.

Әлеге шул сугыш елларында театрда бик күп эш алып бару белән бергә Ильяс музыка училищесын да онытмады. Ул анда яшь скрипкачыларны укытуын дәвам иттерде, ансамбль классын алып барды һәм оркестр өчен программалар әзерләде. Якын дуслары һәм туганнары аның туктаусыз эшләвенә аптырап, ял итәргә кирәк сиңа, Ильяс, дип әйткән чакларда ул:

— Мин физик яктан тап-таза. Ә рухи яктан мин симфоник музыка тыңлаганда ял итәм! — дип җавап бирә торган иде.

Югары культуралы музыкант буларак, ул опера спектакльләрендә дирижерлык итү белән генә һич тә канәгатьләнә алмады, һаман симфоник оркестр оештыру уе белән янып яшәде. Ниһаять, ул максатына иреште: Казан училищесын тәмамлаган музыкантлардан 1948 елда симфоник оркестр төзеде. Ә 1951 елда Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясендә алтмыш ике кешелек тагын бер симфоник оркестр оештырды, аның сәнгать җитәкчесе, дирижеры булып эшләде. Оркестрның музыкантлары нигездә Ильяс училищеда үзе укытып чыгарган кешеләрдән гыйбарәт иде. Безгә, күп еллар буена бергә эшләгән кешеләргә, Ильясның үзенә генә хас дирижерлык почеркы яхшы таныш. Ильяс үз теләген музыкантларга сүз белән генә әйтми, таләпчән-рухландыргыч күз карашы белән дә бик яхшы ирештерә белә иде. Шуңа күрә оркестрантлар аның шул сәләтенә гаҗәпләнеп, гипнозлау серенә ия, ахрысы, дип сөйлиләр иде. Оркестр ансамбленең әсәрне төгәл һәм югары сәнгатьчә итеп башкаруына ирешү өчен дирижерның колагы бик сак, күңеле бик сизгер булырга тиеш. Ильяс әнә шул бик мөһим сыйфатларга да тулысы белән ия һәм, шулар өстенә, ул әсәрне башкарганда беркайчан да аның авторы әйтергә теләгән хис һәм фикерләргә хилафлык итми иде. Зур дирижерлар тарафыннан нигез салынган традицияләрне яклый. Ул традицияләргә искелек дип, модасы чыккан дип караучыларга бик нык хәтере кала торган иде.

Ләкин бу Ильяс Әүхәдиев гел искелек яклы булган, музыка авторларына сукырларча ияреп кенә барган икән дигән сүз түгел. Ул һәр композиторның әсәренә иҗади якын килә. Әсәр авторының төп фикерен саклаган хәлдә аны үз трактовкасында, үз интерпретациясендә халыкка җиткерә иде. Бу җәһәттән караганда, аның Сәйдәшев, Мозаффаров, Яхин, Бакиров, Вәлиуллиннар белән иҗади дуслыгы игътибарга аеруча лаек. Бу композиторлар барысы да Ильясның музыканы бөтен нечкәлекләре белән аңлау сәләтен беләләр һәм шуңа әсәрләрен халыкка ирештерү мәсьәләсенә карата Ильяс әйткән фикер һәм тәкъдим белән килешәләр иде.

Үзе оештырган оркестрны һаман яхшырта, камилләштерә баруны күздә тотып, Ильяс Әүхәдиев ул оркестр концертларында катнашу өчен илебезнең күренекле дирижерларын һәм солистларын җәлеп итү буенча да башлап йөрүчеләрнең берсе булды. Аның инициативасы белән атаклы музыкантлардан И. Бочкова, В. Пикайзен, Ю. Ситковетский, М. Яшвили, А. Гинзбург, Л. Лукомский, Н. Пецкерлар театрга чакырылып, солист буларак оркестр концертларында чыгышлар ясадылар. СССРның халык артисты Натан Рахлин һәм Карелия республикасының халык артисты Исай Шерман (икесе дә дирижер) Әүхәдиев тәкъдиме буенча Казанга эшкә чакырылдылар.

Татарстан композиторларын оркестр уеннарында катнаштыру шулай ук Әүхәдиев теләге белән башланып китте. Р. Яхин, А. Леман, Э. Монасзоннар композитор буларак кына түгел, солист буларак та оркестр концертларында байтак кына чыгышлар ясадылар. Атаклы композиторларны һәм музыкантларны әнә шулай оркестр концертларында катнаштыруның әһәмияте шунда, бу хәл музыка сөючеләрнең симфоник әсәрләр белән кызыксынуын арттыруга, аларның оркестр концертларына ешрак йөри башлавына этәргеч булды.

Симфоник музыканы пропагандалауның күп төрле юлларын таба иде Ильяс. Татар композиторларының әсәрләрен грампластинкага яздырту, Казан культура сарайларында концертлар оештыру, коммунистик хезмәт ударниклары белән очрашулар — барысы да аның башлап йөрүе нәтиҗәсендә эшләнде. Хәтта республикабызның авылларына чыгып колхозчыларга симфоник концертлар биреп кайтуга да бик теләп катнаша иде ул. Анда да вакытының бер минутын да бушка үткәрми, авыл үзешчәннәрен җыеп, алар белән сөйләшә, файдалы киңәшләрен биреп китә торган иде.

Ильясның тагын бер зур һәм бик мөһим эшен искә алып китмәсәм, истәлегем һич тә тулы булмас иде. Сүз үзеге Әлмәттә булган районара симфоник оркестр хакында барачак.

Татарстанда нефть чыгарыла башлагач, елдан-ел арта барган күп санлы нефтьчеләрнең рухи таләпләрен Казаннан барып концертлар бирү белән генә канәгатьләндерү һич тә мөмкин түгел иде. Менә шуңа Ильяс Әүхәдиев нефть районнарының үзәге булган Әлмәт шәһәрендә аерым симфоник оркестр төзергә кирәк дигән фикергә килде. Оркестр оештыру бик катлаулы, күп хезмәт сорый торган мәшәкатьле эш. Атаклы совет композиторы Арам Хачатурян әйтә, оркестр тудыру өчен зур завод салдыруга киткән кадәр көч түгәргә кирәк, ди. Моның шулай икәнлеген Ильяс Әүхәдиев үзе дә бик яхшы белгәндер дип уйлыйм. Ләкин ул, инде әйтеп үткәнемчә, музыкага бәйләнеше булган эшнең авырлыгыннан һич тә куркып тормый, аеруча бер дәрт белән, җилкенеп эшли торган иде. Әлмәттә оркестр оештырганда да ул нәкъ әнә шулай канатланып йөрде. Өлкә комитеты партия оешмасы һәм республикабызның Культура министрлыгы да Ильясның бу ниятен хуплап, ярдәм итеп торгач, аның эшләре бик тиз алга барды һәм ул 1964 елда Әлмәт шәһәрендә кырык кешелек симфоник оркестр төзү бәхетенә ирешге. Оркестрның оркестрантлары шулай ук бөтенесе дә диярлек Ильяс үзе укыткан кешеләрдән гыйбарәт булып, аның холкын, дирижерлык стилен һәм таләпләрен яхшы аңлаучылар иде. Шуның өстенә алар барысы да музыканы чын күңелләреннән ярата торган энтузиастлар, оркестр репетицияләренә һәм концертларына күрше районнардан йөзәр километрдан килеп йөриләр. Ильяс үзе дә айлар буе Әлмәткә китеп, «югалып» тора иде. Ниһаять, бу оркестрның җәмәгатьчелек тәртибендә генә эшләвен дә искә алсак, аның дирижеры Ильяс Әүхәдиевнең һәм оркестрантларының тырышлыгына, музыканы үзләре ярату белән бергә, халыкка да ирештерергә никадәр көч куюларына сокланмыйча мөмкин түгел.

1965 елның 27 декабрендә Әлмәт шәһәренең Техника йортында оркестр тамашачыларга беренче концерт бирде. С. Сәйдәшевнең «Шәрык биюе», П. Чайковскийның «Аккош күле» һәм Ф. Шопенның фортепиано өчен беренче концерты — программада әнә шул әсәрләр иде. Оркестрның җәмәгатьчелек алдындагы беренче имтиханы уңышлы үтте: концертны тамашачылар бик яратып тыңлады.

Шуннан оркестр Әлмәттә генә түгел, Азнакай, Лениногорск, Бөгелмә һәм Баулы шәһәрләрендә дә системалы төстә концертлар бирүне гамәлгә кертте һәм Ильяс Әүхәдиев оештырып җибәргән бу изге эш, аның тырышлыгына һәйкәл булып, хәзер дә шулай дәвам итә.

## Фатыйма Камалова

# ХАЛЫКЧАН МОҢНАР[1]

Шакир Мәҗитов 1907 елның 15 августында Оренбург шәһәрендә эшче семьясында дүртенче, төпчек бала булып дөньяга килә. Гадәттә, төпчек бала кадерле була диләр. Ләкин Шакирга бу кадер бик аз гына эләгеп кала. Гражданнар сугышының дәһшәтле елларында ачлыктан һәм тиф авыруыннан аның әтисе вафат була. Ике абыйсы үз ирекләре белән Чапай дивизиясенә язылып, яшь Совет дәүләтен саклау өчен ак бандаларга каршы сугышка китәләр. Җаек буендагы сугышларның берсендә уртанчы абыйсы Садыйк аклар тарафыннан ерткычларча җәзалап үтерелә. Олы абыйсы Нәсим семьясына кайтса да, озак тормый, фронтта алган каты ярасыннан мантый алмыйча, дөнья куя. Шулай итеп, унбер-унике яшьлек Шакир семьяда ир затыннан берүзе торып кала. Җитмәсә, әнисе белән апасы да тиф авыруына дучар булалар. Фронттан кайткан күршеләре бу семьядагы авыр хәлне күреп, Шакирны Оренбургның Сакмар суы буенда, шәһәр читендә урнашкан «Орлес» такта яру заводына көнлекче хезмәтенә урнаштыра.

Уфадан килгән сал башлыгы Сибгатулла агай Шакирны үз эртиленә верховой, ягъни атка атланып, салдан сүтелгән бүрәнәне судан ярга сөйрәтүче итеп ала. Бу эш җиңел булмый. Кояш чыкканнан алып кояш батканчыга хәтле юеш ат өстендә верховой булып эшләгән Шакирның һәм аның ише бүтән малайларның савырлары чиләнеп интектерә. Алар төннәр буе йоклый алмый сызланып чыгалар. Җитмәсә, ятак урыннары да рәтле булмый, алар яр читенә корылган шалашта яшиләр. Дөрес, моның үз хозурлыгы да була. Сакмар суы күзгә шикелле ялтырап ята. Яр буендагы нечкә билле бөдрә таллар арасында өч аякка эленгән казанда балык шулпасы кайнатулар, учак астында янган чыршы ботакларыннан таралган хуш исләр. Талган беләкләргә көч, янган йөрәкләргә дәрт бирә торган татар, башкорт моңнарын тыңлап ятулар. Гармунда, скрипкада уйналган «Әллүки», «Камәр», «Шәүрәкәй», «Сакмар», «Җаек», «Урал суы», «Ашказар», «Кәләү Гайшә» көйләре... Болар бары да Шакир күңеленә рәхәтлек, рух бирә. Һәм ул, мин дә шулай өздереп уйный алсам иде, дип хыял-

---

[1] Бу истәлекне РСФСРның атказанган һәм Татарстанның халык артисткасы Фатыйма ханым Камалова вафатына берничә ай элек кенә безнең редакциягә тапшырды. Татар сәхнәсенең ветераны Фатыйма Камаловага, музыкада кабатланмас үз юлын тапкан Шакир Мәҗитовка зур ихтирам йөзеннән, истәлекне укучыларга тәкъдим итәбез.

ланып ята. Нәни чагыннан ук өйләрендә энисенең гармун, абыйсының скрипка уйнавын ишетеп үскәнгә, мондагы моңнар аны тагы да ныграк тәэсирләндерә.

Көнлекче эшчеләр, яңгырына, суыгына яки эссесенә карамыйча, бары тик материаль якны гына күздә тотып, алны-ялны белмичә эшлиләр. Авыр хезмәт үзенекен итә: Шакирга бизгәк авыруы эләгә һәм ул аяктан егыла. Көнлекче ятим малайны кем кайгыртсын. Ул бернинди медицина ярдәме күрмичә, көнлекчеләр шалашында туңыппешеп саташып ятарга мәҗбүр була. Хәле бераз арулана төшкәч, ул төшендә гармунда «Фазлуш» көен, скрипкада «Әллүки» көен уйнаганын күрә. Шулай рәхәтләнеп уйнап яткан чагында: «Чү, чү, Шакир энем!» — дигән тавышка уянып китсә, янында әртил башлыгы Сибгат абый басып тора һәм: «Карале, син бит саташасың, манма су булгансың, кая, өс-башыңны алыштырыйм, үзең авырыйсың, үзең җырлап яткан буласың!» — дип сөйләнә икән.

Сибгат абзый аның тирләрен сөртеп, су эчертеп, әйбәтләп яткыра да:

— Син, Шакир энем, борчылма, бүген үзеңне эшләгәнгә исәплә. Сине пайга кертергә булдык. Акчаңны җыйна да әниләреңә кайтарып килерсең, яме! — дип тынычландырып эшенә китә. Бала чагыннан ук иркә-наз күрми үскәнгә, Сибгат абзыйның бу тәмле сүзләре Шакирның күңелен күтәреп җибәрә һәм ул, урыныннан торып, төшендә җырлаган көен өнендә көйләргә керешә. Шалаш эчендәге кыңгыраулы гармунны кулына алып, тез өстенә куя да уйнап карый. Озак та үтми, ул төшендә уйнаган әлеге «Фазлуш» көен чынлап ук уйнап җибәрә. Үзе дә хәйран кала. Аннары «Әллүки» көен уйный башлый. Көй матур чыга. Шакир үз-үзенә ышанмыйча, ул көйне тагын, тагын уйный.

Кич әртил членнары кайтып кергәндә дә уйнавын дәвам итә әле Шакир. Әртилчеләр шалаш буена сузылып яталар да тып-тын калып тыңлый башлыйлар. Гармун моңы Сакмар суларына, бөдрә талларга барып тоташа...

Аннары Сибгат абзый Шакирны үз янына утыртып:

— Синең, энем, көн күрерлек һөнәрең дә бар икән ләбаса,— ди.— Нигә аны бездән яшереп йөрдең? Уйна дип теңкәгә тиярбез дип курыктыңмы әллә?

— Минем моңарчы гармун уйнаганым юк иде, Сибгат абзый. Бүген беренче тапкыр кулыма алдым,— ди Шакир.

— Кит аннан! — ди Сибгат абзый шаккатып.— Беренче тапкыр кулыңа гармун алып шушылай моңлы итеп сыздырып уйнадыңмы? Юк, ышанмыйм мин моңа! Ә скрипка уйнап караганың бармы синең?

— Юк.

— Алайса, менә башкорт Гаделшаның скрипкасын ал да уйнап кара әле. Әгәр скрипканы да бер тотуда уйный алсаң, гармунны беренче тотуда шулай уйный алуыңа ышанам. Шунсыз — юк!

Шулай дип әйтә дә Шакирның кулына скрипка тоттыра. Шакир каушап кала. Куллары калтырый башлый. Ни эшләргә дә белмичә, скрипканы әйләндерә-әйләндерә карарга керешә. Бераз бушаган кылларын тарткалап, уңайлап караган була. Көйләп-сызгалап та карый. Һәм күп тә үтми, әллә кайчаннан уйный белгән кеше сыман оста итеп, «Әллүки» көен уйнап җибәрә.

— Кара, кара, өздерә бит бу малай,— дигән сүзләр аны тагы да рухландыра, ул дәртләнебрәк уйный башлый.

Хәтфә кебек яшел табигать түшәгенә тәгәрәп, хискә бирелгән кешеләрнең кайсы махорка көйрәтә, кайсы күзләрен сөртә, кайсылары тирән уйга батып утыра. Гаделша башкорт, яткан җиреннән күтәрелеп:

— Һин, кустым Шакир, йокы алдыннан безнең туган як йырын — «Ашказар» көен уйна әле, шунсыз күземә йокы кермәс! — ди.

— Мин ул көйне белмим шул,— ди Шакир.

Гаделша скрипканы кулына алып:

— Менә мин ошылай уйнаем. Һин дә ошылай уйнап кара әле,— дип уйнап күрсәтә.

Шакир Гаделшаның уйнавын бик дикъкать белән тыңлап тора. Аннары скрипканы кулына алып, «Ашказар»ны да уйнап җибәрә. Бөтен әртилчеләр тагын бик гаҗәпкә калып, сулу да алмыйча тыңлап торалар. Шакир уйнап туктагач, Гаделша башкорт та:

— Ә һин, Шакир балам, бездән бу һөнәреңне ник яшереп йөрдең һоң? — дип сорап куя.

Шунда Шакир аларга үзенең төшен сөйләп бирә. Моңа ышанырга да, ышанмаска да белмиләр. Арадан берсе әйтеп куя:

— Бу малай изге җан. Бәхетле булсын өчен алла аңар шундый кәсеп биргән,— ди. Икенче берсе:

— Юкны сөйләмә, алла биргән, имеш! — дип, аңа каршы төшә.— Нигә, алайса, бу нарасый баланы ачлы-туклы тамак ялына шулай азап чиктерә? — ди.

Шакир исә аларның сүзләрен колагына да элми. Ул әнисе уйный торган бер көйне хәтерли алмыйча азапланып утыра. Ахырда, исенә төшереп, кулына яңадан скрипка ала да башта әкрен генә, аннары тәмам дәртләнеп «Сакмар су» көен өздереп уйнап җибәрә. Ул да булмый, Сибгат абзый үзенең көчле тавышы белән моңлы итеп җырлап җибәрә:

Сакмар сулары тирән шул
Колач салып йөзәргә.
Ачы хәсрәт, җәфа-михнәт, дуслар,
Ничек итеп түзәргә?

Үсәдер таллар Сакмар суы буенда,
Азап-җәфа чигәрбез дип
Һич юк иде уемда...

Бу кичне Шакирның уйнавын тыңлап, әртилчеләр ярты төнгә кадәр утыралар. Гаделша башкорт аңа әнә шул кичтә үзенең скрипкасын да бүләк итеп бирә.

Ә иртәгесен улының эш хакын алырга дип, Шакирның әнисе килә. Авырып яткан баласын күргәч, аның бөтенләй коты чыга.

— Әйдә, балам, кайтыйк. Ни күрсәк тә бергә күрербез. Әзрәк хәл алгач укырга керерсең. Болай укымыйча надан каласың, үземнең наданлык та үзәккә үткән,— дип, ул Шакирны өйләренә алып кайтып китә.

...1921 нче ел. Яшь Совет иленең хәле авыр. Урал-Идел буйларындагы шәһәрләр ачлыктан, йогышлы авырулардан җәфалана. Халык шул авыр шартларда да җиң сызганып җимерек илне торгызу эшенә керешә. 12 яшьлек Шакирга да боларның һәммәсен үз башыннан кичерергә туры килә.

1924 елда ул мукомол (тегермән) клубы каршындагы ячейкада комсомолга керә. Шул клуб каршындагы үзешчән сәнгать түгәрәге концертларында, берәр пәрдәлек спектакльләрдә катнаша.

1925 елда губкомол Шакирны әлеге «Орлес» заводындагы яшьләр арасына политик-агарту һәм культура эшләрен оештыручы итеп билгели. Клуб каршында үзешчән түгәрәкләр төзү эше дә аңа йөкләнә. Ул көндез эшли, кичләрен концерт, спектакльләр куя. Шул чорда ул Муса Җәлил белән таныша. Истәлекләренең берсендә Шакир бу хакта менә болай дип яза: «Җәйнең матур бер көнендә, эшчеләр төшке

ашка хәзерләнеп торганда, безнең янга бер егет килеп туктады. Мусаны ишетә белсәм дә, күргәнем юк иде. Буйга миннән тәбәнәгрәк, каптара чәч, кара бөрлегән кебек мөлаем күзләр, ап-ак, энҗедәй вак тешләр, йөзе көләч, өстендә карага нечкә генә ак юллар төшкән чалбар, аягында сандал, якасын-җиңен, итәген кара белән чиккән ак киек якалы күлмәк, билендә каеш, кулында шакмаклы кепка. Эшче яшьләр Мусаны шундук әйләндереп алдылар. Исән-саулык сорашу, теге-бу турында сөйләшү башланды. «Менә, Муса дус, таныш булыгыз, бу безнең культура башлыгы комсомол Шакир Мәҗитов»,— дип, мине дә таныштырып өлгерделәр.

Ямь-яшел хәтфә кебек чирәмдә эшчеләрнең «чикмәнле бавырсагы» әзер, парлары чыгып тора иде. Табынга утырыштык. Бик ялкынлы сөйләшүләр башланды. Мусадан Казандагы тормыш, уку йортларына кемнәрне алу-алмау турында, укырга керергә нинди хәзерлек үтәргә кирәк икәнлеген — һәммәсен сораштыра башладык. Шунда аның үзенең планнары белән дә кызыксындык. Муса рабфакны тәмамлавын әйтте, ВУЗга керергә ашыкмыйм әле, диде.

Шулай күңелле генә сөйләшеп утырганда «Орлес» гудогы эшкә чакырып, кисәк-кисәк кенә кычкыртып куйды. Эшчеләр, Мусадан аерылырга теләмәгәндәй, иренеп кенә урыннарыннан кузгалдылар. Без Муса белән икәү генә калдык. Ул миннән тормышым, эшем турында сораштыра башлады. Аннары Сакмар суының бормаланып-бормаланып сузылган ярларына сүзсез генә карап торды да, кинәт торып:

— Шакир дус, син буш булсаң, әйдә, көймәдә йөзик әле, ә? — диде.

Бүген концерт буласы көн, аңа хәзерләнү эше әле бетмәгән булса да, мин Мусаның соравын кире кага алмадым. Ул миңа кыяр-кыймас кына әйтеп тә куйды:

— Көймәдә йөзүнең хозурлыгы музыка белән тагы да шәбрәк була, берәр музыка коралы кыстырсаң начар булмас иде,— диде.

Мин клубка кереп скрипка белән мандолина алып чыктым. Көймәгә кереп утырдык. Ярдан көймәне этәреп, ишәргә тотындым. Муса күлмәген салып ташлады. Аның тыгыз кара-кучкыл тәне кояш нурларында ялтырап тора иде. Очарга әзерләнгәндәй, Муса дулкынланып, киң колачларын җәеп, киерелеп алды да:

— Их, безнең туган җиребез нинди матур бит! Дус кеше, әйдә әле, дәртле йөрәкләр тагы да дәртләнсен, бер сыздырып алыйк,— диде.

Ишкәкләрне бушатып, көймәне агым уңаена җибәрдек тә, мин скрипканы алып, әти бик яратып җырлый торган борынгы «Кәмәр» көен уйный башладым. Көймә җыр көенә аккош йөзгәндәй әкрен генә ага да ага... Бары каты агымга эләгеп, көймә зырылдап әйләнәтулгана башлагач кына, без яңадан ишкәкләребезне кулга алдык. Минем уйнау Мусага бик ошады булса кирәк, бераздан көймәне талгын сулы яр кырыенарак чыгаргач, ул үзе дә мондолина алып, миңа кушылып уйнарга кереште. Без шулай бик күп татар көйләрен уйнадык. Бигрәк тә «Ком бураны»н дәртләнеп уйнаганыбыз хәтердә.

Аннары без көймәне сай җиргә туктатып, өсләрне чишендек тә суга сикереп, йөзәргә тотындык. Муса чалкан ятып та, колачлап та, хатын-кызларча да йөзеп күрсәтте. Шулай ярыша-ярыша, балаларча чупырдаша-чупырдаша коенып туйгач, бөдрә таллы Сакмар суының комлы ярына чыгып, кояшка яттык.

Мин аңа бала чагымнан ук йөрәк түремдә йөрткән хыялымны — укырга теләвемне әйттем. Тик бер зур комачаулык бар, өйдәге материаль як бик кысынкы, дидем. Муса яткан җиреннән күтәрелеп, мине үгетләргә кереште:

— Сиңа Казанга барырга, укырга кирәк! Нинди генә авырлыклар булса да, түзәргә, үзеңдәге сәләтеңә юл ачарга кирәк! — диде.— Хәзерге чорда кемнәрнең гаиләләре бик тук дип беләсең, минекеме, синекеме, башкаларныкымы? — дип тә куйды ул, коры гына итеп.

Без әйләнеп кайтканда, кояш байый башлаган иде инде. Бераз чәй эчеп, капкалап алдык та Мусаны такта яру заводы белән таныштырырга алып киттем. Аңа заводның станокларын, Сакмар суы буендагы бүрәнә күтәрә торган лебедкаларны күрсәтеп йөрдем. Кичен исә бергәләшеп концерт карадык.

Икенче көнне иртә Муса безнең белән саубуллашып китеп барды.

1926 елның июнендә Муса белән тагын бер тапкыр очраштык. Без мукомол клубында кичә үткәргән кичтә булды бу очрашу. Ул кичә ике бүлектән булып, беренче бүлектә «Чиратлы чалбар» исемле комедияне сәхнәгә куйдык. Икенче бүлек концерт иде. Анда мин дә катнашып, халык көйләреннән «Уел», «Сибелә чәчәк», «Кәләү Гайшә», «Сакмар су», «Сүнмәс дәрт», «Күгәрчен» көйләрен скрипкада һәм гармунда уйнадым. Концерт беткәч, сәхнә артына Муса килеп керде дә без дусларча кочаклашып күрештек. Ул минем хәл-әхвәлемне сораштырганнан соң:

— Бер ел эчендә бик нык алга киткәнсең син, Шакир дус, чын мәгънәсе белән профессиональ музыкант һәм кайбер тәҗрибәле артистларга бирешкесез артистлык кабилиятең дә бар икән бит синең! — диде.

Кайтырга чыккач, ул минем киләчәк планнарым, үткән бер ел эчендә нәрсәләр эшләвем хакында сораштыра башлады. Аңа мин комсомолларның дини гореф-гадәтләргә каршы көрәше темасына «Әдрәс бишмәт» исемле музыкаль әсәр язуымны, комсомол ячейкасы карары нигезендә, ул әсәрне сәхнәгә үзем куярга, музыкасын да үзем язарга йөкләтелүен, шул спектакльне караучылардан җыйналган акчаны Казанга музыка мәктәбенә укырга бару өчен ярдәм йөзеннән миңа бирергә булуларын һәм спектакльнең бик уңышлы килеп чыгуын сөйләп бирдем.

— Ул спектакльне кайчан куйдыгыз? — диде Муса.

— Узган атнада гына әле.

— Кызганыч,— диде ул.— Белгән булсам, берәр атна алдан килә идем бит мин! Ярый, узган эшкә салават, ди. Ә сине әсәреңнең уңышлы булуы белән чын күңелдән дусларча котлыйм! Укырга кайчан китәсең?

— Өч-дүрт көннән.

— Нигә алай бик иртә? Укуга август айларында гына алалар бит.

— Анысы шулаен шулай да, тик мин алданрак кузгалырга булдым инде.

— Бик яхшы, батыр бул, һәр вакытта юлыңнан нык атла!— диде Муса һәм пиджагының эчке кесәсеннән бер кәгазь кисәге алды да: — Мин вәгъдәмне үтәдем: менә сиңа «Орлес», Сакмар буйларының истәлеге булсын,— дип, «Орлес гудогы» дигән шигырен бирде.

1926 елның июль башында Шакир Казан шәһәренә сәфәр чыгып китә. Юлда ул Куйбышевтан (Самарадан) Казанга укырга баручы Хәмит дигән бер егет белән таныша. Бу ике юлдаш күптән хыялланган Казан урамына аяк баскач, бик куансалар да, торыр урыннары юклыгы исләренә төшкәч, аптырап калалар. Җитмәсә әле, берәр уку йортына урнашыр өчен дә ай ярымлап вакыт бар. Казанда ай ярым яшәр өчен, ай-һай, күпме акча кирәк! Кайтып китсәләр дә кыен — яңадан Казанга килү мөмкин булмаячак. Шуңа ничек тә чыдарга булалар; акчаларын тартып-сузып, коры-сары гына ашап көн узды-

ралар. Тиздән акчалары бөтенләй бетә, көзге пычраклар башлана. Ярдәм сорап, төрле идарәләргә йөрсәләр дә, ярдәм кулын сузучы да, уку йортына алынмыйча торып, торак урын бирүче дә юк. Ачлык үзәкләренә үтә башлагач, балык базарына барып хәер эстәргә мәҗбүр булалар. Аннары, шәһәр читендә урнашкан хәрби татар полкына барып, солдатлардан калган өстәлләрдәге ботка, икмәкләрне җыйнап, шуның белән тамак туйдыралар. Торган урыннары — Кабан күле буендагы бакча. Электр станциясенең җылы суында күлмәкләрен юалар. Шулай көч-хәл белән яшәп торганда, август аеның унбишләрендә Шакир салкын тиеп авырый башлый. Җитмәсә, көннәр бозыла, яңгырлар китә. Шундый бер көнне Шакир, җылыныр урын эзләп, балык базарына килә. Анда ул Оренбургта үзе белән бергә театрлар куеп йөргән таныш кешесен — Нури Сакаевны очрата. Шакир хәленең мөшкел булуын сөйләп биргәч, Сакаев аны үз өйләренә алып кайтып китә. Сакаевның хатыны Нәгыймә Таҗдарова Шакирны ачык йөз белән каршылый. Аны ашаталар-эчертәләр, өс-башын юып, мунча кертеп, тәмам кеше хәленә китерәләр. Аннары Нури агай аны театр техникумына алып барырга уйлаганлыгын әйтә.

«Бу сүз миңа бик сәер булып тоелды,— дип яза Шакир Мәҗитов үзе бу хакта.— Мин кинәт Нури абыйның сүзен бүлеп: — Мин музыка техникумына керергә килдем. Мин скрипка, гармун, пианино, мандолина уйный беләм. Үзем язган бер пьесам да бар. «Әдрәс бишмәт» дип атала ул. Музыкасын да үзем яздым,— дидем. Нури агай:

— Алай-алай, ярый, алайса, иртәгә барып белешербез,— дип куйды.— Андый сәләтең булгач, бик мактаулы эш. Син бит әле артист булып та уйнадым, үзем язган әсәремне сәхнәгә үзем куйдым дип тә әйттең. Әйдә, без Нәгыймә апаң белән тыңлап, сиңа имтихан ясап карыйк әле. Син безгә үзеңнең әсәреңнән берәр өзек яки шигырь сөйләп күрсәт,— диде.

Күп уйлап тормадым, Муса миңа истәлек итеп биргән «Орлес гудогы» дигән шигырьне сөйли башладым. Икесе дә зур дикъкать белән тыңладылар.

— Афәрин, энекәш! Бир кулыңны! — диде Нури агай.

Нәгыймә апа да, мөлаем елмаеп:

— Бик әйбәт, энем, бик шәп болай булгач, синдә өмет зур,— диде.— Үзең әдәби әсәрләр дә язасың, музыка да чыгарасың, шуның өстенә тагын музыка коралларында уйный да беләсең икән. Гармунчылар конкурсында ау мылтыгы белән дә бүләкләнгәнсең икән. Бу инде, акыллым, синең сәләтле икәнеңне күрсәтә.

Шулай итеп, алар минем хыял-өметләремә дәрт бирделәр. Бер-ике көннән Нури абый мине музыка мәктәбенә алып китте. Педагоглар сәләтемне күреп бик яратсалар да, урын беткәнгә күрә, урнаштыра алмадылар. Киләсе елга бернинди имтихансыз алырга булдылар. Ләкин Нури абый миңа әйтте:

— Синең монда торыр урының да юк, шуңа күрә киләсе елны көтеп тора алмассың. Әйдә, мин сине бу елга театр техникумына урнаштырам, шунда артистлык һөнәренә өйрәнерсең, ичмасам. Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз диләр бит. Быелга шунда укы, киләсе елга, насыйп булса, үзеңә карарсың,— диде.

Шулай итеп, Шакир Мәҗитов Казанда театр техникумы студенты булып китә. Ләкин аңа анда озак укырга туры килми. Үпкә авыруы эләктереп, ул аяктан егыла. Мондый авыру белән тулай торакта яшәргә ярамаганлыктан, Шакир дәвалану өчен бер елга өенә кайтырга карар кыла. Укучы иптәшләре аңа кулдан килгән кадәр ярдәм итәләр. Мәсәлән, Габдрахман Минский үзенең җәйге ак ботинкасын бирә, Ландыш исемле икенче бер иптәше мамык салып җылытылган җәйге пиджак бүләк итә. Шулай итеп, театр техникумы

белән саубуллашып, Шакир көч-хәл белән туган йортына кайтып җитә. Кайткач, больницада өч айлап ятып, сәламәтлеге беркадәр яхшырса да: семьяларының хәле авыр булганлыктан, ул кире Казанга китә алмый.

1927 елда Шакир Мәҗитов Оренбургка күрше Актүбә шәһәренә эш эзләп китә. Анда ресторанга скрипкачы булып яллана, көндезләрен татар китапханәсенә үзешчән түгәрәккә йөри. Тиздән бу китапханә каршында «Актүбә» дигән драма түгәрәге төзелә. Шакир анда үзенең «Ил гөлләре» исемле музыкаль әсәрен сәхнәгә куя, шул коллектив белән җитәкчелек итә. 1928 елда аны губерна сәнгать эшчеләре союзының председателе итеп сайлыйлар.

Шул ук елның ахырында Ильяс Кудашев-Ашказарскийның бертуган энесе Сабирҗан Кудашев тырышлыгы белән, РСФСР Урта Идел краеның тамаша урыннары идарәсе каршында өченче номерлы Колхоз күчмә театры төзелә. Шакир Мәҗитовны шул театрга эшкә чакыралар. Шулай итеп, музыкага, сәхнәгә булган мәхәббәт, хыял әкренләп гамәлгә аша башлый. 1929 елда Шакир Мәҗитовка Шәриф Камалның «Козгыннар оясында» исемле спектакленә музыка язуны тапшыралар. Үзешчән композиторны бу җаваплы эш бик дулкынландыра, шул ук вакытта куркыта да. Башкарып чыга алырмы? Ләкин аңа табигый таланты ярдәмгә килә. Ул «Шахтер егет», «Шахтерлар-дуслар» дигән берничә көй яза. Шул ук спектакльдә Шакир актер булып та катнаша — Мәхмүт ролен башкара. Спектакль зур бәйрәм төсен ала. Ш. Мәҗитов язган көйләр, бигрәк тә «Шахтер егет» җыры халык арасына бик тиз таралып өлгерә. Бу җыр хәзер дә һәркайда яратып җырлана, ул инде халыклашып беткән.

Бу театрда эшләү чорында Шакир Мәҗитов режиссерлык вазифасын да үти, аның куйган спектакльләре халыкта һәм артистларда зур канәгатьләнү тудыра. Бу елларда ул үзе дә бик актив яза. 1926 елда «Ил гөлләре» дигән өч пәрдәлек музыкаль комедия, «Мәдинәкәй сылуым», «Куштирәк авылы» исемле музыкаль әсәрләр яза. 1934 елда «Шәрык кызы Җайзан» (шәрык легендасына ияреп язылган 4 пәрдәлек драма) спектакленең музыкаль оформлениесен эшли. Бу спектакль Оренбург, Куйбышев, Ульяновск, Ташкент, Астрахань, Сәмәрканд, Алма-Ата шәһәрләрендә уйнала һәм зур уңыш казана.

Шакир киң диапазонлы артист та иде, ул сәхнәдә бик күп образлар иҗат итте. «Зәңгәр шәл»дә — Булат, Галәви, «Мәкер һәм мәхәббәт»тә — Вурум, «Кандыр буе»нда — Акбирдин, «Ярлылык гаеп түгел»дә — Тарасов, «Хуҗа Насретдин»да — Зәйнагый, «Каюм Насыйри»да Гали Чокрый рольләрен башкарды.

1936 елда Шакир Мәҗитовны Астрахань дәүләт театрына чакыралар. Ул театрда танылган сәхнә осталары — олы буын артистлардан Зәйни Солтанов, Касыйм Шамил, Фатыйма Камалова, Зөлкарнәй Байкин, Уральский һ. б. эшли иде.

Музыка белемен күтәрү өчен, Шакир Астраханьда Мусоргский исемендәге музыка мәктәбенә укырга керә. Күренекле педагоглардан музыка дәресләре ала. Бер ел укыгач, тормыш шартлары авыр булганлыктан, Шакирның үпкә авыруы тагы ачыла. Тагын больница. Врачлар аңа андый зур киеренкелек белән укырга кушмыйлар, я укы, я эшлә генә диләр. Ләкин Шакир бик актив эшләвен дәвам итә. Аңа постановкалар да, музыкаль оформлениеләр дә тапшыралар. «Шәрык кызы Җайзан» дигән әсәрен ул шушы театр сәхнәсендә үз музыкасы белән куя. Аннары «Аршин мал алан» спектаклен куя. Бу постановка Сталинградта уздырылган край театрлары смотрында беренчелекне ала. Шакир бу елларда сәхнә әсәрләрен тәрҗемә итү белән дә шөгыльләнә. «Айман чулпан», «Кыз-ефәк» исемле музыкаль әсәрләрне казакъчадан татарчага тәрҗемә итеп, Астрахань

театрында үзе куя (музыкасын дирижер Габдрахман Байкин белән берлектә язалар). Бу спектакльләр ел буе сәхнәдән төшмичә, зур уңыш белән бара.

1939 елда Шакир Мәҗитов Казанга килеп, Академия театрына артист булып урнаша. Бу театрда ул «Ярлылык гаеп түгел»дә — Любим Тарасов, «Хуҗа Насретдин»да — Зәйнагый, «Каюм Насыйри»да — Гали Чокрый, «Мәйсәрәнең хәйләсе»ндә — Һидият, Мирсәй Әмирнең «Миңлекамал»ында Гайнетдин колхозчы образларын иҗат итә һәм тамашачыларда җылы тәэсир калдыра.

Казанга килгәч, Шакир Мәҗитов композиторлык хезмәтен дә җанландырып җибәрә. 1942 елда Татар дәүләт академия театрында үзбәк әдәбияты классигы Хәмзә Хәким Задәнең «Мәйсәрәнең хәйләсе» дигән пьесасы куела. Шакир Мәҗитов бу спектакльгә музыка иҗат итә. «Хаҗи әфәнде өйләнә», «Яңа Казан», «Бишек җыры», «Яшьләр алдатмыйлар» (Республика күчмә театры) спектакльләренә музыкаль оформлениеләр яза. Абдулла Әхмәтнең «Салкын чишмә», Халикъ Садриның «Таң кызы», С. Хәснинең «Хәйләкәр Таҗи», «Кисек баш» спектакльләренә дә ул музыка яза.

1958 елда Республика күчмә театры Шакирның «Резидәкәй» дигән музыкаль әсәрен сәхнәгә куйды. Бу спектакль аеруча зур уңыш казанды. Шакир Мәҗитов үзенең Казанга килгәннән соң иҗади эшчәнлеге турында үзе болай дип искә ала: «Казанга килгәнче минем композиторлык эшемә, шул юлдан тайпылмыйча алга баруыма Оренбургтагы Мөсәллим агай Вәлиев ярдәм итсә, Казанга килгәч, аның урынын хезмәт иярләренең иң сөекле, иң яраткан композиторы Салих Сәйдәшев алды. Кешелек сыйфатлары, сизгерлеге, практик ярдәме белән ул мине татар композиторларына якынайтты, иҗатымны рухландырды...

Казанда консерватория ачылуга, без Заһид Хәбибуллин белән шунда укырга кирәк. Консерваториягә студент булып керүемне Салих Сәйдәшев бик хуплады.

— Укы, Шакир дус, юлыңнан адашма, көйләрең, моңнарың матур, халкыбызның нечкә хисләренә кагыласың. Иҗат уңышлары телим,— диде.

Авыр Ватан сугышы елларында без Салих Сәйдәш белән бер коридорда яшәгән идек. Мин музыка язсам, ул, кереп, тыңлап, мин язган көйгә карата фикерен әйтә, аңа төзәтмәләр ясый торган иде. Минем ул вакыттагы күп кенә җырларым шул иҗади дуслык нигезендә туды.

Музыка белемен күтәрүдә Ш. Мәҗитовка шулай ук Василий Виноградов, Мансур Мозаффаров, Заһид Хәбибуллин, Ключаревлар да зур булышлык иттеләр. Шакирның Ватан сугышы чорында язган җырлары Татарстан композиторларының беренче съездында тикшерелеп, аларга зур бәя бирелде һәм аны композитор итеп таный башладылар. Нәтиҗәдә, аның моңнары халык арасында бик тиз таралды.

Сугыш елларында Ш. Мәҗитовның үпкә авыруы янә ачылды. Без, дуслары һәм Салих Сәйдәшев, аны больницага урнаштырырга теләсәк тә, бөтен больницалар сугыштан кайткан яралылар белән шыгрым тулы иде. Бу эштә безгә Александр Сергеевич Ключарев ярдәм итте. Аның ярдәме белән больницага урнаштырган көнне үк Ш. Мәҗитовка операция ясап, аны үлемнән коткарып калдылар. Сәламәтлеге арулана башлагач, ул яңадан өйгә кайтты.

Беркөнне кич мин спектакльдән кайтып кергәндә, Шакир пианино янында утыра, нәрсәдер яза иде. Бер-ике нотаны пианинода кычкыртып карый да тагы нәрсәдер язып куя. Үзе авыз эченнән генә нидер көйли. Мине күрү белән, балаларча шатланып:

— Әнкәсе, утыр әле, миңа тыңла! — дип, бер көй уйный башлады. Бер мәртәбә уйнап чыккач, әкрен генә җырлап күрсәтте.

Бу вакытлы гына юксынуым,
Дусларымның исе китмәсен,
Тик ярата белгән кеше генә
Сагына шулай үзенең иптәшен.

Бу аның С. Хәким сүзләренә язган атаклы «Юксыну» җыры иде.

Ул һәр җырның текстын күңелдән ятлап, тәмам үз итеп бетергәч кенә аңа көй яза иде. Аннары шул көйне кабат-кабат безгә уйнап күрсәтә.

Шакир Мәҗитов үзенең композиторлык иҗатын турыдан-туры Сәйдәш йогынтысы белән башлады һәм шул юлда уңышлы эшләп, соңга таба үзе дә үзенчәлекле бер композитор булып әверелде. Хәтта аның җырларына сокланып, көйләренә ияреп язучылар да булды. Мәсәлән, А. С. Ключарев бервакыт Ш. Мәҗитовның үзенә үк әйтте:

— Шакир! Син ачуланма инде, мин синең «Чын мәхәббәт» көеннән илһам алып, «Татарстан» дигән җыр яздым,— диде.

Шакир көлде дә:

— Хәерле булсын. Дусларым минем иҗатымнан илһам алалар икән, бу минем өчен шатлык кына! — диде.

«Татарстан» җырының соңгы өлеше чыннан да Шакир җырына бик охшаш иде.

Сибгат Хәким белән Шакирның иҗат дуслыгы 1948 елдан башланды. Моңа әлеге шул «Юксыну» җыры сәбәпче була. Аны беренче башлап Зифа Басыйрова җырлый. Һәм ул бик тиз популярлашып фронт сызыкларына кадәр барып җитә. Җыр текстының авторы Сибгат Хәким дә шунда фронтта ишетә аны. Җыр аңа да бик ошый. Сугыш бетеп, Сибгат Хәким Казанга кайткач, Зифаны очрата да ул җырның көен кем язганлыгын сорый. Зифа Шакир Мәҗитов язганлыгын әйтә. Шуннан соң Сибгат Шакирның үзен күреп тә сөйләшә һәм алар арасында озакка сузылган иҗади дуслык урнаша.

1951 елда Ш. Мәҗитов Сибгат Хәкимнең «Шагыйрьнең бала чагы» поэмасына музыка язып, аны үз постановкасында радио аша тапшыра. 1958—1960 елларда С. Хәкимнең «Яшьләр җыры», «Әйт, акыллым», «Совет армиясе» исемле җыр текстларына көйләр яза. Шул ук вакытта Шакир күп кенә башка шагыйрьләр, драматурглар белән дә нык элемтәдә булып, аларның әсәрләренә дә көйләр язды. Аның иҗаты күп кырлы иде. Ул романслар, ариозалар, скрипка, фортепиано, виолончель өчен әсәрләр, трио, квартетлар язды.

Шакир Мәҗитов нәни балалар өчен дә иҗат итә иде. 1964 елда балалар өчен «Нәниләр җыры» дигән җырлар җыентыгы бастырып чыгарды.

Шакир Мәҗитовның барлыгы 100 гә якын җыры бар. Алар татар совет җыр музыкасының якты бер сәхифәсен тәшкил итәләр.

1957 елда башкалабыз Мәскәүдә, татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында композитор Шакир Мәҗитовның иҗатына зур бәя бирелде: ул Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде. Ләкин Мәҗитовның каты авыруы аны 1968 елның 13 сентябрендә арабыздан вакытсыз алып китте.

Ул татар совет музыкасына һәм сәнгатебезгә шактый өлеш керткән халыкчан композиторларыбызның берсе иде. Аның музыкасы, җырлары, моңнары халыкта яши.

**Евгений Гортинский,**
«Комсомольская правда» газетасы хәбәрчесе

# АРКТИКАГА СӘЯХӘТ

Бу репортаж да, хәбәр дә, Арктиканы яулап алу турындагы мәкалә дә түгел. Ә самолетта очканда, «Капитан Кондратьев» дизель электроходында, «Владивосток» боз ваткычында йөзгәндә һәм Төньяк Котып океанында хәзер дә хәрәкәт итә торган яссы өсле айсбергка урнашкан «Северный полюс-22» фәнни-тикшеренү станциясендә булганда куен дәфтәренә теркәлгән юл язмалары. Алар «Казан утлары» журналын укучы якташларым өчен махсус язылды.

Автор.

Безнең бала чак Арктика бозлары романтикасы белән тулы иде. Иптәш малаемның исемен дә Роальд кушканнар — Амундсен хөрмәтенә. Ә күрше кызы Лапанальда исемле иде. Аңлатмасы болай: лагерь папанинцев на льдине, боз өстендә папанинчылар лагере.

Мәктәп күргәзмәләрендә дә атаклы Папанин бозлары булмый калмый иде. Без аны мамыктан ясап, крахмал келәе белән катыра идек: тыгыз кар өеменнән аера алмассың. Ә палаткалар ясау өчен ватман кәгазен кулланабыз. Папанинчылар фигураларын һәм Веселый кушаматлы көчекне үзле балчыктан яки әле яңа гына күренә башлаган пластилиннан ясыйбыз.

Шәһәр үзешчән олимпиадасында берничә кеше, һичшиксез, бер үк шигырьне укый:

Боз өстендә яши дүрт иптәш,
Җир шарының иң түбәсендә.

Папанинчыларга багышлап чыгарылган коңгырт-алсу төстәге ун тиенлек һәм илле тиенлек зәңгәр төстәге маркалар безнең өчен зур байлык иде.

Әлбәттә инде, ишегалларында, тыкрыкларда ул вакытта Казан өчен гадәти булган калын кар катлавын казып кереп, папанинчылар булып уйный идек.

Казанга Отто Юльевич Шмидт килгәнен хәтерлим. Якташларыбыз аны СССР Верховный Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәткәннәр иде. Ирек мәйданында иде бугай, зур митинг булды. Анда партиянең өлкә комитеты, опера һәм балет театры биналары юк иде әле. Шмидт Октябрь һәм Май бәйрәмнәренә һәр елны ике мәртәбә матур итеп буяла торган агач трибунадан сөйләде. Икенче көнне аның рәсемнәре барлык республика газеталарында басылып чыкты. Ә Шмидт челюскинчылар лагерена киләчәктә боз өстендә йөзеп йөри торган станцияләрнең башлангычы дип бәя биргән галим.

Еллар үткәч, инде Казан университетында укыганда «Северный полюс-4» фәнни-тикшеренү станциясендә университет шәкерте Л. Ф. Овчинниковның метеоролог булып эшләвен ишеттек. Күп тиражлы «Ленинец» газетасы редакциясенең тар бүлмәсенә җыелышып, аңа телеграмма яздык. Барып җитәсенә дә, җавап киләсенә дә ышанмаган идек. Ә җавап килде, без аны «Ленинец» газетасына да бастырып чыгардык...

Һәм менә көтмәгәндә узган ел минем үземә:

— Котыпка барасың килмиме? — дип мөрәҗәгать иттеләр.

Тиз генә юлга әзерләнергә керештем; сигаретлар, җылы күлмәк, бүрек, пленкалар, блокнотлар көч-хәл белән портфельгә сыйды. Сыймыйча калган әйберләрне салырга кызым пионерь лагерена йөри торган чемодан кирәк булып чыкты.

*
* *

Минем маршрут: Амдерма — Тикси — Чокурдах — Певек.

Арктика. Мәңге туң җирләр. Тундра. Йортлар субайлар өстенә салынган.

Элегрәк мәңгелек туң җирләрне мин бик гади итеп күз алдыма китерә идем. Алар Котып түгәрәге артында гына кебек иде. Менә сиңа кирәк булса: мәңге туң җирләр Советлар Союзы территориясенең 43 процентын, Канаданың яртысын били икән. Мәңге туң җирләр Монголиядә, Төньяк-Көнчыгыш Кытайда, Чили һәм Аргентинада да күп икән. Болар турында миңа ике ел элек Якутскида, мәңгелек туң җирләрне һәрьяклап өйрәнә торган бердәнбер учреждениедә — Мәңгелек туң җирләр белеме институтында сөйләделәр.

Мәңгелек туң җирләр транс-себер тимер юл магистрален салганда зур мәшәкатьләр тудыра. Күзгә күренмәс ниндидер көчләр тәэсирендә бер заман кинәт юллар чалышая, станциядәге корылмалар җимерелә башлый. Менә шуннан соң инде җир астындагы бу «зәхмәт»нең үз-үзен тотышын өйрәнә башлыйлар.

Туң җирләрне чын-чынлап өйрәнү Совет власте елларында башлана. Якутскида «Главсевморпути»ның туң җирләрне өйрәнү буенча станциясе барлыкка килә.

Хәзер институтка Төньякны үзләштерүче барлык һөнәр ияләре мөрәҗәгать итә: төзүчеләргә дә, нефтьчеләргә дә, энергетикларга да теге яки бу очракта мәңге туң җирнең үзен тотышын белергә кирәк.

Кечкенә генә амбар салганда да институт галимнәренә мөрәҗәгать иткән чаклар бар иде. Хәзер инде биш катлы йортлар салу буенча да барлык мәсьәләләр практик яктан хәл ителгән. Хәл ителгән мәсьәләләр урынына яңалары чыгып тора: газ үткәргеч торбаларны ничек салырга — җир өстеннәнме, җир астыннанмы? Яки котлованнарда — әгәр төбе тигез түгел икән — бетон эшләрен алып барырга ярыймы? — дип, КамАЗ төзелешеннән мөрәҗәгать итәләр, тиз вакыт эчендә җавап сорыйлар. Авыл хуҗалыгы белгечләренең дә үз таләпләре бар.

Канада язучысы Фарли Мауэт, Якутиягә барып кайткач, болай дип яза: «Минемчә, Төньяк Америка Советлар Союзының Төньягы үсешеннән 50 елга артта калган: Канада Төньягының тарихы үсеш тарихы түгел, ә аны эксплуатацияләү тарихы»...

Без утырган «ИЛ-18» самолеты тәгәрмәчләре аэродром бетонына йомшак кына орына. Бу бетонда да бит мәңге туң җирләрне өйрәнүче галимнәр хезмәте бар...

*
* *

Папанинчылардан мин Кренкельне яхшы белә идем. Үз сүзендә нык тора торган кеше иде ул. Редакция заказ биргән мәкаләне, алдан сөйләшкәнчә, көне белән, сәгате-минуты белән редакциягә җиткерә иде.

Аннан Эрнест Теодорович Антарктидага китте. Ул җибәргән радиограммалардан газетага материал әзерләү безнең өчен бәйрәм була торган иде.

Кренкель безнең редакциягә еш килә иде. Үз хәбәрчеләребезнең киңәшмәсендә дә чыгыш ясаганы бар. Үз дигәнен итмәгән кешеләргә аның ихтирамы юк иде: хет шартла — максатыңа иреш. Һәм ул үзе дә шундый иде. Алтмыш яше тулып узса да, Антарктидага кышлауга үзе теләп китүе моның ачык мисалы.

Редакциягә Кренкель үләренә бер көн кала килгән иде. Шуңа күрә аның үлеме безнең өчен һич тә көтелмәгәндә булды. Хәер, үлемне беркем дә беркайчан да көтеп алмый...

*
* *

— Котыпта, боз өстендә кыш үткәрергә сәләтле поляр тикшеренүчесе булу өчен нинди сыйфатларга ия булу кирәк?

Бу сорауга Арктика һәм Антарктика фәнни-тикшеренү институты директоры, Социалистик Хезмәт Герое, профессор А. Ф. Трешников болай җавап бирә:

«Хәзерге поляр тикшеренүчеләре гадәттән тыш кешеләр түгел, гади кешеләр, физик яктан сау-сәламәт, теге яки бу һөнәрне яхшы итеп үзләштергән кешеләр.

Даими түбән температуралы һава, озакка сузыла торган поляр төн, кешеләр белән аз аралашу, кинәт боз ярылып китү куркынычы, һичшиксез, кешеләрнең психикасына йогынты ясый. Бу шартларда яшәү һәм эшләү өчен, әлбәттә, билгеле дәрәҗәдә ихтыяр ныклыгы кирәк. Коллективның бердәмлеген, алга куйган бурычларны яхшырак итеп үтәүгә юнәлдерелгән уртак омтылышлар да зур роль уйный. Ә алар үзара ярдәмләшүдән, бер-береңнең кайбер вак-төяк кимчелекләрен күрмәмешкә салышудан башка мөмкин түгел...»

*
* *

Певек порты. «Капитан Кондратьев» дизель электроходына көнетөне йөк төяләр. Боз утравында кирәк булачак барлык нәрсәне. Фәнни җиһазлар. Җыелма йортлар. Тракторлар. Кинофильмнар. Китапханә. Шартлагыч матдәләр. Әлбәттә инде, һәркем иң башта «үз кирәк-ярагын» төяргә тырыша. Әмма барысы да ташышырга тиеш бер нәрсә бар — ул ...мунча ташы. Әйе, әйе, иксез-чиксез

киңлекләргә җәелгән боз океаны уртасында парлы мунча да булачак. Станция начальнигы эшләрен башкаручы Артур Чилингаров: «Таш ташуга өлеш кертмәгән кешене мунчага кертмим»,— ди.

Фәнни тикшеренүләр, күзәтүләр колачы киңәйгән саен боз өстендә кыш уздыручыларның тормыш шартлары да чагыштыргысыз уңайлаша бара. Папанинчыларны гына күз алдына китерик.

Папанинның «Боз өстендәге тормыш» дигән китабын үзем белән алган идем. Шуны актарам. Анда мондый юллар бар:

«Ул көн материкта вакыттагы бәйрәм алды көненә охшаш иде. Эрнст Рудольф утравына чираттагы метеорологик күзәтүләр нәтиҗәсен тапшыргач, барыбыз да кухняга җыелдык. Баш юу өчен зур гына савыт әзерләдек, кырыну әсбапларын алып килдек... Соңгы тапкыр кырынуыбыз моннан бер ай элек булган иде. Ә башларны Рудольф утравыннан очып китәр алдыннан юган идек.

Женя, җылы су белән чылатып, минем чәчне кырды. Яхшылап юындым. Безнең шартларда шуннан да артыгы мөмкин түгел. Чын мунчага кергәнче әле бер ел көтәсе бар. Бүгенге кебек юыну исә бер айга бер генә эләгә».

Һәм тагын:

«Шулай да бүген салкын тидердем, Петрович арканы скипидар белән уарга кереште. Аның куллары докторныкы кебек чиста булырга тиеш. Әмма ул эштән генә кайткан иде, кулларына карасам — машина маена буялып беткән. Петр Петрович аркага скипидар уганда, аның кулындагы кара май бик тиз миңа күчте...

Җитмәсә тагын, шаярта:

— Кулларны чистарту өчен иң яхшы ысул: синең арканы скипидар белән уу, — ди...

Шунысы кызганыч: шул вакыт аркамны көзгедән карый алмадым. Мөгаен, аркам кара тасмалардан зебрага охшашлы булгандыр...»

Эрнст Теодорович Кренкель — мәзәк сүз әйтергә яратучы кеше — бу очракны да ычкындырмый: «Ашар алдыннан кулларыгызны юыгыз!» дигән лозунгны Төньяк Котыпта да элеп куймаслар инде сезгә»,— ди.

Папанинчыларның эшләре һәм көнкүрешләре өчен боз өстенә ун тонна йөк китерелә. Әлбәттә, заманы өчен бу бик күп. Алар палаткаларда торалар, ә палатка керосин лампасы белән җылытыла. Станциядә врач та, аш пешерүче дә булмый. Хәзер Котыпта кышлаучылар карамагында электр һәм газ плитәләре, автомат телефон станцияләре булганда, ул вакыттагы шартларны күз алдына китерү дә кыен.

*
* *

«Капитан Кондратьев» — яңа судно. Херсон верфеннән ул 1972 елның сентябрендә генә чыккан. Беренче декабрьда аның өстенә СССРның Дәүләт флагы күтәрелә. Аңа чын диңгезче һәм әйбәт кеше Кирилл Георгиевич Кондратьев исеме бирелгән.

...Бу Бөек Ватан сугышы елларында була, 1944 елның өченче мартында. Америкадан кайтып килүче «Белоруссия» пароходы Охот диңгезендәге Лаперуз бугазы районында бозлар арасына эләккән «Маныч» пароходына ярдәмгә юнәлә. Әмма барып җитә алмый, немецларның су асты көймәсе аңа торпеда җибәрә. Пароход шартлап бата.

Утыз биш диңгезче, капитан Кондратьев командалыгы астында, давыллы җилдә бердәнбер исән калган шлюпкага күчеп котылырга тырышып карый. Алтынчы тәүлек киткәч, шлюпка бозлар арасына

кысылып ватыла. Диңгезчеләр, йөзмә бозга күчеп, Итуруп утравына таба китәләр. Давыллы-буранлы көннәр була. Егерме беренче тәүлектә ике генә кеше исән чыга...

Хәзер дизель электроход батыр капитан исемен Арктика диңгезләрендә горур йөртә. Ә «Владивосток» бозваткычы югары киңлекләрдәге бозлар арасында аңа юл яра...



*

* *

Лонг бугазын уздык. Куе зәңгәр су өстендә зур-зур ак боз ватыклары. Бер боз тавы өстендә ак аю тора, күзләре безгә төбәлгән, янында балалары. Әледән-әле су астыннан зур тешле моржлар борын төртәләр. Арктиканы ялыктыргыч гел бер төстә диләр. Бу һич тә дөрес түгел. Боз таулары янында су йомшак яшел төстә булып күренә, бозлар Котып кояшы астында әллә ничә төскә керә. Врангель утравындагы сопкалар түбәсендә ап-ак кар бүрекләр. Авыр соры болытлар урыны-урыны белән никтер апельсин төсенә кергән.

*

* *

Дизель электроходның кают-компаниясендә «СП-22» станциясе начальнигы Владимир Георгиевич Мороз экспедиция турында сөйли, аның членнарына характеристика бирә.

— Без моңа кадәр тиңе булмаган масштабта Арктиканы штурмлыйбыз,— ди ул. — Безнең галимнәр планетабызның боз бүреген комплекслы программа нигезендә өйрәнүне тормышка ашыралар. Бу программа бер үк вакытта унөч миллион ярым квадрат километр мәйданга җәелгән Котып бассейнын аркылыга-буйга очып чыгуны, боз өстендә йөзеп йөри торган 400 автомат станциясе урнаштыруны, галимнәр, төрле белгечләр катнашында фәнни-тикшеренү станцияләре оештыруны эченә ала. Котыптагы диңгезләрнең боз режимын, планетаның Төньяк ярымшарындагы гаять зур территориясендә һава хәлләрен алдан билгеләү өчен атмосфера белән океанның үзара бәйләнешен ачыкларга кирәк. Йөзеп йөри торган ике-өч станция белән генә моны хәл итеп булмый. Арктиканың иң ерак почмакларын тикшерү өчен махсус база кирәк.

Арктика һәм Антарктика фәнни-тикшеренү институтында «Күзге Төньяк» проекты эшкәртелде. Электрон-хисаплау машинасы ярдәмендә мондый базаның кайда урнаштырылырга тиешлеге беленде. Машина күрсәткән урында боз разведчигы, тәҗрибәле гидролог В. И. Шильников Көнчыгыш Арктикада ун квадрат километр мәйдандагы һәм утыз метр калынлыктагы боз атавы тапкач, кешеләр эшли торган станция оештырырга, фәнни тикшеренүләрне киңрәк җәелдерергә һәм шуның белән елга ике йөз мең сум акча янга калдырырга мөмкинлек ачылды.

Күптән түгел Шильников боз атавы өстенә СССР Дәүләт флагы эленгән флагшток урнаштырды...

«Капитан Кондратьев» бортына станция өчен 500 тоннага якын йөк төялде. Исәпләп карагыз: бер тоннадан аз гына артык йөк төйи ала торган «ИЛ-14» самолетына шул кадәр йөк илтү өчен ничә рейс ясарга туры килер иде. Тагы шуңа очу полосасы ясау мәшәкатьләрен, вакытның тар булуын, һава хәлләре торышын өстик... Димәк, бозваткыч белән юл ярып бару — иң арзанга төшә торган юл. Шуны да әйтергә кирәк: судноларда туп-туры йөзеп йөри торган станциягә төшү бездә инде өченче тапкыр кабатлана.

Экспедиция составында тәҗрибәле белгечләр, аларның күбесе боз өстендә инде берничә кыш уткәрделәр.

**Федор Петрович Заяц** — өлкән инженер-метеоролог. Аның күзәтүләре һәр вакыт югары бәяләнә. Ул станциянең парторгы.

**Николай Суганяко** — океанограф һәм астроном. Күптән түгел ул өченче һөнәр — шартлатучы һөнәрен үзләштерде.

**Константин Иевлев** тә ике һөнәр иясе: инженер-метеоролог һәм радист.

Ә **Олег Брок** — радио остасы. Ул иң кыен очракта да Зур Җир белән элемтәгә керә ала.

Врач **Святослав Дерпгольц** кына боз өстендә кыш уткәрергә беренче тапкыр бара. Шулай да без аның өчен борчылмыйбыз.

Повар **Валентин Дондуковның** «СП-19» станциясендә пешергән шашлыкларын әле дә сагынып искә алалар. Менә дигән пешекче һәм яхшы иптәш.

**Анатолий Кунделев** — югары класслы инженер-механик, станциянең техник йөрәге.

**Михаил Судаков** — механик һәм шул ук вакытта һәр экспедициядә Яңа елны каршы алганда Кар кызы ролен дә башкара.

Ниһаять, **Артур Чилингаров.** Көньяк Котыпта да, Төньякта да булган кеше. Мин юк чагында, теге яки бу эш белән Ленинградка очканда, начальник урынына кала.

Тугыз кешенең һәрберсе «коллективта яши ала» дигән формулировкага җавап бирерлек.

— Ә боз өстендә кыш уздырганнан соң, «коллективта яши алмый» дигән характеристика бирерлек кешеләр булдымы?

— Булгалады. Андыйлар бүтән беркайчан да экспедициягә җибәрелми.

Ә Мороз үзе инде егерме өченче Котып экспедициясенә катнаша.

*
* *

Певекта чыга торган газета алда торган экспедициягә бөтен бер полоса багышлаган. Төньяк полюсны үзләштерү буенча да күп кенә тарихи фактлар китергән.

Врач Святослав Дерпгольц газетаны кычкырып укый һәм язылганнарга аңлатма бирә:

«...Грили экспедициясендә 18 кеше үлеп кала». Дуслар, ә безнең экспедициядә барысы тугыз кеше!

*
* *

Каютада кичке әңгәмә. Баштан узган мәзәк хәлләрне сөйләшәбез.

Николай Суганяко сөйли:

— Гидрология палаткасында беркөнне үзем генә калдым. Начальник баш тәртеп алам дип чыгып китте. Озак та үтми, кабат килгән бу, артымда мышнап тора. «Ник бик иртә килдең, Степанович?» — дип сорыйм. Җавап бирми. Әйләнеп карасам — Степаныч түгел, Михалыч икән. Ак аю кунакка килгән. Тиз генә карабин алдым. Куллар калтырый. Тидерә алмадым. Шартлау тавышыннан куркып, чыгып сызды...

Анатолий Кунделев:

— Ә безнең станциягә ак аю үзенең балалары белән килгән иде. Безне, сакаллы кешеләрне, күргәч куркып качты...

Михаил Судаков:

— Ә бездә бер мужик бар иде. Сакалы — бер аршин. Бер тотып караган өчен 200 сум сорый иде. Әмма тотып карарга җөрьәт итүче булмады...

Минем янда Геннадий Елизаров утыра. Ул «Север-25» экспедициясенә катнашкан. Ә хәзер «СП-22» экспедициясен озата бара. Минем колакка иелеп:

— Шәп егетләр бит,— ди ул. — Ни генә эшли башласаң да килеп җитәләр: «ярдәм кирәкме?» Алар белән беркайда да ким-хур булмассың!

*
* *

Артур Чилингаров белән «Владивосток» бозваткычына барып кайтырга булдык. Диңгез өстендә — зур-зур дулкыннар. Бозваткыч катеры «Капитан Кондратьев» бортына һич кенә дә килеп туктый алмый. Шторм-троп белән аска төшәбез. Соңгы баскычка төшеп җиткәч, катердан кычкыралар:

— Дүрт аяклап сикер!

Файдалы киңәш. Катерда палуба өсте бозланган, каток кебек. Үзе гел чайкалып тора. Тотынып кала алмасаң, бозлы суда коенасыңны көт тә тор.

*
* *

Бозваткыч өстеннән түбәнтен генә «ИЛ-14» очып үтте. Боз разведкасы вымпелын ташлады. Атау тирәләрен күп еллык калын боз каплаган. Арктиканың Көнчыгыш районнарында диңгез операцияләре штабы начальнигы Вадим Иванович Абросимов безне озатканда болай дигән иде:

— Ашыгыгыз, югыйсә, судногыз белән плансыз йөзмә станциягә әверелерсез.

Ул, әлбәттә бозлар арасына кысылып калуны күз алдында тоткан иде.

*
* *

«Владивосток» бозваткычы борты. Коридорларга матур паласлар җәелгән. Плафоннар йомшак яктылык сибә. Стенага лотерея таблицасы эленгән. Биллиардка шундый язу эленгән: «Туры суга белмисең икән, таякны күршеңә бир.» Тормыш үз җае белән ага. Кемдер шахмат уйный, кемдер югары диңгез училищесына имтиханга әзерләнә, кемнәрдер урта мәктәптә читтән торып уку классында утыра. Радио вахтадан буш диңгезчеләрне вертолет ангарына волейбол уйнарга чакыра. Чабынырга яратучылар — фин мунчасында: чабынып чыгалар да бассейнга чумалар. Мәскәүдәге Сандун мунчалары бер якта торсын. Кают-компаниядә паркет ялт-йолт итә. Котыпка юлга чыксаң, галстукларыңны, лаклы туфлиларыңны да онытмаска кирәк икән.

*
* *

Бозларны күзәтергә разведкага киткән вертолет кайтканын көтәбез. Инде караңгы төшә башлады — дулкынланабыз.

— Җиде йөзенче, җиде йөзенче, ишетәсеңме?! Бортка кайтыгыз.

Җавап юк. Соңыннан гына билгеле булды: вертолет буранга эләккән һәм элемтәне югалткан булган икән. Ниһаять, пилот Владимир Кудрявцев идарә рубкасына килеп керә.

Хәбәрләр шатланырлык түгел: күп еллык калын бозлар тоташ җәелгән.

Капитан-наставник Николай Федорович Инюшкин белән бозваткыч капитаны Николай Павлович Анчуктин бара алган хәтле алга барырга дигән карарга киләләр.

Тоташ кар ява. Прожектор күз күременә комачаулый гына. Боз өстенә калын кар капламы ятты: тирә-як бер үк төстә — ап-ак. Ә диңгезчеләр беләләр: күп еллык боз бер төсле, ике, өч еллык боз икенче төсле була. Алты төрле бозны төсенә карап белеп була икән. Төсләргә карап бозлар аша үтәрлек урынны аералар. Идел белән Камада гына ул фарватерны маяклар һәм төрле билгеләр күрсәтә, биредә маякчылар юк. Арктикада капитан тәҗрибәгә һәм интуициягә генә таянып эш итә.

Бозваткыч борыны йомшак-зәңгәр төстәге боз кисәкләрен як-якка яра. Рәттән генә дельфиннар шаяра...

*
* *

Ниһаять, тоташ күп еллык боз кыры башланды. Биниһая зур утюгны хәтерләткән бозваткыч калын боз өстенә сикерә, аннан тагын чигенә, чигенә дә бар көченә кабат алга омтыла. Менә дурт метр калынлыктагы боз катламы каты шытырдап, гөрселдәп җимерелә, эре-эре кантарларга ватыла.

— Әгәр әлеге боз атавы барлыгын белмәсәк,— ди капитан-наставник Николай Федорович Инюшин,— станция өчен шундый калынлыктагы боз өстен дә кулай күргән булыр идек.

Бозваткыч бөтен корпусы белән тагын калтыранырга керешә. Үзеңне зилзилә вакытындагы кебек хис итәсең, әле бер якка, әле икенче якка чайкаласың. Өйләрдәге кебек электр лампалары асылынып торса, беркетелеп куймаган булса, телефон трубкалары махсус кыстыргычта булмаса, нишләп кенә бетмәсләр иде икән?..

*
* *

Җитмеш алтынчы параллельне узгач, дрейфка яттык, ягъни двигательләр эшләүдән туктады. Ә боз атавы — айсберг кайда соң?

Мәскәүдә хәзер кичәге кичке сәгать ун. Ә биредә инде бүгенге иртә. Хәер, биредә төн булмады диярлек. Чөнки беркем дә йокламады. Идарә рубкасында бинокль кулдан-кулга күчә. Владимир Бурачков белән Анатолий Кудрявцев тагын разведкага җыеналар.

— Артур, алар белән мин дә барыйм әле?

Рөхсәт иттеләр. Аста иксез-чиксез ап-ак боз кыры. Ара-тирә, сирәк-мирәк кенә күләвекләр күренә, анда-монда боз өемнәре калкып тора, алар махсус зәңгәр төскә буялган кебек.

— Бу урында диңгез тирәнлеге өч мең метр,— ди Кудрявцев.

Ап-ак кар каплаган боз өсте күзләрне авырттыра. Айсберг өстендә калдырылган Кызыл флагны һәрберебез иң беренче булып күрергә тели. Әмма тырышуыбыз юкка. Бозваткычка әйләнеп кайтабыз. Беркем дә сорашмый: болай да ап-ачык.

— Артур, кичә мине нигә алар белән җибәрмәгән идең?

— Һава начар иде. Син бит безнең кебек васыятьнамә язып, кул куймаган...

*
* *

Яссы өсле айсберг өстенә иң беренче булып Мороз белән Чилингаров төште.

Вертолет Кызыл флагның янына ук төшеп утырды. Вымпел белән түбәндәге язу калдырылган иде.

*«Хөрмәтле котыпчылар!*
*Атауны зур кыенлык белән генә таптык. Томан, кар катламы комачаулык тудырды. Шуңа карамастан, атау белән кабат очрашу бик күңелле булды.*
*04198 номерлы «ИЛ-14» самолеты экипажы: корабль командиры Олег Охонский, икенче пилот Александр Сулеев, борт-механик Валентин Лоскутов, борт-радист Владимир Савкин, штурман Олег Замятин, гидрологлар Василий Шильников белән Леонид Читов, термосъемщик Александр Парамоновлар Сезгә уңышлы дрейф телиләр. Сезне безнең өчен дә якын булып өлгергән бу боз атавында очратуыбызга шатбыз»...*

Суднолар айсберг янына килеп җиткәндә, анда инде радиостанция, кают-компания, камбуз, соляр, шартлаткыч матдәләр складлары булачак урыннарга билгеләр куелган иде.

*
* *

Боз атавына төшәр алдыннан экспедициягә катнашучыларга кечкенә генә анкета язып тараттым:
1. Сезне Арктикага нәрсә тарта?
2. Котыпта эшләү өчен, сезнеңчә, нинди сыйфатларга ия булу кирәк?
3. Сез үзегез белән бүтән беркемдә дә булмаган нинди әйбер алдыгыз?
Җаваплар:

**Федор Заяц, өлкән инженер-метеоролог.**
1. Арктикасыз яши алмыйм. Гел үзенә тарта.
2. Кыюлык, батырлык, кыенлыклар алдында туктап калмау сәләте.
3. Хатынымның һәм балаларымның рәсеме.

**Николай Суганяко, океанограф, астроном.**
1. Акча гына түгел, әлбәттә. Хәер, безнең эш хакы да, бик күпләр уйлаганча, ул кадәр зур түгел. Ленинградта гел Төньяк үзенә тарта, ә Төньякта өйгә кайтасы килә.
2. Иң беренче кешелеклелек. Үз эшеңне яхшы белү.
3. Балалар төшергән ике пленка. Ленинградта вакытта аларны эшкәртергә өлгермәдем. Боз өстендә эшкәртермен инде.

**Олег Брок, радист.**
1. Профессия. Мин Ленинград Арктика училищесын тәмамладым. Шул ук вакытта романтика.
2. Иң элек сәламәтлек. Һәм хезмәт сөючәнлек.
3. Эш өчен кирәкле әйберләр.

**Константин Иевлев, инженер-метеоролог.**
1. Отпуск ахырына таба Арктика төшкә керә башлый. Тынлык, тынычлык.
2. Үз-үзен тотуы, эш сөючәнлек.
3. Антарктикада киеп йөргән кепкамны.

**Святослав Дерпгольц, врач.**
1. Чын-чынлап үз-үзеңне сынарга, минемчә, Арктикада гына мөмкин. Хәер, үзем дә белеп бетермим. Бүтәннәрдән аерма буларак, экспедициягә беренче баруым.
2. Түземлелек, юмор.
3. Алты яшьлек кызымның резинадан ясалган керпесен.

**Валентин Дондуков, повар.**

1. 1969 елның август аенда «СП-19» станциясендә минем Арктик һәм комсомол биографиям башланды. Бу станциядә, В. И. Ленинның тууына йөз ел тулу көнендә, мин комсомолга алындым. Беренче мәртәбә боз өстенә аяк басканда үземне космоста итеп хис иттем. Хәзер Арктикадан башка тормышны күз алдыма да китермим. Кызыксыну, яңа тәэсирләргә омтылу шунда чакыра.

2. Кыюлык. Юмор хисе. Юморсыз кеше — котыпчы түгел.

3. Һәр экспедициягә плюш аю баласын алам.

**Анатолий Кунделев, инженер-механик.**

1. Гадәт.

2. Коллективта тату була белү. Җилкәңә бүрәнәнең авыр башын салырга әзер тору.

3. Талисманга ышанмыйм. Солярка суырту өчен үземнең гараждан «БПК» насосын алдым.

**Михаил Судаков, механик.**

1. Кызыклы эшне әллә кайдан эзләргә кирәкми. Ул — коллектив белән бергә, коллектив күз алдында эшләү. Син нәрсәгә сәләтле — коллектив күрсен.

2. Хезмәт сөючәнлек, намуслык, куркусызлык. Иптәшлек хисе — мәҗбүри. Хәер, ул Арктикада гына түгел, бөтен җирдә кирәк.

3. Газ белән яна торган зажигалка. «Без бергә чагында бу газ сине гел җылытып торсын», дип тышына язылган бу зажигалканы хатыным белән улым туган көнемә бүләк иткәннәр иде. Минем хатын — инженер-химик. Мине экспедицияләргә, «балавыз сыкса» да, каһарманнарча озатып кала.

**Артур Чилингаров, «СП-22» станциясе начальнигы эшләрен башкара.**

1. Боз өстендә кешеләрнең үзара мөнәсәбәте. Чын дуслык, рухи якынлык.

2. Вөҗданлылык, тугрылык, коллективта бер-береңне ихтирам итү.

3. Әбием бүләк иткән «тылсымлы» маймыл курчагын даими үзем белән йөртәм...

*

* *

Төн уртасында тавыш көчәйткеч динамиклардан бөтен бозвалкычка:

— Беренче һәм өченче бригадаларга боз өстенә төшәргә! — дигән боерык яңгырады. Йөк бушату расписаниесе алдан ук төзелгән иде. Анда һәркемнең кайда, нинди эштә буласы күрсәтелгән. Хәтта диңгезчеләрнең «тыныч хезмәтен» ак аюлардан саклау өчен дә махсус кеше билгеләнгән. Катгый рәвештә әйтелгән шундый җитди искәрмә дә бар: буран була калса, борттан ерак китмәскә; кар астында калган боз ярыкларыннан сакланырга; түбән температурада бозның гранит кебек үк нык булуын истә тотарга.

Йөк бушату тәүлек буена дәвам итә. Төн караңгылыгын прожекторлар яра. Тракторлар гөрелтесе бер минутка да туктап тормый: рейс вакытында ук җыелган торак йортларны, бензин, солярка мичкәләрен ташыйлар. Агрегатлар, фәнни приборлар, җиһазлар, азыктөлек — һәрберсен тиз арада бушатып бетерергә кирәк.

Ноль сәгать утыз минутта «Капитан Кондратьев» судносыннан Юрий Бурштын бригадасы эшкә керәште. Бригада 400 мичкә солярка һәм йөзләрчә килограмм шартлаткыч матдәләр бушатырга тиеш иде. Иртәнге дүрткә эшен тәмамлады...

*
* *

Валя Дондуковның кәефе киткән: чыгыр белән идарә итүче матрос тонна ярым авырлыктагы азык-төлек бәйләмен ялгыш океанга төшереп җибәргән. Багорлар белән бик аз өлешен генә тартып ала алдылар. Валяның иң кайгырганы шул: электр белән эшли торган ит тарттыргыч диңгез төбенә чумган.

— Валя, экспедициядән кайткач, һөнәреңне үзгәртергә уйламыйсыңмы?

— Сез нәрсә, һич юк. Беләсезме, мин нәрсә турында хыялланам? Бары тик үзебезчә ашлар әзерли торган ресторанда эшлисем килә. Югыйсә, гел лангетлар, эскалоплар, ромштекслар...

*
* *

Эфирга станциядән беренче радиограмма җибәрелде. Митинг. Дондуков белән Олег Брок мачтага Кызыл флаг күтәрәләр. Митинг тәмамланганда кар яварга керешге. Суднолардагы командалар вахта расписаниесе буенча үз урыннарына бастылар. Шторм-трапка юнәләбез. Трактор көпчәкләре белән актарылган кар су сеңгән тоз өемнәрен хәтерләтә.

Кемдер шунда әйтеп куйды:

— Ә көчекләр кайда соң?

Зур Җирдән үк алып килгән Рудик һәм Евражка исемле ике эт әле генә атау буйлап йөгерешеп уйныйлар иде. Шторм-трап буенча мәнә алмыйлар ич инде алар?.. Беркайда да күренмиләр. Әһә, менә кайда икән: бер-берсенә сыенышып кар өстенә ятканнар да, рәхәтләнеп йоклыйлар. Чилингаров Рудикны кулына ала.

— Артур, шул килеш тор әле. Рәсемгә төшереп алам.

— Юк инде, рәхмәт. Гидрометеослужба идарәсе начальнигы Евгений Иванович Толстиков газетадан рәсемеңне күрер иде дә әйтер иде бугай: «Менә сиңа Члингаров! Фән белән шөгыльләнәсе урында Котыпта эт күтәреп йөри!»

*
* *

ТАСС хәбәрчесе Николай Константинович үзе белән магнитофон алган. Ул экспедиция членнарына өйдәге туган-тумачаларына әйтәсе сүзләрен сөйләргә тәкъдим ясады.

Беренче булып Слава Дерпгольц сүз алды. Ул кызына мөрәҗәгать итмәкче. Кечкенә Оля әтисен бер дә җибәрәсе килмәгән. Аннары бер калын дәфтәр биргән дә шарт куйган: барсаң бар инде, тик күргәннәреңне шушы дәфтәргә язып кайт!

Слава йөткеренгәләп сүзгә керешге:

— Ляля! Син өйдә үз-үзеңне ничек тотасың? Акыллы бул, авырма... Әниең белән әбиеңне тыңла... Безнең монда тирә-якта кар. Ак аю күрдек. Синең рәсемдәге кебек. Әмма ул бөтенләй үк ак түгел, саргылтрак төстә. Бик күп моржлар күрдек. Ә без монда әйбәт яшәрбез кебек. Бик каты итеп «әп» итәм үзеңне. Ә хәзер инде әниеңне чакыр...

Аннан Валя Дондуков тавышы магнитофонга языла.

— Кадерле әни һәм туганнар! Безне бик зурлап озатып калдылар. Ике йөздән артык кеше озатты. Иң мөһиме, әни, минем өчен борчылмагыз. Иң мөһиме, үзегез әйбәт яшәгез, ә миңа монда бик әйбәт...

Кайтыр юлга чыгарга исәпле минутлар гына калды. Боз атавына суднoларны беркетеп куйган арканнарны чишү командасы төште. Ул, эшен тәмамлагач, бозваткычка вертолет белән кайтачак. Ә меха-

ник Михаил Судаков һаман магнитофон янында кайнаша, тотлыга-тотлыга сөйли, боз атавы бик зур, ди, барысы да тәртиптә булыр, «хоккей», ди. Янәсе, инглизчә әйтә: о кэй...

Чкалов та, канатларына боз катып авырайган самолетта Америкага очышлый, Котып аша үткәндә Зур Җиргә: «Барысы да тәртиптә», дип радиограмма җибәргән.

*
* *

Боз атавы акрын гына бозваткычтан артка чигенә. Безнең причал урыны — боз атавының су өстеннән чыгып торган стенасы — ерактан ук күренеп тора. Боз өстендә кышларга калучы тугыз кеше безгә кул болгый. Менә алар күздән югала. Күккә саубуллашу ракеталары чөелә...

*
* *

...«СП-22» станциясеннән радиограмма килде. Чилингаров атауда буран кубуы, суднолар торган урынга күп еллык бозлар туплануы турында хәбәр итә. Димәк, «Порт-Артур» — Артур Чилингаров хөрмәтенә ул урынга шундый исем биргән идек — ябык.

Капитан-наставник Николай Федорович Инюшкиннан экспедиция членнарының ничек урнашулары турында аңлатма бирүен үтенәм.

— Атауга барып җитү бик кыен булды,— ди ул. — Башта Аляска ягыннан килеп туктарга уйлаган идек. Аннары шушы юлны сайладык. Хәвеф-хәтәр, бернәрсә дә булмады. Бозлар ярып, сәгатенә 12,8 миль юл бардык. Папанинчылар чорында ачык диңгездә дә мондый тизлек белән йөрү мөмкинлеге юк иде. «Владивосток» — өр-яңа бозваткыч. «Капитан Кондратьев» дизель электроходы да бозлы диңгезләрдә йөри ала торган судно. Совет верфендә совет проекты буенча ясалган. Шуларга карамастан, бу сәяхәт гадәти түгел. Моңа кадәр бу киңлекләрдә бер генә бозваткыч та булганы юк. Полюсның үзенә кадәр дә барып җитә алыр идек. Әмма нинди максат белән? Мәгънәсез рекорд өченме? Җир шарын экватор буйлап бүрәнә тәгәрәтеп тә әйләнеп чыгарга мөмкин. Бу да рекорд булыр иде...

*
* *

Тагын ике радиограмма.

*«Судноларның экипажын боз атавына уңышлы рейс ясавы белән котлыйбыз, сәламәтлек, хезмәттә яңа уңышлар, хәерле юл телибез.*

*Главсевморпути, Чубаков».*

*«Йөзеп йөри торган яңа «Северный полюс-22» станциясен оештыру операциясен уңышлы тәмамлау белән чын күңелдән котлыйбыз. Экспедиция членнарының фидакарьлеге, батырлыгы нәтиҗәсендә бу авыр эш иң кыска срокта башкарып чыгылды. Суднолар экипажына, диңгез операцияләре штабына, бу мөһим заданиене тормышка ашыруга катнашкан барлык иптәшләргә нәтиҗәле ярдәмнәре өчен рәхмәт белдерәбез. Сезгә, кадерле дуслар, сәламәтлек, навигацияне уңышлы тәмамлавыгызны һәм хәерле юл телибез.*

*ААНИИ, Трешников, Крутских, Захаров».*

*
* *

...Бер ай вакыт узды. Көннәрдән бер көнне кич белән редакциягә килсәм, өстәл өстендә бер пачка телеграф бланкалары ята:

*«Мәскәү. «Комсомольская правда». Бер ай элек боз атавы өстендә Ватаныбызның Кызыл байрагы күтәрелгән иде. Хәзер инде төп*

*объектларны: метеостанцияне, радиорубканы, дизель электростанциясен, кают-компанияне, фәнни павильоннарны, торак йортларны төзеп бетердек. Тантаналы төстә парлы мунчаны ачып җибәрдек. Аңа авторы — инженер-механик Анатолий Кунделев хөрмәтенә «Кунделев мунчасы» дип исем бирдек. Мунча ачу тантанасына бик зур бер ак аю да килде.*

*Төзелеш вакытында һава хәлләре бик начар булды: бик салкынайтты, көчле җилләр, бураннар туктап тормады: коллективтан бөтен көчне биреп эшләү, зур осталык таләп ителде.*

*Беренче октябрьдан метеорология, астрономия, океонология, Котып медицинасы буенча даими фәнни күзәтүләр башланды. Бу тикшерүләр планетабызның Котып өлкәләрен планлы үзләштерүнең дәвамы булып тора.*

*«Чилингаров».*

1973 ел, 28 ноябрь. Редакциягә телетайп буенча ТАСС хәбәре алынды.

*«Төньяк боз океаны өстендә караңгы төн хакимлек итә. Самолетлар «Северный полюс-21» һәм «Северный полюс-22» фәнни станцияләренә соңгы рейс ясадылар...*

*— Авиация ярдәмендә котып бассейнын комплекслы тикшерүнең егерме бишенче сезоны тәмамланды,— диде экспедиция начальнигы, география фәннәре кандидаты Н. И. Блинов.— «Север» экспедицияләре үзләренең ачышлары белән дөнья фәненә зур өлеш керттеләр. Боз океаны төбендә зур калкулыклар, тирән батынкы урыннар табылды, югары киңлекләрдә магнит аномалияләре тикшерелде, гидрология һәм һава режимнарының закончалыгы, океан һәм атмосфера проблемалары өйрәнелде.*

*Үзенең чирек гасырлык юбилеен экспедицияләр шактый зур казанышлар белән каршы ала... Хәзер материаллар Ленинградтагы Арктика һәм Антарктика институтының электрон-хисаплау машиналары үзәгендә эшкәртелә».*

*
* *

Әле генә Ленинградка, Арктика һәм Антарктика фәнни-тикшерену институтының директоры урынбасары Н. И. Тябинга шалтыраттым:

— Николай Иванович, «СП-22» станциясенең эшенә Сез нинди бәя бирәсез?

— Бары да әйбәт. Фәнни-тикшеренүләр турында хәбәрләр даими килеп тора. Экспедиция члennарының үзалдына куйган бурычларны уңышлы үтәп чыгачакларына без алдан ук ышандык...

Яңа ел алдыннан очучылар боз атавы өстенә парашютлар белән яңа ел чыршысы, почта, яңа кинофильмнар, җиләк-җимеш ташладылар.

Дүрт ай дәвамында экспедиция члennары урнашкан айсберг көнбатышка таба 500 дән артык километр юл үткән.

Котып төне инде тәмамланып килә. Әмма анда һаман әле өермәле бураннар бик еш булып тора. Салкынлык 30—35 градус. Әмма тикшеренүчеләр «Север-26» экспедициясе самолетларын каршы алырга әзер. Коллективта һәркемнең күңеле күтәренке.

Арктика — Мәскәү.
Февраль, 1974 ел.
М. ХӘМИТОВ тәрҗемәсе.

Хәлиф Курбатов

# ИРЕКЛЕ ШИГЫРЬ

Иректе шигырь үткән гасыр азагында Франциядә барлыкка килә. Ләкин бу вакытта ул әле хәзерге ирекле шигырьне түгел, бәлки катнаш үлчәмле шигырьне белдерә. Һәм шуңа күрә аны соңыннан «верлибр классик» дип атыйлар. Икенче тапкыр күренүендә — 1885 елда — инде ул, чыннан да, бүгенге ирекле шигырь төшенчәсенә туры килә, һәм аны башлап символист шагыйрьләр куллана: «верлибр модерн» [1]. Озак та үтми ирекле шигырь, үзенә бер төрле ритмик төзелеш буларак, бөтен Европаның һәм башка җирләрнең шигъриятенә үтеп керә.

Бенжамен Хрушовски ирекле шигырь төшенчәсен белдерү өчен немец терминын — «фрайе ритмен»ны кулайрак күрә. Чөнки, ди ул, французның «верлибр» дигәненнән басымлы иҗекнең басымсыз иҗеккә мөнәсәбәте түгел, барыннан да бигрәк, силлабик система нормаларыннан азат булу күз алдына килеп баса [2]. Ләкин немец әдәбият белемендә «фрайе ритмен» бер генә мәгънәдә йөрми. Махсус әдәбиятта Гётенең «Прометей» драмасын, мәсәлән, «фрайе ритмен» белән язылган дип күрсәтәләр [3]. Ягъни бу очракта ул термин **катнаш үлчәм** дигән мәгънәгә туры килә. «Фрайе ритмен» ирекле шигырь мәгънәсендә, Э. Ризель мәгълүматларына караганда, XX йөз башларында кулланылышка керә [4].

Рус поэзиясендә бу ике төр шигырь төзелеше өчен бер-берсенә синоним була алырлык «вольные стихи» (ягъни катнаш үлчәмле шигырь; башлыча, төрле үлчәмле ямб яки хорей) һәм «свободный стих» (ирекле шигырь) терминнары йөри. «Свободный стих» белән янәшә шул ук мәгънәдә «верлибр» термины (французныкы) да кулланылышта еш очрый.

Төрек әдәбият белемендә «сәрбәст назым» (ирекле шигырь төзелеше) шулай ук киң төшенчәле. Хикмәт Илайдын ирекле шигырьне мондый өч төргә бүлә: «вәзинли-кафийәли сәрбәст назым» (үлчәмле-рифмалы ирекле шигырь), «вәзинсиз-кафийәли сәрбәст назым» (рифмалы-үлчәмсез ирекле шигырь), «вәзинсиз-кафийәсиз сәрбәст назым» (үлчәмсез-рифмасыз ирекле шигырь) [5]. Боларның беренчесе — катнаш үлчәмле шигырь. Аның мисалы да шуңа туры килә:

---

[1] З и г м у н т  Ч ё р н ы й. Француз ирекле шигыре һәм аның төзелеше. «Поэтика». Варшава. 1961. 249 бит. Мәкалә француз телендә.

[2] Б е н ж а м е н  Х р у ш о в с к и. Хәзерге поэзиядә ирекле ритмнар.— «Телдәге стиль». Томас А. Себеок редакциясендә. Кембридж. Массачусетс. 1966. 184 бит. (Җыентык инглиз телендә.) Шундый ук фикерне рус әдәбиятчыларыннан Владимир Бурич та әйтә: «...шигырь белгечләренә бик үк анык булмаган «верлибр» (Фр.— vers libre) терминын ташларга тәкъдим итәм. Чөнки француз һәм рус телләренең шигырь төзелеше төрлечә, француз верлибры белән рус ирекле шигыре ритмик яктан бер үк түгел». «Вопросы литературы» журналы. 1972. 2 сан. 140 бит.

[3] Э л и з е  Р и з е л ь. Немец теле стилистикасы. Мәскәү. 1959. 363 бит. (Немец телендә.); Эрнст Штейн. Шигырь язу ысулы. Галле. 1963 ел. 104—105 бит.

[4] Э л и з е  Р и з е л ь. Күрсәтелгән хезмәт, 364 бит.

[5] Х и к м ә т  И л а й д ы н. Төрек әдәбиятында шигырь төзелеше. Истамбул. 1958. 149—153 бит. (Төрек телендә.)

Нә сәп,
Нә бән,
Нә дә һүснүндә топланан бу мәса,
Нә дә аләми фикрә бир мәрса
Олан бу мави дәниз
Мәлали анламыйан нәслә эшинә дәйилиз.

. . . . . . . . . . . . . . . .

О бәлдә,
Дурур мәнатык-ы дүшизә-и таһаййүлдә.
Мави бир акшам
Әдәр үстүндә даимә эрам...
Итәкләриндә дәниз
Дәкәр әрваһа бир сүкүн-и мәнам.

(Аһмәт Һашим. О бәлдә.)[1]

Сүзгә-сүз тәрҗемәсе:

Ни син,
Ни мин,
Ни матурлыкны туплаган бу төн,
Ни хәсрәтле уйларга бер тукталыш
Булган бу зәңгәр диңгез
Кайгыны аңламаган буынга таныш түгел.

. . . . . . . . . . . . . . . . . .

Бу шәһәр
Тора гүзәл кыз шәүләсе кебек хыялда.
Зәңгәр бер кич —
Кыялар өстендә мәңгелек йокы...
Итәкләрендә диңгез —
Докер рухына татлы бер төш.

(Әхмәт Хашим. Ул шәһәр.)

Илайдын мисалга китергән калган ике төр шигырь, аеруча соңгысы (үлчәме дә, рифмасы да булмаганы), әлбәттә, ирекле шигырь.

Татар әдәбиятчысы Гали Халит, үзе «ирекле шигырь» терминын кулланып, бу төр шигырьнең сөйләү өчен язылуын билгеләп үтә, шул яктан чыгып аны «сөйләм шигыре» дип тә атарга тәкъдим итә[2].

Ниһаять, терминның кайсын алу-алмау традициягә дә бәйле: күпчелек халыкларның әдәбиятларында, алда әйтелгәнчә, «ирекле шигырь» термины кулланыла. Җитмәсә һәм барыннан да бигрәк, ул үзе белдергән төшенчәгә ярыйсы ук туры килеп тора, шуңа күрә мин дә шул **ирекле шигырь** термины ягында.

Гомумән, катнаш үлчәмле шигырьне дә (полиметрик шигырь), чын ирекле шигырьне дә (дисметрик шигырь) бүгенгә кадәр бер үк термин белән атап йөртү гаҗәп түгел. Чөнки ирекле шигырьгә беренче башлап юлны катнаш үлчәмле шигырь ача, табигый сөйләм интонациясе, үткен яңгырашлы сүз нәкъ шул поэтик форма табылгач, традицион шигырь кысасына буйсынмый башлый.

Махсус әдәбиятта, ирекле шигырьнең тәүге яралгылары халык авыз иҗатында, борынгы язма әдәбиятта, дигән фикерләр бар. Ләкин борынгы әдәбияттагы кайбер сөйләм өекләренең, андагы кайбер синтаксик әйләнмәләрнең (мәсәлән, анафора, эпифора алымнарының очравы һ. б.) чыннан да бүгенге ирекле шигырьгә охшап куюларын экспрессив сөйләмгә, кемнең дә булса дулкынланып сөйләвенә гомумән хас күренеш дип, ә инде, мәсәлән, кайбер йола такмак-такмазаларындагы шигырь юллары озынлыгының (башка телләр өчен — сүз басымнарының да) төр-

[1] Бирелә һәм алда да төрек шигырьләре латин хәрефләреннән хәзерге татар хәрефләренә күчерелеп бирелә (тыныш билгеләре әсәрнең үзендәгечә кала).
[2] Гали Халит. Бездә ирекле шигырь бармы? «Казан утлары», 1971, 5 сан, 152 бит.

лечә булуын поэзиянең әле камилләшеп җитмәве, аның балалык чоры кичерүе дип әйтү дөресрәк булыр [1].

Ирекле шигырьнең катнаш үлчәмле шигырьдән аерылып чыгуына Көнбатыш Европада һәм Америкада (У. Уитмен), шулай ук Төркиядә өч чирек гасырдан артык вакыт узды. Японнарга ул моннан алтмыш ел элек үтеп керә [2]. Рус филологлары ирекле шигырьнең беренче үрнәкләре итеп А. Фет (XIX йөз шагыйре) әсәрләреннән бер-ике мисал күрсәтәләр, ә аның ныклап кулланыла башлавы — В. Брюсов, А. Ахматова һәм аеруча А. Блок иҗатында:

Сколько ни говорите о печальном,
Сколько ни размышляйте о концах и началах,
Все же, я смею думать,
Что вам только пятнадцать лет.
И потому я хотел бы,
Чтобы вы влюбились в простого человека,
Который любит землю и небо
Больше, чем рифмованные и нерифмованные
Речи о земле и о небе [3].

Биредә ритмик буыннарның эзлекле рәвештә чиратлашуы юк; шулай ук һәр юлдагы сүз басымнары яки иҗекләр саны да бер үк төрле түгел; рифма бөтенләй кулланылмый. Шигырьне ирекле шигырь иткән нәрсә биредә — һәр юлның интонацион бер бөтен булып яңгыравы, һәр юл азагы саен шул интонацияне көчәйтүче чара — паузалар һәм, әлбәттә, буеннан-буена әсәрнең тоташ бер поэтик эчтәлеккә ия булуы.

Татар поэзиясендә катнаш үлчәмле шигырьнең бик яхшы үрнәкләре Сәгыйть Рәмиев иҗатында күренә башлап («Таң вакыты», 1908 ел), шуннан соңгы күп кенә шагыйрьләрнең, бигрәк тә Һади Такташның, иҗатында төп урынны ала:

Яшьлек, }
Гомерең | кыска синең, || } (8)
Шундый кыска | булып тоела, || (9)
Кичен чәчәк | аткан була, || (8)
Ә таңында | инде | коела... || (9)
Мәхәббәт, }
Ул | үзе | иске нәрсә, || } (10)
Ләкин || (2)
Һәрбер йөрәк | аны | яңарта, || (9)
Тиле яшьлек | ярты | гомерен бирә || (10)
Аның хисе | белән | янарга... || (9)

**(Һади Такташ. Мәхәббәт тәүбәсе.)**

Бу — катнаш үлчәмле силлабик шигырь. Монда гына түгел, поэманың башка урыннарында да төп үлчәм — дүртенче һәм алтынчы иҗекләрдән соң цезуралы ун да тугыз иҗекле. Ләкин күп кенә юллар шул төп үлчәмнән читкә чыгып китә: ун урынына сигез иҗек (аерым юлларны кушып язгач та ул әле шулай), берүзе аерым юлны билгәгән ике иҗек һ. б. Ритмик төркемнәрнең урнашу тәртибе исә саклана: сулда — дүрт иҗекле ритмик төркем, аннары ике иҗеклесе (яки сигез иҗекле юлда монысы юк), уңда — юл аралаш дүрт һәм өч иҗеклеләре шигырьнең буеннан-буена вертикаль булып төшә. Такташның икенче бер шигырен алыйк:

Җил бүген төн, кулларын артка салып, (11)
Йорт саен, эшле кешедәй, тукталып, (11)
Тикшереп йөри: (5)
Әүхәдинең йорт түбәсе япмаган, (11)
Әүхәди кирәк дип тә тапмаган... (10 + 1)

---

[1] Бу турыда Арсений Тарковский болай ди: «Немецларда да, французларда да, бездә дә ирекле шигырь халык поэзиясе белән бәйләнмәгән — бу очракта «Слово о полку»ны күрсәтү, миңа калса, һич нигезле түгел. Бездә ирекле шигырь барлыкка килгән вакытта рус халык поэзиясе «Слово»дан һәм былиналардан инде ерак кына түгел, бәлки шәһәр җыры һәм такмаклары чорын кичерә иде». Шунда ук Тарковский ирекле шигырьнең килеп чыгуына карата мондый фикерне дә әйтеп уза: «Без французларның шигырьне элек-электән үк, шигъри калыпка ышанмыйча, проза белән тәрҗемә иткәннәрен беләбез. Бәлки француз ирекле шигыре шундый төрдәге тәрҗемәләргә иярү нәтиҗәсе буларак барлыкка килгәндер. «Вопросы литературы» журналы, 1972. 2 сан. 148—149 бит.

[2] А. И. Мамонов. Свободный стих в японской поэзии. Мәскәү. 1971. 6 бит.

[3] Мисал В. В. Кожиновның «Как пишут стихи» дигән китабыннан алып китерелә, Мәскәү, 1970, 159 бит.

Кыш килер дә,
Җил еракларга барып, } (11)
Зур болытларны авылга өстерәр, (11)
Ул тишекләрне күмәр, (7)
Тик, (1)
Мич башында тун киеп яткан килеш, (11)
Әүхәди:
— Ай-яй, малай, салкын!..— } (11)
Дияр.
Әүхәдигә әйтегез: (7)
Түшәмгә төкереп ятмасын, (8 + 1)
Иртәгә үк йорт түбәсен капласын! (11)

Биредә — катнаш үлчәмле төрки аруз (квантитатив шигырь). Күпчелек шигырь юлларының озынлыгы — унбер иҗек; тәфагыйльләре (ритмик буыннары) — фагыйләтен, тагын бер фагыйләтен һәм фагыйләт. Арузның үз термины белән әйтсәк, монда төп үлчәм — рәмәле мөсәддәсе мәхзуф. Ләкин тәфагыйль (ритмик буын) формалары сакланган хәлдә дә шигырь юлларының кайберләре биш, җиде яки тугыз (аларны бер-берсенә кушып яки аерып язып кына унберәр иҗекле итеп булмый),— бу инде шигырьнең катнаш үлчәмле булуын күрсәтә (игътибар ителсен — барысы да так юллар; җөп юллар юк, чөнки ул гомуми ритмны бозар иде — болай караганда ун иҗекле булып күренгән биншенче юл чынында унбер иҗеккә тора, чөнки анда икенче тәфагыйльдәге кыска иҗеккә ритмик пауза туры килә; азактан икенче юлда да шул ук хәл — икенче тәфагыйльдәге кыска иҗекне ритмик пауза алып тора — сигез урынына барысы тугыз иҗек булып чыга). Менә аның схемасы:

—∪—— —∪—— —∪—
—∪—— —∪—— —∪—
—∪—— —
—∪—— —∪—— —∪—
—∪—— —∪—— —∪—
—∪——
—∪—— —∪—
—∪—— —∪—— —∪—
—∪—— —∪—
—
—∪—— —∪—— —∪—
—∪—
— —∪—— —
∪—
—∪—— —∪—
—∪—— —∪—— —
—∪—— —∪—— —∪—

Күренгәнчә, Такташның монда китерелгән һәр ике шигыре дә катнаш үлчәмле, тик аларның берсе силлабик системага, икенчесе арузга нигезләнгән.

Иреклe шигырьнең үзенә килсәк, моңа аерым мисалларны егерменче еллар башындагы поэзиядә очратырга мөмкин, тик аларның барысы да диярлек, Г. Халит бик хаклы әйткәнчә, коры риторика, коры декламациядән узмый — сәнгать әсәре булудан бик ерак [1]. Менә шулар арасында иреклe шигырь белән катнаш үлчәмле шигырь урталыгында торганнарыннан берсе:

Көн — кадак.
Тормыш — чүкеч.
Без —
кеше.
Бәр чүкечне.
Сал кадакка.
Нык
төшер!
Без — усаллар.
Без — җылылар.
Бездә — көннәр
Татлысы.

[1] Гали Халит, Күрсәтелгән хезмәт, 147—150 бит.

Җир шарын
Ярды бит
　　уртага
Кызыл әләм
　　камчысы...

**(Г. Кутуй. Көн — кадак. 1925 ел.)**

Монда аерым юлларның гомуми саны сигез белән җиде арасында тирбәлә. Бу бигрәк тә икенче строфада шулай. Аны кушып язып карыйбыз:

Без — усаллар. Без — җылылар (8)
Бездә көннәр татлысы. (7)
Җир шарын ярды бит уртага (9)
Кызыл әләм камчысы. (7)

Хәтта дүртенче иҗектән соң цезура килергә дә исәпли. Ләкин ул эзлекле түгел — өченче юлда бу тәртип сакланмый. Калган строфалар исә мондый шигъри калыпка тагын да ныграк буйсынмый. Димәк, ритмик төркемнәргә бүленеш ягыннан караганда, бу бөтенләй үк катнаш үлчәмле шигырь була алмый — ул ачыктан-ачык иркле шигырь булып китә. Рифма (арада төгәле дә, якынчасы да бар) баштан алып ахырга кадәр саклана: **кеше — төшер, татлысы — камчысы.** Әммә рифма кулланылу аны иркле шигырь булудан читләштерми — алдарак күрербез, иркле шигырьдә дә рифма әле бу, әле теге рәвештә үз урынын таба.

Иркле шигырь чынлап торып бүгенге көннең яшь шагыйрьләрендә — алтмышынчы елларда мәйданга килә (Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гатауллин, Ренат Харисов һ. б.).

Иркле шигырь халыкара әдәби форма. Тик аны һәр тел үзенең фонетик-грамматик төзелешенә туры килгәнчә һәм ул телдәге шигырь системасына (мәсәлән, гарәп яки фарсы теленең квантитатив, немец, инглиз яки рус теленең силлабо-тоник яки тоник, француз, төрек яки татар теленең силлабик системаларына) хас поэтик чараларны теге яки бу дәрәҗәдә файдаланып, үзенчә тормышка ашыра.

Иркле шигырьнең гомуми билгеләмәсе күпчелек тикшеренүләрдә бер үк төрле диярлек. Һәммәсенә дә тукталып тормастан, бер генә өзек китерик: «Тышкы яктан караганда, «верлибр модерн» ул — классик кагыйдәләргә буйсынмый торган шигырь. Анда һәр шигырь юлы үзеннән элек килгән юлга күләм ягыннан бәйле түгел, һәр шигырь юлында иҗек саны төрлечә булырга мөмкин. Сөйләмне әйтүгә киткән вакыт һәм көчнең, мелодия (тоника) һәм гармониянең (тембрның) эзлеклелеге — бу төр шигырь төзелеше өчен иң әһәмиятлесе шул. Берничә шигырь юлы строфаны хәтерләткән аерым төркемнәр хасыйл итә. Бер үк әсәр эчендә ул төркемнәрнең шигырь юллары саны шулай ук төрлечә була» [1].

Әлеге билгеләмәдән күренгәнчә, иркле шигырьдә төп ритмик берәмлек — шигырь юлы үзе. Шигырь юлын мөстәкыйль ритмик берәмлек иткән чара — юл азагында килә торган пауза. Әгәр ул паузаларны алып ташлап, шигырьне тоташ язып чыксак, шигъри яңгыраш югала. Һәр шигырь юлы — озыны һәм кыскасы — үзенә бер төрле интонация белән, үзенә бер төрле уй-тойгы белән әйтелә. Бу яктан теоретикларның барысы да бердәм фикердә.

Иркле шигырьдә рифма буламы? А. И. Мамонов һәм Д. Самойлов моңа кире җавап бирәләр. (А. И. Мамоновның иркле шигырьдә рифманы кире кагуы, бәлки япон поэзиясендә рифманың гомумән булмавы ягыннан чыгып әйтүдән киләдер.) А. Е. Черкасский кытай поэзиясендә иркле шигырьнең рифмалы да, рифмасыз да булуын билгеләп үтә [2]. А. Жовтис һәм башка кайбер әдәбиятчылар иркле шигырьдә рифманы эзлекле рәвештә түгел, бәлки очраклы рәвештә генә кулланыла ала дип саныйлар. Владимир Бурич: иркле шигырьдә рифма очраклы рәвештә дә булырга тиеш түгел, ләкин очраклы рәвештә шигъри үлчәмнең булуы мөмкин, ди [3]. Арсений Тарковский, иркле шигырьдә рифма булмый дигән сүз дөреслеккә һич туры килми, ди һәм моңа ышанычлы мисаллар күрсәтә [4].

---

[1] Зигмунт Чёрный. Күрсәтелгән хезмәт, 249 бит.
[2] А. Е. Черкасский. Новая китайская поэзия. 20—30 ы годы. «Наука» нәшрияты. Мәскәү, 1971, 197—198, 200, 204 бит.
[3] Владимир Бурич. От чего свободен стих. «Вопросы литературы», 1972. 2 сан. 140 бит.
[4] Арсений Тарковский. Традиционный — это точный.— «Вопросы литературы». 1972, 2 сан. 149 бит.

Әдәби әсәрләрнең үзләрен — төрле телләрдәге ирекле шигырьне җентекләп өйрәнгәннән соң, шундый нәтиҗәгә киләсең: чынлыкта, ирекле шигырьдә рифма кулланылу-кулланылмау милли поэзиянең традицияләренә бәйле; әгәр халык шигыренә яки аның гадәттәге язма шигыренә рифма хас икән, димәк, бу әдәбиятның ирекле шигырендә дә рифма кулланылу табигый һәм киресенчә. Шуңа күрә дә ирекле шигырьнең рифмалы һәм бөтенләй рифмасыз төрләрен танырга кирәк була. Менә аның кайбер мисаллары:

Толымын тешләп, (5)
сулкылдап җылады, (6)
　　　　　　　　җылады... (3)
Дымлы керфек арасыннан (8)
ап-ак мендәрдәге (8)
ике баш эзен күреп, (7)
доньядагы (4)
барлык парлы әйберләрне каргады ул: (12)
үз толымнарын, (5)
машина фараларын, (7)
туфляларны, (4)
ишек яңакларын, (6)
Кулына тоткан (4)
кайчыларга кадәр каргады ул... (10)
Ә кич белән (4)
судан кайтканда, (6)
парлы чиләкләрне иңендә тоеп, (10)
кинәт бөтен тәне белән дерелдәп сөенде ул! (15)
Парлы әйберләргә (6)
каргышы исенә төшкәч: (6)
«Тәүбә! Тәүбә!» — диде. (6)

(Равил Фәйзуллин. Яшь хатын.)

Биредә рифма юк. Шигырь юлының иң кыскасы дүрт, иң озыны — унбиш иҗекле. Озынлыкта шигырь юлының үзенә күрә бер чамасы бар — гадәттә, ул унбиш-унҗиде иҗек белән чикләнә, чөнки шуннан да озын фразаны бер тын алу белән әйтеп бетерү читен. Баштан алып азакка кадәр эзлекле бер тәртиптә килгән ритмик төркемнәр (цезура аралары) яки ритмик буыннар (ачык-ябык иҗекләрнең чиратлашуы) да күренми, юкса, аны катнаш үлчәмле шигырь дип, ә тагын да аныкрагы — рифма булмауны да искә алып — катнаш үлчәмле ак шигырь дип атар идек.

Котсыз суык көнне (6)
шыксыз бүлмәмә син яз китердең. (10)
Әгәр һәр кергән бүлмәгә яз ясасаң, (12)
　　　　　　миңа күңелле булмас... (7)
Тик шулай да бүлмәләргә, (8)
кемнеке генә булса да, (9)
кояш китермә, ямә! (6)

Равил Фәйзуллин шигыреннән («Иңемә кулларың орынгач») алынган бу өзек тә рифмасыз, һәм анда һичнинди цезура да юк.

Ирекле шигырьдә төп ритмик берәмлек — һәр шигырь юлы үзе. Бер шигырь юлын икенче шигырь юлы белән берләштерү — аларны кушып язу ритмны гына түгел, шул юлга салынган мәгънә йөген, мәгънә басымын да юкалта. Һәр шигырь юлы — үзенә бер интонацион бөтен, үзенә бер шигъри сурәт. Күз алдына китерегез: «толымын тешләп» җылау; «парлы чиләкләрне иңендә тою»; соңыннан, күңеле тынычлангач, «тәүбә! тәүбә!» дип әйтүе; «котсыз суык көн», «шыксыз бүлмәгә яз китерү» һ. б. Шигъри сурәт никадәр калку булса, әсәрнең интонацион яңгырашы шул кадәр көчле. Чөнки шигъри интонация ул — юл азагындагы пауза нәтиҗәсе булудан да бигрәк шул шигырь юлына салынган мәгънә йөге, сурәтле уй-тойгы йөге.

Ирекле шигырьдә мәгънәви ритмик басымга, юл ахыры яки уртасы паузаларыннан тыш, башка төрле грамматик яки фонетик чаралар да ярдәмгә килә: анафора алымы, аллитерация һ. б. Әмма шулай да иң әһәмиятлесе — һәр шигырь

юлының билгеле бер тәгәлләнгән җөмлә, синтагма яки тулы бер уй-фикерне белдерүче аерым сүз булуында. Хәер, шигырь юлы азагында шунсыз тулы бер пауза да була алмый (сүз тезмәсенең бер өлешен икенче юлга күчерүнең — «анжамбеман» алымының да үз максаты бар).

Рифмасыз ирекле шигырьгә тагын бер мисал — төрек әдәбиятыннан:

Шу уйанырвәрдийим акчыл сабаһ (11)
Бир әркин гәлинҗик гиби (8)
Әфлатун конҗалы әбүгүмәҗи (11)
Санки йүзгәч йүзгәҗә алабалыклар (12)
Санки канат канада турна сүрүләри (13)
Илкйаз булутларынын әтәкләри чалпара (15)
Санки дүйүн-дәрнәкләр (7)
Чалгы-чагнаклар гиби (7)

Ама сән олмасан һичбири (9)

(Мәтин Әлоглу. Бәнҗиләйин.
«Түрк дили». 1970. 22 сан.)

Сүзгә-сүз тәрҗемәсе:

Шул уянып киткән чагым аксыл таң —
Чәчәк аткан мәк кебек,
Бөресе алсу-шәмәхә тырнак гөл кебек.
Гүя йөзә алабалыклар,
Гүя канат кага күктә торналар...
Язгы болытларның итәкләре — бармак шакылдаткычы,—
Гүя туй мәҗлесе
Яңгырап тора рәтле көй кебек.

...Әмма һичберсе син түгел.

Бу әсәр буеннан-буена диярлек чагыштыру алымы (иртәнге таңның сокландыргыч матурлыгын тасвирлау) һәм кискен антитезага (иң азактан «әмма һичбере син түгел» дип кую) корылган. Грамматик чаралардан анафора алымы күзгә ташлана (ике юл янәшә һәм аннан соң тагын берсе **санки** «гүяки» дип башлана).

Ачуланып тамырларын өзделәр... (11)
Ә гөлләрем үлмәделәр, (8)
гел кояшка үрләделәр. (8)
(Син янымда идең.) (6)
Аяк астында тетрәп җир шуышты, (11)
Мин һаман да егылмадым. (8)
(Син янымда калдың.) (6)
Бүген бөтен нәрсә үз урынында, (11)
тыныч. (2)
Мин — (1)
Бушлыкта калган кебекмен, (8)
бернәрсә дә күрмим, тапмыйм. (8)
(Син киттең...) (3)

(Рәдиф Гатауллин. Ачуланып,
тамырларын өзделәр...)

Бу бөтенләй үк рифмасыз шигырь түгел. Шунысы үзенчәлекле, рифма — рух күтәренкелеген, дәртле чакны тасвирлаган баштагы юлларда: **үлмәделәр — үрләделәр**. Хәтта дүртәр иҗекле ритмик төркемнәр дә әүвәле ярыйсы гына әзлеклелектә килә: ачуланып | тамырларын | өзделәр һ. б. Вакыйга куера һәм, ниһаять, бөтен нәрсә тәмам,— боларында рифма кирәкми дә, чөнки лирик каһарманның рухи халәтендә гармония әкренләп җимерелә. **Мин** дигәч зур пауза, ник дисәң, алда әйтеләчәк сүзләр аның өчен бик мөһим (**бушлыкта калган кебекмен; бернәрсә дә күрмим, тапмыйм**). Соңгы юл бик кыска (**син киттең...**), әйтерсең скрипка кылы кинәт өзелә.

Ирекле шигырьгә классик мисал итеп, А. Жовтис Назыйм Хикмәтнең «Зәңгәр күзле дәү, кеп-кечкенә хатын һәм зелпеләре» дигән шигырен һәм аның Д. Самойлов тарафыннан эшләнгән әйбәт тәрҗемәсен китерә [1]. Менә ул шигырь:

[1] А. Жовтис, Границы свободного стиха.— «Вопросы литературы», 1966, 5 сан, 114 бит.

О мави гөзлү бир дәвди.
Миннаҗык бир кадын сәвди.
Кадынын һайали миннаҗык бир әвди,
бағчәсиндә әбрулийи
һанымәли
ачан бир әв.

Бир дәв гиби сәвийорду дәв.
Вә әлләри өйлә бүйүк ишләр ичин
һазырланмыштыр ки дәвин,
йапамазды йапасыны
чаламазды капысыны
бағчесиндә әбрулийи
һанымәли
ачан әвин.

О мави гөзлү бир дәвди.
Миннаҗык бир кадын сәвди.
Мини миннаҗыкты кадын
Раһата аҗыкты кадын
йорулду дәвин бүйүк йолунда
Вә «Әлвәда!» дәйип мави гөзлү дәвә,
Гирди зәнгин бир җүҗәнин колунда
бағчәсиндә әбрулийи
һанымәли
ачан әвә.

Шимди анлыйор ки мави гөзлү дәв,
дәв гиби сәвдалара мәзар билә оламаз,
Бағчесиндә әбрулийи,
һанымәли
ачан әв...

Сүзгә-сүз тәрҗемәсе:

Ул зәңгәр күзле бер дәү иде.
Кечкенә бер хатынны сөйде.
Хатынның хыялы кечкенә бер өй иде —
бакчасында аллы-гөлле
зелпе
чәчәк аткан бер өй.

Бер дәү кебек сөйде дәү.
Һәм куллары шундый бөек эшләр өчен
яратылган иде дәүнең —
бурасын бурый алмады,
капкасын кага алмады
бакчасында аллы-гөлле
зелпе
чәчәк аткан өйнең.

Ул зәңгәр күзле бер дәү иде.
Кечкенә бер хатынны сөйде.
Кеп-кечкенә бер хатын.
Рәхәткә ачыкты хатын,
арыды йөреп дәүнең бөек юлында.
Һәм «хуш!» диеп зәңгәр күзле дәүгә,
керде, бер бай кәрләнең тотынып кулына,
бакчасында аллы-гөлле
зелпе
чәчәк аткан өйгә.

Инде хәзер аңлый зәңгәр күзле дәү,
дәү кебекләрнең сөюләренә кабер була алмый
бакчасында аллы-гөлле
зелпе
чәчәк аткан өй.

Бу әсәр, Назыйм Хикмәтнең үз иҗаты турында бер вакыт әйткәненчә [1], шигырь төзелеше осталыгының барлык мөмкинлекләреннән файдаланып язылган. Ара-тирә рифма да кулланылган, төрле сандагы юллардан торган тирадалар, бер үк төрле сүзләр белән башланып һәм тәмамланып, һәркайсы үзенә бер мөстәкыйль, ләкин шул ук вакытта һәркайсы бер-берсенә бәйләнешле мәгънәви-интонацион бөтен булып яңгырый.

А. Жовтис үзенең тикшеренүендә: «кабатлауның ысулы алышыну» — ирекле шигырьнең төп үзенчәлеге, дип бара [2]. Ягъни ирекле шигырьдә төрле-төрле кабатлау алымнары булырга мөмкин, ләкин алар анда үзара алышынып тора. Назыйм Хикмәтнең югарыда китерелгән шигырьләрендә силлабик системага хас ритмик төркемнәр кайвакыт күренгәли; синтаксик параллелизм яки кабатлауның кайбер төрләре (анафора, эпифора, бер үк морфологик формалар һ. б.) әле тегендә, әле монда очрап куя; аерым юллар һәр тирада (шигырь юллары төркеме) ахырында бер үк рәвештә диярлек кабатлана; уй-тойгының аеруча аһәңле әйтелүе кирәк булган урыннарда рифма да күренеп киткәли. Әлбәттә, боларның барысы да шигъри сөйләм өчен, шул исәптән ирекле шигырь өчен дә, гадәттәгечә хас күренеш.

А. Квятковский ирекле шигырьне үлчәмле һәм үлчәмсез төрләргә бүлә; хәтта ритмик басымнары һәр юл саен бертөрле килә торган тоник шигырьләрне, мәсәлән, В. Маяковский шигырьләрен, ирекле шигырь дип саный [3]. А. И. Мамонов бу карашка хаклы рәвештә каршы чыга [4].

Ирекле шигырьне өйрәнүчеләр аның ритмына хас күп төрлелек (полиритмик үзенчәлек) турында аеруча басым ясап әйтәләр. Күрәсең, бер үк әсәрдә сүз һәм әйтемнәрне язма сөйләмнән дә, сөйләшү теленең әдәби тереннән башлап гади сөйләменә кадәр алып иркен рәвештә куллану, шигырь юлларының төрлечә озынлыгы һәм паузаларының зурлыгы-кечелеге, һәртөрле синтаксик фигураларның һәм сөйләшү стиленә аеруча хас инверсиянең, башка төр шигырьләрдәге кебек үк, һәртөрле фонетик чараларның да (аллитерация, ассонанс, кайвакыт рифманың да) булуы һәм барыннан да бигрәк сурәтле сүз чараларының гадәттә бик кыю һәм калку төс алуы чыннан да бу шигырьне ритмик яктан баета. Әмма, икенче яктан, ирекле шигырьне язу шагыйрьгә үтә зур җаваплылык өсти: әгәр осталыгың җитмәсә, теләсә нинди риторик фикерне өзек-өзек юлларга салып чыгудан уза алмассың. Ирекле шигырьгә тотынган кеше уй-фикерне сурәтле итеп әйтеп бирә белүнең аеруча зур остасы булырга тиеш. «Яшь шагыйрь,— ди бу турыда С. Наровчатов,— күрәсең, иң элек гадәттәге шигырьдән башларга, тик шуннан соң гына ирекле шигырьгә күчәргә тиеш» [5]. Ләкин һәр яшь шагыйрьнең иҗат үзенчәлеге һәм мөмкинлеге төрлечә, шуңа күрә башлап язучы шагыйрьнең дә беренче әсәрләре ирекле шигырь булырга яки бер үк вакытта ул гадәттәге шигырьләр дә иҗат итәргә мөмкин. Бу тәкъдимне исә нинди генә төр шигырь язсаң да, шигърият кануннарын яхшы үзләштергән булырга тиеш дип аңларга кирәк. Чөнки ирекле шигырь ул,— латыш шагыйре Ояр Вациетис сүзләре белән әйткәндә,— шагыйрь өчен кырыс һәм аяусыз имтихан [6].

Моңарчы без ирекле шигырьнең, башлыча, үлчәмле шигырьдән аермасы турында гына сүз алып бардык. Аның икенче бер күршесе — чәчмә сөйләм. Җитмәсә, махсус әдәбиятта ирекле шигырь ул — нибарысы прозаның бер төре дигән караш та бар бит [7]. Ирекле шигырьнең прозадан, бигрәк тә нәсердән аермасы нәрсәдә? Нәсернең гомум кабул ителгән билгеләмәсе — ул чәчмә сөйләм (проза) рәвешендә язылган шигырь. Аны да юл-юл итеп төзеп, ирекле шигырьгә әйләндереп булмыймы? Юк, булмый. Чөнки нәсердә һәр җөмлә, һәр синтагма образлы фикер йомгагы, образлы фикер букеты түгел, анда җанлы сурәт арасына килеп кысылган

---

[1] Р. Фиш. «Человеческая панорама» Назыма Хикмета. «Вопросы литературы». 1959. 3 сан. 181 бит.
[2] А. Жовтис. Күрсәтелгән хезмәт, 112 бит.
[3] А. Квятковский. Русский свободный стих. «Вопросы литературы», 1963. 12 сан; аныкы ук. «Поэтический словарь». 75—77 бит.
[4] А. И. Мамонов. Күрсәтелгән хезмәт, 65—68 бит.
[5] Сергей Наровчатов. Учит ли верлибр поэтическому мастерству? «Вопросы литературы». 1972. 2 сан. 132 бит.
[6] Ояр Вациетис. Мощь и беззащитность верлибра. «Вопросы литературы», 2 сан, 144 бит.
[7] М. Янакиев. Българско стихознание. София. 1966. 9 бит.

бушлыклар, аралыклар күп. Тасвир ирекле шигырьдәгегә караганда чагыштыргысыз сүлпән. Җөмлә, синтагма бер-беренә тыгыз бәйлелектә төзелгән — араларында, аларны никадәр генә аерсаң да, ирекле шигырьдәге кебек билгеле бер шигъри тойгы уята торган паузалар була алмый. Менә Гадел Кутуйның «Сагыну» дигән нәсереннән бер өзек:

«Мин чит илдә матур гөлләр, хуш исле чәчәкләр исним. Ләкин күпме генә иснәмим, барыбер һава җитми, сулыш кысыла. Гүя үз илемнең энҗе чәчәкләре түгел, аның әреме дә бүген миңа шифа булыр иде.

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Мин шаулап аккан елгалардан, тирән коелардан алып сап-салкын су эчәм. Әмма күпме генә эчсәм дә, сусавымны баса алмам. Мин үз илемнең борынгы Иделен, тын Донын, якты Арагвасын, шигъри Дим буйларын сагынам. Гүя бу мөкатдәс елгаларның суларын түгел, хәтфә болынлыктагы чишмәләребезнең бер йотым суын да бүген мин ширбәт итеп эчәр идем.

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!»

Ләкин шулай да ирекле шигырьнең җөмлә төзелеше ягыннан азмы-күпме нәсергә якын, ләкин интонацион яктан да, сурәтлелек ягыннан да тулысынча чәчмә сөйләм ягында кала алмый торган бер төре бар — ул да булса ирекле шигырь-хикмәт. А. И. Мамонов аны нәсернең («стихотворение в прозе» яки «прозо-стих»-ның) кыска бер төре дип атый [1]. Бу төр ирекле шигырь япон поэзиясенә аеруча хас — ул анда танки дип йөртелә. Аның авторлары сәнгатьтәге кубизм теориясен үзләренә якын күрәләр, шигырьдә һәртөрле хис, дулкынлану читкә алып ташланып, калку образ яки ярылып яткан фикер өстенлек итәргә тиеш, диләр. А. И. Мамонов японның бу төр шигыренә, мәсәлән, мондый мисал китерә:

Контрольдә билет белән бергә
бармакны да кисеп алдылар.

Бу шигырь «Ашыгыч сәгатьтә» (инглизчә «Раш ауез», русча «Часы пик») дип атала, авторы — Китагава Фуюхико. Рус шагыйре Василий Субботинның шундыйрак бер шигыре бар:

Окоп копаю. Может быть — могилу.

Әгәр биш буынлы ямб тәртибен үзгәртсәк («Копаю окоп. Может быть — могилу»), бу шигырьнең япон танкиына охшавы — йөз процент, ди А. И. Мамонов. Немец шагыйре Бертольд Брехт шигыре:

Ди Эһепааре
Леген зих ин ди Беттен. Ди йуңен Фрауен
Верден Вайзен гебәрен.

(«Эс ист Нахт») [2]

Тәрҗемәсе:

Кияү белән яшь кәләш
Ятакта. Яшь хатын
Ятим бала тудырачак.

Инде татар шагыйре Равил Фәйзуллинның ирекле шигырь-хикмәтләре («Казан утлары». 1965. 11 сан):

Җилдә соңгы шырпымны кабыздым.
Мин дөньяда иң бәхетле!

(«Янымда син булсаң».)

Кыз кияүдән кайтты.
Капка төбендәге утыргычка
быел кем утырыр?..

(*)

Тудыру йортыннан чыккан
хәлсез хатын

[1] А. И. Мамонов. Күрсәтелгән хезмәт, 119 бит.
[2] Мисал Эрист Штейнның «Шигырь язу ысулы» дигән китабыннан алынды, 109 бит. (Шигырь латин хәрефләреннән хәзерге татар хәрефләренә күчереп бирелде.)

көрттән арчылган тирәкләргә:
«Котлыйм!» — диде.
(*)
Уылган керләрдән дә
балык исе килә.
Тиздән ире кайтыр.

(«Балыкчы диңгезгә киткәч».)

Бөртекләп җыйдым хәтердән
бәхетле көннәремне.
Ярты уч та тулмады.
(*)
Таш койма өстендә
үсте каен.
Тамырлары киткән саен —
хәвефләрәк...
(*)

Боларның кайберләре табышмак кебегрәк:

Диңгез аша очар
кош канаты
кабартма майлый.

(«Искәртү».)

Күмелгән бәрәңге астында
күмелгән мина ята.
Көтүче чыбыркысы шартлады.

(«Искәртү».)

Ирекле шигырь-хикмәт, гадәттә, теге яки бу дәрәҗәдә аерым юлларга бүленгән бер яки ике-өч җөмләдән тора. Ул — күз алдына шунда ук килеп баскан калку сурәт яки, киресенчә, мәгънәсенә шул арада гына төшенеп җитә алмаслык кинале сөйләм, мәгънәсе тирән яшерелгән метафора. Килеп чыгышы ягыннан ул, мөгаен, япон, кытай, вьетнам поэзиясенә барып тоташа булыр. Аның шулай ук борынгы төрки шагыйрьләр иҗатындагы икеюллыклар — үлчәмле, рифмалы шигырь — хикмәтләр белән дә уртаклыгы юк түгел. Шуңа күрә дә аны, тезмә нәсер («прозо-стих») дип әйтүгә караганда, үзенең поэтик рухына ныграк туры килгәнчә, ирекле шигырь-хикмәт дип атау дөресрәк булыр.

Димәк, барысын бергә җыеп әйткәндә, ирекле шигырьнең өч төре бар булып чыга:

1. Рифмасыз ирекле шигырь.

2. Рифмасы очраклы (яки рифма ара-тирә махсус кулланылган) ирекле шигырь.

3. Ирекле шигырь-хикмәт (шигъриятле сурәт, шигъриятле фикер). Монысы — ярым чәчмә миниатюра. Рифмасы юк яки булса да очраклы.

Ирекле шигырь — бөтен дөнья поэзиясендә чагыштырмача яңа форма. Кайбер халыкларның поэтик традициясенә (мәсәлән, японныкына) ул аеруча якын һәм шуңа күрә анда соңгы елларда (һәм күпме вакыткадыр) гомумән төп шигъри форма урынын алып китә. Ә инде ритмик үлчәм һәм аһәңлелекне аеруча югары куя торган халыкларда ул шигырь, классик формаларны кысрыклап чыгарырга һич тә дәгъва итмичә, үзенә бер поэтик форма, үзенә бер поэтик төрлелек буларак кулланылып килә.

Илдус Ахунҗанов

# ШИГЪРИЯТ ЮЛЛАРЫ ЧАТЫНДА

*Ренат Харис иҗаты турында этюдлар*

1972 елның ахырында Мәскәүнең «Яшь гвардия» нәшриятында «Юллар чаты»[1] дигән исем белән яшь шагыйрьләрнең коллектив җыентыгы басылып чыкты. Анда татар шагыйре Ренат Харисның «Сабантуй» исемле китабы да урнаштырылган. Ниятем шул китапка рецензия язу иде. Яза башлагач, киңрәк килеп чыкты. Китап турында уйланулар әдәби иҗат эшчәнлегенең кайбер мөһим мәсьәләләренә алып кереп китте. Тәрҗемә турындагы тәэсирләрем белән генә уртаклашмакчы идем, шагыйрьнең яшь татар поэзиясе сафындагы урыны мәсьәләсен дә читләтеп узып булмады.

Яңарак язылган шигырьләренең берсендә Р. Харис поэзиягә булган мәхәббәтен сихри һәм ялкынлы мәхәббәт, гомерлек мәхәббәт дип атый. Ул, чыннан да, поэзиягә, сәнгатькә гашыйк; Р. Харис — яхшы мәгънәсендә китапчыл шагыйрь.

Нәрсә соң ул китапчыл поэзия? Башта шул мәсьәләне ачыклап китик. Минем уемча, китапчыл поэзиянең төп хикмәте шунда, теге яки бу китапчыл шагыйрьнең әсәрләрен укыганда, укучы турыдан-туры тормышның үз сурәте белән түгел, ә аның сәнгать әсәрләрендә инде бер тапкыр чагылдырылган, ягъни икенчел сурәте белән очраша. Мисал төсендә Һ. Такташның «Җир уллары» трагедиясен алырга була. Әсәрнең сюжеты Кабил белән Һабил турындагы борынгы легендага нигезләнгән. Такташ, легенда образларыннан иҗади файдаланып, бөтенләй башка юнәлештәге, яңача яңгырашлы трагедия язган икән, бу шул ук китапчыллыкның бер күренеше түгелмени? Я булмаса, шагыйрь һәм драматург Фәтхи Бурнашны, аның «Таһир-Зөһрә» пьесасын алыгыз. Танылган рус шагыйре Блокны алырга мөмкин. Баксаң, «Унике» исемле мәшһүр поэмасын шагыйрь рим тарихчысы Катулл язмаларына таянып язган икән. Бу хакта көндәлекләрендә ул үзе әйтеп уза. Әмма Катилина восстаниесенә бәйле вакыйга шагыйрь өчен этәргеч көч, бер сәбәп кенә була. Поэманың асылын тәшкил иткән төп сыйфатларны шагыйрьнең карашларыннан, революция идеаллары белән рухланып яшәвеннән

[1] Перекрестки. Коллективный сборник. «Молодая гвардия». Москва. 1972 год. Рус телендә.

эзләргә кирәк. Гомере буе революция авазлары, революция гөрелтеләре белән илһамланып яшәгән зур шагыйрь бөек пролетар яңарунын — тарихта тиңе булмаган яңарунын — төп рухын, ритмын һәм үзенчәлекләрен чагылдыра алырлык гүзәл сәнгать әсәре иҗат итә.

Кыскасы, китапчыл поэзия үрнәкләренә мисал күп китерергә була.

Р. Харис иҗатының да нигездә шушы юнәлештә үсүен күрсәтерлек характерлы берничә мисал алыйк. «Яшь гвардия» нәшрияты чыгарган җыентыкта «Мулланур» исемле поэма бар.

Поэма рефреннар ярдәмендә кабатланып килгән шундый юллар белән тәмамлана:

**Хәрәкәттә безнең аң һәм безнең кан —**
**Мәңге исән синең җан,**
**Мулланур!..**

Кемгә ничектер, мин бу юлларда М. Светлов поэзиясенә хас авазлар ишетәм. Шагыйрьнең «Сказ о Чапае» исемле поэмасындагы рефреннарны хәтерлисезме? Хәтерем ялгышмаса, анда «җан» сүзе «йөрәк» сүзе белән, «мин» алмашлыгы «без» белән алмаштырылган, әмма геройның үлемсезлеге турындагы төп фикер якынча бер төслерәк, бер калыптарак, бер юнәлештәрәк үстерелә.

Икенче мисал. Шагыйрьнең «Яңа көн» исемле яңа җыентыгына мөрәҗәгать итик. «Сабантуй» исемле циклга кергән шигырьләрнең берсендә шундый эпизод бар: кызыл чуклы ак сөлге җилфердәп торган колгага бер малай менеп карый, ләкин менеп җитә алмыйча җиргә шуып төшә, гарьлегеннән елар хәлгә җитә. Ләкин уфтанырга урын юк, шунда ук икенче малай әзер тора:

**Бер малай аяк табанын**
**Чирәмгә ышкый...**
**— Җитәр,**
**Дымлангандыр,**
**Халык көтә,**
**Менеп кара, — диделәр.**
**Менеп китте...**
**Бәлки аңа**
**Җир дымы ярдәм итәр!**

Күрәсез, шагыйрь биредә борынгы грек мифологиясендәге Антей турындагы мотивлардан файдаланган. Әлеге мисалларны без ни өчен китердек? Нәрсә бу, иҗади йогынтымы, әллә турыдан-туры эпигонлыкмы? Минемчә, тегесе дә, бусы да түгел.

Светлов белән булган очракны алыйк. Монда төрлечә фараз кылырга мөмкин. Бик ихтимал, иseме дөньяга мәгълүм атаклы рус шагыйре М. Светлов һәм хәзергә әле киң җәмәгатьчелеккә аз билгеле булган яшь татар шагыйре Р. Харис, гражданнар сугышында катнашкан ике батырның трагик үлеме турында уйланганда, бер-берсенә бәйсез рәвештә, бер юнәлештәрәк фикер йөрткәннәрдер, образның бердәй «орлыгын» тапканнардыр. Әгәр шулай икән, ул чагында Р. Харисны Светловча тәгәллек өчен котларга гына кала. Ләкин башкача фикер йөртергә дә мөмкин. Ихтимал, «Мулланур» поэмасындагы Светловча яңгыраган троплар аң катнашыннан тыш башкарылган әдәби йогынты җимешедер, кайчандыр укыган нәрсәнең, вакытлар узгач, томанлы төстә генә хәтергә килеп төшүе, иҗат эшчәнлегенең иң киеренке бер мизгелендә хәтер сандыгында сакланган нәрсәләрнең кинәт ачылып киткән сурәте генәдер.

Инде икенче мисалга килсәк, без монда башка төрлерәк күренеш белән очрашабыз. «Сабантуй»да грек мифологиясендәге мотивлар аңлы рәвештә, белеп, башкача әйткәндә, тенденциоз төстә кулланылган.

Әлеге сюжетның артык киң таралган булуы бары шулай гына уйларга юл калдыра.

Әмма хикмәт хәтта әдәби йогынты һәм сәнгатьчә ассоциацияләрдә генә дә түгел, иң мөһиме шунда, ул йогынты һәм ассоциацияләр шагыйрьне илһамландырган зур һәм мөһим теманың органик өлеше булып киткәннәр, табигый тәстә бергә үрелеп, кушылып баралар. «Сабантуй»да грек мифологиясеннән килгән сюжетның ни рәвешле яңартылуына игътибар иттегезме икән?! Үзенә көч биреп торган җирдән аерылуга мифология герое Антей үлә. Ә Р. Харис шигырендә без колга башына менәчәк малайны барлык авырлыкларын җиңеп чыккан яшь Антей итеп күз алдына китерәбез. Туган җир дымы ярдәм итә!

Р. Харис поэзиясенең китапчыллыгы, икенчеллеге хакында сөйли торган тагын бер мисал — аның М. Яруллин ораториясенә язган «Кеше» либреттосы. 1972 елда аларга бу әсәрләре өчен М. Җәлил исемендәге комсомол премиясе бирелде. Сезнең бу ораторияне тыңлаганыгыз бармы? Әгәр юк икән, ораториянең эчтәлеге белән аз гына булса да таныштыру йөзеннән, аның нинди кисәкләрдән торуын санап узам: I. Җир һәм Кеше; II. Прометей; III. Ленин. Революция; IV. Хезмәт; V. Бишек җыры; VI. Сугыш. Муса; VII. Кешегә мәдхия.

Күрәсез, либретто ораториягә тарихның киң сулышын алып керә. Дөрес, либретто авторы кайбер төгәлсезлекләр дә җибәргән. Прометей турындагы кисәктә: «әйдә бөркет минем йөрәгемне өзгәләсен», дигән җөмлә бар. Хәлбуки, һәр мәктәп баласы бик яхшы белә: бөркет Прометейның йөрәген түгел, ә бавырын чукый. Әмма либреттоның гомуми яңгырашы белән чагыштырганда, бу вак төгәлсезлекләр бөтенләй сизелми дә. Аларны артык төпченеп укыган кеше генә шәйләргә мөмкин.

Культура фактларына, башка халыкларның әдәбияты һәм сәнгате ирешкән казанышларга курыкмый, иркен мөрәҗәгать итү, ул фактларны үз әсәреңнең табигый үсешенә буйсындыра белү — милли шигъриятне интернациональ дәрәҗәгә күтәрүнең, милли чикләнгәнлектән арынуның тагын бер чыганагы менә шул.

Р. Харисны инде башлап язучы шагыйрь дип кенә булмый. Поэзиядәге өйрәнчеклек чорын, хәзерлек этабын ул күптән узды. Менә, мәсәлән, Мәскәү чыгарган җыентыктагы «Яфраклардан бизәкләр» исемле әсәр. Шигырьләр күбрәк юл йөргәндә, юлда языла. Шагыйрь бу юлы көзге урман юлы буйлап бара, аның күзенә төрле-төрле агачларның яфраклары чалына. Менә җыерчыклы карама яфраклары. Карагыз әле! Ә бит ул яфраклар үз башыннан күп хәлләр кичергән кешенең маңгай сырларын хәтерләтә икән ләбаса. Нииндидер сыйфатлары буенча чыклы тал яфрагын яшьле күзләргә, кызгылт усак яфрагын алсу бит алмаларына, мәңге яшел ылысларны чыдамлы йөзгә охшатырга мөмкин икән. Һәм шигырьнең «орлыгы» әзер. Әгәр шагыйрьнең хәзерлеге югары булмаса, әгәр ул үзе күргән шул детальләрдән гомумиләштерүләр ясый белмәсә, «орлык» тишелми калырга да мөмкин иде. Р. Харис аларны терелтә, аларга җан кертә алган. Оригиналның соңгы юллары болай тәмамлана:

Көзге урман буйлап,
Кеше турында уйлап,
Каядыр барам...

Ә менә шул ук юлларның В. Кузнецов тарафыннан эшләнгән тәрҗемәсе:

А я раздумываю о сыне,
Шагая тропкою лесной...

Биредә «баланың» ни катнашы бар? Оригиналда сүз бөтенләй гаилә эчендәге мөнәсәбәтләр турында түгел, Табигать белән Кеше мөнәсәбәтләре турында бара. Шулай да бусы әле әллә ни зур бәла түгел. Тагын тәрҗемәгә мөрәҗәгать итәбез:

**«А я, а я...**
**Я вам нужна**
**Для обрамления портрета (!)**
**Ведь я одна**
**Зимой и летом**
**В лесу приволжском зелена (!)»,**
**Шепнула хвоя.**

Бәланең зуры менә шуннан башлана. Ахырдан икенче юл бөтенләй ялгыш бирелгән, сүзне дә шуннан башлыйк. Географик характердагы аныклау (в лесу приволжском) нигә, кемгә кирәк? Идел буе урманында үсмәсә, ылыс яшел булмас идемени?.. Кыскасы, матур, купшы сүзләрдән тезелгән әлеге тирада тәрҗемәче уйлап чыгарган нәрсә генә. Бу хәлне аңлату артык кыен да түгел. Оригиналда шигырь «Күз сурәте» дип атала. Күрәсең, сүзгә-сүз тәрҗемәдә дә шул ук исем калган булгандыр. В. Кузнецов аны «портрет» дип аңлаган. Нәтиҗәдә шигырьнең буйдан-буйга сузылган үзәк линиясе югалган, әсәрдәге ассоциацияләр чылбыры, әсәрнең музыкасы бозылган.

Мин этюдларны юри әйбәт шигырьнең начар тәрҗемәсеннән башладым. В. Кузнецов тулаем хәзерлекле тәрҗемәче. Бу — тәрҗемә мәсьәләсенә караган фикерләрне кискенрәк итеп куюы өчен кирәк булды. Сүзгә-сүз тәрҗемә буенча эшләү — вакытлы чара, хәзергә шунсыз булмый. Бу хәлдән ничек чыгарга соң? Р. Харис, һичшиксез, тәрҗемәче белән очрашмый калмагандыр — китапка авторлаштырылган тәрҗемә дип куелган бит! Әгәр шагыйрь тәрҗемәчегә әлеге шигырьне тәрҗемә итү принципларын рәтләп аңлаткан булса, оригинал белән тәрҗемә арасында бу кадәр аерма килеп чыкмас иде. Бу, әлбәттә, бер очрак кына. Гомумән алганда, үзара элемтә һәм бәйләнешләрнең әһәмияте әйтеп бетергесез зур, безнең кебек күп милләтле илдә бигрәк тә. Мин ышанам, ике шагыйрьнең үзара очрашып сөйләшүе, әгәр ул очрашу файдалы эшкә юнәлтелгән булса, сүзгә-сүз тәрҗемәләр аша читтән торып танышуга караганда, аларның икесен дә күп мәртәбә ныграк баетачак. Мондый очрашулар еш кына иҗади дуслыкка әйләнеп китүчән була.

Алда әйтелде: кеше һәм табигать, аларның үзара мөнәсәбәте — шагыйрь иҗатындагы төп темаларның берсе. Аның иҗат манерасы өчен нәрсә характерлы соң? Җыеп әйткәндә, Р. Харис иҗатының бер үзенчәлеге шунда, ул кеше һәм табигать дөньясындагы капма-каршы булган, һәрхәлдә, бер-берсеннән ерак торган әйберләрне үзара якынайтырга ярата. Шигырьләрен ул бер төрле башлый, ә ахырларын еш кына бөтенләй көтелмәгәнчә тәмамлый. Әйтик, түбәндәгечә:

**Мин — яфрак!**

Әйе, табигать тормышы белән кушылу, җан иясенең тойгыларына сизгер килү — аның иҗатының, аның стиленең беренче билгесе, беренче шарты булып тора.

Һәр шагыйрь үткәндәге мираска таяна. Р. Харисны Дәрдмәндтән өйрәнә, диләр. Беренче карашка, алар арасында бернинди уртаклык юк кебек. Шул ук вакытта тирә-юньне күзәтү үзенчәлеге, кеше һәм табигать дөньясына керү тирәнлеге буенча да, абстракт төшенчәләрне конкрет әйберләр аша сурәтләүгә йөз тотуы ягыннан да, интонацияләренең төрлелеге һәм тагын нindидер күзгә күренмәс башка сыйфатлары буенча да ул ифрат та Дәрдмәндкә якын, Дәрдмәндне хәтерләтә.

Әмма шагыйрьләр арасында тарихның үзе тарафыннан билгеләнгән җитди аерма да бар. Аерма иҗатның максатка юнәлгәнлегендә. Әгәр

Дәрдмәнднең карт шонкары оча-оча ахыр чиктә утопия һәм социаль иллюзияләрнең хыялый иленә килеп җитсә, Р. Харисның яңа канат чыгарган кошы чын ил, реаль чынбарлык һәм социаль гаделлек иле — кешелек җәмгыятенең иң якты хыяллары тормышка ашкан Советлар иле күгендә оча.

Капма-каршы юллардан киткән ике кеше арасындагы бу бәйләнешне, бу якынлыкны фәнни яктан ничек нигезләргә соң? Кулында алтын приискалары тоткан миллионер, заманына күрә һәр яктан тирән белемле кеше, «Вакыт» газетасының нашире... Күз алдына китерегез: шул кеше, кабинетына бикләнеп, наширләргә бик хас булмаган эш белән шөгыльләнә — үз-үзен аямыйча шигырьләр яза, ритм, рифма өстендә, строфа төзү өстендә газаплана, шигырь формасының башка элементлары белән баш вата һәм язганнарыннан беркайчан да канәгать булмый. Максаты нәрсә? Әдәби осталыкның бөтен мөмкинлекләреннән файдаланып, ул идеаль шигырь иҗат итәргә омтыла. Нигә кирәк бу аңа? Миллионер булу гына җитмәгәнмени? Әмма шагыйрьне алтын чыңыннан да зуррак башка төрле байлык — рухи байлык үзенә тарткан, бу — аңа табигать тарафыннан мул итеп бирелгән талант көче, шул аны, кабинетына бикләнеп, сәгатьләр буе армый-талмый эшләргә мәҗбүр иткән. Матбугатта Дәрдмәнд псевдонимы белән шигырьләр бастырган Закир Садыйк улы Рәмиевне мин әнә шундый кеше итеп күз алдына китерәм.

Дәрдмәнд иҗаты тикшеренүчеләр өчен хәзергә кадәр чишелмәгән төен булып кала, әледән-әле бәхәсләр, капма-каршы фикерләр кузгатып килә. Мондый талантлы, тирән һәм нечкә лирикны, безнең кайбер галимнәр кебек, җиңел генә буржуаз лагерь сыйныфына бирү дөрес булып бетмәс. Бу — сәнгатьнең спецификасын аңлап җитмәү, мәсьәләне артык гадиләштерү бәласе. Зур шагыйрьнең эчке дөньясы катлаулы һәм каршылыклы. Әйе, ул органик төстә үз сыйныфы белән бәйләнгән кеше, ләкин бу аңа иң яхшы шигырьләрендә, хәтта шул ук «Кораб»ында да, үзенең тар сыйнфый карашларыннан югарырак күтәрелергә, бөтен милләтне борчыган мәсьәләләрне күтәрергә комачауламый. Аның фаҗигасе кырыс һәм гыйбрәтле. Бер яктан, ул тарих агымына каршы барырга маташкан үз сыйныфыннан баш тартырлык көч тапмый, икенче яктан, йөрәкләрне тетрәтерлек Ватандарлык хисе, милләт язмышы хакында уйланулар, туган илгә мәхәббәт, канга сеңгән укымышлылык һәр вакыт аның тормышка, тирә-юньгә мөнәсәбәтенең хәлиткеч ягы була. Әгәр ул, Бөек Октябрь революциясе җиңгәч, кайбер дусларының чит илгә китәргә чакыруларын кире кага алган һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр совет властена лояль кеше булып калган икән, бу юкка гына түгел. Һәм аның талантын ихтирам итүчеләр арасында М. Җәлил, Ә. Фәйзи, Х. Туфан, С. Хәким кебек күренекле шагыйрьләрнең булуы да очраклы хәл түгел. Соңгы елларда алар сафына тагын бер кеше — яшь шагыйрь Р. Харис килеп кушылды. Аның бөтен иҗаты буена, «Кайтаваз» исемле беренче мөстәкыйль китабыннан алып «Яңа көн» исемле соңгы җыентыгына кадәр, тегеләйме-болаймы Дәрдмәнд белән бәйләнгән шигырьләр сузыла. Дәрдмәнд поэзиясе — Р. Харисның беренче мәхәббәте, кайнар, мавыгучан мәхәббәте, шуны ул, күрәсең, бөтен гомере буена саклаячак.

Ләкин Дәрдмәнд — аның өчен алла түгел. Ул артист табигатьле шагыйрь иҗатының көчле якларын да, көчсез якларын да дөрес күрә. Р. Харис совет чорында туа, ана сөте белән үк яңа тормыш идеяләрен сеңдереп үсә. Аның дөньяга карашы, идеаллары һәм идея-эстетик концепцияләре дә башка. Алар арасындагы тарихи, социаль, эстетик аерма шуның белән аңлатыла. Бераз алдарак мин Дәрдмәнд поэзиясе Р. Харисның беренче мәхәббәте, дигән идем. Ләкин бу аек мәхәббәт, язучының сыйнфый чикләнгәнлеген истән чыгармый торган мәхәббәт һәм бердәнбер мәхәббәте дә түгел.

Конкрет мисалда аңлатыйк.

Әле 1907 елда ук Дәрдмәнд, Тукайга адреслап, «Шагыйрь» исемле мәгълүм шигырен яза. Шул шигырендә ул халык шагыйрен матур гөлләргә былбыл булырга, нәзакәт багына сакчы булырга чакыра. Политикадан читләшергә чакырган мондый шигырен ул иҗат практикасында берничә тапкыр куллана. Шул вакытлардан бирле алтмыш ел гомер узгач, 1967 елда Р. Харис, ихтимал, Дәрдмәнд белән бәхәскә керүен үзе дә сизмичәдер, шулай ук чәчәк мотивы белән бәйләнгән «Шигырьләр» исемле шигырен яза. Бу шигырендә ул Рудаки, Пушкин, Тукай, Лорка, Хикмәтләрнең фаҗигале язмышлары хакында сөйли һәм әсәрнең иң ахырында, Дәрдмәнд белән яшерен бәхәскә кергәндәй, болай ди:

**Чәчәк өчен Җирдә беркемне дә,**
**Беркайчан да үтергәнне тарих белми...**

Шагыйрь үз идеалын, идея-эстетик карашларын раслый. Димәк, шигырь техникасына, сүз осталыгына, ритмнар хикмәтенә өйрәнергә мөмкин икән, әмма кеше фикерләренә иярү, дөньяга карашлардан өйрәнү мәгънәсезлек булыр иде. Ул чагында Р. Харис Дәрдмәнднең гади бер эпигоны булудан, алай гына да түгел, артык искергән эпигоны булудан ерак китә алмас иде. Бу шигырь органик төстә татар совет поэзиясенең гомуми агымына килеп кушыла, аны тагын да баетып җибәрә. Шул кадәресе кызык, әлеге шигырьдә автор Тукай тәҗрибәсенә, тормышны объектив төстә сурәтләү традицияләренә таяна, ахырдан, Бөек Октябрь революциясеннән соң, халык шагыйренең җиңел кулыннан татар совет шагыйрьләренең бөтен бер плеядасы кабул итеп алып киткән рухи традицияләргә таяна.

Республика матбугатында хәзер Р. Харис иҗаты турында, аерым алганда, аның Дәрдмәнд поэзиясенә мөнәсәбәте хакында да, күп язалар. Аны Дәрдмәнд белән чагыштыру хәтта шигырьләрдә дә күренә башлады. Мәсәлән, яшь шагыйрь К. Мостафин Р. Хариска багышланган дусларча шаяруында болай ди:

**Башкаларга өстән генә карый-карый,**
**Язасың да, сызасың да, үсәсең дә.**
**Болытка да үрелеп була икән, җаный,**
**Басып торсаң Дәрдмәндләр җилкәсенә.**

Әйе, аның турында күп язалар, төрле нокталардан карап, төрле позицияләрдән торып язалар. Мәкалә һәм рецензия авторларының игътибарын җәлеп иткән төп нәрсә — күптәннән килә торган традиция һәм новаторлык мәсьәләсе, аларның үзара мөнәсәбәте, үсеш перспективалары.

Шагыйрь Н. Дәүли «Казан утлары» журналының 1971 елгы 7 санында басылган мәкаләсендә Р. Харисны шигырьнең дисциплинасын бозуда, ритм, рифма, цезураларга игътибар итмәүдә, кыскасы, ялган новаторлыкка хас күп төрле гөнаһларда гаепли. Н. Дәүли, мәсәлән: «Мулланур Вахитов турындагы шигырьләре минем чәчләремне үрә торгызган иде», ди. Ләкин бит «Мулланур» үзенчәлекле, бүгенге поэзия алдына куела торган таләпләрне искә алып язылган поэма. Н. Дәүли исә аңа иске, традицион үлчәүләр белән якын килә. Ә бит татар шигыренең поэтик структурасы, тормышның үзе кебек үк, бер урында гына тормый, ул, диалектиканың гомуми законнарына бәйле рәвештә, үсә һәм камилләшә бара. Биредә тагын бер фикерне искә алу урынлы булыр, дөрес, ул яңа фикер түгел. Ул фикерне Т. Галиуллин бер әйткән иде инде. Чыннан да, үткен күзәтүчәнлеккә, үзенчәлекле сюжетка һәм ачык метафораларга корылган «Мулланур» поэмасы булмаса, Бөек Ватан сугышы кырларында батырларча һәлак булган курку белмәс солдат, искиткеч шәп шагыйрь Фатих Кәрим турындагы цикл, шул ук Нәби

Дәүли тарафыннан югары бәя алган цикл да язылa алмас иде. Соңгы цикл алдагы поэмадан, дөресрәге, аның сәнгатьчә тасвирлау чараларыннан үсеп чыга.

Әгәр Н. Дәүли, таякны артыграк бөгеп ташлаганын сизеп, мәкалә ахырында Р. Харис поэзиясен чамадан тыш мактап җибәрсә, Ш. Әхмәдуллин исә «Уйланырга кирәк...» («Казан утлары». 1971 ел. 8 сан.) дигән рецензиясендә киресенчә эшли: мактау белән башлый, тиргәү белән бетерә. Мәкаләсенең бер өлешендә ул шагыйрьнең иҗат үзенчәлеге хакында кызыклы фикерләр әйтә, аның индивидуаль йөзен билгеләү юнәлешендә җитди адымнар ясый, икенче өлешен шактый күңелсез нәтиҗәләр белән тәмамлый: янәсе, гади укучы Р. Харис шигырьләрен аңламаячак, аларга битараф калачак. Ш. Әхмәдуллин рецензиясе чыгып, бер еллап вакыт уздымы икән, аңарга җавап бирергә ашыккандай, шагыйрь «1972 ел икмәге» исемле поэмасын язып бетерде. Поэма эчке кайнарлыгы, икмәк турындагы уйлануларының көче һәм масштаблы булуы белән аерылып тора. Тәнкыйтьченең үз сүзләрен кулланып әйткәндә, «миллионнарча гади укучылар»ны дулкынландырган, әдәбият өчен ифрат әһәмиятле булган бу теманы, аның кебек, йөрәгенә шулай якын итә алган башка бер шагыйрьне мин хәтерләмим.

Ш. Әхмәдуллин шагыйрьнең сәнгатьчә фикерләве катлаулы булганга өнәми. Бу хакта сүз чыккач, мин аны, киресенчә, тиешле дәрәҗәдә катлаулы булмауда гаепләр идем. Кыскалыкка, афористик формага омтылам дип, ул кайвакыт фикерне әрәм итә, поэтик фикер каршылыклы, өзек-өзек, сайрак булып чыга. Шагыйрьнең андый миниатюралары бүләкләр кибете витринасына куелган бизәнү әйберләрен хәтерләтә. Ләкин мондый кимчелекләрне үсү кыенлыклары дип карарга кирәк.

Төп фикерләре белән килешерлек, канәгатьләнү хисе белән укырлык бердәнбер мәкалә «Казан утлары» журналының 1972 елгы 6 санында басылды. Мин Т. Галиуллинның «Ак сөлге» исемле җыентык уңае белән язылган «Дөньям кызыксындырса...» дигән рецензиясен күздә тотам. Р. Харис иҗатын ялган новаторлыкта гаепләүче башка тәнкыйтьчеләрдән аермалы буларак, ул шагыйрь иҗатына төпле бәя бирә, аның иҗатындагы чын новаторлык үрентеләрен дөрес күрсәтә.

«Тыны кысыла торган кешеләр булганга карап, тауны кичерәйтергә ярамый», — дигән бер француз язучысы. Р. Харис иҗатын тәнкыйть итүчеләргә дә мин шул ук сүзләрне кабатлар идем. Шул ук вакытта, шагыйрь язган һәр нәрсәне мактаучы, аның һәр төчкергәнен илаһилаштырырга яратучы кайбер кешеләр кебек, тауларны артык биеккә күтәрергә дә ярамый. Мәгълүм дәрәҗәдә арттырып җибәрүләр, аның турында язылган аерым рецензия һәм мәкаләләрдә очрый торган тупас һөҗүмнәр, миңа калса, бер нәрсәне аңламаудан килеп чыга: татар шигыренең үсеш эволюциясе бер нәрсә, ә поэзиянең рухи традицияләре бөтенләй икенче нәрсә бит ул.

Тел кебек үк, теләсә нинди шигырь системасы да (буш хәлендә, эчтәлек белән тутырылмаган хәлендә) — сыйныфларга мөнәсәбәттә битараф күренеш; уңай традицияләр исә, социалистик реализм методы җирлегендә яуланган новаторлык казанышлары, киресенчә, һәр вакыт үткен төстә социаль, политик, сыйнфый характерда булалар, сүз хәтта пейзаж лирикасы хакында барган очракта да.

Теге яки бу шагыйрь эшчәнлегенең новаторлык әһәмиятен бары вакыт, дәвер үзе генә дөрес билгели ала. һ. Такташ, М. Җәлил, Ә. Фәйзи, Ф. Кәрим, Х. Туфан, С. Хәким кебек өлкән буын шагыйрьләрнең иҗатына без ничектер еракkарак китеп, еллар фонына куеп карый алабыз, һәм шул фонда аларның теге яки бу күләмдә татар совет поэзиясен яңартуга керткән шәхси казанышлары ачыграк, төгәлрәк булып күренә.

Ренат Харис яшь әле, аның һәммәсе дә алда. Тик шулай да... В. Маяковский сүзләре белән әйткәндә, чын поэзиянең һәр юлы билгесезлеккә сәяхәт. Р. Харис — экспериментлар шагыйре. Ул — эзләнүчән һәм үзенчәлекле шагыйрь. Аның «Мулланур», «1972 ел икмәге» кебек поэмалары, Ф. Кәрим, Дәрдмәнд турындагы шигъри цикллары, «Кеше» либреттосы, «Ак сөлге», «Татарстан», «Укыйм, җырлыйм» кебек шигырьләре шул турыда сөйли. Һәрхәлдә, инде яшь шагыйрьнең бөтен шигырьләре һәм поэмалары үткен төстә заманча яңгырыйлар.

Конкрет мисал китерик.

«Юллар чатында» исемле җыентыкта «Әтием турында шигырьләр» бар. Анда шагыйрь лирик героеның рухи халәте турында сөйли:

**Әти турында күп яздым,**
**Мылтык прикладын**
**Әнием кочкан кебек кочуын мактап,**
**һәрбер җыерчыгын мактап...**
**Пикассоны аңламавын тиргәп,**
**Зәвыксызлыкта гаепләдем тирләп-тирләп.**
**«Җиңел яшәргә тырышасыз»,— дип**
**Әрләгәндә яшьтәшләремне.**
**Әтигә каршы калкан булдым**
**Шигыремдә...**
**Әгәр әти шигырь яза белсә,**
**Нәрсә язар иде икән минем турымда, ә!..**

Бер карасаң, монда аталар һәм балалар арасындагы иске конфликтның яңа варианты искә төшерелә кебек. Әмма алга таба бу конфликт кире алына, Бөек Ватан сугышының башыннан ахырына кадәр катнашкан әтисенең тәҗрибәсенә таяну улына заманны, безнең бүгенге тормышны киңрәк, тирәнрәк аңларга булыша. Бер типтагы, билгеле бер интерваллар аша кабатланып килгән юллар шул хакта сөйли:

**Аһ, син нинди каты уйлыйсың!**
**Маңгаеңда ике ак юл...**

Бу юлларны узган сугышның бөтен авырлыгын үз җилкәләрендә күтәргән өлкән буынның үткәне һәм бүгенгесе белән соклану дип кабул итәсең. Әтиләребезнең героик эстафетасы улларына тапшырыла! Һәм шигырьнең тагын бер ягы бар. Фәнни-техник революция турындагы беркатлы карашлар күптән искерде. Фәнни һәм техник ачышлар, әгәр алар кешелеккә каршы идеяләргә хезмәт итсәләр, исәпсез-хисапсыз корбаннар да китерергә мөмкин. Мәсьәләгә бу яктан караганда, шигырьнең көче бермә-бер арта, ул интернациональ яңгыраш ала. Ата образы эре планда, зур итеп сурәтләнә. Ул хәрби һәм тыныч хезмәтне бәяли белүче образ буларак бирелә.

«Әтием турында шигырьләр» темасын сәнгатьчә эшләүдәге бик мөһим бер детальгә тукталасы килә. Әтисенең «броневикларда» йөргән чорын сурәтләгәндә, шагыйрь «ак юлны» искә алып китә:

**Аһ, син нинди каты уйлыйсың!**
**Маңгаеңда ике ак юл,**
**һәм ул юлларның берсендә**
**Сөт түялгән машиналар,**
**Икенчесендә**
**Корылган туплы броневиклар.**

Татар укучысына бу сүзнең икенче бер яшерен мәгънәсе дә ачык. Аклык, пакьлек кебек эпитетлар фольклор әсәрләрендә дә, язма әдәбият үрнәкләрендә дә элек-электән иң якты, изге хисләрне белдерү өчен кулланылган. Шул рәвешчә, Р. Харис шигырендәге «ак юл» әле Бөек Ватан сугышының гадел һәм изге юлын, бөтен кешелек дөньясын куркыныч чумадан — фашизмнан коткарып калган юлны да символлаштыра.

Үзе яраткан шул сүз ярдәмендә шагыйрь иҗатын җентекләп тикшереп чыгарга мөмкин. Китапларның исемнәренә игътибар иткәнегез бармы? «Ак сөлге» — аның традицияләргә турылыклы булуы, ә «Яңа көн» — новаторлыгы турында сөйли. Шагыйрьнең иң яхшы ниятләре никадәр урынлы һәм нигезледер — анысын вакыт күрсәтер!

Шулай да ул бер ак төскә генә гашыйк кеше түгел. Аның иҗат палитрасында салават күперендәге бөтен төсләрне очратырга мөмкин. Кызыксынган кешеләр авторның «Кызыл төлке» исемле шигырен укып карасыннар. Ул махсус табигатьтәге төсләр байлыгына сокланып язылган әсәр. Әлеге шигырьдән бик ачык күренгәнчә, башка төр шигырьләр белән бергә, Р. Харис тамырлары белән халык авыз иҗаты әсәрләренә барып тоташа торган, күпмедер дәрәҗәдә сынлы сәнгатьтәге аллегорик картиналарны хәтерләткән кинаяле шигырьләр дә яза. Бер карасаң, шагыйрьне төсләр байлыгыннан башка нәрсә кызыксындырмый да кебек һәм ул аларны гади күз белән күреп булмастай урыннарда таба. Ләкин бу тышкы форма гына. Шагыйрьнең төп максаты укучыны дулкынландырырлык аллегорик картина иҗат итү.

Р. Харис, һичшиксез, романтик мотивлар җырчысы. Шушы урында без авторның романтик халәтле шагыйрьләрнең күпчелегенә хас булган бер үзенчәлегенә якынлашабыз. Р. Харисның лирик герое, ничектер, аның үзеннән еракта тора, ул кайдадыр алда, туачак коммунистик тормышта. Ул — идеал образ. Шуңа күрә шагыйрь белән аның лирик герое арасында тигезлек билгесе куярга ярамый. Мисаллар кирәкме? Алар бик күп, мин иң характерлы бер генә мисалга тукталам. Сүз «Ат» исемле шигырь хакында барачак. Ул әллә кайчангы, күптән үткән заманнарга карый кебек. Ләкин традицион бизәкләр һәм детальләр биредә саф символик мәгънәдә алынган. «Ат» чыннан да киләчәккә төбәлгән. Шагыйрь хыялында рәсем ясала: ат һәм аның лирик герое — җайдак. Шигырьдә авторның, ат һәм җайдак (табигать һәм кеше дип укы) бер уй, бер омтылыш белән яшәп, могҗизалар тудырачак заманнар турындагы хыялы чагыла, хәзергә... хәзергә шагыйрь әсәрен шактый моңсу сүзләр белән тәмамлый:

**Мин ул атка атланмадым!**

Шигырь ничек тәрҗемә ителгән соң? Вадим Кузнецов шагыйрьнең хыялын тормышка ашкан чынбарлык дип аңлаган. Шуңа күрә тәрҗемә алга түгел, ә артка, гражданнар сугышы чорындагы вакыйгаларга алып китә:

**Когда я на спину**
**взлетаю ему,**
**тяжесть спадает с плеч.**
**В левую руку**
**поводья беру,**
**правая**
**требует меч.**

Иң әһәмиятле соңгы юл бөтенләй төшеп калган. Шуның аркасында әсәрнең символик яңгырашы югалган. Бу хәтта тәрҗемә дә түгел, мәгълүм бер темага импровизация юлы белән язылган вариация генә.

Рецензияләнә торган китапта, кызганычка каршы, аның бәясен төшерерлек уңышсыз шигырьләр дә урын алган. «Көянтә» исемле шигырь шуның бер мисалы. Әгәр образлы төстә шагыйрьне ат, тәрҗемәчене тәртә белән чагыштырсак, бу очракта гаеп атта да, тәртәдә дә бар. Тәрҗемә В. Кузнецовның үз шигырен хәтерләтә. Оригиналда сүз ук турында, ә тәрҗемәдә көянтә турында бара. Димәк, тәрҗемәдә сурәтләнә торган объект алмашкан. Оригиналда төп шәхес — лирик герой. Тәрҗемәдә аңа су илтүче кыз образы өстәлә. Димәк, тәрҗемәдә субъект та алмашынган. Әмма хатаның иң җитдие

шунда, тәрҗемәче шигырьне чәчәкләп-чуклап бетергән. Р. Хариста ялангы хәлендә генә булган кимчелекләрне тәрҗемәче тагын да үстерә, тирәнәйтә төшкән, биш юлдан торган шигырьне, суза торгач, уналты юлга әйләндергән:

С чем сравнить мне
ее коромысло!
Может с крыльями!
Нет в этом смысла,
ибо крылья
нас вверх поднимают,
коромысло —
к земле пригибает...

С чем сравнить мне
ее коромысло!
Разве с луком!
Так нет в этом смысла:
хоть на лук
коромысло похоже,
но стрелять оно
все же
не может...

Һич кирәкмәгәнгә, уңышсыз төстә бу шигырьдәге лирик герой көянтәне әле канатларга, әле җәяләргә охшатып азаплана. Шигырьдә фикер үсеше юк. Фикер бер урында таптана. Ярар, ахыр чиктә, көянтә тышкы яктан җәягә дә, канатларга да охшасын, ди, ә бу предметларның очлы башлы ук белән нинди уртаклыгы бар? Бу инде кылану. Мондый очракта әдәбият әдәбият белән тикшерелә, тормыш дөреслеген таныл-белү артык планга куча, ә бит социалистик реализм сәнгатендә әсәрнең кыйммәтен билгеләүче бердәнбер критерий — тормыш дөреслеге.

Бу этюдларны язарга керешкәнче, мин В. Кузнецовның башка тәрҗемәләре белән дә танышып чыктым. Ул З. Нури, Р. Гатауллин, Р. Фәйзуллин, Р. Мингалимов шигырьләрен тәрҗемә иткән. Ул тәрҗемәләр өчен нәрсә характерлы соң?

Тәрҗемә шигырьләрнең һәммәсе диярлек энергияле, экспрессив, күп сыйдырышлы, аз сүзле һәм динамик. Әлеге сыйфатларның байтагы теге яки бу дәрәҗәдә Р. Харис иҗатына да хас, димәк ки, тәрҗемәче үз амплуасына туры килердәй шагыйрь тапкан дияргә була. Ләкин әдәби тәрҗемә өчен ул гына аз. Теге яки бу милли шагыйрьне уңышлы тәрҗемә итү өчен, аның поэзиясенә хас идеяләрне, образлар системасын аңлау, аңлатып бирү һәм укучыга җиткерү өчен, бик мөһим булган, шулай да ярдәмчел чара гына саналган сүзгә-сүз тәрҗемәләргә мөрәҗәгать итү генә җитми. Әлеге шагыйрьне иҗатка рухландырган җанлы тормышның үзе белән дә якыннанрак танышу сорала. Тәрҗемә эшенә реаль төстә якын килүнең төп принцибы шул. Әгәр шул принцип үтәлсә, тәрҗемәче өчен аны һәр адымда саклап торган иярүчәнлек тә, икенче яктан, тәрҗемә ителә торган шигырь белән тәрҗемәченең үз шигырьләре арасындагы чик җуелырлык дәрәҗәдәге ирекле лек һәм урынсыз өстәүләр дә алай ук куркыныч булмаячак. Шунда, бары шунда, татар һәм рус телләренең төзелеш материалы бер-берсеннән нык аерылуга да, татар һәм рус шигърияте арасында принципиаль үзгәлекләр булуга да карамастан, тәрҗемә төп-төгәл булачак.

Минем тагын бер тапкыр тәрҗемәче эшенең иҗади характерына басым ясыйсым килә, ул, тәрҗемә итә торган әсәрнең үзәген саклаган хәлдә, үзе иҗат итәргә, читтән әйткәнне көтеп тормыйча, теге яки бу сурәтләү чараларын үзе сайлап ала белергә тиеш. Бу очракта тәрҗемәченең интуициясе зур роль уйный.

Романтик мәктәп тәрҗемәчесе Жуковскийның «прозада тәрҗемәче — кол, шигырьдә — көндәш» дигән сүзләрен нәкъ шул мәгънәдә

аңларга кирәк. Әйтик, «Шигырьләр турында шигырьләр»нең уңышы нәрсәдә? Хикмәт шунда, В. Кузнецов оригиналның рухына үтеп керә алган, инде иркәле шигырь белән язылган әсәр тәгәл ритмикалы һәм шундый ук тәгәл рифма белән икән, ахыр чиктә, анысы әллә ни куркыныч нәрсә түгел. Ә «Ат» нигә уңышсыз чыккан? Уңышсызлыкның төп сере шунда, тәрҗемәче авторның төп фикерен аңламаган, шуңа күрә тәрҗемә оригиналдан бик нык ераклашкан. Иҗади эзләну иҗади тәвәккәллек белән алмаштырылган!

Шулай да В. Кузнецовка карата мәрхәмәтле булыйк, нигездә, аның эше тәкъдир итүгә лаек. Р. Харисның «Карама яру», «Яфрак», «Чияләрнең күзгә аклыгы белән» кебек шигырьләре дә, «Мулланур» поэмасы да оригиналның мәгънәсен аңлап, образлар системасын бозмыйча, оста тәрҗемә ителгәннәр. Р. Харисның «Өянке» дигән шигыренә В. Кузнецов хәтта оригиналга караганда да көчлерәк яңгыраш бирә алган. Аны тулысы белән китерәбез:

Если мне макушку срежешь,
Чтоб не рос я в вышину,—
густотой побегов свежих
я раздамся в ширину!

Если мне обрубишь ветви,
чтоб вширь не рос весной,—
зашумлю над вешним ветром
бесконечною листвой!

Если листья срежешь вскоре,
чтоб в крону я не рос,—
я тогда подамся в корень,
под землей продолжу рост!

Если мне подрубишь корни,
чтобы вовсе извести,—
над твоей могилой черной
буду заново расти!

Тагын шул ук мәңгелек тема! Сүз бер агач турында гына барса, бу хәтле сузып торуның кирәге дә булмас иде. Бу — аллегорик шигырь, аның төп көче читләтеп әйтүдә, кара реакция, кешелеккә каршы көчләр никадәр генә кысмасын, хөр фикер һаман яшәячәк, тантана итәчәк — шигырьдән аңлашыла торган төп мәгънә әнә шул.

...Ренат Харис зур шигърият юллары чатында тора. Ул үзенә шул юлларның кайсыннан китәргә кирәген әйбәт белә. Татар телендә дүрт, русча бер җыентык чыгарган шагыйрь үз иҗатының өлгергәнлек чорына аяк басты. Яшьлек ачышлары белән илһамланган шагыйрьнең иҗаты киләчәктә тагын да киңәя төшәр һәм тирәнәер дип ышанасы килә.

◆ ◆ ◆ ◆

# КИТАП КҮЗӘТҮ

## КЫЗЫЛЛАР ҺӘМ АКЛАР

Язучы А. Алдан-Семенов исеме Татарстан укучыларына яхшы таныш. Безнең матбугат битләрендә аның яңа әсәрләреннән өзекләр басылып барганга гына түгел. Шагыйрь, прозаик, газета корреспонденты буларак, А. Алдан-Семенов — иҗат эшчәнлеген безнең Татарстан туфрагында башлап җибәргән кеше.

«Кызыллар һәм аклар»[1] исемле романының нигезенә дә дәһшәтле 1918 елда Казанны азат итү өчен барган көрәш вакыйгалары салынган. Хәер, бу кадәресе язучының кайчандыр безнең якларда яшәвенә генә бәйләнмәгән. 1918 елның җәй һәм көз айларында революциянең язмышы нәкъ менә Көнчыгыш фронтта — Казан өчен барган сугышларда хәл ителә. Утлы боҗраның башка урыннарындагы кебек үк, биредә аклар белән кызыллар бугазга-бугаз килеп сугышалар. Көрәшнең бер ягында коммунистлар һәм эшче отрядлары, Идел флотилиясе матрослары, латыш укчылары, татар, чуваш, мари роталары торса, аларга баштанаяк коралланган акгвардиячеләр, авыл кулаклары, төрле политиканнар тарафыннан алданган чехословак легионерлары каршы куела.

Романның исеме үзе үк ул вакытта Россиядә барган сыйнфый, мораль һәм психологик бәрелешләрнең никадәр кискен төс алуы хакында сөйли. Әсәрнең төп геройлары (аларның күбесе реаль тормыштан алынган тарихи шәхесләр) өчен нинди төсне сайлау, кайсы яктан торып көрәшү күптән хәл ителгән мәсьәлә. С. Гусев, Н. Маркин, Л. Рейснер кебек коммунист политработниклар, РКП(б)ның Казан губерна комитеты председателе Я. Шейнкман, дивизия начальнигы В. Азин, командарм В. Шорин һич икеләнүсез революцияне, эшче-крестьян дәүләтен — кызыл төсне яклыйлар. Легендар Азин турында автор болай яза: «Революциядән соң кешелек дөньясы ак һәм кызыл төсләргә бүленде. Ул (Азин — А. Л.) бары шул ике төсне генә таный иде, бернинди башка төсләрне, ярымтоннарны танырга теләмәде. Кайчандыр тез чүккән, башкаларга хезмәт иткән, җәфа чиккәне, хәзер исә бөтен буена басып үз хокукын дауларга күтәрелгәне — кызыл төс. Кызылны изеп яшәгән, аңа күтәрелергә комачаулаган бөтен нәрсә — ак төс» (86 бит). Адмирал Колчак, Каппель һәм Рычков кебек генераллар бөтен көчләре белән Совет властен юк итәргә, буржуаз-помещиклык тәртипләрен кире кайтарырга тырышалар.

Язучы гражданнар сугышын сыйнфый көрәшнең иң киеренке, иң югары формасы дип бәяли, бу көрәшнең ул вакыттагы барлык сыйныфларны һәм сыйнфый катлауларны ничек итеп үз ихтыярына буйсындыруын күрсәтә. Кайсы сыйныфтан чыккан булуларына карамастан, Россия халкының иң яхшы вәкилләре ахыр чиктә хезмәт ияләре ягына басарга мәҗбүр булалар. Ротмистр Долгушин һәм хәрби врач Константин Сергеевич Хмельницкий икесе дә дворяннар, ләкин аларның революциягә мөнәсәбәтләре тамырдан аерыла. Ротмистр революциягә мужиклар бунты дип карый, ул аларны, камчы һәм пулялар белән куркытып, яңадан помещикларга буйсындыру ягында тора. Хмельницкий өчен революция — илнең киләчәге, бөтен фаҗигаләрдән котылу

[1] А. И. Алдан-Семенов. Красные и белые. Рус телендә. I-китап. Мәскәү. 1970 ел;
А. И. Алдан-Семенов. Красные и белые. II китап. «Дальный Восток» журналы, 1972 ел, 3, 4, 9, 10 саннар.

юлы, халык ихтыяҗларын канәгатьләндерергә мөмкинлек бирә торган бердәнбер чара.

Билгеле, революция, гражданнар сугышы алып килгән яңалыкны халыкның барлык катлаулары да җиңел генә кабул итте дип булмый. Арада буталып калучылар, шик-шөбһә белдерүчеләр дә булмады түгел. Совет язучылары мәсьәләнең бу ягын да читләтеп узмадылар, безнең әдәбиятта революциягә авыр, катлаулы юллар аша килүчеләр хакында да күп язылды. Гражданнар сугышы утында аерым крестьяннар һәм интеллигенция вәкилләре арасында яшәп килгән вак буржуаз иллюзияләр янып көлгә әйләнә. Революциядә ниндидер өченче юлны эзләүнең хыял гына булуын тормыш үзе ачык күрсәтә. Вакыйгалар барышы кулга мылтык алып интервентларга һәм контрреволюционерларга каршы көрәшмәсәң, Бөек Октябрь нәтиҗәсендә яуланган социалистик һәм демократик казанышларның юкка чыгарга мөмкин икәнен аңларга ярдәм итә. А. Алдан-Семенов романының көче шунда, ул әнә шул нәрсәләрне сәнгать чаралары ярдәмендә ышандырырлык итеп күрсәтә алган. Роман битләреннән безнең алга Игнатий Парфенович Лутошкинның — хөр фикерле кеше булганы өчен патша төрмәләрендә утырган, сөргеннәрдә булган, толстойчылык белән мавыгып йөргән илгизәр философның кызыклы образы килеп баса. Баштарак, Азин дивизиясенә килгән генә коннәрдә, ул кулына мылтык алудан баш тарта, кешеләрне көч белән түгел, ә сүз белән ышандырырга кирәк, ди. Соңга таба, акгвардиячеләрнең вәхшилеген үз күзләре белән күргәч, үз җилкәсендә үлем баржасының бөтен газапларын татыгач, Лутошкин акларның чираттагы һөҗүмен пулемет уты белән каршылый.

«Кызыллар һәм аклар» романының тагын бер күркәм ягы аның документаль характерда булуында. А. Алдан-Семенов Мәскәү, Казан, Ижевск, Свердловск, Иркутск һәм башка шәһәрләрнең архивларында озак еллар буе эзләнү эшләре алып бара. Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы тарихына караган бик күп материал туплый. Ул үзе сурәтли торган вакыйгаларга кыю рәвештә В. И. Ленинның 1918—1919 елларда Көнчыгыш фронттагы хәлләргә бәйле телеграммаларын китереп кертә, гражданнар сугышында катнашкан кешеләрнең истәлекләреннән, төрле приказлардан, хәрби донесениеләрдән иркен файдалана. Шуларның һәммәсе әсәрнең ышандыру көчен арттыра, аны кызыксынып, мавыгып укырлык итә.

Социализм идеаллары өчен көрәш — тарихи зарурият, шуның белән бергә, үз ирекләрен һәм бәйсезлекләрен яклаучы изелгән массалар өчен зур бәйрәм дә иде; гражданнар сугышы елларында төрле милләт кешеләре, эчке һәм тышкы контрреволюциягә каршы көрәшә-көрәшә, дөньяга иң алдынгы идеология — марксизм-ленинизм алып килделәр. А. Алдан-Семенов ышандырырлык мисаллар, нигезле дәлилләр ярдәмендә әнә шуны күрсәтә алган.

Бәхәссез әдәби уңышлары, тирән тарихилыгы һәм партиялелеге А. Алдан-Семеновның «Кызыллар һәм аклар» романын Совет власте өчен көрәш темасына багышланган әсәрләр арасында алгы рәткә куя.

**А. ЛИТВИН.**

# ГӨРЛӘВЕКЛӘР ЯЗ АЛЫП КИЛӘ

Алдымда Гәрәй Рәхимнең «Гөрләвек» җыентыгы[1].

Соңгы битен яптым да, шундагы шигырьләрнең фикер очын эзләп, уйга калдым. Хыялымда бала чакның матур бер хатирәсе яңарды.

...Безнең авыл кырыннан ук ялан башланып китә. Яз җиткәч, малайлар җыелып шунда чыгабыз да уйнаклап-уйнаклап аккан гөрләвекләрдә көймә узыштырабыз. Дәфтәр битеннән ясалган кәгазь көймәләр куыша-куыша ындыр артларыннан үтәләр дә, кызыл тасмадан ясалган флагларын җилфердәтеп, күздән югалалар. Шул көймәләр белән бергә уйлар да еракларга китә:

— Безнең көймәләрне агызып киткән гөрләвекләр кайларга барып җитте икән? Башта Сөнгә кушылганнардыр инде, аннан Агыйделгә, Агыйделдән Иделгә...

Бер уйласаң, язучылар иҗаты да шулай — алар да башта бәләкәй гөрләвек кенә булып башлыйлар да бормалы-бормалы тормыш юллары аша Иделгә — мең еллык тарихы булган татар әдәбиятына килеп кушылалар.

Г. Рәхим — шундый «гөрләвек»ләрнең берсе. Аның шигъри гөрләвеге билгесез чоңгылларга ташланмый, мәһабәт Иделгә килеп тоташа.

Гәрәй Рәхим — әйбәт мәгънәдә виртуоз шагыйрь, аның стихиясе — сүзләр. Ул бер өлге ала да сүзләрдән «челтәр бәйли», аңа халык орнаментларыннан матур-матур бизәкләр төшерә, җитмәсә, алар Гәрәйгә генә хас шаянлык белән дә өртелгән булалар. Шуңа күрә бу бизәкләр социаль мәсьәләләрне күтәргән шигырьләрдә дә үз төсләрен югалтмыйлар.

«Неон яктысында уйлану» шигырен алып карыйк. Техник прогресс гаять киң колач алган дәвердә кешелекне нинди язмыш көтә? Әсәрдә сүз әнә шул турыда бара.

Ә бомбаны бирмәгәндер сиңа,
Бу тик ялгышыдыр дөньяның.
Куян ясыйм диеп бомба чыкса?!.
Зыяны бармыни куянның?..

Сизеп торам, куян дигәч синдә
Потенциаль аучы уяна.
Нәсле корсын, халыкара бер ау
Игълан итик бомба-куянга.

Күрәсез, шигырь җитди темага багышланган. Ләкин мондый темага караган байтак шигырьләрдән аермалы буларак, әсәрдә лирик җылылык бар, шаяру аша әйтелгән җитди фикер бар. «Соус» белән бирелгәч, шигырь җаңга да ятышлы, фикерләр дә үтемле булып чыккан.

Г. Рәхим сүзләрдән челтәр бәйли дигән идек. Төптәнрәк уйлап карасаң, бу — шагыйрьнең дөньяны күрү формасы да икән әле. Берничә чигештә шул нәрсә бик ачык күренә.

...Яңгыратып кызлар көлә,
Кызлар көлә — ямансу.
Тып-тын гына кызлар елый,
Кызлар елый — ямансу.

Сызылып кына таңнар ата,
Таң атуы — ямансу.
Сызылып кына кояш бата,
Кичләр бигрәк ямансу...

(«Ямансу».)

Яки:

— Һай, ямьсездән дә ямьсез,
Ямьсездән дә ни ямьсез?
— Ямьсездән дә ямьсез шулдыр —
Илен каккан ир ямьсез...

Күрәсез, күз явын алырлык образлар да юк (бер яктан, бу — Г. Рәхимнең кимчелеге дә булып тора), шаккатырырлык чагыштырулар да очрамый, әмма бу юллар битараф калдырмый. Биредә шагыйрь безне сүзләр хәрәкәте белән сихерли, ул фикер-хисләрен шул хәрәкәт аша белдерергә омтыла. Кыскасы, бу — ритм патшалыгы, биредә сүзләр стихиясе хакимлек итә. «...Үткән гомер — кара күмер», «...Кемдер квартир сорый», «...Сызланма дип, сыкранма дип» кебек шигырьләр дә шул юнәлештә иҗат ителгән.

Г. Рәхимнең тавышы интонацияләргә бай. Менә ул тыйнак, мәгънәле; менә ул уйчан, борчулы; икенче карасаң — чәнечкеле. Димәк, без шигырьләр-

---

[1] Г. Рәхим. Гөрләвек. Шигырьләр. Казан. 1974 ел. Редакторы Р. Даутов.

дә шагыйрьнең рухи дөньясын да күрәбез. Чыннан да, әгәр шагыйрь укучысын үз хисләренең сафлыгына һәм хаклыгына ышандыра алмаса, ничек итеп аның рухына үтеп керә алсын ди?! Ә укучы, бигрәк тә бүгенге укучы, сизгер. Ул кемнең чын утта янганын, кемнең пыскып кына ятканын, кемнең җырында фальшь ноталар яңгыравын шундук сизеп ала һәм бер алданганнан соң синең китабыңны кулына алып та карамаячак инде.

Г. Рәхим — бу яктан бәхетле шагыйрь. Аны яратып укыйлар. Күп кенә әсәрләре шигырь сөючеләр телендә. Моңа шагыйрь үзе сәбәпче. Чөнки аның лирикасы — эчкерсез лирика. Сүзебез җирдә егылып калмасын, бер шигырьне карап үтик:

Урамнар артында яшел болын,
Араны кимерә яшь колын.
Аранда тилмерә яшь колын!
«Урамнар артында яшел болын...
Урамнар артында яшел болын...»

...Тябенә, әйтергә теле юк.
Араны кимерә яшь колын.
Нишләсен, әйтергә теле юк:
«Урамнар артында яшел болын,
Урамнар артында яшел болын...»

(«Урамнар артында яшел болын»...

Урамнар артында гына яшел болын, чыгарып җибәрәсе иде аны шунда, уйнасын иде иркенлектә, хозурлансын иде гүзәл җәйнең матурлыгы белән. Юк шул. Чалгы чүкегән агайларның да, июньдәй көләч кызларның да, чирәмдә кояшка йөз тотып нур җыючы чал чәчле бабайның да яшь колын хакында уйларга вакытлары юк. Колын аранда тилмерә... Ай-һай, бер колын турында гына микән бу шигырь?!

Ә «Көз-патша» шигыре? «Көзге урман», «Миләш төбендә», «Хыялый төбәктә», «Көтмәгәндә», «Болыннарны атлар табырлаган» шигырьләре... Аларның һәммәсе дә хыялларга киңлек, фикерләргә тирәнлек бирердәй шигырьләр.

Шушы уңай белән тагын бер генә сүз. Хәзер 1 класс баласын да проблемалы укытабыз, ягъни уйланырга мәҗбүр итәбез. Шигърият тә үз укучысын шушы юнәлештә тәрбияләргә тиеш. Ул да, укучы алдына җитди мәсьәләләр куеп, аны уйландырсын, аңа әдәби «ачышлар ясарга» ярдәм итсен. Дөрес, бу өлкәдә уңышларыбыз да юк түгел. Әмма теләк шул — алар тагын да баетылсын, тирәнәйтелсен. Моны заман таләп итә.

Китапта мәхәббәт турында да әйбәт шигырьләр бар. Ләкин «Юл уңаенда» шигыре үзенчә шәп. Һ. Такташның «Урман кызы» интонацияләре яңгырап киткән бу шигырь романтик буяуларның куелыгы белән үзенә җәлеп итә.

...Лирик герой ике юл чатында басып тора. Кайчандыр шушы урында сөйгәне аңа шашып-шашып сөю хакында сөйләгән. Еллар үткән, алар аерылышканнар. Хәзер менә ул үзе, үткәннәрне искә төшереп, чал тарихтан килгән мөсафирдай сөю хакында фикер йөртә. Никадәр тормышчан, никадәр кешелекле һәм гыйбрәтле аның фәлсәфәсе:

...һәм шушында, гөлләр арасында
Бер имән йорт саласым килә.
Анда булыр су һәм кара икмәк
(Мөсафирлар керәп ашасын).
һәм ишеккә һәркем күрсен өчен
Килә шундый язу кагасым:
«Мәхәббәттә һәйкәл, сарайлардан,
Хәтфәләрдән ерак кач, адәм!
Җир кешесе булып кер, кунак бул,
Бу ишекне киереп ач, адәм!»

Без хәзергә кадәр җитди Гәрәй турында гына сүз алып бардык. Ә икенче кырыйда юмористик Гәрәй елмаеп басып тора. Аның юмористик шигырьләренең максаты көлдерү генә түгел. Алар — чәнечкеле, алар — әйбәт тормыш, әйбәт шигырь таләп итүче «нәни» көрәшчеләр. Каләмдәш дусларына язылган пародияләре дә, кыска шигырьләре дә шул таләпчәнлек белән сугарылганнар. Бер шигырендә Гәрәй болай ди:

Түзеп тормам,
Тагын тик бер тапкыр
Купшы сүзләр белән ялтыра —
Пычак кебек үткен шигырь белән
Мин суярмын сине, халтура.

Бу юллар югарыда әйтелгәннәргә ачык дәлил булып торалар. Һәм икеләнмичә әйтергә мөмкин, алар үз адресатларын бик тиз табачаклар.

...Гөрләвекләр җиргә яз алып килә. Алар йөгереп үткән кырларда күкрәп игеннәр үсә, болыннар яшел хәтфәгә төренә.

Шигъри «гөрләвек»ләр дә күпләрнең күңеленә яз, шатлык алып килер. Ул сугарган күңелләрдәге «матурлык» дигән изге шытымнар чәчкәгә бөреләнер.

**Н. ГАМБӘРОВ,**
Казан дәүләт университеты студенты.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## РСФСР ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНДА

14 апрельдә РСФСР язучылар союзының секретариаты булып узды. Анда татар язучылары Азат Әхмәдуллин, Әбрар Кәримуллин, шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов, прозаик Миргазиян Юныс, Чиләбе оешмасыннан шагыйрь Басыйр Рафиков Язучылар союзы членлыгына кабул ителделәр. Секретариатның эшендә РСФСР язучылар союзы секретаре шагыйрь Сибгат Хәким дә катнашты.

## ТАТАР ШАГЫЙРЕНЕҢ ИҖАТЫН МӘСКӘҮДӘ ТИКШЕРҮ

16 апрельдә РСФСР язучылар союзында Илдар Юзеев иҗатын тикшерүгә багышланган утырыш үткәрелде.

Утырышны РСФСР язучылар союзы секретаре Виктор Тельпугов ачты. Фикер алышуда Мәскәү шагыйрьләре Михаил Львов, Владимир Костров, тәнкыйтьче В. Вигилянский, Чувашстан язучылар союзы идарәсе председателе Николай Дедушкин, РСФСР язучылар союзының җаваплы хезмәткәрләре Василий Шкаев, Роман Палехов, Татарстаннан Сибгат Хәким, Гариф Ахунов, автор Илдар Юзеев үзе һәм аның «Соңгы сынау» китабын русчага тәрҗемә иткән шагыйрь Николай Беляев, язучы Ямил Мостафин, «Литературная Россия» газетасы хәбәрчеләре катнашты.

Фикер алышуда катнашучылар Илдар Юзеев поэзиясенә югары бәя биреп, аның русча шигырь һәм поэмаларын аерым китап итеп «Современник» нәшриятында бастырып чыгару турында карар кабул иттеләр.

Сөйләшү бер Илдар Юзеев иҗатына гына багышланып калмады, гомумән татар әдәбиятының иң яхшы вәкилләре иҗатын Мәскәү нәшриятларына әзерләү турында барды.

## ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ

Халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукай туган апрель аенда быел да зур шигърият бәйрәм үткәрелде. Егерме алтынчы апрельдә республикабыз әдипләре Габдулла Тукай каберенә бардылар. Казандагы В. И. Ленин, Г. Тукай, М. Җәлил, А. Пушкин һәйкәлләренә чәчәкләр куйдылар. Аннары Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры бинасы янында шигърият митинг булды. Митингта шагыйрьләребездән Сибгат Хәким, Илдар Юзеев, Зәки Нури, Равил Фәйзуллин, Шәйхи Маннур, Нури Арсланов, Галимҗан Латыйп, Гөлшат Зәйнашева, Марс Шабаев, Гәрәй Рәхим, Рәдиф Гатауллин, Мәхмүт Хөсәен, Роберт Әхмәтҗанов үзләренең Тукайга багышланган шигырьләрен укыдылар.

* * *

Шул ук көнне кич язучыларның Габдулла Тукай исемендәге клубында әдәбимузыкаль кичә булды. Шагыйрь Нури Арсланов алып барган ул кичәдә шагыйрьләрдән Сибгат Хәким, Хәсән Туфан, Зәки Нури, Илдар Юзеев үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар. Аннары Татарстанның халык артисты Эмиль Җәләлетдинов, Татарстанның атказанган артистлары Габдулла Рәхимкулов, Сөләйман Йосыпов, Җәвәһирә Сәләхова һәм артистка Флера Сөләймановалар катнашында бик әйбәт концерт бирелде.

* * *

Татарстан мәгариф хезмәткәре культура йортында да Тукай кичәсе үткәрелде. Кичәнең беренче бүлегендә филология фәннәре кандидаты, язучы Мөхәммәт Мәһдиев «Тукай һәм бүгенге татар әдәбияты» дигән темага доклад ясады. Икенче бүлегендә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Тукай премиясе лауреаты композитор Рөстәм Яхин Тукай сүзләренә язган көйләрен пианинода уйнады, Татарстанның атказанган артисты, Тукай премиясе лауреаты Айрат Арсланов Габдулла Тукай шигырьләрен сөйләде, «Сәйяр» ансамбле җырчылары шагыйрь сүзләренә язылган көйләрне җырладылар.

Тукай кичәсендә М. Горький һәм Г. Тукай премияләре лауреаты шагыйрь Сибгат Хәким дә катнашып, үзенең яңа шигырьләрен укыды.

## КОМПОЗИТОР ХӨРМӘТЕНӘ

Татарстан Министрлар Советы һәм РСФСР Культура министрлыгы РСФСР Министрлар Советына Әлмәт шәһәренең музыка училищесына композитор Фәрит Заһидулла улы Яруллин исемен бирү турында тәкъдим кертканнәр иде. Ул тәкъдим кабул ителде. Хәзер Әлмәт училищесы Ф. З. Яруллин исемендәге музыка училищесы дип йөртелә башлады.

## «ИДЕЛ» ФОТОКЛУБЫ ҮСӘ

Казанның В. И. Ленин исемендәге культура сараенда моннан ун ел элек фото-

һәвәскәрләр группасы оешкан иде. Ул группа һаман үсә барып, «Идел» фотоклубына әверелде. Клуб членнары үзләренең фоторәсемнәре белән бөтен Союз күргәзмәләрендә һәм Америкада, Чилидә, Англиядә, Франциядә, Таиландта, Португалиядә үткәрелгән халыкара күргәзмәләрдә катнаштылар һәм төрле дәрәҗәдәге дипломнар белән бүләкләнделәр.

## МУЗЫКАЛЬ ФЕСТИВАЛЬ

Апрель аенда Владимир Ильич Ленинның туган көненә багышланган музыкаль фестиваль үткәрелде. Ул фестивальдә республикабыз музыкантлары һәм җырчылары белән бергә РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Дагстан композиторы Мурад Кажлаев җитәкчелегендә Дагстан телевидениесе һәм радиосы ансамбле дә катнашты.

* * *

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Шагыйрьләребездән Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Нури Арсланов, Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим һәм Зөлфәт педагогия институты студентлары белән очрашып, яңа әсәрләрен укыдылар, сорауларга җавап бирделәр.

## ӘДИПНЕҢ ЮБИЛЕЙ КИЧӘСЕ

Шушы елның унҗиденче апрелендә язучы Самат Шакирга илле яшь тулу уңае белән Казанның мәгариф хезмәткәрләре



йортында әдипнең юбилей кичәсе үткәрелде. С. Шакирның иҗаты һәм тормыш юлы турындагы докладны филология фәннәре кандидаты, шагыйрь Зәет Мәҗитов ясады. Кичәдә «Сәйяр» ансамбле артистлары көче белән концерт бирелде.

Әдипнең юбилей кичәсенә мари шагыйре Макс Майн, Зеленодольск һәм Балтач районнарыннан да вәкилләр килгән иде.

* * *

Илле яше тулу уңае белән һәм мәгариф өлкәсендә күрсәткән хезмәтләре өчен, Самат Шакир Татарстан АССР Мәгариф министрлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

«Үлемсезләр» исемле китабында панфиловчыларның фашистларга каршы көрәшен уңышлы яктыртканы өчен, юбилярга Панфилов дивизиясенең дә Мактау грамотасы тапшырылды.

* * *

Шагыйрьләр Мостафа Ногман, Рәдиф Гатауллин, прозаик Мәдинә Маликова Казанның политик мәгариф йортында республикабызның райком һәм шәһәр комитетлары бүлек мөдирләре алдында чыгыш ясап, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

* * *

Шагыйрь Гәрәй Рәхим Казанның Мәскәү районы октябрятлары слетында катнашып, балалар өчен язылган шигырьләрен укыды.

* * *

Язучы Рафаэль Мостафин республикабыз прокуратурасы хезмәткәрләре, Казанның Совет районы пропагандистлары, кооператив техникумы студентлары һәм Идел буе районы урта мәктәпләре укучылары белән очрашулар үткәреп, бүгенге татар әдәбияты турында сөйләде.

* * *

Казанның 48 нче мәктәбендә Сәет Шәкүровның «Тормыш бусагасында» исемле драмасы буенча укучылар конференциясе үткәрелде.

* * *

Татарстан дәүләт музеенда Рафаэль Мостафинның «По следам поэта-героя» («Герой шагыйрь эзеннән») исемле китабы буенча укучылар конференциясе булды. Анда күп санлы китап сөючеләр белән бергә, шагыйрь Сибгат Хәким һәм Советлар Союзы Герое Михаил Девятаев та катнаштылар.

* * *

Язучылардан Гәрәй Рәхим һәм Вакыйф Нуруллин Казандагы кооператив техникумында укучы студентлар белән очрашу үткәрделәр. Бүгенге татар әдәбияты турында сөйләделәр һәм үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Бүлекнең чираттагы утырышы яшь шагыйрь Мәхмүт Газизовның иҗатын тикшерүгә багышланды. Чыгыш ясаучылар язучылардан Сажидә Сөләйманова (төп докладчы), Рафаил Төхфәтуллин, Энже Мөэминова, Мәхмүт Хәсәнов, Шамил Бикчурин, Гамил Афзал, Эдуард Касыймов, Әдип Маликов, яшь язучылар Разим Вәлиуллин һәм Хәниф Хөснуллин М. Газизовның «Миләш сиртмә», «Бер, ике, өч»... исемле шигырь китапларына, кулъязма хәлендәге яңа җыентыгына төпле анализ ясадылар, шигырьләренең отышлы һәм җитешсез якларын күрсәттеләр.

* * *

Әлмәттә 1 нче номерлы татар урта мәктәбендә язучылар белән очрашу кичәсе булды. Гамил Афзал, Сажидә Сөләйманова, Юныс Әминов, Сәет Кальметов үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, укучыларның күп санлы сорауларына җавап бирделәр.

* * *

Азнакай эшчеләр поселогы пионерлары Татарстан язучылар союзының Әлмәт бүлегендә кунакта булдылар. Шагыйрьләрдән Гамил Афзал, Сажидә Сөләйманова, драматург Сәет Кальметов балаларны нефть шәһәрендә яшәүче язучыларның иҗатлары белән таныштырдылар, аларга үзләренең әсәрләрен укыдылар.

* * *

Әлмәттәге 13 нче мәктәптә Сажидә Сөләйманованың, Мәмәт авылы мәктәбендә Клара Булатованың иҗат кичәләре булды. Шагыйрәләр балаларга үзләренең иҗат планнары турында сөйләделәр, яңа шигырьләрен укыдылар.

* * *

Драматург Юныс Әминов Баулы районының Исергәп авылы клубында үткәрелгән комсомол-яшьләр кичәсендә чыгыш ясады һәм Исергәп урта мәктәбе укучылары белән очрашу үткәрде. Ул бүгенге татар әдәбияты турында сөйләде, яңа пьесасыннан өзек укыды.

* * *

Татарстан телевидениесе язучы Шамил Бикчурин иҗатына багышланган зур тапшыру үткәрде. Тапшыруда Шамил Бикчуринның «Каты токым» романыннан өзекләр укылды, «Тальян моңы» музыкаль комедиясеннән аерым күренешләр башкарылды. Тапшыруда Шамил Бикчурин белән бергә язучы Гариф Ахунов, яшь язучы Альберт Хәсәнов, Лениногорскидан килгән нефтьчеләр дә катнашты.

* * *

«Москва» журналының 2—3 саннарында Шамил Бикчуринның «Каты токым» романы рус телендә басылды. «Волга» журналының бу елгы март саны С. Сөләйманова шигырьләре белән ачылган.

* * *

Әлмәт шәһәрендәге татар әдәбияты түгәрәге утырышында яшь әдәбиятчы Шәриф Хисамиевның яңа шигырьләре тикшерелде. Шагыйрьләрдән Гамил Афзал, Сажидә Сөләйманова (түгәрәк җитәкчесе) яшь автор шигырьләренә җитди анализ ясадылар, поэзия әсәрләренең үзенчәлекләре турында сөйләделәр, иҗат тәҗрибәләрен уртаклаштылар.

## ЯШЬЛӘР КИТАБЫ АТНАЛЫГЫ

Шушы елның апрель аенда Язучылар союзы һәм ВЛКСМ өлкә комитеты инициативасы белән республикабызда яшьләр китабы атналыгы үткәрелде. Шул атналык көннәрендә шагыйрьләрдән Гәрәй Рәхим, Әхсән Баянов, Рөстәм Мингалимов (Чаллыда), Шамил Маннапов (Арчада), Рәдиф Гатауллин (Буада) китап яратучы яшьләр белән очраштылар һәм үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, бүгенге әдәбиятыбыз турында сөйләделәр.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210